


# КАЗАН УТЛАРЫ

11
НОЯБРЬ
1982

# АВТОРЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

«Казан утлары» журналы, КПСС ҮКның май (1982) Пленумы карарларын тормышка ашырудагы уңышларны тулырак яктырту өчен, иң яхшы очеркка «Авыл офыклары» конкурсы игълан итә.

Татарстанның авыл хуҗалыгы эшчәннәре соңгы вакытта игенчелектә дә, терлекчелектә дә житди уңышларга ирешеп, «Азык-төлек программасы»н үтәүгә сизелерлек өлеш кертте. Конкурска җибәрелгән очерклар шул эшнең фидакарь каһарманнарын, уңай тәҗрибәсен, авыл хуҗалыгы алдына куелган бурычларны һәм аларны хәл итү юлларын сәнгатьчә тасвирлап бирергә тиеш.

Конкурсның срогы — 1 ел, 1983 елның 1 январеннан 31 декабрена кадәр.

Конкурска җибәрелгән язмаларның журналда басылырлык дип табылганнары 1984 елда да биреләчәк.

Иң яхшы очерклар өчен түбәндәге премияләр билгеләнде.

1. Бер беренче премия — 150 сум.
2. Ике икенче премия — 100 әр сум.
3. Өч өченче премия — 75 әр сум.

Редколлегия язучыларның, журналистларның һәм башка иптәшләрнең конкурста актив катнашуларын үтенә.

Машинкада басылмаган кульязмалар кабул ителми, һәм конкурс таләпләренә җавап биреп бетерә алмаган язмаларга анализ ясалмаячак.

ЖЮРИ

# КАЗАН УТЛАРЫ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
1922 елның май аеннан башлап чыга

11

НОЯБРЬ

1982

## Бу санда

СССРның ТӨЗЕЛҮЕНӘ 60 ЕЛ

Р. НИЗАМИЕВ. Ватанымның бер көне. Шигырь . 3

Ә. ГАФФАР. Бишек. Повесть . . . . . . . . 4
М. ШАБАЕВ. Кеше булып... Шигырьләр . . . . 47
М. ХУҖИН. Өч каен мышгы. Хикәя . . . . . 52
Л. ХӘМИДУЛЛИН. Буранлы төндә. Хикәя . . . 59
Р. КУТУЙ. Шагыйрь. Шигырьләр . . . . . . 69

ДУСЛАР ҖЫРЫ

И. ЛЯПИН. Йөрәк. Шигырьләр . . . . . . . 72

М. ӘМИРХАНОВ. Соңгы җыр. Хикәя . . . . . 75
С. ШӘМСИ. Җәйнең кыл уртасында. Хикәя . . 84
Ф. САФИН. Туган җир. Шигырьләр . . . . . 90
Л. ШАКИРҖАНОВА. Сәмәрканд базары. Шигырьләр . . . 93
М. ВӘЛИЕВ. Дөнья дигән йортыбыз. Шигырьләр 95
Р. ЗӘЙДУЛЛИН. Ташларгамы җанны... Шигырьләр 99
Р. ШӘРИПОВ. Сүнгән чакта җир өстендә учак. Шигырьләр . . . . . . . . . . . 101

СССРның 60 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ӘЙДИ. Тылсымлы көч. Очерк . . . . . . 102
Л. КОВАЛЕНКО. Иң кадерле истәлек. Очерк . . 111

МАЙ ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

Х. БӘДРЕТДИНОВ. Авылым каһарманнары. Очерк 118

КАЗАН АЛАРНЫ МӘҢГЕ ОНЫТМАС

Р. САБИРОВ. Шлиссельбург тоткыны . . . . . 123
Пушкин Казанда . . . . . . . . . . . . 125
Галим, ректор, китапханәче . . . . . . . 128

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Г. ИДЕЛЛЕ. Дусларыбыз иҗаты турында . . . 132

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Р. МОСТАФИН. «Шагыйрь композитор булырга тиеш...» . . . 140
Г. ГЫЙЛЬМАНОВ. Вакыйга һәм хис гармониясен эзләп . . . 146
Р. МӨХӘММӘТШИН. Яңа әдәбият бишеге янында 151

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Ә. ШӘРИПОВ. Иҗади хезмәттәшлек тамырлары 156

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ә. КӘРИМУЛЛИН. Мәрҗани турында яңа сүз . . 163

СӘНГАТЬ

Ф. ВӘЛИЕВ. Татарларда керамика сәнгате . . . 166

КЛАССИК ӘДӘБИЯТ ҮРНӘКЛӘРЕ

М. ГОРЬКИЙ. Республика корольләренең берсе 171
Укучы сүзе . . . 181

БЕЗНЕҢ САФКА

Х. ӘЮПОВ, Р. НИЗАМИЕВ, Н. ГЫЙМАТДИНОВА 188
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . 190

Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ

Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН (*җаваплы секретарь*), ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ (*баш редактор урынбасары*), РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ.

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 21/VII-1982 ел. Басарга кул куелды 14/X-1982 ел. ПФ 09015. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65049. Заказ Ю-309. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1982 ел.



# СССРның төзелүенә 60 ел

Рашат Низамиев

## Ватанымның бер көне

Кояшны, таңны күтәреп
Оча кошлар кәрваны.
Яңа көннең күкрәгендә
Яшь егетләр дәрманы!

Кырларда арыш өлгергән,
Буада — көмеш балык.
«Җирем-суым»,— дия-дия
Чәчкәнен ура халык.

Эштә ирләр бәхәсләшә —
Гүя кече парламент...
Кайнар цехлар кочагында
Пешә асфальт парланып.

«Чаллы» сүзе искермәде,
Саллы булып яшьнәде!
Гасыр йөген төяп чаба
Яшь «КамАЗ»лар гаскәре.

Кранчы кыз, көлә-көлә,
Болытны да каптырган.
Шуңадыр, салган йорты да
Ак болыттай актырган.

Шыбырдатып имәннәрне
Узды-китте яңгырлар.
Отыйм дисәң, яфрак саен
Җырлар элеп калдырган.

Тарих — уяу: кылларына
Бер кагылып ал гына,
Утлы елларның күмерен
Сибеп ташлый алдыңа.

Булмасын өчен сугышлар,
Булмасын өчен яра,—
Бүгенге көн, байрак тотып,
Тарихка кереп бара!

Әхәт Гаффар

# БИШЕК

ПОВЕСТЬ

## Беренче бүлек



Аит үзен кайтарып куйган зур йөк машинасын капка төбеннән озатып калды да, ишегалдына кереп, урта бер җиргә килеп басты. Аның әкрен генә җиргә сузылып ятасы да кояш җылыткан яссы, ак ташка битен куеп торасы килә иде. Кайчандыр үзе, апалары белән абыйлары, энекәшләре, этисе һәм әнкәсе яланаяк та, чабата, резин галош, туфли-ботинка, күнитек белән дә шомартып бетергән яссы ак ташлар. Шуларга колагыңны куеп тыңласаң, кайчандыр бу йортта яшәгән, кайсы мәңге кайтмаска киткән, ә кайсы еракладан бер кайтып керәчәк кешеләрнең аяк тавышлары ишетелер иде микән? Аитны тамагы төбенә килеп тыгылган кайнар төен һәм күз яше буып алды.

Эссе ишегалды бушлыгында бары тик чикерткәләр зыңы гына ишетелеп тора иде. Ул бушлыкны Аит төяп кайткан әйберләр дә тутыра алмаган. Киресенчә, алар ул бушлыкны тагын да сиздеребрәк торалар бугай.

Хәер, биредә инә төртерлек тә буш җир юк икән. Бердәнбер буш урын — Аитның башы түгелме соң? Аның бер генә уе да юк. Бу мәлдә аңа уй кирәкми дә. Ул басып тора һәм күзәтә генә. Әйтерсең лә карлы тау түбәсенә менеп баскан да үзеннән түбәндәге дөньяга карап тора. Ишегалдындагы әйберләр аның бер өлеше мәллә? Хәер, юк. Киресенчә. Ул үзе ишегалдындагы һәр нәрсәнең бер кисәге бугай. Мондагы һәр нәрсә — буявы уңып, кибеп бетә язган калай түбәле карт йорт (иске түгел, нәкъ менә карт йорт), дүрт баганалы урыс капка, үләр алдыннан гына этисе яңадан корып-сипләп куйган абзар-кура, кыл урталай ярылган бүрәнәләрдән буралган келәт, карлыган бакчасының аратасыз коймасы, зәңгәргә буялган болдыр, инде яргаланып бетү генә түгел, эчтән чери башлаган бүрәнәләр өеме, күп санлы келәләр һәм төрле бикләр, болдыр баскычы төбендәге тегермән ташы китеге, кече капкага, абзар һәм келәт ишекләренә таба салынган яссы ташлар, өй кәрнизеннән сузылган яңгыр аккыч калай юллык, аның астындагы тузган тимер мичкә, болдыр тәрәзәсе төбенә эчтән тезеп куелган эреле-ваклы дистәләгән үләнгерләре, утын кискеч «кәҗә»... Алда-артта, унда-сулда, якын һәм ерак.

Аит сагынып кайтты. Ул үзенең күз карашы төшкән һәр нәрсәнең күңелендә терелә, җанлана, хәрәкәтләнә барганын тоеп алды. Бирелә-ге әйберләр, һәрбер нәрсә, гүя ниндидер тылсым белән кайчандыр тора-таштай катып калганнар да, менә хәзер, аның җылы карашы төшкәнгә уянып, тирән итеп сулап җибәрделәр кебек. Ул туган йортын кергән-нән артык тыныч күңел белән барлап торуына гаҗәпсенеп куйды. Та-мак төбендәге кайнар төер эреп югалды, күзен чылаткан яшь әлпәсе кипте. Шушы урында ул хуҗасыз, хәтта ташландык йорт-җирне битараф төстә күзәтүенең уйлар һәм хәтер белән алмашына баруын тоеп алды. Һәммә нәрсә аның күз алдында җанланып, әүвәлгечә, үзе бел-гәнчә терелеп китте. Алар хакындагы уе, күз алдына китергән күренеш-ләр, кыска, кырыс булса да, кадерле иде. Ул иң кирәген генә хәтерләргә тырышты. Иң кирәген, иң кадерлесен. Калганнарының әһәмияте юк. Тау башына менеп җиткәч, күтәрелгән вакыттагы һәммә авырлыклар-ның әһәмиятсез, вак нәрсәләрдәй генә булып калуы кебек. Хәер, аек акыл белән уйлаганда, хәтердәге нәрсәләрнең вак-төяге дә, иң зур ис-тәлеге дә бер үк әһәмияткә ия бугай.



Менә капка. (Мин аның ачык калганын исемә төшереп, ябып куярга ниятләп барган идем.) Әйе, менә дүрт имән баганалы капка. Багана-лары җир турысыннан чери башлаган икән инде. «Катырак җил чык-са...» — дип уйлап бетермәдем, капка, таяныч эзләгәндәй, миңа таба авыша башлады. Такта ярыгыннан кояшның нечкә генә бер нуры килеп керде дә, көзгедәгечә минем хәтеремдә чагылып, уйнаклап алды. Бер генә мизгелгә сукыраеп калгандай булдым. Һәм мин шул ялкынлы ка-раңгылыктан үземә таба йөзеп килгән җигүле күк бияга каршы йөгер-дем. Табан астын урамдагы калын чирәмнең салкынча сулышы кы-тыклый, күкрәгемне шатлык кыса.

— Капка ауды, эти! Сөенчегә нәстә бирәсең?

Капка ауганга — сөенче! Ул заманнарда капка аву — крестьян гаи-ләсе өчен сыер үлү белән бер үк төсле афәт. Күп балалы гаилә өчен бигрәк тә. Балалар өчен түгел, аларга һәр яңалык — сөенче алырлык куаныч. Һәр афәт ата-анага килә.

— Капка ауды, эти! Сөенчегә нәстә бирәсең?

— Өстегезгә аумадымы? — Арбадан сикереп төшкән эти мине күтә-реп алмакчы була, тик «сөенче» хәбәр аны шул кадәр куркыткан, аның мине калтыранган тезенә кысарга гына хәленнән килә.— Өстегезгә ау-мадымы?

— Юк. Әни...

— Нәрсә булды әнигезгә?!

— Берни дә булмады, эти. Әни булмаса...

— Шул-шул менә — ул булмаса! Ә ул бар, улым.— Эти, күтәреп алып, мине арбасына утырта, үзе дә үрәчәдән аягын салындырып утыра, күк атка (ул атның Күгәрчен кушаматлы булганы исемә төште)... күк атка чөңгерә дә күчтәнәч капчыгының бавын чишә башлый — район үзәктән кайтышы, буш кул белән түгел. (Ул колхозның хуҗалык мөдире иде.)

Капка ауганга — сөенче!

Тычканга үлем, мәчегә көлке.

Җәй башы. Көн кояшлы, ләкин бик җилле. Ишегалдында учак янын-дагы шикелле җылы. Өй нигезе буендагы чокырда тавыклар тузанда коена. Тыныч, рәхәт. Әни кер уды да, инештә чайкап менгәч, капка җепсәсеннән лапас баганаларына тартылган юка бауга элеп куйды, ә безне, өч-дүрт бала-чаганы, кагылып керләрне пычратмасыннар дип, урамга чыгарып җибәрде. Кече капкадан тышка атлавыбызга, урамны

бетереп тузгып килгән «шайтан туе» өермәсенең эссе, тыгыз сулышы тын юлларыбызга кереп тыгылды...

Ә капка әкрен генә итеп, күрше Хафиз бабай биленә таянып, урыныннан торгандагыча, бер-ике мәртәбә ыңгырашып кына авып төште...

— Баш исән булсын, карчык,— диде әти.— Яңага вакыт иде инде. Аны сүтүе дә чыгым ич әле.— Сүзен ул:— Берүк, ут-күздән саклана күр! — дип тәмамлады.

Яңа капкага иске капка келәсен куйдылар. Яссы тимер тасмадан матурлап бөгеп ясалган келә, аз гына көч салу белән, келт итеп ачылып китә, әйтерсең лә фотоэлементы бар. Безнең ата-бабаларыбыз матурлыкка утә сизгер булганнар шул. Фотоэлемент нише генәме соң?

Аит барыбер түзмәде, кинәт чүкте дә, әкрен генә алга иелеп, учларына таянды һәм битен яссы ак ташка куеп ятты.

Аның ирене, ирексездән:

— Бигайбә,— дип кыймылдады. Тагын әле йөгерек, әле әкрен, әле сулышын бүлеп, әле иркенләп тын ала-ала:

— Бишегем, кайнар бишегем минем,— дип пышылдый башлады.— Тик син каты бәгырьле булма... зинһар,— дип дәвам итте ул.— Мин йомшардым инде, кичер, бигайбә,— дип пышылдады.— Дөнья... дөнья зур, аның миңа биргән бәхете үзеннән дә зур булып чыкты ахрысы... Барысын да аңа кире кайтардым... Бишегем,— дип яңагын таштан алды ул.— Кайнар бишегем,— дип тураеп, тезенә калыкты һәм, торып, тирән бер үкенеч хисе белән: — Бигайбә,— дип кабатлады.

Кулы белән битен каплап, бер кавым, ниндидер тавышлар ишетергә теләгән кебек, сагаеп, нәрсәгәдер колак салып торды. Нинди тавышлар бу? Әллә тавышлар, әллә тау упкыннары шикелле төпсез тынлыкмы? Бәлки шушы иске йортның кайнап торган чакларындагы көндәлек тормыш итү тавышыдыр, бәлки кайбер бәйрәм көннәренә туры китереп, сирәк-мирәк җыелгалый торган кунак-төшем, тыйнак мәҗлес шавыдыр? Әллә бала-чага көлүе янсә елавы микән? Һәрхәлдә, Аит өчен кадерле, изге, юанычлы һәм юксынулы авазлар. Югыйсә, ул аларны шул кадәр дә гаҗиз калып тыңлап тормас иде. Әнә ич, аңа әнкәсе белән әтисе эндәшкән кебек булып китте. Тик каян? Күктәнме, әллә кое төбеннәнме?

Әнкәсе:

— Кайттыңмы, бәбкәм? — дип сорады.

— Кайттым,— дип җавап бирде Аит.

— Ашарыңа җиттеме?

— Җитте.

— Кара, чабатаң тәмам тузган лабаса!

— Чабатаң? Мин хәзер чабата кимим инде, әни. Ә менә йөрәк тузды бугай.

— Солтан авылы белән безнең авыл арасы җиңел юл түгел шу-ул... Унбиш чакрым... Туз, туз. Мәктәп юлы картайган көннәреңнең юлларын җиңеләйтер.

— Иң җиңеле язгы ташуларда чабата киеп узган шул унбиш чакрым юл икәнен белсәң иде син, әни! Анда чабата гына туза иде. Ә дөнья гизгәндә, йөрәк туза икән...

— Әйдәле, Аит! Малларга печән салып керик әле, улым. Бүген-иртәгә сыер бозауларга тора, алла теләсә!..

Бу тавыш әтисенеке иде. Аит аны мең кеше берьюлы сөйләшкән җирдә дә танып алыр иде.

«Әти...» — дип уйлады ул. Уйлады гына, әмма күз алдына китерә алмады. Атасы белән әнкәсенең тавышлары аның күңеленә җил кебек кенә орынып узды. Ул текәлеп карап торды да, иелеп, кулына балта ал-

ды. Күгәргән балта коргаксыган сабында буш утыра иде. Ул, тирән сулап, яргаланып беткән бүкәнгә кизәнде. Ләкин, балта күтәргән кулы астыннан өйләренең аркылы-торкылы такта кагылган өч тәрәзәсен күреп, шунда таба атлады. Кубарылып ташланган такталар, каз каурыйлары сыман, тавышсыз-нисез генә як-якка очып китте. Ул тәрәзәгә кунган тузанны сөрткәләде, кулын күз өстенә куеп, өй эченә карады. Һәм караңгы пыялада әтисенең ап-ак йөзе белән маңгайга-маңгай, күзгә-күз очрашкандай булды. «Ир-егет, шулай бишегенә әйләнеп кайта ул, улым».

Аит артка сикерде. Янтаеп, кырый тәрәзәгә ташланды, һәм аның да такталарын кубарып ыргыткач, тәрәзәнең пәрәвезле өлгесе аша үзенә карап торган әнисенең йөзен күргәндәй булды. «Рәхмәт, улым, йортны ятим итмәдең».

Аит балта тоткан кулының беләге белән маңгай тирен сөртеп алды. Йөзенә әкренләп елмаю чаткысы тарала башлады, һәм ул эчтән генә көлеп куйды. Яхшы хуҗасы тавышына күкрәк эченнән генә кешнәп җавап биргән тук атмыни!

— Кайттым әле, мать честна!..

«Менә хәзер чүмеч белән генә чөмереп алып, әчегән бал эчеп җип-пәр идең ул, брат!» — диде ул үз-үзенә.

Ул атасының: «Әчегән бал! Җитмәсә, чөмереп!.. Мин сугыштан кайтып кергән мәлне борыныңнан агып төшкәнне иренең белән суырып торганыңны онытма, малай актыгы»,— дигән тавышын ишеткәндәй һәм аның кисәтүле тырпайган, тәмәке тартудан тырнагы саргайган буынтыклы бармагын күргәндәй булды.

Тын иде. Әле һаман тын иде. Чикерткәләр сайравыннан тынлык зыңлап тора кебек. Җиләс. Хәер, ара-тирә шоссе юлдан узучы машиналар тавышы ишетелгәләп куйгалый, күршедә генә тавык кытаклап җибәрә, урам буенча бер эт өреп уза.

Аит бүкәнгә барып утырды. Әле генә ташып торган хисләре сүрелергә дә өлгерде. Ул нидер югалткан һәм шуны эзләгән кеше сыман, төрле якка карангалап, тик берни күрмичә болдырга менде, кулы үзеннән-үзе баскычка сөялеп торган гитарасына үрелде. Ул чәнти бармагының тырнак очы белән иң нечкә кылына чиртеп куйды, аннары бер аккорд сугып алды — ля бемоль.

Тормышның... текә... тавында
баусыз калдым ялгыз...

— дип, хәтерләгән кебек кенә итеп көйләде ул һәм җырның:

Бөркетләрнең ояларын
ташлар иште түбән.
Кайда син? Ишетәсеңме:
Бу — минем тәүбәм...

— дигән өлешен ул күңеленнән генә җырлап алды. Бу җырны ул үзе чыгарган иде. Памирда. Ярты чакрымлы текә бер кыяны үткән чакта. Аит — иң алда. Аңа орынып, болытлар агыла. Көн кояшлы иде, сирәк болытлар кошлар көтүе шикелле уздылар да киттеләр. Бу җырны көйләп-эзләп биеккә күтәрелүе аңа игътибар тупларга булыша кебек иде. Ул көнне аны баш түбәсеннән өстәрәк ниндидер ярыктан җил сызгыруы тынычсызлап торган иде. Хәер, ул сызгыру җил тынгач та бетмәде. Ул сызгыру да түгел иде бугай, ә тау-кыяның тартылып, киерелеп торган кылы, эчке резонансы булгандыр. Сызгыру аның кәефенә кире тәэсир итә, аны узып китәргә ашыктыра, бармакларын кабаландыра һәм, бер дә бер мәлне шул кабалану белән сызгыруның резонанслары бергә туры килеп һәм бер-берсенә ярашып, Аитны күтәрелгән кыясы-ние белән җимереп ташлар кебек тоелган иде.

Ул чакны бу җыр һәм аңа сүзләр уйлау аның кәефен бер тигезләнештә, бер яссылыкта тотып торган иде. Хәзер исә, ул җырның кинәт кенә үзенә теге сызгыру кебек кире тәэсир итә башлаганын тоеп алды. Шуңа күрә аннан котылу өчен хәтерендә яңарып җиткән һәм инде теленә, бармаклары очыннан гитарага күчәргә торган өлешен җырлап бетерергә ашыкты:

Югарыга менгән саен
Җилләр дә заһәр.
Түбәннән югары мену
Хәтәр, ай, хәтәр...

Хәтәр... Ә тагын да хәтәррәге — югарыдан түбән төшү. Менгәндә күз һәм бармаклар белән капшап менәсең, ә төшкәндә — аяк очы белән капшанып. Ничә елларга сузылган шәһәр тормышыннан соң авылга торырга дип кайтуын ул аяк очлары белән капшанып, кыядан түбән төшүгә тиңләштереп карады. Ни көтә аны монда? Хәтәр билгесезлек.

Төшкәндә ул иң ахырдан була торган иде. Кыядан төшкәндә ахырдан булу — менгәндә иң алдан булу белән бер үк.

## Икенче бүлек

Җырның дәвамы бар иде әле. Ул өлеше, чыннан да, аңа тау сызгыруы сыман тәэсир итәчәк иде. Чөнки анысы — аның үз җанының резонансы.

«Әгәр хәзер сиңа ирек бирсәм, син минем кәефемне җимерелеп төшкән кыя шикелле итәчәксең! — дип уйлады Аит.— Кит, онытыл!»

Ул гитарасын өеп куйган әйберләренең арткы ягына шудырып төшереп җибәрде. Гитара бөтен кыллары белән зыңлап тынып калды.

Бая үзен кайтарып куйган шоферны сыйламакчы булып, ул бер рюмка чыгарып куйган иде — шул күзенә ташланды.

Аитның «Әче бал безнең үзебез белән, эти!» — дип, үзен биләп алган моң киеренкелегеннән котыласы килә иде. Ул чит ил күренешләре, этикеткалар белән чуарланып беткән сумкасының (спорттан киткәндә, дуслары бүләк иткән истәлек) замогын ачып җибәрде дә эчемлек шешәсе суырып чыгарды. Тик аның рюмкадан эчмичә, үзенең иң соңгы җиңүе өчен бирелгән бәллүр кубоктан эчәсе килеп китте. Туган нигезендә яшәргә (ә бәлки үләргә дәдер) кайтуы да аның соңгы җиңүе түгелме соң? Соңгы җиңүе ләбаса! Ул савыт-саба әрҗәсеннән сары күлмәгенә төреп салган кубокны эзләп тапты да, шул ук күлмәгенең җиңе белән сөртеп алгач, шаулатып эчемлек салды. «Сезнең исәнлегегез өчен, әни!» — диясе килде, тик сүзсез генә эчеп куйды. «Инде исәнлек өчен түгел, истәлек өчен генә»,— дип уйлады ул кул сырты белән авызын сөрткән чагында. Аскы иренен тешләп һәм күзен кыса төшеп, өнсез калгандай булып, бер читкә карап алды. Башында тагын бернинди уй калмады, күзе берни күрмәс булды... Ниндидер котылу чарасы эзләп, уң кулын алга сузды да әйберләр арасыннан шпагасын суырып чыгарды. Нигә икәнен уйлап тормастан, ул аның салкынча корычына иренен тидереп алды да баскычка утырды. Һаман да шулай өнсез калган рәвештә шпаганы идәнгә суккалый башлады.

Урамнан сөйләшә-сөйләшә бер төркем кешеләр узып китте. Тик аның төбенә кадәр ачылган кече капка ягына күтәрелеп карыйсы килмәде. Әгәр караган булса, ул анда үзенә таба якынлашучы бер туташнымы, ханымнымы күреп алыр иде. Ә хатын-кыз аның каршысына ук килеп туктады. Аит аны һаман күрми иде әле. Ул бары тик шпагасының бер

мәлне кинәт хәрәкәтеннән туктап калуын һәм очында ике тамчы кан пәйда булуын гына искәреп алды. Игътибар беләнрәк караса, кан тамчылары түгел, бәлки кызылга буялган ике тырнак икән. Ул карашын ялтырап торган тырнаклардан ак, озынча һәм шома бармакларга күчерде, ул бармаклардагы ташлы һәм ташсыз алтын йөзекләргә игътибар итте. Тик түзмәде, башын кисәк күтәреп, алдында торган хатынга бөтен барлыгы белән күрердәй итеп карап куйды. Аның каршысында кайчандыр чәчен сарыга буяган (ул колагы тирәсенә җыйнап куйган чәченең очларында гына калган) ак йөзле, учактан кар өстенә чәчрәгән утлы күмерне хәтерләтеп янып торган иренле һәм яшел күзле, сыгылма билле һәм җиңел сөякле, кызыл кофта белән ак вельвет чалбар кигән бер хатынкыз басып тора иде.



## Өченче бүлек

Аит аның башта иреннәре кыймылдый башлавын күреп алды, аннары:

— Ярамый,— дигән тыныч тавышын ишетте.

— Нәрсә ярамый? — дип кайтарып сорарга мәҗбүр булды Аит.

Ханым ни әйтергә белмичәрәк торды.

— Нигә ялгызың эчәргә... Алай кирәкми,— диде ул шешәгә ымлап.

— Әлегә монда син кирәкмисең,— диде ул хатынга каш астыннан туп-туры карап.

— Ялгыз эчмә,— диде хатын кабатлап.

Алар әле һаман берсе — шпаганың сабыннан, икенчесе очыннан тоткан килеш торалар иде.

Аит юри тупас итеп:

— Кушыласың килә ахрысы,— диде.

Хатын шпага очын ычкындырды, иелеп шешәне алды һәм әйләндерәәйләндерә аның язуын карап чыкты.

— А-а-а! «Камю!» — диде ул телен шартлатып. Аит аның вак кына тигез тешләрен күреп калырга өлгерде. Хәер, хатын тешләрен яшермичә, җай чыккан саен, ешрак күрсәтергә күнеккән булса кирәк.— Бик илаһи утырасың. Алла кебек.

— Аллага «Сез» дип эндәшмиләр. Аллага якынрак булыйм дисәң, аңа «син» дип эндәшү мәгъкульрәк.

— Ярый, килешәм... Әй, син, алла! Монда ошый миңа!

Хатынның уйный башлаганын тоеп, Аит кырыс кына:

— Миңа ошамый,— дип куйды.

— Алайса, ник күктән җиргә төштең, алла?

— «Төштең» дип, каян алып әйтәсең? Бәлки мин менеп китәргә җыенганмындыр.

— Мал-мөлкәтеңә караганда, син күктән төшкән булырга тиеш.— Хатын, матур хәрәкәт белән бер адым ясап, янда торган йомшак, коңгырт төстәге эре чәчәкләр төшерелгән канәфигә борылып утырды.— Ә миңа монда ошый! — диде ул тешләрен күрсәтеп. Аның чак ачылган тешләре арасыннан кызыл тел очы тукталып калды. Бу хәлендә ул мәчене хәтерләтеп куйды. Аның зур күз алмасы, нечектер, мәченеке кебек аркылыга кысылып тора иде шикелле.

— Миңа ошамый,— диде Аит юри. Әгәр дә «миңа ошый» дисә, алар арасындагы сүз өзелеп торачак, яңа сүз башлавы җиңел бирелми. Хатын да нәкъ аның «ошамый» диюенә ябышты ләбаса.

— Ник ошамый? Тәхетеңә ярашып җитми мәллә? — диде ул һәм аягын аягына куйды да ияге белән учына таянды.

— Миңа син ошамыйсың! — диде Аит. Бу сүздән соң хатынның чы-

гып китэсенә икеләнмәгән иде, тик ул тыныч кына, тавышын һич үзгәртмәстән:

— Алай артык борчылма: ошаган чаклар да булыр әле,— диде. Әйтерсең лә алар әллә ни гомердән килгән таныш-белешләр.

— Телеңә карап фараз кылганда, син бик күпләргә ошамыйсың булса кирәк,— диде Аит, шул ук «ошамый» сүзен дәвам иттереп.

— Әйе, мин сине шатландыра алам: шул телем аркасында мин хәтта иремнән дә котыла алдым.

Аит аның туры һәм кыю сүзләренә гаҗәпсенеп, аны баштанаяк карап чыкты.

— Син ул ирне бик бәхетле иткәнсең. Инде мине бәхетсез итәргә чамаламыйсыңдыр бит: минем сиңа ни зыяным тигәне бар?

— Кем белә: бәлки бәхетле итәрмендер әле.— Хатынның күз карасы тагын баягыча ук — мәченеке кебек, аркылыга кысылып куйган шикелле тоелып китте.

— Рәхмәтләр яусын инде, куандырдың,— диде Аит хатынның шаяртуын аңлагандай.

Дөрестән дә: болай шаярып сөйләшү аларның икесенә дә ошады булса кирәк. Хәтта кәефләрен күтәреп җибәрде, ул гына да түгел, арага көзге пәрәвезләр сыман җиңел һәм матур бер җеп сузылгандай булды. Әлегә исә аларның һәр икесе өчен дә бер-берсенең шаярып сөйләшкәнен аңлавы рәхәт иде.

— Миңа ошый монда,— дип кабатлады хатын һәм кәнәфигә бөтен гәүдәсе белән чумып, аркасын терәп утырды. Кайдадыр рестораннар, коктейль-барлар... Ә монда...— Ул әйтеп җиткермәде, кулын җәеп җибәрде дә як-ягына каранып алды.

— Иске-москымы? Кайда кыйшык, кайда жимерек, кайда черек...

Хатын сүзен әйтер алдыннан көлеп:

— Сиңа бик килешеп тора! — диде.

— Мондый сүзең өчен куалап чыгарыр дип шикләнмисеңмени соң?

— Һич. Сиңа бүген әңгәмәдәш кирәк.

— Психолог икәнсең.— Аит чиста нур белән тулып торган кубокка коньяк салды.

Хатын аның һәр хәрәкәтен, һәр карашын күзәтеп тора иде. Аит кубокны югары күтәреп, аңа сузды:

— Эчкерсезлегең өчен!

Савытның түбәнге бер өлешендә ачык күрән нур ноктасы җемелдәп тора иде. Аңа хатынның да күзе төште, ләкин ул, карашын әлеге ноктадан бармагындагы якут кашлы йөзегенә күчереп карады: кайсы нурлырак? Тәгаен чагыштырырга теләгәндәй, ул кубокны үрелеп алды.

«Бу дөньяда һәр нәрсәне чагыштырып була шул,— дип уйлады Аит.— Син хәзер, ханым, коньяклы бәллүр савыт нуры белән алтын йөзегеңнең кашын чагыштырып утырасың. Ә шул ук вакытта минем үзеңне кем беләндер чагыштырып утыруымны башыңа да китермисең, ханым». Тик ул бу хатынны кем белән чагыштырганын хәтерли алмады.

Аның каравы, ул инде хатынның рубин йөзеге һәм коньяклы бәллүр җемелдәвеннән дә балкышлырак бер нурны исенә төшерә алды. Ул нурда, күктәге йолдызларның нуры җиргә миллиард еллар аша килеп җиткәне кебек, Аитның хәтеренә таба ерак үткәннән — бала чагыннан ук юл алмады микән?

Мин аны Байкал күле дип атадым.

Инешнең авылыбыздан ярты чакрымнар түбәнрәк урынында жигүле ат, машина-трактор чыгып йөрер өчен уңайлы бер кичү бар иде. Инешебез күп сулы түгел, ләкин тирән ярлы. Ә кичү урыны ике яктан да сөзәк, житмәсә юлы тау юллары кебек бормаланып менә — йөк йөр-

тер өчен утә дә кулай. Шуның өстенә кичү тирәсендә елга төбе ап-ак ташлы, юри түшәсәң дә, алай тигез һәм каты булмас. Су монда җәелеп, сай гына булып, чишмә шикелле челтерәп ага. Бу урынга авыл көтүе төшлеккә туктый торган иде. Сыерлар җәйге челләдә суга ук кереп ята, төркем-төркем сарыклар да башларын үз күләгәләренә төртеп, суда басып тора.

Бу төшкә җитәрәк, инеш текә борылыш ясый. Биек, кызыл ярлар. Ярда катлам-катлам токымнар чиратлаша: иң түбәндә ак таш, аннан соң кызыл ком, аннан кызыл балчык, аннан ары торф, иң өстә кара туфрак. Кызыл ком арасыннан без алтын бөртекләре эзли идек. Берсе котырткanмы, хыялыбыз кушканмы... Безнең авыл тирәсендә җир астында алтын бар икән диләр иде, ул йодрык-йодрык булып, нәкъ шул кызыл ком арасында ятадыр шикелле иде безгә. Язгы ташуда кузгалган бозлар ярны туктаусыз ашый, ңартып тора, ком белән ташларны кичүгә таратып сала. Ә яр астындагы тобага ике дилбегә дә төшеп җитми диләр иде.

Бер елны, ташудан соң, инеш суы ниндидер кодрәт белән, текә борылышка орынмас хәлдә калды. Тоба урынында түгәрәк, тирән күл хасыйл булды. Артык суы бәләкәй чишмә хәтле генә булып агып тора иде. Мин Байкал күле дип менә шул күлне атаган идем. Ул халык теленә дә күчте.

Башта аннан язын торып калган зур-зур балыкларны сөзеп алдылар. Бәртәс, чуртан, табан, җәен...

Вакыт үтү белән, суның төсе күзгә күренеп үзгәрә башлады. Башта ул зәңгәрсу иде. Аннары яшел төскә керде. Күпмедер вакыттан соң ул төссезләнә башлады, суы салкынайды, төбендәге елгыр балыклар күзгә күренеп йөзә, тик тоттырмыйлар иде. Кимегәннән-кими барып, бер заманны тәмам юкка да чыктылар. Бу без — малай-шалай өчен, моңарчы күрелмәгән, җавабын хәтта дөньядагы күп нәрсәне белеп бетергән әти-әниләребез дә тапмаган тылсымга әйләнде.

Бактың исә, балыклар җылы инеш суына күчеп беткәннәр икән.

Аның каравы күлнең төссез суына әллә кайдан гына көмештәй нур иңә башлады. Ул көндезләрен балкып тора иде. Төбенә ярдан ишелеп төшкән кызыл ком җәюле алтын табакмыни! Берәүләр ул балкышны чишмәләр белән җир астыннан килә дип сөйләделәр, хыялга баераклары... күлгә төннәрен көянтәле Ай кызы суга төшә икән, төшкән уңайдан бер коенып та ала икән дип чыгарды. Имеш, ул көмеш нур күл суына сылу кызның ахак тәненнән юылып кала икән. Авыл кешеләренең хыялга тагын да баераклары ул нурны Ай кызының төнге күз яшьләреннән күрде. Ике дилбегә җитмәс шундый тирән күлне көмеш нур белән тутырыр өчен ялгыз Ай кызына күпме күз яше түгәргә кирәк булды икән соң?

Чынын беркем белмәгән. Бары тик гашыйклар гына... Дөньяда гашыйклар белмәгән сер була димени?! Алар бүтән кешеләр күзе күрмәгәнне кайнар йөрәкләре белән сизә ләбаса.

Бер егет сөйгән кызына Искәндәр кашлы көмеш йөзек бүләк иткән, ди. Кызы, ямьсез дип, алмаган, имеш. Авылымдагы Байкал күленең төссезләнеп калган бер мәле бар иде ич әле. Ул көмеш йөзекнең Искәндәр кашы нәкъ менә шундый төстә булган, имеш.

— Көмеш нурлы күл буена кил, ул йөзеккә шунда йөрәгебез төсен иңдерербез,— дигән бичара егет. Кызы, ышанмаса да, күнгән тагын. Тулган ай чыгып, айдагы көянтәле сызу кыз бөтен йөзенә елмаеп җибәргәндә, җитәкләшеп күл буена килгәннәр. Егет төссез кашлы көмеш йөзеген учына яшереп, ялганы фаш булу оятыннан курка-курка гына суга манчып чыгарса, ни күрсеннәр: йөзек кашы кызлар бите сыман алсуланып-алсуланып яна, ди!

Кыз мәхәббәтеннән тилереп, егет сөюеннән шашып, текә яр башына менгәннәр дә Ай кызына, рәхмәтләрен кабул кылуны сорап, кулларын сузганнар. Ай кызы көянтәсенә сарылып яткан кулы белән чиләгенең берсен янтайткан да егет белән кызның аяк астында яткан күлгә тәңкә-тәңкә су тамчылары коеп җибәргән һәм юкка чыккан. Яшьләр аны күлгә төште мәллә дип борылып карасалар!.. Көндезләрен ай шикелле көмеш нур белән тулып торган төнге күл иртәнге кояш сыман алсуланып, аларның каршысында җәйрәп ята икән. Бусын әле бер кешенең дә күргәне булмаган.

Шуннан соң мин Байкал күле дип атаган күлне Искәндәр күле дип йөртә башладылар. Кояшлы көннәрдә ул ай шикелле көмеш нур белән балкый, ә айлы төннәрдә кояш сыман алсу төс белән җемелди. Үзем күрдем. Үз күзләрем белән күргәнне үз йөрәгемә салып куйдым. Ул йөрәктә генә калды инде — алдагы елны язгы ташу Искәндәр күлен ком белән күмеп китте. Аның урынында тирән күзле, йөгерек сүзле салкын чишмә генә торып калды. Хәзер анда көтүчеләр көндезге ашка дип алып килгән сөтле шешәләрен батырып куялар...

Күл төбенә ярдан ишелеп җәелгән кызыл ком һәм саф чишмә суы шулай тылсымлы иткән бу күлне. Алтын табакка салынган чишмә суын күргәнегез бармы сезнең? Шул Искәндәр күле була инде ул. Балачагымның йөзек кашы.

Бу дөньяда Аитка әнә шул Искәндәр күленең үз йөрәгендәге нуры бернинди балкыш белән дә чагыштыргысыз кадерле иде.

Шуны тоеп алган кебек, янсә коньяктагы ачык көрән нур бөртеген үзенең рубин кашлы алтын йөзегеннән көнләгән һәм аны тизрәк юкка чыгарырга теләгән шикелле микән, хатын бәллүр кубоктагы сыекчаны сөзеп кенә эчеп җибәрде.

— Өч йөз генә торадыр бу бәллүр,— диде ул иренен кызыл тел очы белән ялап алгач. Аксыл көрән нур юк иде инде, ул хатынның алсу канына тарала башлагандыр.

— Алай бәллүр хакын саный башласаң, әллүр моннан!

— Алай да шәп мал икәнен әйтеп каласым килә. Үзеңнекеме?

— Атаң башыныкы булсынмы тагын! — дип кычкырды Аит.

— Бая син мине психолог дип атадың. Ә син үзең псих икәнсең. Син нәрсә?

— Кәбестә,— дип пышылдады Аит.

Икесе дә көлеп җибәрделәр.

— Үземне бәхетсез дип йөри идем. Моңа кадәр синең ише пычак теллеләргә юлыкмавым белән бәхетле икәнмен әле мин.

— Кызганычка каршы, инде менә юлыктың.

— Зарланмыйм. Монда миңа, ни әйтсәң дә, ачык чырай, такта чәй ич әле! — диде хатын, кубогын күтәреп.— Хан кызлары кебек, бәллүр кубоктан затлы коньяк авыз итеп утырган көнем!

— Хан кызлары күз яшьләре генә эчкән.

— Бәхетсезләр...

Аит аның кулындагы савытка коньяк өстәргә ниятләп үрелде.

— Юк, юк, рәхмәт. Инде болай да... нинди оятсыз хатын бу дип уйлый торгансыңдыр.

— Синең кулыңда — җинүчеләр кубогы. Бу мизгелдә синең бәхетеңә көнләшеп була.

— Нигә бу мизгелдә генә?

— Чөнки бу мизгелдән син чыгып киткән булырсың инде.

— Әйбәт тост! — Хатынның тавышы калтыранган шикелле булды. Ул җайсыз кузгалып куйды, артыгы белән кыюсыз, тыйнак кунактай, уңайсыз утырган килеш калды.— Шушы тостыңа үзең дә кушыл инде. Югыйсә мин генә талымсызланган булып чыгам.

— Кәефеңне кырдым ахрысы... Син дөрес әйтәсең: бүген миңа әңгәмәдәш кирәк. Ничек кенә кирәк әле!.. Тик миңа бүген син дә, башка берәү дә кирәк түгел. Миңа бүген бер генә әңгәмәдәш кирәк — ул да булса — үзем. Кешегә үз-үзе кирәклегенең ни икәнен беләсеңме син? Үз-үзеңә генә кирәк булган чак — кешенең иң бәхетсез чагы ул, ханым... Күп сөйләнеп ташладым. Я, танышыйк соң...

— Танышмаганда яхшырак. Андыйлар үзара эчкерсезрәк була. Тәүбә кылгандагы кебек, дөресен сөйлисең. Ярып салып. Эч серләреңне яшермичә. Анннары сөйләгән сүзләрең өчен бер-берең алдында тамчы да оялмыйча аерылышасың.

— Алай да кем атлы соң син?

— Әй, нәрсәгә соң ул?

— Синең исәнлегең өчен бер эчәсем килә, туташ,— диде Аит.

Хатын үзалдына елмаеп:

— Туташ түгел,— диде, якты, аяз күккә карап.

— Туташ дияргә дә бик була, ханым.

Хатын, алга иелеп, аңа ак кулын сузды.

— Сөмбел, ханым димәсәң дә була.

— Сөмбел,— дип кабатлады Аит.

— Бер шагыйрь кисәге Гиацинт дип йөргән иде.

— Охшагансың,— диде Аит, аңа тутырып карап.

— Комплиментлар яратмыйм.

— Ялгышмасам, Сөмбел — төнлә ачыла торган чәчәк булса кирәк.

— Син хаклы. Артист халкы кешеләр өчен кичен генә ачыла.

— Син артистмыни?

— Без авыллар буенча гастрольгә чыктык.

Сөмбел күчмә театр артисткасы иде. Бу авылның кунак йортына килеп урнашкач, кибет карап кайтырга дип чыктылар. Чир диярсең: авылларга килеп төшсәләр, алар иң әүвәл кибетләрне әйләнеп кайталар. Алырга теләгән нәрсәләре дә юк, шулай да тыелып кала алмыйлар. Бәлки озын көнне үткәреп җибәрүнең инде гадәткә кергән бер чарасыдыр бу?

Асылына төшебрәк карасаң, артистның җаны мәңге ачык килеш торган тирән җәрәхәт сыман ул. Тормышта тагын кемнәр шулай һич икейөзлеләнмичә үз-үзләре булып кала белә икән?

Сөмбел дә менә шундый җаннарның берсе иде. Бая кибеткә төшешли җәрәхәтле төсмерләр белән ишетелгән гитара авазларына сагая калды да яшел чирәмле капка төбенә таба атлап китте. Авыл җирендә шулай оста гитара чиртүчегә карап узарга теләү табигый ләбаса. Моннан да битәр бөтен торышы белән ташландык икәнлеге беленеп торган йортның ниндидер бер тылсымы, сере бардыр кебек иде. Ул берәр эшсез студент затын очратасына һич шикләнмәде. Гитара тынып калды, ә ул капкага таба нибарысы бер-ике адым атларга өлгерде. Ары киткән хезмәттәшләре аңа борылып, кайсы чакырып кул изәде, кайсы көлде, кайсы «кыюрак!» дигән ишарә бирде.

Ә капка төбенең чирәме калын, йомшак, паласка баскандагыча, аякка рәхәт иде. Ул бары тик шул рәхәтлекне татып карар өчен генә тагын ике-өч адым атлады. Кемнедер йокысыннан уятырга теләгәндәгечә сак кына, салкын суга кергәндәгечә сагаеп кына, караңгы бүлмәдә капшанып баргандагыча куркып кына. Андый чакта итәгең кузгаткан җил дә ишетелә, аяк басуың да каты кебек, йөрәгең дә бөтен кешегә ишетелерлек булып тибә бит ул.

Менә хәзер дә, һәр атлаган саен, тук та тук аваз килә башлады. Ирексездән, ул үз адымнарын шул тавышка көйләп басты. Башта ул аяк астындагы чирәмне карап, аның яшел генә, үрмә сабакларының япон рәсемнәрендәгечә ассимметриясенә, чәчәкләренең он бөртеге хәтле генә таҗларына сокланып барды. Аннары ачык капкага сузылып

кергән җиләс һава агымын тоеп алып, карашын шунда күчерде. Кечкапканың кеше колагын хәтерләтеп бөгелгән келәсен искәреп узды. «Нинди гармония: келә, чыннан да, һәр аяк тавышын сагаеп тыңлаучы капканың колагы лабаса!»

Шунда ул табак-табак ак ташларны күреп алды. Аралары чирәмле. Ул аларны яшел белән каймаланган сатин кулъяулыкларга охшатты. Басып керер өчен аяк астына кулъяулыклар салып куйган кебек. «Мондый җирне кайда күрер идең,— дип уйлады ул. Басып йөрер юлыңа шундый мәгънә салып кую өчен йорт хуҗасына нинди акыл иясе булу кирәктер! Я хода! Монда гаҗәп матур һәм тату торганнардыр! Ә хәзер абзарның арык сыер тиресе шикелле эленке-салынкы салам түбәсендә эсселектән шәлперәйгән алабуталар моңаеп утыра».

Тимер белән суккан тавышны эзли-эзли, ул карашы белән ишегалдының кече капкадан күренеп торган бар нәрсәсен капшап чыкты. Коргаксып беткән арба тәгәрмәче, стенадагы чөйгә эленгән йөгән авызлыгы, ыргак, ишегалды уртасына өеп куелган кәнәфи, сүтелгән өстәл, кибеттән алынганнан бирле ачылмаган яссы әрҗәләр, берсе яңа, берсе таушалган чемодан, тагын әллә нәрсәләр өеме, келәт почмагына кыстырылган урак, төпсез чиләк, болдыр баскычындагы кыйммәтле магнитофон. Ул кеше кулын, аның йөнтәс беләгендәге браслетлы сәгатьне, һәм, ниһаять, нык муенга утырган, аеры иякле, ач яңаклы, кысыграк күзле, калын кашлы һәм артка таралган чәчле ир-атны күреп алды.

Шунда ук танып алды ул аны. Әлбәттә, таныды.

## Дүртенче бүлек

Бигрәк тә ул аның сәҗдә кылган картныкы кебек ише, һичнинди уй затын белдермәгән, буш, тирән күзләренә игътибар итте. Әллә үкенеч, әллә кайгысы бар, әллә аек, әллә исерек, әллә киеренкелек, әллә битарафлык... Әллә бөтенләй өеннән чыгып китәргә җыенган, әллә инде, төянеп, бөтенләйгә кайтып төшкән. Әмма чыгып китәсе кешенең йорты бу хәлгә үк төшмәс.

Ниндидер бер тылсымлы пышылдау чакыруына ияргән сыман, ул капкадан эчкә узды. Бөтен җаны-тәне белән бу серле ир заты бәргәләгән шпаганы, очыннан эләктереп, туктатырга теләде. Ул, кемнедер юаткан сыман: «Хәзер, хәзер»,— дип уйлады.

Ул бу йортның шаулап-гөрләп торган чагын да бик яхшы хәтерли иде.

— Бая, беренче күрүгә, мин сине китәргә җыенгансың дип торам. Ишегалдыгызда алабута үсә, каралты-курагыз ишелергә тора... Ишегалды уртасында — мал-мөлкәт... Димәк, күрергә генә түгел, торырга дип кайткансың. Мондый хәлдә кешегә авыр.

— Җиңеләйтергә теләгән идеңмени? Җиңелгәннең хәлен җиңеләйтеп булмый, ханым.

— Җиңелгәннең?

— Минем кем икәнемне беләсеңме?

Сөмбелнең сикереп торып, «Беләм, Аит абый!»— дип кычкырасы килде. Аитның моңарчы үзен танымавы гына тыеп калды. «Танымады. Күңеле белән карамыйча, узгынчы дип кенә кабул иткәнгә күрәдер. Әллә мин шулай танымаслык булып үзгәрдем микән?..»

— Мин...

— Кирәкми, әйтмә,— диде Сөмбел.

Аит, аннан күзен алмастан, кубокка бер-ике йотым коньяк агызып алды.

— Шулай. Узгынчыга мине белү нигә хаҗәт... Элек мин мондый кубоклардан бары тик җиңүләрем өчен генә эчә идем...

— Ә хәзер?

— Җиңелүем өчен.

— Анысы да булгалый торган эш. Тагын җиңәрсең әле.

«Болар бергә түгел инде ахрысы,— дип уйлады Сөмбел. Үзен ышандырыр өчен, ул үзен болай уйларга этәргән сәбәпне дә уйлап тапты: Аит әле бер генә мәртәбә дә «без» димәде, гел «мин» дә «мин».

— Спортчы гомерендә һәммә җиңүләр дә артта кала торган бер чик була.— Аит бер йотып куйды да, коньякның тәмен татыгандай, тынып калды.— Бу яктан сез, артистлар, бәхетле. Сезнең халык сиксән яшьтә дә унөч яшьлек Джульеттаны уйнар идем дип дәгъвалыйдыр,— диде Аит.

— Кайбер чакны утыз яшьтә дә ишанның карт хатынын уйнарга туры килә. Бигрәк тә син режиссер белән килешә алмаган ялгыз, өстәвенә шактый чибәр бер хатын да булсаң.— Сөмбел бармак очлары белән генә үзен баштанаяк сыпырып үткәндәй бер хәрәкәт ясап алды.

«Анысы хак, чибәр»,— дип уйлады Аит.

— Академия театрыннанмы син?

— Юк, күчмәдән. Хәзер күчмә дип аталмый, исемен үзгәрттеләр. Тик җисеме шул көенчә калды. Тоташы белән чегән тормышы — гомер буена көпчәкләр өстендә.

Аит чак кына салып, кубокны аңа сузды. Сөмбел алмады.

— Рәхмәт.

— Кире какканны яратмыйм, ханым.

— Мин нигәдер кире кагарга яратам шул. Югыйсә, карт ишанның иң карт хатынын уйнап йөрер идеммени? Үзең эч. Син матур итеп эчә беләсең икән: назланып, тәмен татып.

— Я алайса, ни өчен эчим?

— Киләчәктәге җиңүләрең өчен.

— «Киләчәктәге җиңүләрең»... Барысы да артта калды.

— Кешенең иң авыр җиңүләре алда... Мондый хәрабәләр арасына кайтып төшү — үзе бер зур җиңүдер ул.

— Җиңелдем дигәч тә, үземне тормышта соңгы уколны алган кеше дип уйламыйм әле мин. «Әйе, минем әле үземне җиңәргә теләгән язмышның үзенә кадыйсым бар, үзенә! Иң татлы җиңү — соңгы очко»,— дип уйлады Аит. Аның шпага белән һаваны чәнчеп-чәнчеп аласы килде.

Бу йортны, үзенең туган бишеген, ул җәннәт итәргә уйлап кайтты. Анлык кына капиталы җитәрлек. Яшәп күрсәтәсе килә иде. Аңа үч итеп, аңа!

— Менә монда румын гарнитуры,— диде ул кубогы белән әрҗәләргә ишарәләп.— Ә менә монда...— Ул кулын селтәп алды.

— Нигә элегрәк кайтмадың? Нигезегез тәмам тузган. Ә кайчандыр бу йорт авылда иң тазалардан, матурлардан иде.

— Күргәнегез бар идемени?— диде Аит, аңа карамыйча гына.

Сөмбел кузгалып куйды.

— Бәй, моны күрү кирәкмени? Бар нәрсә дә монда кайчандыр зур тәртип булганын сөйләп тора. Иске йорт булса да, берни аунап ятмый.

— Аунаганнарын ташып бетергәнгә күрә ул.

— Ташып бетергәнче кайт идең.

— Батырлык җитмәгәндер.

— Батырлык?— Сөмбел тынып торды. Каршысында утырган иргә авыр бер сүз әйтүен аңласа да, ул:— Мин... хатының риза булмагандыр дип торам,— диде.

«Кызык бу хатын-кыз логикасы,— дип уйлады Аит.— Бөтен нәрсәне хатын-кызга гына бәйле дип белә».

Хәер, хатыны белән аерылышмаса, ул бирегә торырга дип кайткан булыр иде микән? «Батырлыгым җитмәс иде»,— дип килеште ул. Хәзер үз нигезеңә кайтыр өчен дә б а т ы р л ы к к и р ә к ш у л. Бүгенге дөнья әллә нишләде. Ә бәлки бер нишләмәгәндер? Батырлык ул, элек кайда һәм кайчан кирәк булса, бүген дә шунда һәм шул вакытта кирәк. Аның бары тик төсе генә үзгәрде. «Төсе?»— дип сорады ул үз-үзеннән. Батырлык, һичшиксез, кан төсендә — кызыл гына булырга димәгән. Хәер, тыныч көннәр батырлыгы күбесенчә яшерен. Бүгенге көн батырлыгы үтә шәхси эш. Беркем артыңнан куып тормый. Шуңа күрә аны эшләве дә кыенрак. Бүген син читләтеп үтәргә һәм үзеңне акларга мөмкинчелек биргән бик күп сәбәпләре бар аның. Әйтергә кирәк, житди сәбәпләре!.. Менә шул сәбәпләрне җиңә, шәхси читлегеннән чыга алган кеше — каһарман ул. Ә ул, Аит, каһарманмы? Ул туган нигезен җимерелүдән, бетүдән саклап калыр өчен бар дәрәҗәмнән, ирешкән биеклегемнән ваз кичеп кайттым, дип әйтә аламы? «Кыргансың икән! — дип көлде ул үз-үзеннән.— Моны гап-гади бурыч дип тә атарга була лабаса! Туган бишекне саклау бурычы. Тик һәр бурычны үтәү — каһарманлык түгел». Аннары соң ул монда үз киләчәгеннән ваз кичеп түгел, ә бәлки үткәненнән качып, җимерелгән үз язмышын төзәтү исәбе белән кайтмады микән? «Юк! Мин монда дөньяны тагын бер мәртәбә җиңәр өчен кайттым».

Әйе, ул бу йортны җәннәт итәчәк әле! Иске булса да, бүрәнәләре чыкылдап тора, нарат такта белән тышлап та җибәрсәң, ике гомергә чыдарлык. Ишегалдын гына кара — үзе бер Сабан туе мәйданы хәтле бар. Аның әтисе белән әнисе яши белгәннәр дә соң! Кешеләрнең ишегаллары уч төбе хәтле генә. Аит нигә шулай икәнен чамалый. Җәен себерергә, кышын карын көрәргә иренүдән шулай кечкенә, тотып алыр өчен такта кызганудан, күңел тарлыгыннан. Ә аларның нәселе иренүнең, ялкаулыкның ни икәнен белмәгән дип сөйлиләр. Ләкин менә балалар гына кайткалап, төзәткәләп тора алмады. Менә иртәгә, менә иртәгә дип тыныч кына яши бирделәр. Йортны сатып җибәрергә дә кызгандылар. Ә тормыш гел бүген бит ул, каһәр! «Иртәгә» дигәнең үлгәч кенә килеп җитә...

Аит таянмый-нитмичә, мәченеке кебек сыгылмалы гына бер талпыну белән урыныннан торып басты. Әгәр бу хәрәкәтне ни беләндер чагыштыру кирәк булса, Сөмбел аны оста артистның яхшы куелган — сыгылмалы, йөгерек, көйле тавышына тиңләр иде. Артист үз тавышы белән идарә итә белгән кебек үк, спортчы да үз тәнен, мускулларын үзе дә сизмәстәй дәрәҗәдә хәрәкәтләндерә ала икән.

— Рөхсәт итмәссез микән, Сөмбел ханым?— диде Аит. Шуннан соң капканы ябып килде дә аның каршысына килеп басты.

Аның гәүдәсе, торышы, кыяфәте, йөзенең тыныч, үз-үзенә ышанган төсмере матур иде. Беренче күргәндәге Аит башлыча уенчак тайга тартым иде. Хәзер ул уенчаклыкны акыл һәм тәҗрибә буйсындырган. Ә Сөмбелне ничек танымый соң ул? Сөмбел, бәлки таныгандыр, тик нигәдер белгертергә теләмидер яисә базмыйдыр дигән өмет белән:

— Мин үземә таныш булмаган ир-ат белән биемим шул,— диган булды.

— Алайса, таныш булыйк: Аит.

«Юк, танымаган».

— Кызык исем,— диде Сөмбел һәм, аның үзенә таба сузылган учына таянып, урыныннан торды.— Дөнья чемпионымы әле?

— Элеккеге. Сирәк исем — Аит.

— Медальләрегез күпме?

— Алар хәзер истәлеккә генә ярый инде... Бал-маскарад телисезме?

Рәсемнәр белән чуарланып беткән шул ук сумкасыннан шпагачы битлеге һәм медальләр тасмасы алып, Аит Сөмбелгә кигезеп куйды, ә үзе шпага такты. Яссы ташлардан төшеп, вальс бии башлаганда гына Сөмбел алабуталарга абынып китте.

— Монда бик онытылып әйләнермен димә.

— Әйе, сәхнә түгел.

— Син дөнья буйлап чемпион титуллары яулап йөргән арада, нигезегезне алабута басып киткән.

Аит кисәк туктап калды. Аның күгелҗем мәрмәрдән уеп ясалгандай ияге Сөмбелнең күзе турысында иде, һәм хатын, аерым-ачык итеп, ул нык иякнең тетрәп куйганын күреп алды.

— Пәрдә, ханым,— диде Аит.— Спектакль тәмам.

Һәм ул тыелгысыз ярсып шпагасы белән алабуталарны уңлы-суллы туракларга керešте. Ул селтәнгәндә корыч чыбыкның чажлавы музыканы да басып китә иде. Кайдадыр каргалар каркылдашып алды.

Сөмбел бая биредә пәйда булгандагыча тыныч кына:

— Кирәкми, Аит,— дип караган иде, тәэсире булмады.

— Аит! — диде ул тавышын күтәрә төшеп.— Тынычлан, Аит! — һәм шпагасын югары күтәргән бер мизгелендә аның күкрәгенә ташланды.

Мөгаен, көтмәгәндә юлга йөгереп чыккан һәм өстенә килгән машинадан куркып калган баланы коткарырга да шулай ташланалардыр.

## Бишенче бүлек

Аит гаҗәпсенүдән зур ачылган күзләре белән аңа текәлде. Сак кына итеп, иkeләнеп, аның иңбашына орынды. Уч төбенә аның җиңелчә генә калтыранган дулкын таралды.

— Кирәкми,— дип пышылдады Сөмбел.— Ирләргә килешми.

Сөмбел читкә тайпылды. Аңа аркан торган килеш башындагы битлекне, иңбашына кыйгачлап салган медальләр тасмасын салып, әрҗә өстенә куйды.

— Монда күңел ачу, маскарад кына, ханым. Гафу ит.

— Спектакльгә чаклы минем вакытым бар әле. Әйдә, әйберләреңне өйгә ташып куябыз. Төнгә монда калмаслар лабаса. Мин кермәсәм, инде шактыен ташып бетерер идең.

— Рәхмәт. Башта әчтәге иске-москыны чыгарып ташлыйсы бар әле. Бераз төзәтәсе, юасы, җайлыйсы...

— Иске-москы? Кирәге чыкмас дисеңме?

— Эш анда түгел. Искә төшереп тормасыннар.

— Ихтыярың...— Сөмбел башын гына борып, аңа карады. Аит аның үзен кызгануын тойды.

— Син чыннан да бөтенләйгә кайттыңмы?

— Бөтенләйгә.

— Ә... хатының... балаларың? — диде Сөмбел, өзек-өзек итеп. Моның белән ул соравының житдилеген белгертергә теләгән иде. Ә Аит Сөмбелнең бу сорауны үзе өчен күптән ачыклап куйганына шикләнми иде инде. Сүз ни хакында гына кузгалмасын, ул әле бер генә мәртәбә дә «сез» дип авыз ачмады ич. Ул: «Син чыннан да бөтенләйгә кайткансың»,— димичә, «Сез чыннан да бөтенләйгә кайтырга карар кылгансыз икән»,— дия ала идеме? Болай әйтсә, сүз әлбәттә, гаилә хакында дип аңлашылыр иде. Димәк, «хатының, балаларың» дигәне бары тик тел төбе яшерәсе килүдән генә. Мәче — тычкан уйнау яки бу ханым алдында фәрештә сурәтендә күренергә тырышу мәгънәсез. Шуңа күрә ул кырт кисеп:

— Аерылыштык,— диде.

Аның бу сүзеннән соң Сөмбел башын чак кына артка ташлый төшеп, елмаеп куйды. Башын артка ташлавы аны биегәйтеп тә җибәрде бугай. Кешене шатлык, тантана, горурлык я мактану хисе генә биегәйтә. Башка бөтен хисләр дә аның буен кечерәйтеп җибәрә. Аның елмаюын күрмәмешкә салышу, хәтта җәзасыз ук калдыру да мәгънәсезлек булыр иде. Хис яшермәү ирләргә дә кирәк сыйфат.

— Мин синең елмаюыңны күрәм, ханым,— диде ул, фикерен бөтенләе белән үз иркенә җибәреп. Әмма бу сүзләрне әйткәндә ул үзе дә күңелсез йөз белән елмаеп тора иде.

— Ни сөйлисең син?— диде Сөмбел һәм, башын алга иеп, кулы белән йөзен каплады — гәүдәсе шундук кечерәеп, мескенәеп калды.

— Әйе, әйе! Уңышсызлыкка очраганнар үзең генә булмавы кайвакытта куандыра да ул! Син шуңа елмайдың.

Аит аны, җавап кайтарып тормастан, чыгып китәр дип көткән һәм туры бәреп әйтүенә үкенгән дә иде инде. Шул ук вакытта ул Сөмбелнең чыгып китмәячәгенә дә төшенде: ул җиңелергә ярата торган хатынкыз затыннан булырга охшамаган.

Әнә ич: кулы белән битен яртылаш каплаган килеш (әллә ачык изүеннән күренгән күкрәк турындагы тирән уентыгын каплавы микән?), кисәк кенә аңа таба омтылды. Күзе ачылган, еш-еш сулу ала.

— Мине яңагыңа сугып җибәрде дип бел!.. Яки йөгереп чыгып китте дип... Гарьләндердең һәм үпкәләттең... Мин үземне бәхетсезләрдән санамыйм, тик кеше бәхетсезлегенә куана торган бәхетсез түгел әле мин... тәкъсир!

— Алайса ник елмайдың соң?

— Син уйлаганнан түгел. Була бит шундый мәгънәсез уйлар: мин үземне син ташлаган хатын итеп күзалладым... Ә ул хатынны — үзем итеп.

— Моңа еларга кирәк, елмаерга түгел.

— Фаҗигаләрнең елмайтырдайлары фаҗигалерәк.

— Гафу ит. Соң... сук һәм ташлап чыгып кит.

— Боларның икесе дә бик җиңел эш. Кайчагында калуы авыррак була. Кайчагында түзү һәм калу кирәк. Бәлки сиңа да хатының белән калу кирәк булгандыр.

— Безне бу хакта уйланмаган ахмаклар дип беләсең мәллә?

Аит магнитофонны сүндерде. Тагын зыңлап торган тынлык урнашты. Һаман да шул чикерткәләр генә әле озын, әле өзек-өзек итеп аваз сала.

Аларның икесе арасындагы күренмәс җеп тә шулай киеренке зыңлап торгандыр шикелле. Кайдадыр биектә, нәкъ аларның баш өстендә эленеп торган зур кургаш шарның җебе өзелгән дә, шул шар, сызгырып, аларга төшеп килә сыман. Шуны тоеп, ләкин качарга һичнинди талпыныш ясамыйча, алар бер-берсенә сүзсез караш ташлап алдылар. Карашлары гүя торган саен үзләренә якынлашып килгән кургаш шар кебек авыр иде, тик алар бер-берсен котылгысыз читләшүдән коткарырга ашыкмадылар. Әгәр дә Сөмбелнең иренендә иннек сөртелмәгән булса, Аит аның агарып калуын күрер иде. Хәзер исә ул аның күзенә игътибар итте. Сөмбелнең күзе яшькелт төстә, һәм ул яшеллек аңа тау башыннан күренгән түгәрәк үзәнне хәтерләтте:

— Сау бул,— диде Аит һәм гитарасын алды да болдыр култыксасына, ачык ишеккә каршы барып утырды. Бернинди уе булмагангамы, бармаклары гитара кылларын чирткәли башлады.

— Гитараң яхшы. Зыңлап тора. Яңгыравыклы.

— Болдыр шулай ишеттерә, такталары нарат, шуңа яңгырый... Бу йорт кеше тавышын сагынган... Корридадан соң буш калган стадион кебек ташландык, сагышлы.

— Коррида... Испаниядә булганың бармыни?
— Юк. Мексикада күрсәттеләр... Бөтен дөньяны айкадым-айкадым да чыгып киткән бишегемә әйләнеп кайттым... Әле дә ярый, хәлдән тайгач, кайтып егылыр өчен ата-ана нигезе бар. Без аларга үзебезне дөньяга китергәннәре өчен генә түгел, безгә теләсә кайчан кайтып егылырга мәңгелек бишек калдырганнары өчен дә бурычлы,— диде Аит, йорт-җиргә ишарәләп.— Әти белән әнинең яшьлек кошлары оя корган бишек... Моннан якты дөньяга җиде бала канат ныгытып очкан.
— Берегез-бер авылда түгелме?
— Укыдык без.
— Сатасыгыз калган йортыгызны.
— Арып, хәлдән таеп егылган атны атып үтергән шикелләме?.. Безнең бу хәлсез йортны сатарга кулыбыз күтәрелмәде. Хыянәт итү кебек тоелды... Тик вакытында ирләр булып калу кирәк икән! Кызганыч...— диде Аит.
— Кызганып кайттыңмыни?
— Нәрсәмнедер югалттым, Сөмбел. Ни эзләп кайттым — белмим... Бүген авылда беркемдә дә булмаган нәрсәм бар ич әле минем — Камю коньягы! Һәм...
— Баш очында түбәме?— дип бүлдерде аны Сөмбел.
Аит ташка сикереп төште.
— Һәм — син,— диде ул.— Яхшы әңгәмәдәш.
Сөмбел читкә борылды.
— Ни югалтса да, ир-ат бер генә нәрсә эзли шул — хатын-кызларны.
— Дөнья шулай яратылган ич, Сөмбел: кешеләр үз-үзләрен күп очракта башкаларда таба.
— Бәла дә шунда шул: «таба». Ирләр үз-үзләрен очраган бер хатын-кыздан табарга риза.
Аит аның каршысына килеп басты.
— Хәзер бу гади эшләнә, шулаймы?— диде ул һәм Сөмбелнең күкрәгенә кушырып куйган кулларын түбән шудырып төшерде.
— Ничек була инде ул гади диюең?
— Менә болай,— диде Аит һәм җитез бер хәрәкәт белән аны үзенә таба тартып китерде дә иреннәреннән суырып үпте.
Сөмбел тынсыз калды. Коньяк йотымы аның кәефен күтәреп җибәргән иде. Гадәти булмаган бу очрашу һәм сөйләшүдән, Аитның кыюлыгыннан аның тәне оеп киткәндәй булды. Юк, моны ул үз-үзеннән яшерми, юк! Ләкин ул күңелендәге кайсыдыр бер кылның үз кәефенә буйсынырга теләмәвен дә тоя иде. Нәкъ менә гадәти булмаган бу очрашу һәм сөйләшүнең шулай гади бер хәрәкәткә килеп терәлүе белән килешә алмады. Башка чакны, үзен мәҗбүр итеп булса да, артык игътибар итмәгән атлы гына кыланып, уздырып та җибәрер иде...
— Яхшы аңлаттың,— диде ул, хәзер нишләргә тиешлеген уйлый-уйлый.— Ә җавабы тагын да гадирәк аның.
— Нинди?— Әллә уңайсызланып, әллә ничек — Аит башын түбән иде, ә Сөмбел изүен капларга дип күтәрелгән кулы белән селтәнеп, аның яңагына сугып җибәрде.
— Аңлашылгандыр дип уйлыйм!
Ә Аит аның кечкенә кулыннан яңагын сакларга уйламады да ич маса!
Сөмбел капкага таба китте.
— Капкаңны ач әле,— диде ул башын горур тотып.
Аит аңа аркан баскан килеш, борылмыйча гына:
— Кулың шактый озын — ач та чык,— диде.
— Мин монда ачык капкадан кердем.

Аит салмак адымнар белән, таштан-ташка басып кына килде да капканы ачып куйды.

— Юлыңа ак җаймә,— диде ул тыныч кына.

— Сыең өчен рәхмәт, чемпион!

Сөмбел чыгып китте. Аит аны борылып карар дип көткән иде. Юк, карамады. Китте. «Кирәкмәс иде»,— дип уйлады Аит һәм, капканы ябып, баскычка килеп утырды. Ашыйсы килә иде. Әллә эче поша микән?

«Сөмбел»,— дип уйлады ул буш кәнәфигә карап һәм аны шунда утырган итеп күз алдына китерде дә:

— Сөмбел,— дип пышылдады.

## Алтынчы бүлек

Кич җитеп, ни арада караңгы төште. Өйләрдә ут алынды, ә кайберләрендә бер кабынып, инде сүнәргә дә өлгерде: авылда иртә яталар, иртә торалар. Авыл кешесе көндәлек тормышын, кояш белән табигатькә һәм мал-туар мәшәкатенә, бала-чага мазасына көйләп тора. Аның йокыга һәм авырырга вакыты юк. Иркенләп йоклый икән — кеше арасында саны юк, чынлап авырый икән, инде җаны гына калган була.

Аит үзенең авылга кайтып төшүенә әллә ни гаҗәпләнгән кешене очратмады. Кичә иртән күрше Мөкатдис кенә кереп чыккан иде.

Аның беренче сүзе Аитны сискәндереп җибәрде. Исәнлек-саулык сорашкач, ул:

— Үләргә кайттыңмыни?— дип әйтеп салды.

— Ник алай дисең, Мөкатдис абый?..

— Авылда торырга шәһәрдә сансыз, кеше чутында йөрмәгән булдыксызлар, я терелергә иманы калмаган авырулар гына кайта, парин. Башында акылы, тәнендә сау җаны булганнар кире кайтамы соң?

— Юньле мал ашаган урынына кайта диләр ич әле.

— Җүнле малны, ашап симерә торгач, тотып суялар аны, парин... һәй! Теге чакны геройны ычкындырмасаммы? Калыр идем мин авылда, бар! Берәр базага директор итмәсләр идемени?

Кайчан гына очрашсаң да, Мөкатдис моны искә алмыйча калмый. Бер заманны, шәһәрдә больницада икәнен ишетеп, Аит аның янына күрешергә барды. Ята, күңеле көр, зурлап килгәне өчен рәхмәт яудыра-яудыра күреште, хәл-әхвәл белештеләр, сөйләштеләр, искә алдылар... һәм ахырда, Аитның ничек карыйлар, зарың юкмы дигәненә каршы тагын шул ук сүз:

— Җүнлерәк карый торган урыннар да бардыр, монда да зарланырлык түгел... тик, парин, теге чакны геройны ычкындырмасаммы?..

Ул чакта аны өчме-дүртме ай яткырдылар да чыгардылар. Операция җиңел үткән. Операция дип әйтерлек тә түгел — эчен ачканнар да япканнар гына. Солтания шуннан соң ике ай буена әтисе янына авылга кайткалап йөрде, кайткан саен елап килә иде. Врачлар Мөкатдиснең туганнарын чакыртып алып, аны ике ай гомере калган дип биреп җибәргәннәр. Аннан соң ике ел үтте, ул вакыт эчендә Аитның үз гаиләсендә күпме борчу, мәхшәр булып узды, Солтаниянең авыр фаҗигасе бүтән нәрсәләрне калын битарафлык туфрагына күмеп калдырды.

Ә Мөкатдис исән-сау, тик ябык, күз төпләре капчыкланып тора, ә күз алмасының агы, акчарлак йомыркасыдай, сары һәм көрән таплар белән чуарланып беткән. Башында ямшәйгән һәм таплы эшләпә, өстендә соргылт пинҗәк, кыек якалы көлсу күлмәк, күкрәк кесәсенә күгәрек тимер каптырмага кидерелгән кызыл карандаш һәм бөгелмәле калай линейка тыккан.

Теге чакны геройны ычкындырмаса, ни буласын ул әйтеп бетерми,

анысын тел очында гына калдыра, анысын гаптәше үзе күз алдына китереп бетерергә тиеш; һәрхәлдә, теге чакны геройны ычкындырмаса, Мөкатдиснең хәле хәзергедән шөкранә яхшырак, җиңелрәк, мәртәбәлерәк булырга тиешлеген күңеленә салып куярга мәҗбүрсең. Иң кимендә кемнеңдер, кайчандыр, кайдадыр, ни өчендер Мөкатдискә карата гаделсезлеккә юл куйганлыгын искәреп куясың, үз күңелеңдә аңа теләктәшлек, кызгану хисе уяна.

— Разведканың ни икәнен беләсеңме син, парин? — дип сорар иде ул сүз башлаудан әүвәл.— Ул, парин, кыш көне Иделгә бәке уеп, су астында йөрү белән бер гамәл. Үз бәкеңә килеп чыга алсаң, якты дөньяда әҗерең бетмәгәненә шөкер кылырга була. Юкса, син әйләнеп кайтканчы, бәкең шакыраеп катуы да ихтимал. Иң мәсъүле шунда — разведчикның үләргә хакы юк. Ә изге бер сәгатьтә үлеп калуның яшәүдән җиңелрәк тоелган вакытлары барые аның, парин!

Мөкатдиснең иске, мәгънәлерәк гыйбарәләр кулланырга, шуның белән сөйләгәненә серле төсмер бирергә ярата торган гадәте бар иде.

Разведчикның үләргә хакы юклыгын Аит бик яхшы белә. Үзе шаһит. Үзе һәм хатыны Солтания. Хәер, хәер!..— Бу — авыр яра. «Кагылмый тор, кагылмый тор»,— диде ул үз-үзенә. Аннары соң... ул аның хатыны да түгел инде.

Мөкатдис зыянлы кеше түгел ул. Дөнья дигәнең тормышка ризасыз кешеләр арасыннан хәтта тарих булып тарихка да файда китергән бик күпләрне белә.

Юк, Аит Мөкатдисне теге чакны геройны ничек ычкындырганын сөйләүдән мәхрүм итәргә кыймады. Бәлки кеше шуның өчен кергәндер дә. Бәлки кеше шуның өчен яшидер дә!

Аит матур, бәллүр рюмкага салып бирде. Мөкатдис аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торды, эчәр алдыннан коньяк шешәсенә бик хикмәтле нәрсә күргәндәй, күзен тал яфрагы кебек кысып, сәерсенеп карап торды, кулына алырга үрелгән иде,— кире уйлады һәм рюмканы гади стаканга бушатты да тары бөртеге йоткандай гына итеп эчеп бетерде.

— Синең урынга теге... кем әле? — диде Аит.

Мөкатдис аның ни хакында сүз кузгатканын ирене кыймылдавыннан да белер иде. Ул бу сорауны иркенләбрәк сөйләшергә мөмкинлеге булган һәрбер очракта теләсә кемнән көтә иде ахрысы.

— Әйе, Шамякинга,— дип җөпләргә ашыга ул. Хәзер инде вакытка ул хуҗа. Вакытка гынамы? Хәзер инде ул хикмәтле, корсагында балавыз шикелле саллы печать бүлтәеп торган яшел шешәдән ятсынмый, кулына ала, мөһеренә иренен түгәрәкләндереп өреп карый да, стаканны читкәрәк этәреп, алдына рюмка куя. Үзе салмый, ул әрсезлеккә караганда хөрмәтләүне яратарак төшә.

— Ташладым мин, парин,— дип сөйли башлады Мөкатдис.— Шулай, немецның блиндажын капладык. Кәрә-керешкә өч-дүрт гранат томырдык, автоматларны чалгы урынына гына селтибез, безнең пуля турамаган кыл да калмагандыр. Бәреп керсәк, җан әсәре калмаган, кайсы кайда өч немец чәчелеп ята, ә безгә җансыз тел кирәкмәс, итекләр генә пычранып бетте. Сөртим дип бер чүпрәк эләктергән идем, тышта атыш китте, чәчрәп чыктык та караңгылыкка чумдык, ә караңгыда без — чәйдә эрегән шикәр белән бер... Теге чүпрәкне ташлап калдырмаганмын, парин. Итектәге немец канын бик сөртәсе килгән иде шул, кан күреп күнегелсә дә җирәндерә. Кайткач карасам, чыклы үлән итекне гөлт иттергән, куенга кыстырган чүпрәк тә кулга затлы нәрсә күк тоелды. Үзебез йокыга түндек, Шамякин аягын юарга чыгып китте... Разведкадан кайткач, аягын юа бу... Мә, мәйтәм, һәркайсыбызга бер әр чолгау чыксын дим, теге чүпрәкне почмакка томырдым да бөгәрләнеп яттым...

Бу урынга җиткәч, Мөкатдис эчеп куймый булдыра алмый иде инде.

Аның теге чакны геройны ычкындыруының бөтен хикмәте шушында ята иде.

— Иртән уянып китсәм, чолгау да юк, Шамякинның да тыны ишетелми. Тыштан да эзләп карадык — юк. Эчләр «жу» итеп китте, парин! Чишмәгә төшкән жиреннән немец чәлгән дибез инде. Тегеннән-моннан сорашабыз, берәү әйтте: таң алдыннан сак астында батальон штабына алып киткәннәр моны. Эчләр тагын — «жу» — кичә разведка алдыннан бер консерва ялмап куйган иде бу. Барып чыккан, мәйтәбез, кухнядан суккан. Шуннан югалды бу. Командирлар да аны-моны белгертми. Сорарга дисәң, шикләндерә... Кичкә кайтып төште бу! Пилотка кыңгыр моның, авыз ерык, бер көтү офицер иярткән. Үзгәреп киткән кебек. Баксаң, парин, күкрәгендә Алтын Йолдыз! Моны Герой итеп кайтарганнар! Акыл ышанмый, күз күрә! Безне моның каршысына тезеп бастырдылар да, берәм-берәм кулыбызны кысып, «Кызыл йолдыз» тагып чыктылар. Теге чүпрәк хикмәтле икән. Немецның дивизия штандарты булып чыккан ул, каһәр!.. Миңа, жүләргә, аяк сөртеп кенә ташлыйсы калган... Исеме генә дә ни диген бит — штандарт. Дөнья булгач, шундый-шундый штаннар да була икән ул.

— А Шамякин? — дип сорады Аит.

— Кем белә инде аны? Озакламый яраландым, аерылыштык...

Мөкатдиснең бөтен сөйләгәне бер ягы белән кызыклы иде: Аит студент чагында ук Шамякин дигән геройның дөньяда юклыгын сорашып белде. «Теге чакны геройны ычкындырган» Мөкатдиснең хикәясе авылга бик кирәк булганын белгәнгә күрә генә бу серен ачарга базмады. Кайчагында тормышта начар дөреслеккә караганда яхшы ялганнар да кирәк бит. Мөкатдис елга бер-ике мәртәбә «Кызыл йолдыз» орденын тагып чыга — тагын ни кирәк? Нидер булган ләбаса, нидер булган!

— Бу нәрсәң бушагач, шешәсенә керермен әле, — Аит, — диде ул ухылдап урыныннан торгач. — Кырачин тотарга ыңгай.

— Көнбагыш маендыр, Мөкатдис абый.

— Анысына минем шәбрәге бар, парин! — диде ул. Анда да сынатмый кала белә иде.

Мөкатдис: «Бозауга су эчертәсе бар», — дип чыгып китте. Ул рәхмәт әйтүне кирәк санамый иде: әллә анлык кына сөйләмиме? Кайвакытны ул «Тагын керермен әле», дип чыгып китә. Ә беркайчан да үзе чакырмый иде.

Аның тагын бер темасы бар. Жае киләме, юкмы, «Синең атаң яхшы кеше иде, мәрхүм», дип башлый да, «Минем балаларым игелекле», дип тәмамлый. Теләсәң ничек аңла! «Синең атаң яхшы кеше, ә мин андый ук булмасам да, минем балаларым сезнең ише игелексезләр түгел», — шулай дип әйтүеме? Ничек аңлыйсың. Ул кешене үпкәләтүдән курыкмый, үзенең уен эчендә саклап тотмый торган кеше — бары тик шул гына. Аның артыннан Аит: «Үзеңнән башка сине беркем дә хөкем итә алмый», — дип уйлап калды.

Аит хәзер генә аннан бик мөһим бер нәрсәне сорашасы килгәнлеген төшенде. «Солтаниянең хәлен сорашасы калган, — дип уйлады ул. — Өлгерермен әле. Хәзер минем вакытым күп инде, өлгерермен...»

## Жиденче бүлек

Аит яңгыр чылатырдай нәрсәләрен болдырдан ташып бетерде. Әкрен генә итеп, радиоалгыч сөйләп тора иде.

Хәзер инде төн, уты янып торган һәм ишеге ачык болдырда ул иске китап-журналлар, дәфтәр-кәгазьләр актарып утыра. Пончып бетте инде, тик моның үз тәме бар иде. Бер ишесен пөхтәләп өеп бара, күбесен

ишегалдындагы байтак җыелган өемгә атып бара. Болдырга, болдырдан — өйалдына, ә аннан өйгә чебен-черки, күбәләкләр кереп тулды — һәр җир ачык иде: Аитның күптән инде кеше тормаган өйнең үзенә генә хас ят, коры тузан һәм тычкан исләрен җилгәреп бетерәсе килә. Кичәле-бүгенле ул моңа ияләшеп бетте инде. Япа-ялгыз гына тормый ич, кергән-чыккан кеше борынына әллә каян бәреп торачак.

Кәгазьләр арасыннан яньчелеп, яссы хәлгә килгән конфет кабы кулына эләкте. «Берәребез әнигә алып кайткан булган, күрәсең». Шундук өемгә ташларга уйлаган иде дә, нинди конфет салынган булганын беләсе килеп, әйләндереп карады. «Ни җитте кап түгел бу». Конфет кабының тапланып беткән аскы ягына җыр юллары төшкән иде. «Ак иделгә басма салдым, басып су алганым җук, сезнең яктан кошлар сайрый җыламый калганым җук. Ага сулар ага сулар ага сулар ник болай, аккан сулар кире кайтмый яш гумерләр дә шолай. Ак иделдә юа алмадым ак кына беләгемне хәсрәт урап алган яштән үк җөрәгемне. Ак идел сулары кебек тар сулар булмас инде минем җөрәккәем кебек ярсулар булмас инде».

Аит бу язуны нәкъ шушының ише мең язу арасыннан да танып алыр иде. Кулыннан гына түгел. Сүзләреннән. Моңы белән хәсрәтеннән. «Агыйделгә басма салдым — сезне дөньяга китердем», «басып су алганым юк — рәхәтегезне күрә алмадым»,— дип укыды Аит. «Сезнең яктан хәбәрләр килә еламый калганым җук»... Нинди хәбәрләр? «Әни кайгыга караганда шатлыктан күбрәк елый иде»,— дип исенә төшерде Аит. Шулай микән, шулай микән соң? Әй, шулай булсачы, шулай булсачы соң! Юк бит, юк. Юк ләбаса! «Безнең әниләр дөньяга транзит пассажирлары булып кына килгәннәр шул».

Ул конфет кабын үзенә аеры алып куйды.

Күк йөзен тутырып, аҗаган күбәләкләре канат кагына башлады. Үткән сугышның бу йортка орынып үткән кайтавазы шикелле тоныкына булып, Кама ягыннан күк күкрәгәне ишетелә иде. Ачык ишектән бөтерелә-бөтерелә күбәләкләр керә һәм утка елыша. Аларның берсе — иң зурысы һәм зәңгәр күлмәклесе болдыр баскычына кунгандай булды — Сөмбел.

— Аҗаган уйный... Бөркү — яңгыр явар ахры,— диде Сөмбел әкрен генә.

Аит радиоалгыч боргычына үрелде. Аңа бу мизгелдә ят, ә гаять таныш аһәңле тавыш шуннан киләдер кебек тоелды. Аннары баскыч төбендә утырган Сөмбелгә күзе төште.

— Кеше бар дип торам, син икәнсең,— диде ул.

— Мин кеше түгелмени?

— Безнең авылда шулай сөйләшәләр,— дип аңлатты Аит.— Чит кеше — кеше түгел ул, ә кунак.

Сөмбел рәхәтләнеп көнбагыш яра иде.

— Театрыгыз бүген дә китмәдемени әле?

— Башкаларыбыз китте.

— Ә син?

— Калдым әле.

— Спектаклегез?

— Бүген Ишанның хатыны бергә ким булыр. Аңа көн саен биш хатын димәгән. Минә синең берәү дә юк. Гаделлек кайда?— дип көлде Сөмбел.

Алар тагын кичәгечә уен-көлкедән, бер-берсен аңлап шаярудан башладылар.

— Миңа кияүгә чыгарга дип калмагансыңдыр ич?

— Көтмәдеңмени?.. Җуләрме мин?— диде Сөмбел бераз тын торгач.

— Түгел.

— Нинди?
— Акыллы. Мин көттем сине.
— Тагын бер килеп чыгасымны белдеңме соң?
— Белдем.
— Кайдан?
— Безнең кичәге сөйләшүебезнең дәвамы булырга тиеш иде?
— Кичә син үпкәләдеңме? — диде Сөмбел, караңгылыкка борылып.
— Юк. Кыйммәт түләп алган нәрсә кадерле була ул... Шундый бәягә торган үбү беләсеңме нинди татлы булды?
Сөмбел, дога кылгандагыча кушырып, кулларын йөзенә куйды да:
— Китеп барган булсам, артымнан эзли чыгар идеңме соң? — дип сорады.
Ишектән җиргә төшкән сары яктылык рамында ул борынгы рәсем кебек күренә иде. Баскыч төбенә һәм бакча капкасына таба сузылган ташлар ул картинаның күп вакыт үтүдән яргаланган буявын хәтерләтәләр һәм бу күренешнең картинага охшавын тагын да арттыра төшәләр иде.
Аит беравык уйланып торды, аның үзен ихлас тоткан хатынга дөресен генә әйтергә хакы бар. Аннан соң сөйләшүнең көтелмәгәнчә башланып китүенә, шуңа өстәп, көтелмәгәнчә борылыш алуына ялган җавап ябышмый, туфли табаныннан килеп чыккан кадак очы кебек, шундук фаш булыр иде.
— Юк.
Сөмбел кисәк аңа борылып карады. Аның ирене үпкәләгән балаларныкы шикелле бүлтәеп тора, менә-менә елап җибәрер сыман иде.
— Ник? — дип сорады ул.
— Сине эзләп китсәм, син миңа ияреп кайтмас идең.
— Парадокс. Үз аягым белән килгәнне, бераү үтенеп, я ялынып килсә, ничек кайтмас идем икән?
— Хатын-кыз ялынганны яратмый. Алар үзләренең тәэсиренә буйсынырга теләмәгән ирләрне артыграк күрә. Чөнки сораганны, бигрәк тә ялынганны кире кагу тоз булып аларның канына сеңгән.
— Үзең дә ышанмаганны сөйлисең. Яки үзең шулай теләгәнне. Әллә... — Сөмбелнең борын яфраклары дерелдәп куйды, үзен-үзе тынычландырырга теләгәндәй, ул учларын кулбашларына куйды да каты итеп кысты ахрысы, киерелгән бармакларының ак эзләре бетми торды, беткәч, тимгел-тимгел кызарып чыкты. — Әллә, — дип дәвам итте ул өзелеп калган сүзен, — мине монда кичәге «юлыңа ак җәймә» диюеңә каршы әйләнеп килде дип уйлыйсыңмы?
— Мин әйтеп бетермәдем, — диде Аит. — Сезнең халыкның, ягъни хатын-кызның, беренче максаты — үзенә игътибар итмәгән ирне яратудан элек, үзенә буйсындырудан гыйбарәт. — Аит аны тыңлаттырып тынычландырыр өчен юри озаклап сөйләргә чамалаган иде дә, буталып калудан курыкты, ә һәр буталу, иң элек, ялганлауга якын. Шуңа күрә, сүзе бетүен белдереп, тамагын кырып куйды.
— Тик шунысы бар: безнең үзебез яраткан кешене генә буйсындырасыбыз килә шул, — диде Сөмбел.
— Ирләр моны тиешенчә бәяли белә дип уйлыйсыңмы?
— Бер нәрсә сөйлим, тыңлыйсыңмы? — диде Сөмбел.
— Кинәнеп тыңлыйм, — диде Аит. Ул Сөмбелнең иңенә көрән курткасын китереп япты, алдына термостан салып чәй куйды. Болдырга кереп утырырга кыстамады. Ләкин Сөмбел идәндәге чынаякны алды да, аны учларына кысып, баскычка менеп, иске патефонга утырды.
— Бер табышмак әйтәм. Җавабын мин теләгәнчә дөрес бирсәң, мин синең яратам дигәнеңә ышанырмын.
Аит аптырап китте: нинди «ярату»? Аның моңа бернинди сәбәп бир-

гәне юк ләбаса. «Шаярта»,— дип уйлады ул. Һәм Сөмбелнең шаяртуын аңлаган һәм кабул иткән атлы кыланып:

— Нинди җавап бирим соң: син теләгәннеме, әллә үзем дөрес дип тапканнымы?— диде.

— Минем өчен үзем теләгәне дөрес,— диде Сөмбел.— Тыңла, Аит.

Бөтен күк йөзен аҗаган яктыртып алды. Аның зәңгәрсу балкышы Сөмбелнең йөзен күлмәге белән бер төскә мангандай итте. Өй артындагы тупыл башларыннан җил шаулап узды. Беренче сыек болытлар йолдызларны хәрәкәткә китерде, алар, текә елга ярындагы ояларына кереп китүче кәрәшәләр кебек, берәм-берәм караңгы болыт кыясына чумып уйный башладылар.

— Яңгыр килә,— диде Аит.

— Тыңла әле, Аит... Бер Роза чәчәге Океанга гашыйк булган да, ди, аңа кадәр барып җитеп, бөтенләйгә аныкы буласы килгән, ди.

— Ах, мут чәчәк!.. Син уңайсыз утырасың, Сөмбел. Күч монда.— Аит толып җәелгән иске диванда утыра иде, читкәрәк шуышып, урын күрсәтте.

— Бүлдермә... Роза чәчәге бер елгага төшкән дә юлга чыккан. Бара торгач, бер чоңгылга килеп җиткән бу. Әйләнеп йөри дә йөри икән, тик юлын дәвам итә алмый интегә икән. «Чоңгыл, кадерлем, мине чыгарып җибәр әле»,— дип үтенгән бу. «Бер таҗыңны бирсәң, чыгарам»,— дигән чоңгыл. «Юк!»— дип кире каккан Роза чәчәге, чоңгылга таҗын бирмәгән. Ничек итсә иткән, әйләнә торгач, бер җаен туры китергән дә чоңгыл кочагыннан исән-имин ычкына алган... Ага икән, ага икән — елгага аркылы ауган бер агачка килеп төртелгән. «Агач, кадерлем, мине тизрәк үзең аша чыгарып җибәр әле, мин инде болай да тоткарландым, шиңә башладым»,— дип ялварган Роза чәчәге. «Бер таҗыңны бирсәң, чыгарам»,— дигән агач. «Юк!»—дигән Роза чәчәге һәм су кимегәч кенә агач астыннан чыгып китә алган. Шулай итеп, ул, ниһаять, Океанга барып җиткән. «Мин килеп җиттем»,— дигән ул аңа. Һәм үзенең гыйшкын сөйләп биргән. «Күрәм,— дигән Океан,— тик син миңа кирәкмисең».— «Нигә?— дип сораган Роза.— Мин сиңа бер таҗымны да югалтмыйча, саф килеш килеп җиттем».— «Саф. Ләкин син шиңгәнсең инде»,— дигән Океан һәм Розаны үзенә алмаган, дулкыннары белән яр читенә кагып чыгарган да ташлаган.

— Бичара Роза чәчәге!— диде Аит.

— Мәхәббәтен саклап шиңгән Роза чәчәге бичара була микән?.. Ә Океан? Дөрес иткәнме ул?

— Океан яшь, дәртле, көчле булгандыр. Ә Роза чәчәге шиңгән ләбаса!

— Ярый. Синеңчә шулай булсын. Тик әле мин җавап сорамыйм, ашыкма. Мин дәвам итәм әле... Икенче бер Роза чәчәгенең дә Океанныкы буласы килгән. Елга буйлап аккан да киткән. Ә елгаларның күбесе океаннарга кадәр җитә... Тик бусы чоңгылга да, агачларга да таҗларын кызганмаган... Аның каравы Океанга шиңгәнче үк барып җиткән. Һәм Океан аны үзенә алырга риза булган, ди... Син ул Роза чәчәкләренең кайсысын/сайлар идең икән, Аит? Я менә хәзер җавап бир инде.

Ул сөйли башлауга, Роза чәчәкләренең берсе Сөмбелнең үзе булып чыгарга тиешлеген Аит искәреп куйган иде инде. Моны аның икенче Роза хакында сөйләгәндә матур сүзләр эзләп тормавы, йөз хәрәкәтләренең хиссезлеге, ишарәләренең саранлыгы ук әйтеп торды бугай. Икенче Роза — һичшиксез, ул үзе иде, чөнки нәкъ шул салкын һәм битараф сөйләве белән ул Аитның игътибарын җәлеп итәргә теләде дә. Икенче Роза турында сөйләгәндә аның үз эчендәге ниндидер бер исталектән арынасы килгәнлеге сизелеп тора иде. Шуңа күрә ул Сөмбелнең «Роза чәчәкләре арасыннан кайсын сайлар идең?» дигән соравына

— Икенчесен,— диде.
— Нигә анысын?
— Син аларның икенчесе бит. Һәм син минем үзеңне сайлавымны телисең.
Сөмбел аның иң җиңел юлны сайлап алуына гаҗәпләнмәде.
Сөмбел урыныннан торды да бөрешеп утырган Аитка таба китте. Менә ул аның янәшәсендә, кулын сузып, бармак битләре белән генә аның чәченә кагылып ала һәм, аның учы белән сихерләнгәндәй, Аит диваннан күтәрелә башлый. Аларның йөзләре бер-берсенә якынайган саен, Сөмбел Аиттан ераклашканнан-ераклаша бара кебек. Нәкъ теге чактагы сыман!

## Сигезенче бүлек

— Иисус воскрес!
— Воистину воскрес!
— Иисус воскрес!
— Воистину воскрес...
— Иисус воскрес...
— Воист...
Чиркәү эче көндезге кебек яп-якты, электр лампочкалары яна, нечкә шәм очларында хәнҗәр очлары булып утлар калтырана, яшь кенә поп үз алдында селкеп торган чылбырлы савыттан борынны кытыкларлык тәмле ис тарала.
Бөркет томшыгына охшаган кәкре борынлы, йөзе нәрсәгәдер гаҗәпләнгән баланы хәтерләткән яшь поп үзенең биек һәм иркен мәйданында халыкка әле аркан, әле кырын, әле әйләнгәләп йөренә, ул да булмый, бераз вакытка югала да берсеннән-берсе затлырак тоелган япанчаларын алыштырып тора, шуңа күрә модельләр йортындагы халыкка сезон модаларын күрсәтүчеләрне искә төшерә. Халык инә дә төшмәслек күп, шуңа карамастан, кешеләрнең йөзләре аермачык күренеп тора.
Ә алар өчәү иде: Сөмбел, Аит, Солтания. Бирегә аларны Аит алып керде.
Ул елны Сөмбел, яңа гына өйләнешкән апасы белән җизнәсенә ияреп, беренче мәртәбә авылга кунакка кайткан иде. Солтания белән Аит авылларыннан унбиш чакрымдагы урта мәктәптә укыйлар, тулай торакта торалар, дуслашып алгач, Солтания Сөмбелне үзе белән мәктәбенә алып китте, ә ялга үз авылларына кайтышлый Аит аларны юл өстендә утырган рус авылының чиркәвенә алып керде.
Юл өзек, кич кырын гына чыгып киткәннәр иде, соңардылар. Биредән аларның үз авылларына хәтле нибарысы ике чакрым гына, шунлыктан курыкмадылар, инде төн уртасы якынлашуга карамастан, гомерләрендә дә күрелмәгән тамашага исләре китеп торганда, әллә ничек кенә бирелеп китеп, халыкка иярделәр.
Солтания Сөмбелнең колагына:
— Белгән догаларыңны укы, безгә чиркәүгә керү гөнаһ,— дип пышылдады.
Сөмбел үзенең пырхылдап көлеп җибәрүен сизми дә калды.
— Ник? — диде ул.— Мин бернинди дога да белмим! Мине беркем...— һәм ярты сүзендә киселеп калды: янында торган яланбаш, бөтен кыяфәте — җыерчыкланып торган нечкә генә озын муены, кагылсаң, һәркайсы чыңлап җибәрердәй тоелган күперенке чәче белән тузганакны хәтерләткән бер картның керфексез, зәп-зәңгәр күзләреннән очкыннар чәчрәде кебек. Сөмбел аннан күзен ала алмыйча, үзе белән янәшә торган Аитка елышты, кулын түбән шудырып, бар көче белән аның кулына чытырдап ябышты.

Карт читкә борылды. Сөмбел аның тирән бер нәфрәт белән карап куйган күзләреннән котылгач та әле Аитның кулын үз учларыннан ычкындырырга кыймый торды: шул тикле курыккан иде, күрәсең! Ә анары... йөзләгән халык арасында Аитның тирләгән кулын яшертен генә тоткан килеш басып торуы әллә ничек рәхәт, кызык, романтикалы иде! Аит... Аит чибәр иде! Хәер, эш аның чибәрлегендә генә дә түгел иде ахрысы. Ул беренче тапкыр үз йөрәгенең шәм сыман эреп, бөтен тәнена таралып бетүен тойды. Тойды гынамы соң? Күрде!

Аңа тагын кемдер карап тора иде. Шул карашны маңгае белән тойды диярсең. Очлы иде ул караш, үчле иде! Баягы тузганак бабай дип белеп, ул астыртын гына аңа карап куйды, тик бабай авызын көнбагыш яргандагы шикелле тиз-тиз кыймылдатып, барысыннан да алдан һәм катырак итеп:

— Воистину воскрес!— дип кычкыра иде.

Шунда ул Солтаниянең:

— Син белгән догаларыңны укы, чиркәүгә керү гөнаһыңны юарлык булмаса да, кеше егетен тартып алмакчы булуыңны...— Солтания астан гына аның кулыннан тотты да дүрт бармагы белән берьюлы тырнап җибәрде. «Сөмбел «аһ!» итеп куйды. Ә Солтаниянең күзе... Янып тора иде! Тузганак башлы картның зәңгәр күзләре инде генә идеме соң! Мәхәббәткә кагылышлы нәфрәт бар нәрсәдән аяусызрак икән.

Ә Сөмбел Аитның кулын аның саен катырак кысты. Солтаниягә үч итеп.

Бер заманны, әллә инде шунда эчтә үк, әллә инде тышка, саф һавага чыккач, кешеләр берсенә-берсе:

— Христос воскрес!

— Воистину воскрес...— дип, үбешергә тотындылар. Күрше — күршесе белән, танышлар — дус-ишләре белән, һәм, билгеле инде, туганнар — туганнары беләндер.

Көтмәгән-нитмәгәндә Сөмбел Аитны үбеп алды. Аит — иренен корт чакканмыни!— кул сырты белән сөртеп ташлады. Солтания караңгылыкка кереп югалды, Аит, «Җүләр» дип, Сөмбелнең кулыннан эләктереп алды да өстерәп диярлек аның артыннан йөгерде. Авылга кадәр шулай җитәкләшеп кайттылар, чөнки Сөмбел дөм-караңгыда бөтенләй бара алмый иде.

Икенче көнне Солтания аның белән сөйләшмәде. Ә клубтан кайтканда Сөмбел аларны бергә күрде. Ажаган уйный иде, су астындагыча, яшькелт нурга күмелгән якта рәшәткә буендагы бүрәнәдә Аит белән Солтания утыра. Аит нидер сөйли, Солтания чың-чың итеп көлеп куя. Сөмбел, аркасы белән рәшәткәгә сөялеп, шул бәхетле көлүне тыңлады, күз яшенең иң тозлысын беренче мәртәбә ул шунда татыды. Көнләде ул әлеге көлүдән! Бөтен гомеренә җитәрлек итеп көнләде. Әйе, кичә Аит аерылдык дигәч, ул көнләү тагын уянып, аның йөзенә елмаю булып таралды да бөтенләйгә, инде мәңгегә сүнде — аерылганнар!

Ә бүген инде, нигәдер, Сөмбелнең елыйсы килә. Әгәр язмыш аны Аит белән кабат очраштырган икән, кемнедер көнләштерерлек матур язмыш түгел инде бу! Әнә ич, танымады да! Ул аның янына мәхәббәтенә ашыккан, тик инде күп нәрсәсен югалткан икенче Роза чәчәге булып әйләнеп кайтты. Бәлки бу язмыштыр? Язмыштан узмыш юк, диләр. Бәлки узмаскадыр? Калыргадыр? Бәлки ул Аитка кирәктер? Ни уйлап кабат килде соң әле Сөмбел бирегә? Икенче Роза чәчәгенең язмышы бүтәнчә тәгалләнә ләбаса. Әгәр аныкы да — Сөмбелнеке дә шулай бетсә?

— Икенче Роза чәчәге белән Океанның мәхәббәте ни белән беткәнен беләсең киләме?— диде ул.

— Күзалларга була,— диде Аит һәм аның биленнән кочып алды.

— Юк шул, болай түгел,— дип көлде Сөмбел һәм аннан этелеп:— Хәер, соңыннан... Соңыннан әйтермен.
— Кайчан — соңыннан?
— Белмим. Аннары.
— Табышмак,— диде Аит.— Инде минекен дә тыңлап кара.
Ул диван пружиналарын шыгырдатып торды да стена буенча өч өемгә тезеп куйган китап-дәфтәрләр янәшәсендә үзенә аерым торган яшел тышлы калын бер китапны кулына алды.
— Миң дә бер кичәме әллә ул?
— Коръән.
Аит Коръән тышлыгын ачты да сырын сырга туры китереп, өчпочмаклап бөкләнгән ике кәгазь алды.— Көндез мин бу Коръәннән этинең фронттан язган ике хатын табып алдым. Табып дим... Ихтимал алар үзләре мине тапкандыр.
— Бөти шикелләләр,— диде Сөмбел.— Укыганым бар, элек балаларга шундый өчпочмаклы бөтиләр такканнар.
— Әйе, Сөмбел. Болар — картайгач та бөти итәрлек хатлар. Тыңлыйсыңмы, укыйм.

## Тугызынчы бүлек

— Фронт хатларында ни язылганын күзаллавы читен түгел,— диде Сөмбел.— Сагынудыр инде... Сугыштыр... «Жди меня, и я вернусь, только очень жди»... Шушының бер төредер.
— Алай булса да начар түгелдер. Тик болар икенчерәк. Көчлерәк.
— Шигырьдән дә көчлерәкме?
— Чын тормыш шигырьдән көчлерәк.— Сак кына бер хатны ачып, Аит үзенә укыган кебек тын гына: — «Сезгә сагынып,— дип башлады. Баскычка утырды. Чиксез караңгылыкка карап, дога әйткәндәй:— «Якыным Гайшә!»— дип пышылдады.
Сөмбел сигарет кабызды. Каршысындагы күренеш илаһи иде. Аны нинди дә булса рәссам ясады микән? Кайчан да булса ясар микән? Ачык ишек караңгылыгында үткән сугыш эченнән телгә килгән хат иясе үзе утыра мәллә? Кем ясаган һәм кем ясаячак мәшһүр картина соң бу? «Карагыз!» дигән төсле, ажаган кабынып ала, һәм кулына хат тотып утырган Аитның күләгәсе караңгы күк гөмбәзенә йогып кала кебек. Помпей һәм Хиросима кешеләренең стеналарга, урам ташларына, күпер такталарына төшеп калган җансыз күләгәләре сыман, ишегалды ташларына да Аитның тере күләгәсе сузылган. Аит, хатлы кулларын сузарак биреп, утка кырынрак утырган, аның ишегалдына төшкән шәүләсе тезләнеп күктән нидер ялварган төсле булып күренә. Тавышы гел бер көе, битараф, хиссез. Ә хаттагы сүзләрнең тәэсире аның саен көчлерәк, чыннан да, ниндидер ялварулы догага тартым, борынгы язулардагыча тыныч, мәңгелек иде. Әнә ич: «хатыным» димәгән, «якыным» дигән. «Яратам» яки «мәхәббәт» дигән сүзләр хәзер генә китте ул. Шуның белән бөтен телебез тулган, китаплар. Матур сүзләр. Тик таптап, шомарып беткән, көчсез, телсез, мәгънәләрен җуйган сүзләр. Ә тормышта әнә ничек булган: гадирәк, нәфисрәк, ялкынлырак!.. Ахыр килеп, тыйнаграк — «якыным»... Монда ни генә юк: хатыным, иң якын кешем дию дә бар бу сүздә... Шушы ук сүздә тагын ялкыным, якынлык та бар... Хат әллә барып җитә, әллә юк... Ара чиксез ерак... Юл ераклыгы, вакыт ераклыгы... Ләкин хис, тою якын... Сагыну көчле, сагыш зур, наз бөек — «якыным!»... «Яратам» дигән сүзләрне хәзер ничек җиңел әйтәбез! «Син миңа ошыйсың», «Мин сине якын күрәм» диюләр тәмам онытылды, төссезләнде, уңды, тәме китте... Шушыннан соң гына ләбаса әле ул сөю, мәхәббәт, ә иң соңгысы — ярату!..

«Якыным Гайшә! Сиңа, матурым Әлфиягә вә иң матурым Наиләгә, шулай ук мин киткәч туган кечкенә бәбигә, кыскасы, барыгызга да сәлам...»

— Кечкенә бәби дигәне — мин булганмын,— диде Аит бүленеп һәм дәвам итте:

«Туганнардан — якын туганым Гайшә апаларның һәрберсенә, Солтан авылы туганнарымның һәрберсенә, Хафиз абыйларның һәрберсенә, калган башка туганнарның һәрберсенә миннән сәлам тапшыр. Күршеләрдән Бәдигол апаларның һәрберсенә, Хәйрулла абыйларның һәрберсенә, шулай ук язылмый калганнарның да һәрберсенә сәлам. Кыскасы, мине сораганнарның һәрберсенә миннән сәлам әйтерсең! Ярый... Якыным Гайшә! Нихәл суң? Үзеңнең саулыгың бармы? Бәгырьләрем, Әлфия, Наилә һәм кечкенә бәби саулармы? Мине, ягъни әтиләрен искә алалармы? Башка хәвеф-хәтәр юкмы? Адашың Гайшә апалар ни хәлдә суң? Үзе һәм балалар саумы суң? Бигрәк тә якын җизнәмнең хәбәре бармы? Ул бәгърем дөньяда бу көндә тере микән, юк микән? Бәдретдин абый үзе һәм Билал абый өйдәләрме? Минем уйлавым буенча, өйдә түгелләр булырга кирәк. Хәерле булсын... Ярый, Хафиз абыйлары һәм Бәдигол апалары ни хәлдә торалар? Минем уйлавым буенча, алар искечә торалар булса кирәк. Ярый... Якыным, Гайшә, нихәл? Суң, ризык мәсьәләсендә аптырамыйсызмы? Ә инде минем уйлавым буенча, аптырый торган булырга кирәк. Беләмен, бәгырьләрем, көн уздыруларыгыз ансат түгелдер. Ә инде ягу өчен утын мәсьәләгез, анысы, минемчә, юк инде. Нишлик суң, бер без генә түгел. Беләсең, хәтереңдәдер: безнең тормышның шөкер, бик рәхәт вакытлары бар иде. Беләсең, безнең бар нәрсә җитеш иде. Ул бергә-бергә балалар белән уйнашып, рәхәт гомер иткән вакытлар минем бер дә исләремнән чыкмыйлар. Ә инде минем белән бергә гомер иткән вакытларың, минемчә, синең дә исләреңнән чыкмый торгандыр булырга кирәк. Ярый, нишлик суң, бәгырьләрем, бер без генә түгел, сабыр итик. Ул рәхәт гомерләр, исән булсак, тагын да булырлар әле. Ерткыч, тыныч халыкны тынычсыз иткән һәм халык талаучы дуңгыз борын Германия фашизмын штыкка күтәреп, калганнарын туган илебездән куып чыгарып, ул кабәхәт ерткычлардан чистартканнан суң, исән булсак, сезнең янга кайтып, янадан рәхәт һәм шатлыклы гомер итәрбез... Ярый, якыным Гайшә! Нигә суң сез миңа хат язмыйсыз икән? Менә мин 6 нче аемны хәрби госпитальдә ятам. Сезгә ничә мәртәбәләр хат яздырып салдым. Ә сездән бер хат та алганым юк. Менә шул мәсьәлә минем өчен бик күңелсез. Әллә бер-бер төрле хәл булдымы икән дип борчылам. Әллә мин язган хатларны сез ала алмыйсыз микән? Мин сугыш кырыннан ранный булып чыктым, 29 нчы сентябрь көнне кич белән. Бу көн, 3 нче март көне, минем ранный булганыма 156 көн, ягъни 5 ай да 6 көн, 6 нчы аем дигән сүз...»

Сөмбел «яратам» дигән сүзнең хатта бөтенләй булмавына игътибар итте. Ләкин андагы һәр сүздә шул мәгънә балкып, зиһеннең бар җирен тутырып, мәк чәчәге кебек ялкынланып сизелеп тора иде. Табигатьтәгечә, нәфис һәм серле итеп, чәчтән сыйпаган шикелле юатып һәм упкындагы сыман назлап язылган. Монда — икәүнең бөтен дөнья күз алдында җәйрәп яткан газиз, илаһи бер бәхетле тормышы. Монда — мәхәббәтнең чиста дәръясы. Өстә генә йөзеп йөргән буш сүзләр юк, хистирән, сагыну тыелгысыз, киләчәккә өмет ышанычлы, нык... Әчкерсезлек, гадилек... Исбатлаулар кирәкми, аерылышуга зарланып шыңшучит, төшенкелек ят нәрсә монда!..

— Чагыштырып утырам да... Без яшәмибез, ә бәлки йоклыйбыз гына икән,— диде Сөмбел. Аит тынып калгач. Ул аны хисләнеп туктады дип уйлаган иде, уйларын таратам дип эндәште:— Укы, укы

— Бетте. Бу хатның ахыры сакланмаган.

— Ә кулындагысы?

— Анысы бөтәне.

— Әнкәңнең җавап хатымы?

— Юк. Мин укыган хатны алганчы, юлга әни хаты чыгып киткән була. Бу — шуңа җавап...

Аит икенче хатны укый башлады.

«Әй, бәгырьләрем, әй... матурларым... Бервакытта да хәтеремнән чыкмый шул ук Әлфиям белән матурым Наиләнең кыланышлары. Матурым Наиләнең, конфет бирәм дигәч, минем ике битемне үбүләре һәм шуның өстенә әтием, конфет бирсәң, әлһәмдел өйрәтәм диюләре... Шулай ук матурым Әлфиянең матур көйләрне зурлар кебек матур итеп җырлаулары һәм аның идәндә матур итеп биюләре. Шулай ук икенче Аитем (гәрчә күрмәсәм дә), менә шулай бишектә утырадыр, менә шулай көләдер, менә шулай үрмәлидер, менә аны әнисе шулай биләгәндер, суңра кочагына алып, матурым, ичмаса әтиең өйдә юк диеп сөйгәнсең, шулай сөя торгансың дип, йокыга яткач һәр көн сәгать 2 гә, 3 кә кадәр йоклый алмый ятам. Матурларым белән мине юксынып сөйләүләрегез, син аны коендырганда синең тирәңдә матурларым Әлфия белән Наиләнең, и-и матур бәби, матур бәби дип йөрүләре, син аны коендырып биләгәч, алар аны әле берсе, әле икенчесе алып сөюләре. Суңра аны кочагыңа алып, әтиең өйдә булса, ул да сине безнең кебек сөяр иде диеп, синең аңарга күкрәк сөтеңне бирүләрең, шуннан соң сикертә-сикертә сөюләрең — менә шулар һәммәсе минем күз алдыма киләдер...»

## Унберенче бүлек

— Елыйсы килә!! Нинди ярату, я тәңре! Шекспир, билләһи газим Шекспир хисләре!.. Мин сәхнәдә шушы хатларны алып укыган бәхетле хатын ролендә уйнар идем.

— Сәхнәдә... Ә тормышта яшәр идеңме соң? Сәхнәдә мәхәббәт уйнамыйча, тормышта шул хатын булып яшәр идеңме, Сөмбел?

Аит хатларны Коръәнгә тыгып куйды. Ул хатлар хәзер өзелеп төшкән ике яфракны хәтерләтә иде инде. Истәлеккә дип, китап эченә тыгып куйган сары яфраклар.

Сөмбел моңсу гына елмаеп куйды.

— Мондый хатларны язу да, уку бәхетенә ирешү дә бүгенге ирләр һәм хатыннар кулыннан килә торган эш түгел шул инде. Заманасы әллә нинди: тутык хисләр, ә йөрәкләр, әйтерсең лә, сүнгән мичләр!..

Юк, Сөмбелгә кушылып, Аит заманны гаепләргә җыенмый иде. Сугыш, ачлык, мәрхүмлекләр вакытында шундый сөю булганны, бүген нинди булмаска тиеш ул? Ул кайдадыр үзе укыган: «Бу дөньяда нидер тиешенчә түгел икән, моңа бары тик кешеләр үзләре генә гаепле»,— дигән сүзләрне исенә төшерде. Ул үзе — Аит нишләде соң? Бер селтәнү белән хатынын ташлады да китте. Дөрес, моны ул үзе теләмәде, моны Солтания теләде. Ялварырдай булып теләде, мине азатлыкта калдыр, үзеңне миннән азат ит дип сорады.

Һәм Аит азатлыкка чыгып китте. Ул үзен дә, Солтанияне дә гаепләргә базмады. Әйтмәде түгел ич, әйтте, бергә яшик, берни булмагандай яшик, диде. Язмышка язмагач, бәхеткә килмәгәч, ни хәл итәсең соң?

— Әйт әле, Сөмбел: үзеңә атап шушындый хатларны язардай кешең булсын өчен ни бирер идең икән син бүген?

Сөмбел җавап бирмәде.

— Фәкыйрьләр без. Нинди фәкыйрьләр!— диде ул.— Ә синең үзеңнең шушындый хатлар язып җибәрерлек кемең бар соң, кемең бар?

Аит дәшмәде чөнки андый кешесе юк иде инде.

Караңгы төн уртасында яшенле яңгыр алар йокларга яткан карт өй турысына килеп җитте. Пружиналары уңайсыз төртеп торган иске диванда тузган толып ябынып яткан Аит уеннан берөзлексез Сөмбелнең соңгы сүзләрен кичереп ятты. Әйе, аның йөрәге көзен буш калган кош оясы кебек салкын иде.

Яңгыр шавына ниндидер кыштырдау авазы килеп кушылганын ишетеп, Аит сагая калды. Кайдадыр эре-эре тамчылар тамганы ишетелә. Йөрәк тибеше кебек сак кына итеп, кемнеңдер аяк атлавы сизелеп китте. Билгеле, Сөмбел. Аит аны өйдәге тимер караваткa яткырган иде. Ул башын күтәреп караганда болдыр ишеге ачылып китте һәм ул яшен яктысында ишек янагына сөялеп торучы Сөмбелне күреп алды. Ул өстенә ак җәймә бөркәнгән, яшен яктысында мәрмәр сыннымы, өрәкнеме, ниндидер кошнымы хәтерләтеп басып тора. Аит торып аңа якынлашканда, ул баскычтан түбән төшеп китте дә, кулын җәеп, торган саен кызурак итеп әйләнергә кереште.

— Сәхнәдә дә шушындый матурмы син?— диде Аит, тамашадан ни көләргә, ни сокланырга белмичә.— Хәер, син ишанның карт хатынын уйныйсың бит әле, кайда анда матур күренү...

— Ялгышасың...— Сөмбел туктап калды, йөзен яңгырга каршы куйды да ирененә тәгәрәп төшкән яңгыр тамчыларын тел очы белән ялап торды.— Ишан хәтле ишан буласы ир беренче хатынлыкка асыл затларның берсен сайлап никах укыткандыр. Сәхнәдә мин карт, ләкин гүзәл бер шайтанны уйныйм.

— Ә тормышта син гүзәл бер... фәрештәсең...

— Юк, Аит. Күрмисеңмени? Суга төшкән тавык мин. Гап-гади мескен тавык.

Караңгыда Сөмбел ачык күренми иде. Бары тик яшеннең калтыранган яктысында гына Аит аның ак җәймәсе чыланып, тәненә ябышып беткәнен шәйләп алды. Кулы салынып төшкән, чәченнән, җәймә очларыннан, күкрәк аермасыннан йөгерек тамчылар тама. Тәненең һәр сызыгы яшен уты белән каймаланып күренә. Яшен яктысы сүнеп, ишегалды караңгыда калганда, ул беравык Аитның күз алдында ялкыннан ясалгандай чагылып торды әле. Күзен йомып, кояшка карагандагы шикелле. Аннары аның шәүләсе томандагы әйбер төсле соры булып кына төсмерләнә, ераклаша, ләкин аннан бер өзлексез эсселек бәреп тора шикелле. Ул еракта җемелдәгән учак кебек, Аитны үзенә дәшә сыман иде.

— Миңа... ошый монда... — диде Сөмбел, каядыр өскә карап. Нәкъ кичә әйткәненчә. Кичә ул бу сүзләрне Аитны үзе белән сөйләштерергә теләп әйткән иде. Ә бүген, хәзер? Алар әз сөйләшмәделәр ич инде, бу халдә сөйләшү мәгънәсез булыр иде. Аит кичәгечә: «Ә миңа ошамый»,— дип бәхәсләшеп тормас ич инде? Һәм ул, һавадан аның чакыруын эзләгән шикелле, кулын сузып, бармакларын тырпайтты да, баскычның ике басмасын атлап, түбән төште.

Яңгырның салкын сулышы йөрәген куырып алды шикелле, бөтен тәнен инәдәй чирканчык бәсе чәнчеп узды.

— Синә... салкындыр ич,— диде ул.

— Ялгызлык суыгы хәтәррәк.

Алга сузылган кулының бармак битләре белән генә ул караңгылык томанында эрер-эремәс төсмерләнгән хатынның кулбашына орынды, аның салкыннан калтырануын тояр шикелле иде, тик юеш җәймә жылы иде.

Аитның тыны киселеп калды. Мондый тойгыны аның күптән инде

кичергәне юк иде. Беренче кат күзе төшкән, яраткан кызы Солтанияне озаткандагы хисенә, беренче кат Солтаниянең куенына кергән чактагы кичерешкә кире әйләнеп кайткан шикелле булды. Тик хәзерге мизгелдә аның каршында ул хис, ул тойгы, ул кичерешнең кайсысы басып торганына Аит һич кенә дә төшенә алмады. Күзең төшкән беренче кызны ни өчен озатканыңны, ни өчен үпкәнеңне, ахыр килеп, аңа ни өчен өйләнгәнеңне күңелеңнең һәм тәнеңнең беренче нинди боерыуына буйсынып эшлисең — кем белә икән соң? Кайсысы көчлерәк икән — хис, тойгы, кичерешләрме, әллә шул боерумы?

Ә хәзер кем көчлерәк — Сөмбелме, әллә улмы? Язгы су ургымы астыннан калкып чыккан боз шикелле булып, ул боерыкка Сөмбел буйсыныр микән? Әллә соң Аит әкренләп Сөмбел хисләренең боерыгына буйсындымы? Югыйсә, карышуы мәгънәсез булачак көч белән аны Сөмбелгә ни тартып тора соң?

Солтания, Солтания! Солтания...

Хәзер Сөмбел якынрак иде. Солтания хәзер алда торган ераклык түгел, артта калган ераклык. Артта калган ераклык — үткән вакыт. Ә Сөмбел йөрәкне эретердәй учак булып, ак кайнарлыгы белән бөтен ишегалдын тутырып басып тора. Юк, ул учак кына микән? Үзе басып торган ишегалды ташы белән болытлар арасында балкыган яшен. Теләсә, ул хәзер Аитны боз хәленә калдыра ала, теләсә — яндырырлык зат иде.

— Икенче Роза чәчәге белән Океан арасындагы мәхәббәт тарихының ахырын беләсең киләме синең, Аит?— дип пышылдады Сөмбел.

— Бәлки соңыннан... аннары?..— диде Аит.

— Ә хәзер нәрсә? Я, нәрсә? Нәрсә, Аит? Аит...

Сөмбел Аитка таба борылды. Шул мәлне яшен яшьнәде, чатнап һәм чытырдап күк күкрәде. Сөмбел, өреккән тай сыман сискәнеп, Аитның кочагына ауды. Учына кунган күбәләкне тотып алгандай гына итеп, Аит Сөмбелне кочаклады да күкрәгенә кысты.

— Шушылай җиңел очрашкач, ничек авыр аерылышыйк ди инде без, Аит? Җиңел акыллы Роза белән ахмак Океан очрашуы!

Аит үзенең иңбашына тамган яңгыр тамчылары арасында Сөмбелнең ике-өч бөртек кайнар күз яшен тоеп алды. Алар, кайнар ташкын булып, аның тәне буенча түбәнгә, аска тәгәрәштеләр.

— Аит, кадерлем... берәр төрле эчемлек алып чык әле, җаным...— дип, Сөмбел әллә елаудан, әллә туңудан калтыранды.

Аитка аны кочагыннан ычкындыру авыр иде. Ул, баштанаяк чыланып беткән Сөмбелне өстенә бөркәнгән ак җәймәсе белән бергә сыгарга теләгәндәй, аның кулбашыннан башлап бөтен гәүдәсен сыйпап төште һәм, аның бармак очларына җиткәч, тотыныр урын таба алмыйча, кулы белән караңгылыкны кыскалап торды. Ә Сөмбел, башын артка ташлап, суга сусаган кеше шикелле, ирен читләренә агып төшкән яңгыр тамчыларын тел очы белән ялап тора иде.

— Сөмбел... сусагансың.

— Әле син биредәмени? Минем синең берәр бәллүр фужерыңны ташка бәреп ватасым килә... Кызганмыйсыңдыр ич?

Аит аңа караган килеш кенә чигенә башлады, юеш баскычтан болдырга күтәрелде. Өйдәге әйберләрнең кайда икәнлеген кулы онытмаган, бизмәгән икән әле, болдыр ишегенең яңагыннан әз генә читкә кагылган иде, кулы үзеннән-үзе электр боргычына туры килде дә, ник икәнен абайлап тормастан, утны кабызып җибәрде. Сөмбелне яктылыктан читкә, караңгылыкка тайпылыр дип көткән иде, ә ул баскан урынында кала бирде. Бары тик әллә аннан ятсыныпмы, әллә үз-үзеннән оялыпмы, әллә соң туп-туры яуган яңгырдан туңа башлапмы, бөрешәрәк төште, әмма башын имәде, муенын сузып, йөзен югары тоткан килеш ирен читләрендәге яңгыр тамчыларын ялаштыргалап алды.

— Беләсеңме син кем?— дип эндәште Аит.
— Кем? Кем?
— Искәндәр ташы син.
— Александритмы? Бик матур түгелмен икән. Александрит — нурсыз таш.
— Көндез төссез, салкынча. Аның каравы төнге ут яктысында... кайнар шикелле.

Сөмбел авыз эченнән генә көлә калды. Ә Аит болдырдагы кәгазь әрҗәдән төссез вино сайлап алды да, ике фужер эләктереп, аның янына ашыкты. Баскычның беренче басмасына басар алдыннан шешәле кулы белән тагын электр боргычына таянды. Ишегалды тагын төн канаты астына сыенды. Яшен дә баштагы шикелле чатнамый инде, күк күкрәүләре, торган саен ераклаша барган ат тоякларының җирне тупырдатканы шикелле, тоныкланып калды. Яңгырның тигез шавына түбәләрдән тамган авыр тамчылар тавышы килеп кушылды. Күрше йорт ишегалдында каз каңгылдап куйды, Аитларның коймасы башында ике яшел-зәңгәр ут уйнаклап калды. Аны Сөмбел дә күреп алды.
— Ни ул?— дип сорады ул. Үзе үк көлеп җавап та бирде: — Мәче.

Аит шешәнең укасын ертып, авызын аска каратып тотты, төбенә учы белән китереп сукты. Мәче калын тавышы белән аваз салды да ашыкмыйча гына, сузылып, койма буенча китеп барды — чите ачыклана башлаган күк яктылыгында ул кара шәүлә булып кына күренә иде. Яшен яшьнәп җибәрде, һәм мәче зәңгәр нур белән каймаланып, ап-ак булып күренеп калды.
— Я!— диде Аит һәм Сөмбел тотып торган фужерларга, шаулатып, вино агызды да шешәсен ташка бастырып куйды.
— Я?— диде Сөмбел. Ул фужерны күзе турысына китереп, яшен чаткысы уйнаклавын эчемлек аркылы карап торды.
— Чиста... Хисләр дә шундый чиста булсын иде ул. Аит,— диде ул.— Хисләр... шушылай үтә күренмәле булса иде.
— Алайса, хисләр чисталыгы өчен, Сөмбел!— Аит ашыгып эчеп куйды. Аңа бу төн тиздән бетәчәк бер уен гынадыр кебек тоелып алды. Ул каядыр, нәрсәгәдер өлгермәс шикелле иде...

Ә Сөмбел ашыкмады. Ул үз фужерын ирененнән аермыйча гына, вак-вак йотымнар белән эчеп бетерде дә — чираттагы яшен яктысы чагылышыннанмы соң — күзен йомды, фужер тоткан кулын йөзенә якынайтып алгач, кискен селтәнеп җибәрде. Күк күкрәгән калын авазга челпәрәмә килгән бәллүр пыяланың нечкә чыңы килеп кушылды. Аның каядыр очып китәсе килеп китте. Күзен ачканда ул үзенең, чынлап да, Аит кочагында әйләнүен күреп алды. Бераздан ишегалды һәм аның тирәли үскән карт тупыл ябалдашлары, колгадагы ватык сыерчык оясы, абзарның салам түбәсендәге бастырыкларның тырпаешкан очлары әйләнүдән туктадылар да... барысы да артта калдылар. Ул бая үзе йоклап чыккан өйнең ят исен сизеп алды.

Аитның Сөмбелгә Искәндәр күле турында сөйлисе килә иде. Ләкин... Солтания ишетеп торыр кебек тоелды. Ул үз-үзенә: «Түбән карама!»— дип боерды. Түбән карама... Бу — тауларга менүчеләр законы. Хәзер исә ул Аит күңелендә «Үткәннәргә карама!» дип боеру булып калыкты. Үткәннәргә карама, анда — Солтания. Әмма алда Сөмбел булыр микән соң?

Алар икесе дә тышта яңгырның туктавын ишетеп ятты.

## Уникенче бүлек

Ә Җиргә әкрен генә яктылык иңгәнен аларның берсе дә күрми калды. Яңгырдан соңгы тыныч төннең серле авазлары аларны бик ерактан гына әйләнеп үтте.

Кояш мул иде.

Урам буенча язгы ташудай шаулап узган көтү дә аларның йокы ярларына кагылмыйча узып китте. Аннан соң авыл тагын тынычланып калды. Иртәнге мәшәкатьләрен бер кат үткәреп җибәргәч, кешеләр ашап-эчеп алыр өчен өйләрендә югалып тордылар.

Бакчаларда ара-тирә өлгергән алмалар коелыша иде. Тыңлап торсаң, аларның җиргә орынуларын беренче кат тәпи йөреп киткән балаларның аяк тавышына охшатып булыр шикелле.

Алдан Аит уянды. Озаклап түшәмнең куна тактасыдай тигез һәм киң такталарын карап ятты, матчага кыстырылган ниндидер кәгазьләрне күзеннән кичерә башлады. Страховой белешмәләре, төрле квитанцияләр.

Ул, аягын идәнгә төшереп, торып утырды. Сөмбел стенага таба борылып ята иде. «Мин аңа беркем дә түгел шул,— дип уйлады ул.— Югыйсә читкә карап ятмас иде. Иренә сыенмаган, таянмаган, ышыкланмаган хатын үзен-үзе чикли, читләштерә, кадерсезгә әйләнә, тупаслана...— Ул, уеннан бүленеп, усал итеп, мыскыллы көлеп куйды.— Ир!.. Хатын!.. Кайчаннан бирле? Аның хатынлы ир булудан туктавына ничә ай бит инде! Хәзер кем соң ул? Ир-ат, бары тик ир-ат кына! Дөньядагы бөтен хатыннарга ул бары тик ир-ат кына, беркемгә дә сыенырлык, таянырлык, терәк булырлык ир түгел икән ич инде...— Ул үзен әллә кызгана, әллә әрли иде, хәер, нишләсә дә, барыбер түгелмени? Ул беренче тапкыр үзе турында «мин» димичә, өченче заттан уйлавына сәерсенеп игътибар итте.

Ул Сөмбелнең өстенә җәймә ябып куйды. Сөмбел уянмады, кояш нуры төшеп җылыткан мендәрендә йоклап калды, ә Аит ишегалдына чыгып басты. Баскыч такталары җылынып беткән, ә ташлар кап-кайнар булган инде.

Аның кәефе төшеп китте. Солтаниянең шушы ташларга яланаяк баса-баса иртәләрен кер уып йөрүләре, көндезләрен ишегалдына киптерергә җәеп куелган печәннәрне ике япьле агач сәнәк белән әйләндерүләре, кичләрен аякларын тезләренә кадәр җылы туфракка буяп бетереп, яшелчәләргә су сибеп йөрүләре — кайда болар? Аяклары... Иң аянычы шул — аяклары. Солтаниянең аяклары... Алар хәзер юк инде. Үзе бар, ә аяклары... Аит өчен ул үзе дә юк инде. Әллә Солтаниягә — Аитмы? Кайсысы кайсысына юк?

Ул тагын күңеленнән генә үз-үзенә: «Аска карама!» — дип боерырга мәҗбүр булды.

Ул, кое янында юынып алгач, өч кирпечне бер-берсенә мич шикелле итеп терәп куйды да, өстенә ике тимер кисәге куеп ут тергезгәч, чәйнек утыртты.

Болдыр ишегендә Сөмбел күренде. Кай арада киенеп-ясанырга өлгергән.

— Ах, нинди тәмле озон исе,— диде ул.

— Озон? Ялгышмасам, моны бездә саф һава диләр.

— Иртүк бәхәсләшәсе килми.

— Алайса, хәерле иртә.

— Хәерле иртә, Аит. Нишлисең?

— Ат дагалыйм,— диде ул көлеп.

Сөмбел эндәшмичә генә баскычтан төште дә ялтырап яткан бәллүр китекләрен учына җыеп, чыңлатып карады.

— Боз кисәкләре шикелле... Мин сиңа кыйммәткә төштем ахрысы.

— Сатулашма.

Чәйнек капкачы тишегеннән пар бөркеп чыга башлады. Аит ике чокыр белән кофе савыты алып чыкты.

— Төрекчә ясалган кофе,— диде ул һәм болдырдагы патефонны кофе куеп эчәр өчен алып чыгарга ниятләп, эчкә керде. Патефонга кулы

орынуга, аның капкачы ачылып китте, борынына ниндидер татлы бер ис килеп бәрелде. Кәкре муенлы уйнаткычы эчкә бөгеп тыгылган, капкачына боргыч һәм инә савыты беркетелгән. Ул аның җибәргеч рычагын этеп караган иде, пружинасы бушап бетмәгән булган ахрысы, тәлинкәне әйләндергәче хәрәкәткә килде. Һәм Аит әнисенең тавышын ишеткәндәй булды.

«Балам! Атагыз сугыш кырында яраланып, госпитальдә ята әле. Миңа ач торырга күнегәсе җугые. Яшьли ятимә калып, миңа җиде тулганда беткән гражданнар сугышы михнәтләрен кичердем, ачлык елның мәхшәреннән исән-сау чыгуым бер хәл, мин сезне табып үстерүем бәхетенә бик шөкермен. Сезгә дә сугыш белән ачлык килде, минем сымак ятим калуыгыз бик ихтимал ые. Тешемне кысып, иренемне тешләп, бөтен нәрсәгә түздем. Соңгы сарыгымны суйдырдым да, кечкенә агач чанага бәйләп салып, Карнауык, Шәле урманнары аша Казанга тартып киттем. Атаңнар сугыш кырында, мин белгән тирә-юнь — Чирмешән, Ырга, Солтан Гобәй, Зәңгәрле, Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авылларының матча шикелле асыл ирләре сугышта. Качып кайткан, качып ята дигән бер генә ят, хәвефле-хәтәр хәбәр дә ишетелгәне җук. Мин белгән тирә-юнь авылларда татар хатыннары андый хурлыкка төшмәделәр, шөкер. Ул елларны татар авыллары тирәләрендәге урманнарда сугыштан качып килгән бүреләр генә яшеренеп ятты. Татар хатыннары ирләрен тота белгәннәр дә соң ичмаса.

Казанга барып җиттем. Хәсрәт мине сарык саткан акчага азык-төлек, ситсы-калуш алырга кыстады. Ә сагыш, ә сагышым бер кибеттә уйнап торган патефон күреп чыкты да җитәкләп кире алып кереп китте. Шул ук чанага салып, Шәле, Карнаук урманнары аша Казаннан патефон белән тәлинкәләрен алып кайттым. Хәсрәтемә түзәрием, сагышка түзеп булмады. Хәсрәткә түзәргә — сабырлык, сагышка түзәргә җыр кирәк икән ул. Мең дә тугыз йөз кырык икенче җыл мартының айсыз, нурсыз бер төнендә мин караңгылыкка чумган авылыбызга бәләкәй агач чанага салынган патефонны уйнатып кайтып төштем. Бөтен авыл атаң кайтып килә дип йокысыннан уяныл каршыма чыкты. Ә син әтиеңнең гармунда ничек уйнаганын бик яхшы беләсең ич, улым, бөтенегезне өйрәтеп бетергән ие. Уйный ые да соң, әх, уйнап та күрсәтә ие соң!

Гармунчылар сугышка китеп беткәч, җөрәкләр кысылып кына калган ые. Шул кысылган җөрәкләрне ачып җибәрергә дигән ният белән патефон алып кайттым. Хәсрәткә түзәргә — сабырлык, сагышка түзәргә җыр кирәк икән ул. Мең тугыз йөз кырык икенче җыл мартының айсыз, нурсыз бер төнендә мин караңгылыкка чумган авылыбызга бәләкәй агач чанага салынган патефонны уйнатып кайтып төштем. Балам! Безне дошманның җиңә алмасына авылым кешеләре шул төнне тәмам ышанды. Бер кабынган ышанычны сүндерерлек караңгылык, бер җырланган җырны туктатырлык яшеннәр дөньяда җук.

Балам! Утырма син патефонга. Кеше дә утыртма...»

Аит ишегалдына чыгып, яңгыр юып киткән бүкәнне баскыч төбенә китереп куйды да кофе ясады. Эреп бетә торган кофеның чак кына көйгән һәм әчкелтем хуш исе ишегалдына җәелде.

Сөмбел чынаяктагы кофены иснәп карады.

— Әгәр дә минем йокыдан уянуыма шушындый тәмле исле кофелар әзерләп торсалар, биредә бөтенләйгә калу-калмавымны уйлаганда да ярый.

— Бөтенләйгә?— дип сорады Аит.

— Алай да синнән җүнле ир чыкмастыр, шәт,— диде Сөмбел җавап бирмичә.

— Нишләп?

— Җүнле ирләргә кофены хатыннары ясап эчертә.

3*

«Кофены Солтания яхшы әзерли иде»,— дип исенә төшерде Аит. Болдырдагы шкафтан ике бал кашыгы белән ике шакмак шикәр алып чыкты да бүкән алдына чүкте.

Шикәр салып, кофеларын болгатып эчтеләр.

— Әйе шул: җүнле ирләргә кофены хатыннары ясап эчертә. Син минем кунагым, шулай булгач, сый-хөрмәт — миннән.

— Мин синең кунагың түгел.— Сөмбел чынаягын бүкәнгә куеп, урыныннан торды.

— Кемем соң?

— Бүгенгә хатының дип фараз ит.

— Хатыным?— Аит кофесын ялгыш йотып йөткергәләп куйды. Беренче тапкыр ул Сөмбелнең шаяртуын үзе дә сизмичә чын итеп кабул итә язды.

— Кофеңны түгәсең ләбаса, бүкән!

— Бүкән?— Аит көлеп җибәрде.— Хатынлы ир генә бүкән була ала шул, әйеме?

— Гафу ит, ялгыш ычкындырдым...

— Тагын шундый берәр сүз ычкындыр әле. Тансыкка!

— Өлгерермен. Минем репертуарым шактый бай.

— Бәлки шулай яшәү кызыктыр ул. Синеке шикелле бай репертуар белән.

— Хатыныңның репертуары ярлы идемени? Сез тату торгансыздыр шикелле. Татулыкта матурлык дип юкка гына әйтмәгәннәр.

Аит:

— Әйе, тату,— дип көрсенде.

— Алайса нигә көрсенәсең?

— Бүген минем иң авыр көрәш көне.

— Минем белән көрәшергә җыенмыйсыңдыр ич?

— Синең белән татулаштык бугай инде. Шуңа күрә көрәшәм дә. Үз-үзем белән.

— Төшенеп җитмим.

Аит болдырга кереп китте. Күзе стенага, җилпуч белән янәшә элеп куйган гитарасына төште. «Түбән карамаска!»— дип уйлады ул. Күңелен тирән бер сагыш биләп алды. Ул үзенә аркан утырган Сөмбелгә карап алды. Сөмбел таза, сау хатын, ялангач кулбашлары ташып, күлмәге тәненең һәр хәрәкәтен белдереп тора. Бүген ул нигәдер кичәгечә чибәр булып күренми иде инде. Күңеленә сава башлаган бушлыкны тутырырга теләп, ул кулына гитарасын алды. Текә таулар башында, түбән карамас өчен, ул җырларга күнеккән иде.

Тормышның Каф тауларында
баусыз калдык икәү.
Түбәнгә ничек төшәргә,
ничек — белсәң икән!

Пар бөркет оча куышып —
ялкын-ут кебекләр.
Шундый канатлы иде ич
безнең дә өметләр!..

Таш кыскан эдельвейс кебек,
шиңде безнең вәгъдә.
Пыскыган салкын учактай
яшәүдән ни мәгънә?

Бөркетләрнең ояларын
ташлар иште түбән.
Кайда син?
Ишетәсеңме:
бу — минем тәүбәм...

Сөмбел үзенең бу иртәдә шаяртырга тырышуларының урынсыз булганлыгын аңлап алды. Бүген аңа үз-үзен бераз бүтәнчәрәк тотасы калган ахрысы. Солтания Аит алдында гаепледер, аңа берәр авыр, төзәлмәс җәрәхәт ясагандыр дип уйлаган иде бит. Хәер, нигә Солтания? Бәлки Аиттыр? Һәрхәлдә, соңгысы дөресрәк, чөнки ачуы, үпкәсе булса, ул ир башы белән мондый моңсу җыр җырлап утырмас иде. Аңа карата мөнәсәбәте дә бүтәнчәрәк булыр иде. Кайсыдыр хатынга үч саклаган ир башка хатыннар белән дә тупас кыланучан. Ә Аит үз-үзе белән көрәшә...

— Җырламыйсың син,— диде Сөмбел, Аит гитарасының кылын соңгы кат чиртеп куйгач.

— Нишләдем соң? Гафу ит, мин синең өчен җырламадым.

— Әйе, бу — синең күз яшең. Күпмедер дәрәҗәдә моңа мин дә сәбәпче.

— Киресенчә, Сөмбел!— Аит, ашыгып килеп, аны арттан кочып алды.

— Миңа хатының турында сөйлә әле.

— Үткән эшкә салават, кирәкми... Альпинистларның «Түбән карама!» дигән законы бар. Үткәннәргә күтәрелсәң, төпсез киләчәккә егылып төшеп китүең бар. Ә мин киләчәгемдә бер үзем. Альпинистлар, ичмаса, ялгыз булмыйлар.

Сөмбел аңа сыенып торды да, алга иелеп, аның кочагыннан чыкты:

— Кофе яса әле,— диде ул.— Үзең дә эч.

Янәшә торып, бер-берсенә карашмыйча һәм сүзсез генә кофе эчеп утырдылар. Аит абзар-кураны күзеннән кичерде. Йорт ул күз алдына китергәннән күпкә искергән икән инде.

— Син аны мин уйлаганга караганда да ныграк яраткан булгансың,— диде Сөмбел.

— Моны каян алып әйтәсең әле?

— Синең «түбәнгә карама» дигән законың үлем куркынычыннан котылыр өчен әйтеләдер ул, әйеме? Синең үткәннәрне уйламаска, аны искә алмаска тырышуың да үз-үзеңә шул «түбәнгә карама» дию сымаграк ахрысы. Альпинистлар егылмас өчен түбән караудан сакланган шикелле, син дә... үткәннәреңне үлем янаган төпсез чоңгыл итеп күрәсең. Бәлки бу миңа тоела гынадыр... я булмаса, мин шулай телимдер, гафу ит... Тик... синең өчен үткәннәрең үлем белән янаган төпсез биеклеккә тиң икән... син аны... («Аны» дигәнне Сөмбел басым белән, аерып әйтте, әмма аның кем хакында сөйләгәнен Аит болай да бик яхшы белә иде.) син аны яраткансың. Бик яраткансың. Хәзер дә яратасың. Син аны искә төшерергә куркасың. Югалтырга теләмәгәндә генә куркалар. Кадерсез нәрсә куркытмый.

— Без аның белән таулар ярата идек. Марух дигән үткелләрне кичтек, Данбайда булдык, Баксан тарлавыгын кичтек, Эльбруска күтәрелдек. Донгус дигән бер урында... юлларыбыз аерылды... Ә без аның белән күрелмәгән биеклекләргә күтәрелеп, түбән карарга — аяк астыбыздагы үзәннәргә, болытларга, баш очыбыздагы кояшка, йолдызларга яки яшеннәргә карарга ярата идек. Кайчагында кояш аяк астында була, үзәнгә таба тәгәрәп төшә, ә шул ук мәлдә баш очында күк күкрәве ихтимал.

— Тормыштагы кебек икән,— диде Сөмбел.

— Тау башларында сайлану мөмкинлеге юк. Син анда берүзең. Хәтта икәү... бишәү булганда да берүзең. Безнең яшенле, күк күкрәүле бураннарга эләккәнебез бар. Күз алдында хәтта шарлы яшеннәр дә пәйда булгалады. Син ялгыш орындыңмы — беттең, сине беркем коткара алмый, юкка чыгасың, хәтта көлең дә калмый! Янсә баш очында да, аяк очында да кояш — ә син ишелеп-ишелеп яуган кар эчендә, тәмуг суыгында эленеп каласың, әмма тамчы да ашыгырга ярамый. Бәлки

син ашыккан җиргә иптәшләреңнең соңлабрак менеп яисә төшеп җитүе хәерлерәктер?.. Таулар мена нәрсә ул, Сөмбел. Эльбрус... Андагы кыяларда эдельвейслар гына чәчәк атып утырмый. Без бер үткелне кичкән чакта бозга катып калган фашистларны күрдек. Күп иде алар. Туплар ята, пулеметлар... һәм кешеләр. Яңа гына үлгән кебекләр. Үлгән түгел, ә бәлки йокыга гына киткәннәр сыман. Шунда ук — үзебезнең солдатлар да. Җәрәхәтләреннән агып чыккан каннары да боз астында төсен җуймыйча сакланган... Тауларда кешене адым саен үлем сагалап тора.

— Шуңа карамыйча менә идегезме?

— Үлемне җиңүе рәхәт иде. Үлемне, авырлыкларны, куркуны. Таулар кешеләрнең йөрәкләрен бер итә иде.

— Юлларыгызны аерган да ич.

— Ә ул бөтен куркыныч артта калгач булган хәл. Таулардан төшеп, базада соңгы көнне үткәргән чагында мин аны тау болынына алып чыгып киттем. Җылы иде. Чәчәкләрнең, үләннәрнең аяк астындагылары түгел, ә ялангач кыя уентыкларында бер ялгызы үсеп утырганнары җетерәк, матуррак шикелле, нык холыклы кешеләр сыман кырыслар... Унөч көн буена таш кыяларга чөйләр кагып, ыргаклар беркетеп, репшнурда күтәрелүләрдән, төшүләрдән, беркая ышыкланмыйча, кыялардагы өстәл шикелле генә уентыкларда салкын төн кунулардан тупасланып беткән кулым ул чәчәкләрне өзгәнче үк сытар сыман, яргаланып беткән иреннәр кыргый җиләкләрне авызга алганда әчетә, тау башларында сварка утыдай чагылып торган ап-ак карлар күзләрне талчыктырган — яшел урман күләгәсендә дә күзләрдән яшь ага.

Ләкин безгә икәү булганда рәхәт иде.

Көтмәгәндә, алдан һичнинди билгесен күрсәтмичә, көн бозылып китте. Бәлки, бер-беребез белән мавыгып сизми калганбыздыр, белмим. Көрәп-көрәп кар яварга тотынды. Август ахыры гына иде әле. Шундук яшен яшьни, күк күкри, таулар өскә ишелердәй булып калтырый шикелле. Караңгыланды, әйтерсең лә көн уртасы түгел, ә төн уртасы. Солтания аягын авырттырды. Чалгы белән чапкандай ауды. Әллә аягын каймыктырды, әллә тамырын тарттырды... Ахырдан сынган икәне беленде. Күтәреп төшә башладым. Аяктан егарлык итеп җил исә, ниндидер иләмсез зур торбадан безгә генә өрдереп торалар диярсең. Ышык урын табып, яшеренгән булдык. Кая анда! Үзәкләргә үтәрлек салкын! Туңа башладык. Ә буран... Котыра гына! Палаткаларыбыз белән бергә безне күмеп киткән бураннарны мин әз кичермәдем. Унбиш минут саен чыгып, палатка түбәсен көрисең...

Ул көнне Данбайда өч турист туңып үлгән. Берсе — ике бала анасы. Таулар андыйларны да сихерләп чакыра, күрәсең. Фаҗига... Адашканнар. Группаларындагы кешеләр, ялгызлары котылырга исәп тотып, кайсы кая таралышып беткән. Ә тауларда бәладән ялгыз котылып булмый. Фаҗиганең икенче ягы шунда: бу туңып үлгән кешеләрнең өчесе дә башкаларны коткарам дип һәлак булган. Ике бала анасының үзен коткарырга кеше табылмаган, киресенчә, ул үзе... Ни уйлады икән ул?.. Башкалар өчен яшәргә теләүчеләр еш рак һәлак була... Кырыс статистика, әйеме?

Бураннарның очы-кырые күренмәгәч, аны ботаклар, үләннәр белән томалап калдырып, базага үзем генә төшеп киттем. Ярдәмгә кешеләр дәшәргә дип. Буран туктаганны көтеп утырсак, икебезнең дә озакка чыдамаячагыбыз ачык иде. Һәм адаштым мин. Моңа бернинди хакым булмаса да, адаштым! Ә миңа ашыгырга кирәк иде. Үзебез өчен генә түгел, әле тумаган, ана карынындагы өч айлык җан иясе өчен дә ашыгырга тиеш идем... Адашкан кеше ничек кенә ашыкса да соңара. Солтанияне табып алып, базага алып төшкәндә соң иде инде... Ул исән калды, тик... Тик аның аякларын кистеләр. Өшегән иде... Ул мине ки-

черә алмады. «Мин сине аяксыз хатыннан азат итәм!» дип, разводка бирде.

Бер караганда, минем гаебем юк ич, әйеме? Бөтенесенә ахмак очрак гаепле. Әмма шул ахмак очраклар өчен дә акыллы кешеләр гаепле шул. Яшәүнең иң дөрес, иң гадел законы шундый... «Син ялгышырга тиеш түгел!» дигән бурыч кешегә бәлки бер генә тапкыр биреләдер. Минем бер ялгышуым гомеремне мәгънәсез итеп калдырды... Ул мине гафу итә алмады... Бәбиебез тумады. Икенче бәбиебез.

Ә безнең әтиләребез сугыштан да адашмыйча исән кайтырга омтылганнар. Ни өчен? Без һәм безнең кебек миллионнар дөньяга килсен өчен! Әгәр дә алар җиңелсәләр яки бөтенесе үлеп бетсәләр? Аларны кем гафу итәр иде? Безнең әниләребезме? Аларның үз аналарымы?

Данбай мине ялгыз итте.

Мин аның мине гафу итүен, кичерүен теләмим. Юк, юк, аның янына кире кайтмаска сылтау булсын дип түгел! Йөрәгем мәңге җәрәхәтле торсын дип. Җан авыртсын, сызласын. Аның аяклары өчен дә сызласын. Җаны сызламаган кеше тозсыз ипи шикелле ул.



## Унөченче бүлек

Аит үзләренә каршы йорттан пыяла банка белән сөт алып чыкты. Ачык йөзле Асия карчык бушка бирергә теләгән иде дә, тиешле акчасын түләп алды. Карлы базда төн кунган, салу белән банканы тирләтеп чыгарган салкын, куе сөт. Күңеле булган карчык, алъяпкыч итәген тутырып, ярылып китәм дип торган помидорлар да чыгарып бушаткан иде.

Сөмбел белән салкын сөт эчеп, яргаланып торган помидорларга эре тоз сибеп ашадылар. Тагын су кайнатып, кофе ясадылар. Бу юлы — Сөмбел.

— Җүнле иргә кофены хатыны ясый диденңме әле?

— Кунагы да ясавы бик ихтимал!

— Син, теләсәң, ял ит,— диде Аит.— Мин бу әрҗәләрне бушатып, әйберләрне урнаштырыйм инде.

— Булышсам, хуҗабикә булып калыр дип шүрлисеңме әллә?

Аит хатын-кызның үзе белән бергә, бигрәк тә бертигез итеп эшләвен өнәп җиткерми иде. Бәлкем гаиләләрендә ир балалар күп булып, ирләр эшен гел үзләре генә эшләгәнне күреп үскәнгәдер? Ә бу юлы ул килеште. Сөмбел белән бергәләп, өйдәге иске әйберләрне ишегалдына чыгарып өя бардылар. Иң элек киң матрац белән тимер караватны чыгарып куйдылар. Ул атасының шул матрацны йомшак мүк белән тутырып, яңа тукыма белән тышлаганын исенә төшерде. «Сиңайтәм, бу матрац хан кызы тәне нише гөбердәп калды, билләһи газим!» — «Хан кызларын тотып караганың бармы әллә?» Ерагаеп, тәмам югалып калган тыйнак кына бер көлешү авазы ишетелгәндәй булды. Аит үткәннәрне аерым-ачык күрә һәм ишетә иде.

Аннары көйгән аяклы өстәл чыгарып куйдылар.

— Бу өстәлне мин әнигә стипендия акчасына алып биргән идем,— диде Аит.— Мич авызы янына куйган да көйдергән. Ашъяулык япкач, күзгә артык бәрелеп тормый анысы.

Шулай һәр әйбернең диярлек тарихын сөйли-сөйли, алар икәүләп борынгы калын, әмма бозылып беткән көзге, ярык куна тактасы, күәс, самавыр, күрегә ертык тузган гармун, какшап беткән тумбочка, этажерка, ватык савыт-саба нише әйберләрне чыгарып, ишегалды уртасына өя бардылар.

— Болары нинди чүп-чар инде тагын?— дип, Сөмбел кочагыннан тимер-томыр бушатты.

— Ә болары чүп-чар түгел аның, Сөмбел.
— Ни соң? Сынык кылыч, кисәү...
— Шушы иске йортка сыйган егерменче гасыр болар... Менә бу сынык самурай кылычы — рус-япон сугышыннан, бабай истәлеге.— Аит сабындагы агач тоткалары шылтырап торган сынык кылычны җиргә кадап куйды.— Бу дүрт кырлы күгәрек штык белән шул ук бабай үндүртенче елдан унҗиденче елга хәтле германнар белән сугышып йөргән.— Ул штыкны да кылыч янына кадап куйды.— Ә менә монда тагын бер тимер-томыр булырга тиеш...— Аит йөгереп диярлек өйгә кереп китте, сәгать өстеннән бизәкләре кырылып беткән калай тартма алып чыкты да аны әкрен генә ачып җибәрде һәм тагын атасының тавышын ишеткәндәй булды: «Беләкне менә шушы снаряд ярчыгы каеп алды минем, улым»...— Бусы соңгы сугыштан әти алып кайткан истәлек, беләгеннән чокып алганнар,— диде ул һәм кызыксынып, шул ук вакытта шикләнгән сыман, тартмага иелгән Сөмбелгә саргаеп беткән марляга төрелгән күгәрек, ләкин теткәләнеп беткән үткер кырлы тимер кыйпылчыгын чишеп күрсәтте.

Ул безнең кулыбыз җитмәс шүрлектә, кәрҗиненнән ташып торган виноград тәлгәшләренә охшатып эшләнгән зәңгәр төстәге фарфор савытта саклана иде. Иң беренче тапкыр аны кайчан күргәнбездер, анык хәтерләмим. Мөгаен, безне үз тирәсенә җыеп, әти аны безгә үзе күрсәткәндер.

Кайчакларда әти җимеш тулы кәрзин сурәтендә эшләнгән әлеге савытка үреләә. Бу вакытларда без инде каз бәбкәләре кетә башлаган булабыз. Әтинең ел саен шул савытка үрелгән минутлары тугызынчы май көне түгел иде микән? Әйе, Җиңү көне.

Хәзер күзләремне зур ачып, мин шул мизгелләрне күзаллыйм.

Әти савытны гадәттә кичен ача торган иде. Сигезле лампаның саргылт яктысы аның күзен тагын да зурайта, маңгаендагы җыерчыкларын тагын да тирәнәйтә шикелле. Без, тын да алмыйча, әти бармакларының һәр хәрәкәтенә йотылып багабыз.

Ул бармаклар озын һәм әтинең холык-табигате кебек туры, каты иде.

Бераздан соң әти үзенең учына текәлә. Аның күзе кысыла төшә, һәм безгә ул багучы кебек, учындагы сырларыннан үз язмышын эзли сыман тоела иде.

Хәзер инде беләм: әти тәкъдирен эзләмәгән. Ул әкияттәге күрәзәчедәй, учын серле көзге итеп, үткәненең кырыс, тузанлы юлларын күргән.

Уйларыңда ниләр иде синең, эткәй?

Бәлки яндырылган авыллардыр?

Бәлки дошман танклары изеп-сытып үткән помидор бакчаларыдыр?

Бәлки Җиңү языдыр?

Карашларыбыз эткәй йөзеннән әкрен генә аның учына күчә һәм... һәрчак шулай: безне эчке бер курку хисе биләп ала. Әйтерсең лә, анда бөгәрләнеп кара елан ята.

Юк, елан түгел, елга ярына көчле ташкын чыгарып аткан агач төбенә охшаш чәрдәкләнгән корыч ярчык ята иде анда. Күгәргән мина кыйпылчыгы. Бармак башы хәтле генә булса да, ул ярчык шушы мизгелләрдә, гүя, эткәйнең уч төбен утлы тимер шикелле кыздыра, ә безнең бөтен күңелләребезне, бөтен өебезне дәһшәт шавы белән тутыра. Ул күк күкрәгән авазлар белән шартлар да, вак кисәкчекләргә чәрдәкләнеп, безнең кулбашыбызга кадалыр, һәм анда эткәйнеке төсле тирән чокыр калыр сыман тоела иде...

Хәзер безнең иң биек шүрлеккә дә буебыз җитә инде, ярчыктан ку-

рыкмыйбыз. Аңа күнегүдәнме, иялэшүдән янсә аны онытудан түгел. Ул элеккечә үк чит, чирканыч, вәхши. Без аңа нәфрәт белән карыйбыз. Әйтерсең лә, ул күгәргән ярчык түгел, ә барлык явызлыкны үзенә җыйган кара бер янчык...

Әти кебек, кайчак мин дә аны учыма алам. Кайчандыр ул әти тәнен чокып кергән, ә хәрби табиб, әманәт итеп, аны яраланган сугышчының учына салган.

Ул сугышчы юк инде... Ярчык аның учыннан минем учыма күчте. Ул — әманәт. Үлгәннәрнең кисәтү сүзе. «Күрегез, ярчык! Сугыш ярчыгы!»

Сугыш ярчыгы... Мин учыма карыйм. Мин багучы түгел. Тәкъдиремне эзләмим. Мин — элеккеге сугышчы улы. Мин учымда көрәш юлларын һәм ярчыксыз елларны эзлим. Миндәйләр күбәү. Сыкрый-сыкрый учларында корыч ярчык кысучылар күбәү. Зәңгәр савытларда кыйпылчыклар саклаучы өйләр күбәү. Ярчыкларга башта куркып, аннан соң чиркanып һәм нәфрәтләнеп багучылар күбәү. Миллионнар алар! Һәм аларның йөрәкләре, чаң суккандай, бер уй белән тибә, бер уй: «Кирәк калса, ярчыклардан пуля коелыр!»

— Кызык чүп-чар монда, әйеме? Тарих чүп-чарлары... Без иске өйдән чыгарып аткан тузгыган әйберләр шикелле җиңел генә итеп, боларны кешеләр хәтереннән чыгарып атып булмый. Ярамый! Җир шарындагы барлык иске йорт-җирләргә моның ише истәлекләр шыплап тутырылган. Кайчандыр кешеләрне үтерүгә кулланылган әйберләр белән музейлар тулган... Бу кылыч белән штыкны стенага — баш очыма элеп куям мин.

— Домокл кылычы итепме?

— Дөрес әйтәсең. Дөньядагы һәрбер кешенең башы турысына кылыч элеп чыгарга кирәк.

— Ярый алайса, боларын кире керт, ташлама... Әйдә, урнаштырып бетерик.

— Бар да тузган, бөлгән монда! Бар да какшаган, уңып беткән... Йа, хода! Үтсә дә үтә икән гомер...

Аит, балта алып, болдырның бер ягына җайлап куелган әрҗә такталарын сүтәргә тотынды. Монда яңа караватат, диван, өстәл, шифоньер, ике кәнәфи...— румын гарнитуры. Ә Сөмбел, кое чыгырын чыгырдатып, ике чиләк су алды да, күлмәк итәген авыл хатыннары шикелле кыстырып, өйне, өйалдын юып чыгарды. Кул арты белән маңгай тирен сөртеп алгач, ул кәнәфигә килеп утырды.

— Боларын кая куярсың икән инде?— диде ул яңа әйберләргә ишарәләп.

— Әле үземне кая куярга белгән юк,— диде Аит. Ул такталарны кочагына алып, келәт кыегы астына өйде. Диван белән караватны, урындыклар белән кәнәфиләрне, өстәл белән шкафларны өйгә кертеп урнаштырдылар. Стенканы җыюы читенрәк иде, ул калып торды. Өй эче бераз сәеррәк төс алды.

— Менә бу интерьер!— диде Сөмбел, сокланып карап торгач.— Вилла. Җәннәтне көнләштерерлек.

— Беренче юлга ярый инде.

— Ә икенче юлга нишләтәсең?

— Өйне эчтән дә, тыштан да такта белән тышлап чыгам.

— Җәннәтең ничә урынлык булыр икән: бер үзеңәме, әллә ике кешелекме?

Аит чүп-чарны чыгарып түкте, ә Сөмбел болдырны юып чыгарды да, юган чүпрәген сыгып, баскыч төбендәге ташка җәеп куйды.

— Бу минуттан аягыңны сөртеп йөри торган бул, тәкъсир!

— Менә, соравыңа үзең үк җавап бирдең: синең бу өйне ике кешелек итеп ясыйсың килә. Ярый соң, әлегә тыңлыйм һәм буйсынам. Баш өсте, ханым,— дип сөйләнә-сөйләнә, Аит бик тырышып аклы-кызыллы йомшак аяк киемен чүпрәккә ышкып торды.— Элеккеге ситсылар нинди булган, ә?— диде ул аяк астындагы чүпрәккә күзе төшеп.— Өйне, болдырны юып чыгарсаң да, төсе, чәчәкләре уңмаган.

— Күлмәк ул,— диде Сөмбел.— Заманында кемдер кигән инде аны.

Аит аягын алмаш-тилмәш җирдән күтәреп, чүпрәктән әкрен генә ташка чыгып басты.

— Ничек кулың барды?!— диде ул тешләрен кысып. Сөмбелдән ниндидер куркыныч янаганын тойгандай, беләге белән битен капла-ды.— Кабәхәт,— дип пышылдады ул һәм ишегалдына чыгарып ташланган әйберләргә күзе белән генә түгел, ә җаны белән дә текәлеп калды.

— Рәхмәт. Бәлки мин синең бу сүзеңә чыннан да лаекмындыр.

— Гафу ит, мин үземне әйтәм. Әнинең чәчәкле күлмәген шушы хәлгә җиткерүгә мин үзем гаепле. Тормышыбыз җайлы чагында нигә сукыр соң без? Әниләрнең тузганчы кияргә дә өлгерми калган күлмәге белән идән югач, кем соң без? Без аларның үзебез күрмәгән күпме кайгы-хәсрәтләрен, шушы күлмәк шикелле итеп, аяк астыбызга җәеп салганбыз ич.

— Бичара әнкәң белән атаң... Алар минем бу күлмәк белән идән юганны түгел, ә бәлки синең менә бу әйберләрне чыгарып ташлаганыңны карап торсыннар иде әле. Ни әйтерләр иде икән?

«Әйе, әти дә, әни дә минем бу әйберләрне чыгарып атканымны карап тордылар,— дип уйлады Аит.— Хәтеремнең үткәннәргә төбәлгән салкын тәрәзәләре аша карап тордылар...»

— Мин начарлык эшләргә теләмәгән идем,— диде ул.— Мин бары тик бишегемне кире кайтарып алырга гына теләгән идем. Кайчандыр үземне тирбәтә-тирбәтә арыган, тузган бишегемне... Җилләр-яңгырлар, карлар, кояш эссесе ямьсезләп бетергән, тик мәңгегә йомшак һәм жылы калган бишегемне. Мин бары тик әти үзенең гади крестьян акылы белән ясаган, әни исә гади җаны белән җылыткан бишегемә янадан кайтып, арыган тәнемне, җанымны шунда ял иттерермен дигән идем... Әнинең күкрәк сөте белән сугарылган бишек... Бишек... Шуңа арыган тәнемне биләүләп салып, җанымны тирбәтергә... Кешегә йокларга, ятарга, балалар үстерергә, үткән көннәрен санамыйча гына үлемен көтеп алырга туган бишек кирәк!.. Ләкин бишекләр кешеләр өчен генә, Сөмбел! Ә мин синең кулларың белән әнинең чәчәкле күлмәген чүпрәк итеп идән юдым... Мин үземә тыныч бишек тапмакчы идем, тик бишегемә хыянәт иткән булып чыктым...

Кеше табигатендәге мондый кискен үзгәрешне башка вакытта Сөмбел һич аңлап бетерә алмас иде. Кеше җаны — карурман. Ә Аитның кичәге тыныч, шуклыкны да, чынлыкны да бөтен тирәнлегендә кабул итә торган, сизгер күңелле, кырыс холыклы икәнлеге һәр саран хәрәкәтендә беленеп торса да, кирәк икәң күзе, кирәк икән сүзе, кирәк икән ымы-ишарәсе белән йомшак, ягымлы да була белүче Аитның кинәт шушындый төпсез төшенкелеккә бирелүен ул бөтен йөрәге белән төшенде. Монда ул иң беренче чиратта үзен гаепләде. Дөрес, ул Аит күңелендә уянган канәгатьсезлек тойгысының чыганагы, беренче сәбәпчесе түгел, алай да үзе генә яшәргә дип кайткан, арыган-талчыккан, зур кичерешләрдән яңа гына арынып килә торган ир-ат янында аның — билгесез, таныш булмаган хатынның пәйда булуы кирәкмәс иде, күрәсең... «Югыйсә, аның мине танымавы гаҗәп түгелмени?»— дип уйлады Сөмбел. Хәер, ул аның күзенә бер генә чагылып калды калуын, анда да бөтенләй бүтән кеше белән мавыккан чагында, ләкин

алай да, алай да, алай да... Ихтимал, бәлки теге пасха төнен әйтәсе калгандыр. Әмма бу Аитның җанын тагын да ярсытмас иде микән соң? Аңа үткән бер тәүлек эчендә «түбән карамау» чынлап та хәерле булган. Теләгәнме-теләмәгәнме, ул Солтания белән чагыштырып караган лабаса Сөмбелне! Әгәр ул чакырылмаган кунак төсендә бирегә килеп кермәсә, кем белә, бәлки Аит тыныч кына урнашыр, көннәрен уйламый-нитми генә үткәрер иде. Ә чагыштыруның Сөмбел файдасына хәл ителмәве ап-ачык: югыйсә Аит аның белән бөтен дөньядан ваз кичеп мавыкмас идемени? Ул Аитның иң авыр тойгылары көйрәгән күмерләргә җил өрдереп җибәргәндәй иткән икән лә! Аның бирегә вакытсыз килеп кергәнлеге бәхәссез. Ул монда чит, чит, чит... Хәер, әле чыгып китәргә соң түгел! Риваятьтәге Роза чәчәге сыман, аны бирелә кабул итүен иттеләр, ләкин моның ахыры бүтәнчә дә бетә ала ич әле. Әле соң түгел, әле төзәтергә мөмкин, әле һәркемгә үзенчә калу җае бар. Һәркем бер-берсе алдында азат. Тик безнең һәркайсыбыз аның алдында азат түгел,— дип уйлады Сөмбел.— Ул бирелә юк, алай да без аңа бәйле. Солтания!.. Ут Аитны үзеннән азат иткән, имеш... Юк, ул аны үзеннән... коткарган!

— Беләсеңме мин кем?— дип сорады Аит һәм дерматины тузган, кайчандыр ялтырап торган тимерләре төртек-төртек күгәреп беткән патефонга барып утырды да дога укыгандагыча киң итеп ачып куелган учларына текәлде.— Троя аты мин, Сөмбел.

— Троя аты?

— Троя аты. Шушы иске йортка, минем беренче һәм иң соңгы бишегемә килеп кергән Троя аты... Мин аны менә ничек итеп туздырып ташладым... Хәзер бу йорт туздырылган кош оясына охшап калды. Син ничек уйлыйсың?

Сөмбел аның алдына килеп тезләнде, кулыннан тотып, күзләренә карады.

— Мин уйламыйм, мин күрәм,— диде ул, аның учын сыйпап.— Мин үземнең, йөгерек су сыман, синең бармак араларыңнан агып киткәнемне күрәм... Син күрәсеңме? — Ул аның учын йөзенә якынрак китерде.— Аркылы-торкылы сукмаклар белән кискәләнеп беткән уч төбендә ялтылаш өзелеп калган бер эзне күрәсеңме син?

— Син минем белән каласыңмыни? Синең өзелмәгән эзең кайсысы соң?

— Юк, мин китәм. Мин таҗларын өләшеп бетергән теге Роза чәчәге сыман китәм.

— Ул Океанныкы булган лабаса!

— Кичә синең тыңлап бетерергә түземлегең җитмәде: ул Роза чәчәге, таҗларын өләшеп бетерүенә карамастан, үзен алырга әзер торган Океанныкы булырга теләмәгән — киткән...

Аитның алдында тезләнеп торган хатын әйткән бер генә сүзгә дә карышасы килми иде. Ул аның белеп сөйләгәнен, дөрес уйлаганын, тиешле карарга килгәнлеген төшенеп утырды. Нәрсәгәдер үгетләү, аннан тагын нидер көтү, теләү мәгънәсезлек булыр иде. Нигә? Сөмбел бу вакыйга агышын һәм, иң мөһиме, аның күңелендә ургып торган кичерешләрне сизгер тойган.

— Беләсеңме нәрсә?— диде ул бераз тын торгач. Аның тавышы тыныч, дустанә, үкенечсез иде.— Хатының кичергән сине.

Аит аның мондый сүзләрен һич көтмәгән иде. Ул, патефонны аударып, сикереп торды да таш өстендә яткан балтаны гайрәтләнеп бүкәнгә чабып куйды.

— Ул синең аяк-кулларыңны бәйләп тотмас өчен сине үзеннән азат иткән. Ышан, Аит, хатын-кыз йөрәге белән сизеп әйтәм. Ул иң изге бу эшен сине яратуы хакына эшләгән. Аның сине азат итүе кичәге хатлар белән тиң изгелек, Аит.

Тынлык караңгы кое шикелле тирән, ә кояш тау башындагы мәңгелек кар түбәтәе шикелле якты, ләкин, нигәдер, салкын кебек иде. Аяк астында эрегән кургашын ташкыны. Чикерткә аваз сала. Аның чырылдавы Аитка шул авыр кургашынның сүрелгәндәге чатнавы булып ишетелде. Аңа оят иде. Бөтен тәненә гарьләнү дулкыны җәелде, кайнар һәм ярсу каны йөрәгеннән какты, аның тагын, бирегә кайтып кергән минутындагы шикелле кулларын киң итеп җәеп, ишегалдының җылы, яссы ташларына сузылып ятасы, җаны авыртуын балык кебек бәргәләнеп сүрелдерәсе килә иде, ләкин ул Сөмбелгә тыныч күренер өчен бар ихтыяр көчен тупларга кирәклеген уеннан ычкындырмады. Аның Сөмбелне «Синең ни эшең бар? Ник катнашасың яисә тыкшынасың?» дип битәрлисе дә бик килә, ләкин ул үзен:

— Рәхмәт сиңа,— дияргә мәҗбүр итте.

— Кызык. Без бер-беребезне яраттыра да, читләштерә дә алдык.

Сөмбел торды, болдырга кереп, элгечтән кызыл сумкасын алып ачты да көзгесенә карап, каш-керфекләрен төзәткәләп куйды, иренәнә мул итеп куе чия төсендәге иннек сөртте.

— Кая барасың инде хәзер?

— Кая булсын, шунда — Океанга таба...— диде Сөмбел елмаеп һәм ялан аягына биек үкчәле сабосын киеп, кызчыклар шакмак-шакмак уйнагандагы шикелле, таштан-ташка сикергәләп алды.

— Таҗларың җитәр микән соң?

— Ә синең үз чәчәгеңә... хатының Солтания янына кайтыр өчен... йөрәгең җитәр микән, Аит?

Аит уңайсызланып китте. Әйтерсең лә чит өйгә килеп кергән дә, хуҗалары өйдә юклыгын күреп, ни калырга, ни чыгып китәргә белмичә аптырап басып тора. Андый чакта кая барып төртелергә белмисең. Утырсаң, тыйнаксызлыкта, әдәпсезлектә гаепләүләре бар, чыгып китсәң, тагын әллә ничек: бүлмәләреннән берәр әйберләре югалып, шуны синнән күрсәләр? Сөмбелгә бирергә кирәк булган җавапны аның үз-үзенә бирергә дә кыюлыгы җитмәс иде. Кинәт кенә ул үзен эченә таш тыгып куелган һәм аңа таба очып килүче туп каршында калгандай хис итеп куйды. Тотаргамы, тотмаскамы? Тотсаң, җәрәхәт аласың, тотмасаң — оттырасың. Читкә тайпылып калсаң, куркаклык санала. Анысы оят һәм хурлык. Әгәр дә ул хәзер Сөмбелгә, димәк, иң алдан үз-үзенә җавап бирмәсә, соңыннан хәтта үкенүе дә гарьлек булачак. Солтания...

«Туктале, каян белә ул?»— дип уйлады ул, менә хәзер, бу минутта гына булса да җавап бирми торырга сылтау табуына куанып. Куанып? Ул тагын оялып куйды. Ләкин инде ул:

— Син... аның Солтания икәнен каян беләсең?— димичә булдыра алмады.

— Теге пасха төненнән, Аит. Хәтерлисеңме?— Сөмбел аңа карт укытучы хатын сыман кырыс һәм үзенә буйсындырырга күнеккән кыяфәттә карап куйды. Аит аның күзләренең өченче көн танышкан чагындагыча, каршындагы кешене сынап, шул ук вакытта шукланып кысылуын күреп алды. Юк, өченче көн генә түгел икән шул, Сөмбел аңа шул пасха төнендә дә нәкъ шушылай караган иде түгелме соң? Аит, берничә минуттан теше сызлый башлаячагын сизеп торган кеше кебек, арыну чарасы булмаган курку тойгысына буйсына барганын тоеп алды. «Аның белән тагын бер тапкыр очрашыр өчен, шулай, яшәүнең дистәләгән үткелләрен, тарлавыкларын кичәргә, Солтанияне чыннан да читкәрәк куеп торырга кирәк булды микәнни соң?» Мондый хәлгә юлыгыр дип, ул башына да китерә алмас иде, ләкин чынбарлык, киселгән жирдән ага торган кан кебек, аның күз алдында лабаса.

— Ир кешенең кире кайтырга йөрәге җитәргә тиеш, Аит,— диде Сөмбел һәм, аның янына килеп, кулын сузды.

— Сау бул,— дип пышылдады Аит.

— Очрашканда исәнләшмәдек, аерылганда да саубуллашмыйк.— һәм Сөмбел зәңгәр күлмәк итәген җилпеп борылды да капкадан чыгып китте.

Аит ялгызы калды. Әйтерсең лә башын иеп, үзе менә алмаган тауның итәгендә басып тора. Ул әле кем дә аяк басмаган бер, үн, йөз тау башына менәргә, кыяларга күтәрелүнең мең газабын кичәргә, үз күңеленә җыела башлаган яшенле һәм күк күкрәүле давылларның һәммәсенә дә риза, риза, риза иде. Тик ничек тә егылып төшмисе, ә шунда, кояш янында каласы иде.

Ул, бераз нишләргә белмичә басып torгач, ишегалдына чыгарып ташлаган әйберләрне өйгә — элеккеге урыннарына ташырга керешге.

## Ундүртенче бүлек

Ике көннән соң, кичке сәгать алтылар тирәсендә, Мөкатдис Аитка хат кертеп бирде. Үрелеп алганда, хат күбәләктәй җиңел генә түгел, ә бөтенләй авырлыгы да булмаган почта бер кәгазь кисәге генә иде. Башта ул ирен чите белән генә елмаер-елмаймас төстә: «Сөмбелдәндер»,— дип кенә уйлап куйды. Конверт күнегелгән зурлыкта түгел, ә озынча һәм тар. Аның тышына күзен йөгертүгә үк,— әйтерсең лә Мөкатдис аның кулына хат сузмаган, ә очлы башы белән без сузып, ялгыш учына чәнчеп алды,— Аит кискен генә итеп аңа карап куйды, гүя кыя күкрәгендә асылынып торган җирәннән бауда үзеннән соң килгән альпинистның «Саклан — елан!» дигән боерыгына буйсынып, күз алдындагы бер уч үлән арасыннан маңгаена текәлеп торучы агулы еланның салкын карашы белән очрашты. Иң әүвәл ике көн элек үзе белән сөйләшеп утырган Мөкатдиснең — Солтаниянең әтисе — үзенә «бабай» тиешле кеше икәне исенә килеп төште. Нәкъ менә шушыны аның хәтеренә төшерергә теләгәндәй, Мөкатдис, гадәти булмаганча кыюсыз, шуны искәртергә туры килгәне өчен оялып, җитмәсә, элгәре үзенә кияү тиешле кешенең үзен танымавына бик эче пошкан кыяфәттә, хәзер икесенең дә бер-берсенә шушындый хәлдә калуларына уңайсызланып һәм үкенеп, бәләкәйләнеп, бетеп, коелып, ниндидер тирән бер сагыш белән тулып, Аит каршысына баскан да, әле хат сузган кулын да төшермичә, түзем белән генә үзенә рәхмәт әйтүләрен, я хушлашып кул сузуларын көткән шикелле басып тора иде.

Менә шушы хис һәм күренешне кичереп алгач, Аитның кулында күбәләк канаты шикелле генә җиңел булган хат кургаштан коелгандай авыраеп, салкынаеп китте.

Хат Солтаниядән иде.

Үзәкләрне өзәрдәе, бәгырьләрне кисәрдәе хатның аннан булуы, аларны үткәннәренә алып кайтучы бауны ике арадагы төпсез упкын аша Солтаниянең ыргытуы, ике йөрәк арасындагы кап-караңгы тынлыкта башта аның авазы яңгыравы гына да түгел, ич авыры каршындагы Мөкатдиснең иңенә төшкән теләсә нинди авырлыкны сабыр гына күтәреп тора алачагын белдереп, үзенә карап торуы иде.

Аит, хатны кояшка каршы куеп, кай яктан ачарга кирәклеген чамалап карады да, конвертның читен бармак очы белән генә чеметеп ерта башлады.

— Солтаниядән,— диде ул йомшак кына.

«Якыным Аит!

Авылыбыздагы өебезнең алмагачлары теге елны салкын тиеп корып беткәндер инде. Көзен яңа алмагачлар утыртасы булыр инде, әйеме?

Солтания».

— Яраса, миңа да укы әле,— диде Мөкатдис карлыккан тавыш белән һәм, тыңларга әзерләнгәндәй, сумкасының бавын җайлабрак куйды.

— Ярый, ник ярамасын! — диде Аит. Югартын бар нәрсәне изеп, сытып, ватып, чәрдәкләп, әвәләп ишелеп төшкән кар ташкыныннан кыяның тар кыегы астына елышып, үзе аша уздырып җибәргәч, бөтен күкрәге белән тауның сыек һавасын сулап алдымыни. Аның хәтта: «Ярый, ник ярамасын, бабай!» — диясе килгән иде дә, теле тыелып калды.— Алмагачлар корып беткәндер, көзен яңаларны утыртасы булыр инде, әйеме дигән... Утыртасы булыр, ник утыртмаска ди! Тел төбе ачык ук түгел түгелен...

— Нәрсәсе?

— Әллә миңа гына утыртырга кушкан, әллә үзе белән бергәләшеп...

— Сиңа, Аит,— диде Мөкатдис.— Берүзеңә.— Һәм ул йөге авырлыгына чыдап-чыдап та түзә алмагандай, капка баганасына сөялде дә шуның буенча аркасы белән шуып, җиргә сыерылып төште.— Солтания... бүген вафат булган ул, бичара. Без әнкәсе белән телеграмма алдык. Иөрәге, кияү. Әх, әх!..

— Бабай...— дип ыңгырашты Аит. Авыл күгенә борчак кырыннан кайтып килүче каргаларның шәүлә шикелле тып-тын көтүе килеп керде. Ул Солтаниянең тагын бер мәртәбә үзен «азат» иткәнен аңлап алды. Инде — мәңгегә. Ул аптыраудан, ни соң әле бу дип сәерсенүдән, мондый көтелмәгән, бу мизгелдә гадәттән тыш гайре табигый тоелган хәбәрне кабул итә алмыйча кулын җәеп җибәрде, әйтерсең лә аның алдына чиксез ераклыктан бер алма очып килә, аның шул алманы тотып алып, яланаяк һәм күлмәге суга чыланып беткән, маңгаена борчак-борчак тир бәреп чыккан Солтаниягә бирәсе килә. Ул аны учы белән сөртеп куяр да, елмаю белән тулы иреннәрен ачып җибәреп, тешләренең ак балкышын алма суы белән сүндерергә ашыккандай, зур итеп бер тешләп алыр иде. Һәм аның күкрәгендә җемелдәгән эре тир тамчылары белән ирен кырыеннан ияк очына сузылып төшкән, ә аннан күкрәгенә тамган алма суы бергә кушылыр иде.

Бөркетләр ояларын
ташлар иште түбән.
Кайда син? Ишетәсеңме:
Бу — минем тәүбәм...

Ишетәсеңме! Күкләр тыныч иде. Ә күкрәк, күкрәк...

*1981*

## Марс Шабаев

### Кеше булып...

Кеше булып туу нинди бәхет!
Карагыз сез сабый балага:
Биләвендә тибенгәләп ята,
Биләүләрдә дөнья тар аңа.

Нечкә муен чак күтәреп тора
Иләмсез зур башын,
Башында
Чәче дә юк әле,— мамык кына —
Аң чаткысы инде бар шунда!

Алсу йодрыкларын төйнәгән ул,
Күз йомылган, йөзе чытылган,
Телсез авыз сөрән салып сорый,
Ими сорап елый, чукынган!

Нәни тәннең һәрбер күзәнәге,
Көчәнүдән бүрткән кендеге
Сөткә сусый...
Нинди бөек,
Зур эш —
Авыз белән ими берлеге!

Кеше булып үсү нинди бәхет!
Төннәрендә, тәмле төшендә
Атына-атына көлә үсмер бала,
Көлә-көлә туплый көчен дә.

Тыгыз тәне тулыша, дәрт кузгала,
Ул дөньяга карый сөенеп.
Егет булып җитә, я кыз була —
Яшәү өчен сөеп-сөелеп!

Яшьлегендә аңа бар да гади.
Үтәлер күк һәрбер хыялы.
Диңгезләрне кичәр, океаннарны,
Буйсындырыр тауны-кыяны.
Галәмнәргә менәр — батыр булыр:
Ил-җир таныр аның эшләрен!

...Үссен кеше шулай, ышанып үссен,
Күрә-күрә матур төшләрен...
Кеше булып яшәү җиңел түгел!

Чәчләр сиздермичә агара...
Гомер үткәч кенә тотынмагыз
Хакыйкатьне эзләп карарга.

Көчең барда — җир җимертеп яшә!
Җир җимертеп эшлә ичмасам!
Ай-йолдызлы галәм кулмәгенә
Җир тузаны кунмас һичкайчан.

Кыска төннәреңә алмаш булып
Йокысызлар килер, озыннар...
Язмышыңны куркып көтеп ятма,
Язмышыңа каршы үзең бар!

Бер йокысыз төндә кинәт кенә
Яшен телеп үткән шикелле,
Хикмәтле уй килер синең башка...
Һәм син менә шул уй-фикерне
Байрак итеп күтәр:
— Кеше!— диген,—
Якты дөнья — синең тәхетең.
Мин телимен һәрбер адәм-затка
Кеше булып яшәү бәхетен!

Кеше булып яшәү җиңел түгел...

## «Кыйссаи Йосыф»ның бер нөсхәсен укыганда

Ул бер сәях. Илдән илгә күчкән,
Телдән телгә...
Киез тирмәләрдә йоклаган.
Зинданнарга кергән, сарайларга...
Аны кемнәр кулда тотмаган!

Дәрвишләргә иптәш-сердәш булган
Учак яктысында, эңгердә.
Ул ханнарның асыл кызларына
Сөю хисе салып өлгергән.

Ул үзенә җыйган бик күпләрнең
Күз карашын, аһын-зарларын.
Гасыр аша кичә-кичә килеп,
Җанны өтәрлеге бар аның.

Еллар аккан... саргылт кәгазь битен
Вакыт корты әзләп кимергән.
Гарәп хәрефләре төрки-татар
Фикерләрен безгә китергән.

Күп гасырлар үтеп, менә хәзер
Минем алда ята бу кыйсса.
Ул үзгәрәк кебек борынгыдан —
Эчтәлеге шул ук, югыйсә.

Ул үзгәрәк... Саргылт кәгазенә
Көлләр кунган, корым утырган...
Чит-читләре көйгән, күмерләнгән...
Гасырларның афәт-утыннан
Ул барыбер исән котылган.

Бер битендә — алтын тузан эзе,
Үткен күзгә күренер-күренмәс.
Нәрсә яшергәннәр? Кем хәйләсе?
Уйлагандыр: «Бу эш беленмәс...»

Бер битендә — майлы бармак эзе —
Берәр бәкме шунда актарган?..
Бер битендә — шыксыз тутык табы:
Калды икән нинди ал каннан?

Кеше каны белән сугарылган
Китап сыкрый,
Китап яралы...
Тарих,
Тарих, синең битләреңдә
Фаҗигале серләр бар әле!

Бу нөсхәне кемнәр күчергәндер?
Күчереп язу — оста кулга ни!
Тарих, әйтче: кабере кайда?
Кем ул —
Кыйсса иҗатчысы Кол Гали?

## Минем җанда...

Минем җанда һәр ни җавап таба:
Әйтелгән сүз, ымлы бер караш,
Тукай моңы, Сәйдәш аһәңнәре,
Чал чәчле карт, кыйгач кара каш.

Табигатьнең давыл-зилзиләсе
Кубарыла минем җанымда!
Яшеннәре яшьни, күкләр күкри...
Җаным аша еллар агыла.

Мин — Кайтаваз. Миндә бу дөньяның
һәр төсмере, һәрбер сулышы
Кабатлана... Төклетура гөҗли,
Ә җанымда — дөнья сугышы.

Язларында килми калса бар кош,
Җаным түрләрендә оясы...
Шатлыкларга урын табылыр ул,
Кайгыларын кая куясы?!

Давылларда Идел үрсәләнә —
Акчарлаклар елый, күрсәнә!
Җаным ачык. Мин аларны дәшәм,
Ышана белеп әгәр керсәләр.

Тыңлап кара: зеңләп, чыңлап тора,
Җырлап тора тормыш көнозын...
Җаным аша дөнья үзе ага...
Юкса мин дөньяның кеме соң?!

Минем җанда һәр ни җавап таба...

## Кеше кайчан үлә?

Авырганда уйлап яттым:
Кеше кайчан үлә?
Сез әйтерсез: мәгънәсезлек!
Моны һәркем белә...

Ә мин әйтәм: беләләрдер...
Ләкин күпләр белми.
Каберләргә кереп кенә
Кеше әле үлми.

Кеше үлми — шахталарда
Ташлар басып кына,
Җәллад аның башын кисеп
Яки асып кына.

Кеше үлми йөрәккәе
Өзелеп төшеп кенә,
Туфрак булып, үлән булып,
Шытып үсеп кенә.

Кеше үлми — иле өчен
Ут-ялкынга кереп,
Кеше үлми оныткannan —
Ялгышмагыз берүк!

Кеше үлә — мәхәббәтен
Изеп-таптап үтсә,
Хакыйкатьтән йөз чөерсә,
Аны атлап үтсә.

Кеше үлә — җиңел генә
Антын бозып куйса,
Бу дөньяда рәхим-шәфкать,
Миһербанын җуйса.

Кеше үлә — кешеләргә
Ышанычы бетсә,
Өенә, туган иленә
Бер хыянәт итсә.

Менә шунда кеше үлә!
Моны һәркем белә...

## Корыган имән монологы

Мин корыган... Мине киссәгез дә:
«Беткән...»— диеп рисвай итмәгез.
Башка сыйфат, башка рәвешләрдә
Яши алам әле — типмәгез!

Минем тамырларым җир-туфрактан
Яшәү көче алган,
Мәхәббәт...
Яшел туганнарым арасында
Мин мәһабәт идем, мәһабәт!

Берәр йортның нигезенә ятыйм,
Я матчасы булыйм — сыгылмам...
Гасыр буе җыйган ныклыгымны
Сез сынарсыз йөз ел соңыннан.

Миндә әле җегәр, миндә запас —
Дистә гомерләргә җитәрлек.
Ясагыз сез миннән имән өстәл —
Өсләрендә туйлар итәрлек.

Теләсәгез, тимер кыршау билле
Таза кисмәк миннән ясагыз:
Имән яфраклары тутырырсыз,
Кышкылыкка кыяр япсагыз.

Кирәк икән — капка баганасы
Чабып куйсын балта остасы.
Гашыйк парлар сөялергә булыр —
Тормышның бит юктыр туктасы.

Я булмаса,— әйтергә дә кыен...—
Сез кемгәдер табут коярсыз...
«Имән кебек таза иде...»— диеп,
Бер мәрхүмне җирләп куярсыз.

Соңгы чиктә, турап өегез дә
Утын булыйм — исраф итмәгез.
Салкын бәгыregезне җылытырмын,
Зинһар, тибеп кенә китмәгез!

*1981—82*

Мәгъсүм Хуҗин

# ӨЧ КАЕН ЫШЫГЫ

ХИКӘЯ



Урманның кырт борылышыннан төпсез сазлыкка хәтле төшен Бүре буйлыгы дип йөртәләр. Нәкъ борылышта карт имән бар. Шул учарлы имән төбендә Тимгелкүк ялгызы төн чыкты. Хуҗасы Гайнулла кичке эңгер-меңгердә калдырып киткән иде аны. Шуннан бирле баскан урыныннан кузгалганы юк Тимгелкүкнең. Кояш чык бөртекләрен елтыраткач, үлән чемченгән иде. Шуннан бирле авызына тәгам кергәне юк бичаракайның. Тимгелкүк тәмам хәлдән тайды, ә хуҗасы чыкмый да чыкмый. Авылдан урманга менүчеләр булса, Тимгелкүккә ярдәм итәрләр иде, берәү дә күренми шул...

Кичкырын Хөсния кер чайкарга инешкә төшкән иде, шуннан яңа хәбәр ишетеп менде: Посадскида ат өләшәләр икән...

— Җыен юк сүз чишмә-инеш буенда булыр инде,— диде Гайнулла, хатыны бу хәбәрне әйткәч.— Әллә син, сәвит керде дигәч тә, бушлай ат бирерләр дисеңме, зиһенсез.

— Өләшәләр икән шул, инеш буенда түгел, сәвитнең үз өе янында ишеттем бу яңалыкны,— дип исбатларга кереште Хөсния.— Атсыз хуҗалыкларга гына бирәләр, ди. Бөтенләй дә бушка, ди.

— Нинди атлар икән соң алар?— дип ышана язды Гайнулла.— Атсызлар бихисап, барысына да җитәрлекме икәнни шулай ук?

— Сугышта булган атлар, ди. Поездга төяп кайтарганнар Посадскига, тизрәк алырга кушалар икән. Бик хәлсезләнгәннәр, ди, шулай булмыйни соң, ничә тәүлек ашамый-эчми кайтсыннар да синә.

— Хәзер нәнүк менә чынга тарта кебек хәбәрең, Хөсниятттәй.

Гайнулла аумакай кеше түгел, ишеткәнен кат-кат төпченә, кылганын да зарурлыгына инанмыйча эшләми, аягын атлаганчы, басар төшенең ныклыгын капшап карый. Егет килеш Хөсниягә йортка кергәнче, күрше авылдагы берәүдән кердешнең хәлен тәфсилләп белешкән дә бу турыда Хөснияцең үзенә дә әйткән ул.

— Тик атлар яралы бугай.

— Шулай диләр аны элгәре үк, хәбәреңнең башы-ахыры моннан Посадскига хәтле, югыйсә. Менә хәзер сүзең дөрескә охшый. Яралы атларны, мантымас хәлгә төшкәнче, өләшү дөрес, әлбәттә.

— Нинди булса да ярар иде әле, абзарыбызга ат керер иде. Барып

карыйсыңмы әллә, Гайнулла? Асрар идек ничек тә, ярасын да төзәтер идек. Мин дә барыйммы соң синең белән? Алып кайтышырга булышырмын үзеңә.

— Куыра беләсең дә инде борчакны...

Хатынына бүтән сүз эндәшмәде Гайнулла, өйалды баскычына барып утырды да уйга бирелде.

...Нигә болай ук ашыктыра соң әле Хөсния, чыннан да атлы булу теләгеннәнме икән? Әллә йортка кергәндә синең, Гайнуллаш, мыскал хәзинәң дә юк иде, бушлай ат өләшкәндә авызыңны ачып калма, чабатаңны киен дә чыгып йөгер, кеше арасында, Гайнулланың үз аты, дигән сүзе ни тора, дип уйлавымы аның? Гайнулла аты, ә!.. Хакмы икән соң Хөсния хәбәре? Хөсния ялган сөйләми, гөнаһысына кереп булмый. Ул ялган сөйләми дә бит, әгәр аның үзенә ялган алкасы киертеп җибәргән булсалар? Тиз ышанучан Хөсниягә карап мина да ялганга сөрлегергәме? Әгәр чыннан да ат өләшә калсалар, һәм шул чакта мин һавадагы ваемсыз чыпчыкка мөкиббән китеп утырсам? Өләшүләре бик ихтимал, сәвитнең игелекле яклары шушы өч елда күп булды. Туктале, Гайнулла, ышанмавың аркасында мәсхәрә базына мәтәлмәгәең. Ә мәсхәрәнең авызы зур аның, йотарга гына тора синең кебек мәлҗерекләрне. Әйдә, чабата киндерәләреңне кысып бәйлә дә Хөсния хәбәренең дөреслеген-чынлыгын сәвит өенә барып белеш...

Хөсния иренең үз эченә бикләнеп утыруларына күнеккән инде. Шуңа күрә ул Гайнулланың бу юлы да телен йотуына исе китмәде, керләрен киртәгә элеп бетереп баскычтан менгәндә, дымлы кулы белән иренең чигәсенә кагылып алды да (уйла, янәсе, уйла!) өйгә кереп китте. Бераздан коштабак тулы бәрәңге кабыгы күтәреп кире чыкса, Гайнулланың, тумыштан гарип сул аягын яннан селтәп, капкага таба баруын күрде.

— Кая киттең? Ашның бәрәңгесен салам озакламыйча, кысыр аш тиз пешә ул.

— Эш чыкты,— диде Гайнулла, башын гына борып. Очлы озын нягге иңенә тиде. Күзләрендә сер уйный иде.— Эш чыкты,— дип кабатлады ул.

— Тагын ни уйладың инде? Аш өлгерткәндә генә табылып тора эше дә,— дип үпкәләбрәк әйтте хатыны.— Атка барырга, дигәч...— Хөсния иренең кинәт кул селтәвеннән бүленеп калды.

Совет йортына якынлашып килгәндә Гайнулла, элекке ниятеннән капылт кына кире кайтып, аскы урамга борылды.

Ат өләшү хәбәренең хаклыгын кемнәндер сорашсаң, дип уйлады ул, син беркатлы адәм, диярләр, ышандыңмы шул әрмичә шартлый торган куыкка, дип көләрләр. Әгәр чыннан да ат өләшсәләр? Алып кайта калса, безнең йорт яныннан узучылар, җирән яллы ак кашканың күккә чөелгән башын койма өстеннән күреп, шәп тә соң Гайнулланың аты, дип мактасалар? Иң дөресе, Гайнулла, әйдә, сыпырт туптурыдан Посадскига...

Бүре буйлыгында Тимгелкүк икенче төнен уздырды. Ул хуҗасы Гайнулла урман куелыгына кереп киткән төштә һаман да кузгалмыйча басып тора.

Бүген дә көн аяз килә, бүген дә чык бөртекләрендә кояш нурлары уйнар. Бүген дә чыклы үләннән авыз итәсе иде, азыгы-суы шул булыр иде. Әмма моның өчен көч кирәк, ә хәзер, башны түбән исәң, кире күтәреп булырмы? Ай-һай. Күкрәктән, бөтен гәүдәдән көч ташып торган чагы кайчан гына иде соң Тимгелкүкнең?

...Кылычлар бәрелешүдән беренче тапкыр колагы чыңлады, туп

гәрселдәвен беренче тапкыр ишеткәч, бөтен гәүдәсе калтыранды һәм дүрт аягына берьюлы чүкте.

Аннары... Аңа атланучылар алышынып торды. Алар утларга керделәр, сулардан чыктылар. Кайсы җирләр булды икән болар?

Аннары... Бөтен көчкә чабып барганда янәшәдә генә снаряд шартлады, аңа атланган яшь егет, гәүдәсен тота алмыйча, иярдән шуып төште дә җиргә йөзе белән капланды. Тимгелкүк тә шунда яраланды. Кайсы җир иде икән монысы?

Их, дөньяны беренче күргән чирәмлектән башлап узылган юллардан дуамалланып кабат чапсаң икән!

Хөсния ат җитәкләгән Гайнулланы олы капканы ачып каршылады. Тимгелкүк, ят ишегалдына кергәч, инде нишләтергә уйлыйсыз мине, дигәндәй, кешнәмәкче булган иде дә, тик күкрәк тутырып кешнәргә көче җитмәде.

— Әбәү, җаным ла, кайтып та җиттеңме үзебезгә!— дип, Хөсния атның кара ялыннан, каты маңгаеннан ике куллап сөяргә тотынды.

— Тимгелкүк аның исеме, Тимгелкүк, дип эндәш.— Гайнулланың озынча йөзендә масаюлы шатлык балкый иде. Хәзер масайсаң да урынлы лабаса — Кердеш Гайнулла атлы ир булды лабаса!

— Тимгелкүк, карының ачтыр инде синең, ни генә салыйм икән соң алдыңа? Гайнулла, нигә ипи алып китмәдең ашатырга?

Хөсния, җавап та көтмичә, өйгә йөгереп китте һәм, иренә калдырган кичәге ашны күтәреп, атылып та чыкты. Ат, үзенә азык китерүне сизеп, өйалды баскычына таба атлады. Хөсния коштабакны астыннан ике куллап тотты, Гайнулла ашка икмәк турады. Тимгелкүкнең иреннәре, ашка тигәч, дерелдәп алды. Ашны тиз ашап бетерде дә Гайнулла кулындагы икмәккә үрелде. Хөсния, икмәкне сындыргалап, ашатып бетерергә теләгән иде дә, ире каршы төште.

— Әнисе,— диде ул, хатынының җилкәсенә кагылып,— ач карынга берьюлы күп ризык килешмәс. Азрактан тагын ашатырбыз. Бая Тимгелкүккә чирәм чемчендереп кайттым, хәзер дә ашады, су эчертик үзенә.

— Чишмә суы җылынып җитмәгәндер, яңарак кына алып менгән идем. Казанда җылымса суым бар иде.

Суны да чама белән генә эчерделәр.

Май аеның соңгы көне кичкә авышты. Гайнулла белән Хөсния өйалды баскычының түбәнге басмасына янәшә утырдылар. Тимгелкүк, башын сырты биеклегендә генә сузып, яңа хуҗалары каршында басып тора. Беравык онытылып йоклап ала да Гайнулла белән Хөсниягә күзләрен тагын мөлдерәтеп карый. Ир белән хатын, хуҗалыкка сөенеч китергән Тимгелкүккә сокланып, әңгәмә коралар.

— Бирмәскә маташтылар бит башта миңа атны.— Гайнулла төргән тәмәкесен кабызмыйча артына куйды.— Тартмыйча түзим әле моны,— дип, сүзне кинәт кенә икенчегә борды ул.— Тимгелкүкнең борынына төтене керүе бар. Сугыш төтене дә туйдыргандыр инде аны. Һе,— дип елмайды аннары,— әле бит бер чүллине кыстырмакчы идем, атны юам, янәсе.

— Аласың калган соң,— диде моңа каршы Хөсния.

— Юк, кирәкми. Моңарчы авызга бер тамчы хәмер капмаганны атлы булгач кына аракы эчә башлау ярамый да ярамый инде.— Гайнулла, бераз уйланып торгач, ат алу вакыйгасына кабат күчте.— Әй-йе, бирмибез, атың юклыкка сильсәвит кәгазен китер, диләр.

— Ай-й аллам...

— Инде кире борылудан бүтән чара калмады, дип торганда, бәхетемә волость хуҗасы очрады. Гайнулланың аты юклыгын беләм, бире-

гез егеткә ат, диде. Тыңладылар волость хуҗасының сүзен, көтү булып җыелган атларның иң алдагысын җитәкләп китереп, нуктасыннан кулыма тоттырдылар.

— Тимгелкүкне инде, имә.

— Әйе. Ә исемен үзем куштым.

— Дөрес кушкансың исемен, Гайнулла. Күрче, үзе күк, үзе тимгелле.

— Ә мин ак яллы җирән кашка эләгер, дип уйлаган идем.

— Юк, безгә Тимгелкүк төс.

— Мин дә төс түгел димим ич. Анда, бәлки, ак яллы җирән кашкалар булмагандыр да әле. Булса да Тимгелкүкне алыштырмас идем мин.— Гайнулла хатынына елышыбрак утырды.— Тимгелкүккә кулым тиюгә үк, беләсеңме син, бөтен тәнемә җылы йөгерде, күңелемә бәхет тулды.— Ул хатынының иңенә кагылды.— Атлы булу бәхетеннән тилергән икән бу, димәсәң, тагын бер сүз әйтәм.

— Әйт, Гайнулла, әйт.

— Йөрәкләр кушылгандай булды безнең, Тимгелкүк белән минем.

— Шулай булмыйча соң! Без хәзер өчебез бер җан булдык. Синең белән мин — хуҗалар гына, ә нур — Тимгелкүкнеке.

Ир белән хатын, бер-берсенә елышып, сүзсез генә утыралар. Алар каршында, иркәләүгә-назлауга тансыклаган сабыйдай, Тимгелкүк басып тора.

— Арт санындагы ярасы зур инде зурын да,— дип башлады Гайнулла, атлы булу шатлыгыннан сөйләшмичә утыруны гөнаһка тиңләп.— Ите умырылган, әмма төзәлер дим мин аны. Шундыен да дәү ядрәләр белән атышалар инде сугышта.— Монысын ул, сугышны күрмәсә дә, атлы ир — чын ир булуына мактанып һәм сөенеп әйтте.— Безнең бәхеттәндер инде, сөягенә тимәгән.

— И-и, ярасын төзәтербез, алла боерса. Озакка китсә, дәвага сучәкән үләнен ничек тә эзләп табарбыз. Аннары, чабышка барасы юк, аксаклап йөрүе генә зыян итмәс.

— Анысы шулай. Менә мин дә кирәгендә аксаклап булса да йөрим бит әле, шөкерана.

— Яралы булса да, ат ат инде ул, Гайнулла, ат.

— Әнисе, Тимгелкүкне әйтәм, чабышкы булмагае, торыклары чабышкыныкына охшаган. Хәер, сугыш атларының барысы да диярлек чабышкы инде. Әмма Тимгелкүккә җитәрдәе булмагандыр кебек.

Алар атка тагын икмәк ашаттылар, су эчерттеләр.

Кич булды.

— Гайнуллакаем, бая нигә син миңа, әнисе, дидең? Безнең балабыз юк ич.

— Син дә бит миңа, Гайнуллакаем, дип эндәштең. Беренче тапкыр.

Хөсния иренең куенына сыенды.

— Гайнуллакаем...— дип кабатлады ул.

— Әнисе, мин йортка кергәнгә...

— Өйләнешкәнебезгә, диген.

— Өйләнешкәнебезгә инде дүрт ел булды, әмма балабыз юк шул. Булмас та, бәлки. Тимгелкүкне балабыз кебек тәрбия кылырга туры килмәгәе безгә...

Хөсниянең әти-әнисе киңәттән дөнья куйдылар. Шуннан соң буйга җиткән кыз кияүгә чыкты, дөресрәге, сөйгән егетен йортка кертте. Чөнки, йорт-җирне ташлап, кияүнең ишле гаиләсенә, болай да кысан йортка килен булып күчүнең хасияте юк иде. Матур гына яшиләр иде, тик балалары булмады да атка тиенә алмадылар. Ире герман сугышыннан кайтмады. Революция кубасы ел керер алдыннан, әллә инде

үзенең аксаклыгыннан хурланып кыз сорарга тартынганга, әллә чын нан да ятратканга, утыз яшен узып та сазау йөрүче Гайнулла тол Хөс ниягә сүз кушты. Инде дүрт ел әйбәт кенә гомер сөрәләр. Иккән ик мәкләре, асраган терлек-туарлары икесенә җитә, тик хуҗалыкны бө тәйтергә ат кына кирәк иде. Менә көтмәгәндә Тимгелкүкләре дә булды үзләренең.

Яратышалар идеме, әллә хөрмәт итешеп кенә яшәү дә икесене тыныч холык-фигыльләренә туры килә идеме, тол хатын белән кер дештән оешкан гаиләдә бу турыда моңарчы уйламадылар һәм сөйләш мәделәр.

Гайнулла белән Хөсния Тимгелкүкне тагын ашаттылар, эчерттеләр. Төн таңга авышты.

... Тимгелкүк Бүре буйлыгында икенче төнен чыкты. Ялгызы. Хуҗа сы һаман юк. Тимгелкүк, чыклы үлән чемченеп капкач, авырлык белән генә башын күтәрде. Их, күккә чөйсәң икән башны!

Ә ул төннән соң нәрсәләр булган иде әле?

Тиз иләште Тимгелкүк Гайнулла белән Хөсниягә, яңа хуҗалар да яратып карадылар атны. Тимгелкүк бераз тернәкләнгәч, Гайнулла аны, тезгененнән җитәкләп, урам әйләндереп йөртте, кырга алып чык ты, тора-бара урманга — Бүре буйлыгына хәтле менеп төшәргә га дәтләнделәр алар. Ярасын яңа тире каплый башлады.

Беркөнне Тимгелкүк, Хөсния чиләк-көянтәсен күтәреп капкага юнәлгәч, аның артыннан иярде дә, ябылырга өлгермәгән капканы этеп, урамга чыкты.

— Кечкенә баладай ияреп йөрисең килдемени, әйдә алайса, кит тек. Апаеңа су алып менәргә булышырсың,— диде Хөсния, атны иркә ләп.— Гаҗәп тоеладыр инде сиңа авылда, туп тавышы ишетеп, үлем күреп гадәтләнгән җанга.

Тимгелкүк тау башында басып калды, Хөсния су күтәреп менгәч, авызын чиләккә тыкты.

— И-и, балакай, чистага тота торган чиләгем иде ләбаса.— Тимгел күк судан авызын алды, артка чүгә төшеп, ал аякларын тышаулы ат тай күчереп, кайту ягына борылды.— Ачуланмыйм ич, әйдә, эч. Әллә үпкәләдең инде.

Инеш буйларына һәм чишмәнең сөзәк тавына иләнгәч, Тимгел күк, алгы аякларын терәп, аска да төшә башлады, ә менгәндә — сол дат гадәтен итә — юырта иде.

Бер көнне Гайнулла аңа камыт киертте, Тимгелкүк беренче мәртә бә тәртә арасына керде. Камыт кытыклавына озак күнегә алмады ул.

Бер кыш узгач, Тимгелкүкнең ярасы төзәлде, ат көрәйде, тимгелләре елтырый башлады. Аны савыктырыр өчен сучәкән үләне эзләүнең кирәге булмады...

Сабан туе алдыннан Гайнулла Хөсниягә:

— Әллә, энисе, Тимгелкүкне чабышка җибәреп карыйбызмы?— дип әйтә куйды.

— Кирәкмәс, Гайнуллакаем, ат азапламыйк.

— Чабышкы бит ул безнең Тимгелкүк!

— Артта калса тагын...

— Беренче килә, дим. Чын әгәр! Тәртә арасына кергәч тә чабасы дип кенә белә Тимгелкүк. Арттан килсә дә хурлык түгел, яралы ат тан көлмәсләр.

— Көлүче булмас та анысы... Артта калган атка карчыклар сөлге бәйләгәндә, минем болай да күңелем тула. Карчыкларның Тимгелкү-

гебезне хурлыктан йолырга тырышуларын күрсәм, бөтен сабан туена кычкырып елармынмы?

— Еласаң да, Тимгелкүкнең баш килүе шатлыгыннан еларсың

...Сабан туенда атларны Бүре буйлыгындагы учарлы имән яныннан авыл кергәндәге үзәнгә тикле чабыштыралар, юл монда тигез һәм киң.

Тимгелкүккә Гаян атланды.

— Тезген белән дә суга күрмә атка,— дип өйрәтте аны Гайнулла.— Яратмый сукканны-ачуланганны, иркәләүне ярата, сугышта кыен күреп тә гарыктыр инде ул. Калдыр камчыңны.

— Гайнулла абый, дим...

— Камчы кирәкми аңа. Калдыр, югалтмыйм.

— Гайнулла абый, чабышта ат өстендәге малай камчысыз буламы инде? Мәйдан әйләнгәндә, үзем үргән камчы белән мактанасым да бар бит әле минем! Менә күрерсең, Гайнулла абый, Тимгелкүккә камчының очын да тидермәм.— Гаян камчы бөлдермәсен беләзегенә киде.

Ризалашмыйча булдыра алмады Гайнулла бу дәлил белән, әйе, чабыш атларының мәйдан әйләнәселәрен һәм малайга шунысы күбрәк горурлык китерүен онытып җибәргән иде ул.

Баш килде Тимгелкүк, йорттумаларны әл-л-лә кайларда калдырып килде.

Тирә-юнь авылларда аңа тиң чабышкы бүтән елларда да булмады. Чабыш атын махсус тотучылар Гайнулладан Тимгелкүкне сатып алырга теләделәр, НЭП тудырган бер бай, ике атымны бирәм, дип кызыктырып та карады. Сатмадылар да, алыштырмадылар да Тимгелкүкне. Нигә аерылсыннар ди алар аңардан. Гайнулла белән Хөснияггә дан китергән, юк, дан гына түгел, бәхет китергән Тимгелкүк ләбаса ул! Алай гына да түгел, Гайнулла белән Хөсниягә Солдатлар дигән кушамат тактырган Тимгелкүк ич ул! Монысы аксак Гайнулла өчен аеруча шатлык иде.

Тимгелкүкне хуҗасы калдырып киткән төштә көтәргә өйрәттеләр.

Учарлы имән төбендә хәзер дә Гайнулланы көтә ул. Көтеп торумы соң бу? Кузгалырлык та хәлең булмагач, хуҗаң килсә дә ярдәм итә алыр микән?..

Тимгелкүк быел печән өстендә ашаудан язды, Гайнулла белән Хөсния күпме тырышып тәрбияләсәләр дә, күзгә күренеп ябыга-кибә башлады.

Учарлы имән янында Тимгелкүкнең нигә ялгызын калдырды соң ул? Чабышкысының үлемен күрәсе килмәдеме? Әллә бүре буйлыгында бүреләрдән ашату өченме? Юк, хуҗасы турында алай уйлау гөнаһ булыр.

Кая югалды соң? Килергә тиеш бит инде ул, Тимгелкүкнең хәлен аңлый бит. Урманда Тимгелкүкне савыктыра торган үлән эзләп йөридер ул, әлегә таба гына алмыйдыр, табуга, аксаклап килеп тә җитәр. Әллә адаштымы икән? Әллә Тимгелкүкне савыктыра ала торган үләнне эзли-эзли арып, урыныннан кузгалырлык хәле юкмы? Әйләнеп килергә тиеш Гайнулла, куелыкка кереп киткәндә, көтәргә кушты кебек ул Тимгелкүккә. Теге үсемлекне ашагач, Тимгелкүк савыга да савыга инде.

Тимгелкүк, соңгы көчләрен җыеп, алгы аякларын алмаш-тилмәш күчерә-күчерә авылга таба борыла башлады. Ниһаять, аның аяклары сабан туйларында үзе ничә тапкырлар чабып узган юл катысын тойды, һәм Тимгелкүкнең тәненә көч тулгандай булды. Көчле ат алга омтыл-

мыйча түзә диме инде — Тимгелкүк авылга таба ыргылып чабарга теләде.

Тукта, хуҗасы кала, аның ялгызын ташлап китәргә ярамый, солдатча булмый бу. Хөсния көтәдер көтүен, тик бит ул Гайнулланың һәм Тимгелкүкнең бергәләп кайтуларын көтә. Көтәдер. Аларның таң беленгәнче үк чыгып китүләрен сизми дә калды бугай ул.

Тимгелкүк кирегә борылды — соңгы көч тә көч икән ул!— һәм Гайнулла эзеннән ешкынлыкка кереп китте. Үзе табачак ул хуҗасын, үзе!

Хөсния сөйләгән иде сучәкән турында. Бүре буйлыгындагы шушы учарлы имән янынннан туп-туры керәсең дә, барасың да барасың... Кая барасың? Менә анысын белмиләр Хөсния белән Гайнулла. Сучәкәннең кайда икәнлеген белүчеләр бар, әмма моны бүтәннәргә әйтергә ярамый, үләнне кирәге төшкән кеше үзе эзләп табарга тиеш. Тагын бер шарт һичшиксез үтәлергә тиеш: сучәкәнгә баручы бу турыда берәүгә дә әйтмәскә, үзе белән бер генә җан иясен дә ияртмәскә тиеш. Шушы шартларны үтәмәсәң, үләннең шифасы тими, ди.

Ачау урманында гына үсә торган сучәкәнне борын заманнардан ук авыру атны савыктыру өчен эзләгәннәр. Бу үләннән авыз иткән ат яңадан туган кебек була, аның төнәтмәсен сөртсәң, ярасы кул белән сыпырып алгандай төзәлә икән. Борынгы бабаларыбыз яуда кылыч яралаган атларны шулай дәвалаганнар. Ни хикмәттер, атларга гына шифасы тия икән сучәкәннең. Өстәл кадәр генә төштә үсә икән ул. Тагын шунысы да бар: ана бүре саклый икән аны, ул азык эзләргә киткәндә генә алырга мөмкин икән сучәкәнне.

Сугыштан алган ярасын төзәтергә кирәге булмаган иде үләннең. Гайнулла белән Хөсния булышкач, яраны төзәтергә Тимгелкүкнең үз көче дә җиткән иде. Бу юлы да савыгыр, дип өметләнгәннәр иде Гайнулла белән Хөсния. Хәзер исә бик кирәк Тимгелкүккә сучәкән. Шуны авыз итсә, чабышкы көче, ярышу дәрте, яшәү бәхете тагын кайнар иде аңарда. Һәм Гайнулланы атландырыр иде дә бәхет кошыдай очар гына иде ул Хөсния янына!

Гайнулланың сучәкәнне эзләп киткәненә ике тәүлектән артты. Хәзер Тимгелкүк аның артыннан бара. Соңгы көчләрен җыеп...

Сазламык беткәч, калкулык башлана. Шул төштә, ябалдашларын кыйблага янтайтып, өч каен үсә. Гайнулла, уртадагы каенга терәлеп, кыска аягын янга сузып, хәрәкәтсез утыра, сул кулы салынып төшкән, уңын, сучәкән тотып, күкрәгенә кыскан. Йөзендәге төкләр өстеннән кырмыскалар чабыша, алар керфекләргә бәреләләр дә, тонык күзләрне күреп читкә тайпылалар. Әйе, сучәкәнне тапкан ул, тик озак эзләп бик йончыган, тәмам хәлдән тайган, шушы әрсез кырмыскаларны куарлык та көче калмаган.

Ашык, ашык син, Тимгелкүк! Сучәкәнне тәмләп ашагач, яратып биленә Гайнулланы атландыр да Хөсния янына алып кайт. Хуҗаң сине үлемнән коткара, син дә аңа изгелек кыл,— бөтен өмете синдә аның.

Тимгелкүк хуҗасы янына җитеп килә, өч каен ышыгы менә генә инде.

Һәм Гайнулла сәерсенеп беравык чабышкыга карап торды да, кинәт аңына килеп, күзләре аера башлагач, шифалы сучәкәнне хәлсез кулы белән Тимгелкүккә сузды.

## Лирон Хәмидуллин

*Тәрҗемәче һәм прозаик Лирон Хәмидуллинга бу айда 50 яшь тула.*
*Аның беренче хикәяләр җыентыгы 1968 елда басылып чыга. Шулай ук үзе эшләгән мөхитне — тимер юл төзүчеләр тормышын чагылдырган «Дала иртәсе» дигән повесте да аерым китап булып басыла.*
*Лирон Хәмидуллин күп еллар инде СССР әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры булып эшли, тәрҗемә белән шөгыльләнә. Тугандаш халыклардан — казакъ, үзбәк, каракалпак язучыларының әсәрләрен татар укучысына җиткерүдә аның мәгълүм өлеше бар. Аның тәрҗемәсендә үзбәк язучысы Ә. Мохтарның «Чинар» романы, казакъ язучысы Ә. Әлимҗановның «Отрар хатирәсе» татар телендә дөнья күрделәр.*
*Журнал редколлегиясе исеменнән без Лирон Хәмидуллинны 50 яшьлек юбилее белән котлыйбыз һәм бу санда аның «Буранлы төндә» исемле яңа хикәясен укучыларга тәкъдим итәбез.*

# БУРАНЛЫ ТӨНДӘ

ХИКӘЯ

I



Текә Яр бүлекчәсе бригадиры Зәкәрия өчен әллә ничегрәк, көтелмәгәнчәрәк килде әле бу кыш. Юл эшенең бигрәк тә шушы айларда авыр буласын ул әзме-күпме белә дә иде шикелле, әмма болай ук йончытасын, ыжгырган җиле, бетмәс-төкәнмәс карбураннары белән бу кадәр теңкәгә тиясен белеп тә җиткермәгән, күрәсең. Хәер, уку дәверендә үтелгән бер-ике айлык практика вакытында ниләр генә күреп тә, ниләр генә белеп бетерәсең инде?! Ни дисәң дә, ул вакытта җаваплылык әле барыбер башкалар өстендә булган, ә практикант Зәкәрия аләр ышыгында торып кына бригадирлык иткән икән. Ә хәзер сигез километрлык юл бөтен авырлыгы белән аның җилкәсенә басып тора. Түзсәң түз, түзмәсәң, оятыңны җилкәңә атландырасың да, чыгып качасың инде бирегдән.

Дүрт-биш иске барак-казармадан, бер уч йортлардан гыйбарәт булган Текә Яр разъездында тормыш, шау-шулы дөньяның нәкъ үзәгендә торган кебек булса да, Зәкәриягә ул җир читендәге онытылып беткән аерым бер утрауны хәтерләтә башлаган иде. Хәер, андый пункт, бригадир бүлмәсенең бер стенасын алып торган тимер юл картасында бөтенләй үк юк иде шул. Урал-тауны буйга да, аркылыга да телгәләп үткән, урыны-урыны белән, үрмәкүч тозагын хәтерләтеп, бер урында болгана-чолгана чуарланып беткән ул кызыл сызык юлларда күпме шәһәр, күпме станция исеме язылган булса да, кыя-таулар арасына кереп, тарлавык төбенә төшеп утырган Текә Яр анда бөтенләй юк иде. Дөрес, андый билгесезлекне бик үк өнәп бетермәгән Зәкәрия, килеп эшли башлаган көннәрендә үк, картадагы кызыл пәрәвез челтәренең

бер төшенә — исемнәре таныш ике станция аралыгына шәмәхә кара белән тәртке төртеп куйган иде. Чама белән Текә Яр әнә шунда, тырнак буе араның кыл уртасындагы шушы ноктада булырга тиеш иде. Әмма аңа карап кына ялгызлык, ташланганлык хисе үзгәрмәде, торабара чиргә әверелә башлады шикелле.

Ә бит кайчан гына әле билгесез бу ноктага ул олы эшләр башкарырга ниятләп, канатланып килгән иде. Һәм ул вакытта шушы шыксыз разъезд аны үзенә бер сөенеч белән, табак-табак сары кояшлары — көнбагыш башлары белән көлеп-елмаеп каршы алды. Хәтта Текә Ярны камап алган әлеге кара-кучкыл текә таулар да ул чакта алай ук шыксыз, яман күренмәделәр. Киресенчә, күңелкәйне җилкетеп, иртә-кичен үзләренә әйдәп, дустанә сокланып тордылар шикелле. Зәкәрия аларга шундук балаларча гашыйк булды. Килеп урнашуының икенче көнендә үк, олы туганы белән көрешергә ашыккандай җилкенеп, шул тауларга менеп китте. Ул вакытта иң текә кыяга үрмәләү дә җиңел тоелган иде. Күккә ашып, тау-таш иңнәренә баскан килеш еракларга төбәлеп басып тору үзенә бер могҗиза, ләззәт бирә торган иде.

Ә хәзер әнә шул таулар, шул кырыс кыялар никтер аның җанын кысрыклыйлар, иркенләп хәрәкәт итәргә дә ирек бирмиләр сыман. Шулар тотмаса, күптән инде ул бу кар базыннан чыгып киткән булыр иде, күптән инде тормыш кайнап торган зур станциягә барып җитәр иде. Аның күз алдына шау-гөр килгән, купшы киенгән кешеләр тулы шәһәр урамы килеп басты. Тик ни хикмәт, бу — нәкъ урам уртасында рельс, шпаллары белән калкып торган тимер юл икән ич. Станция урамымы соң бу? Һәм нишләп әле бу ачулы йөзле адәм заты аңа, Зәкәриягә, алга үтәргә ирек бирми, төрле яклап кыса, этенә соң? Һәм нишләп аның булышчысы, уң кулы булып исәпләнгән Карәмәт тә аңа шундый кырыс итеп карый да йөзен яшерә, карый да йөзен чыта. Поезд килә түгелме, Зәкәрия өстенә килә, тизрәк тайпылырга, читкә чыгып калырга иде бит! Әнә инде урам да калтырана башлады, зур гына тепловоз, иләмсез гәүдәсе белән бөтен нәрсәне томалап, аның колак төбендә үк «пуф-пуф» килеп пошкырырга кереште. Килеп җитә, өскә менә бит инде, ә Зәкәрия һаман баскан урыныннан кузгала алмый азаплана...

## II

Тышта җил улавын тыңлап, ни гомерләр шушындый уй-саташулар кичерешендә яткан Зәкәрия берөзлексез челтерәп торган телефон тавышына уянып китте. Ашыгып, бүлмәнең каршы ягындагы эш өстәле янына, телефон аппаратына ташланды. Тәрәзәне калтыратып, казарма стенасы яныннан гына, авыр йөк төягән составның текердәп үтеп баруы ишетелеп тора иде.

Менә вагон тәгәрмәчләре рельслар тоташкан җөйгә ешрак бәрелә башлады, димәк, составының башы инде разъезд стрелкаларын үтеп, туры юлга ук барып чыккан. Машинист халкы гел шулай бит: хәтәр урыннан тепловоз ераклаштымы, койрык турында уйлап тормый, тизрәк рычагка үрелә, тизлекне арттырырга тотына. Шуннан инде койрыктагы вагоннар да, атасыннан калышкан малай шикелле, кая барып бәрелергә белми айкала-чайкала чабыша башлыйлар. Шул вагонның берәрсе юлдан мәтәлеп төшсә, юлчыларны гаепләячәкләр.

Гадәт буенча: «Әһә, туктап тормады, димәк, каршыда әле поезд юк», дип уйлап алды Зәкәрия. Берәр ел элек аңа, син шулай һәр поездны күңелеңнән уздырачаксың, дип әйтсәләр, ул һич тә ышанмаган булыр иде. Кайберәүләрнең: «Төштә дә поезд күрә башладым инде» дигәненә дә ул ышанмый иде. Хак әйткәннәр икән ләбаса.

Зәкәриянең соңгы берничә көндә кәефе начар шул әле. Җил-суыкка чыкты исә, тәне өшеп чымырдарга, калтыранырга керешә, бөтен

тәнен салкын тир каплап ала. «Жан тирләрең чыга башлар әле бер заман»,— дигәннәр иде аны, әллә дөрес инде?! Булмас ла! Юк сүздер... Тик әллә шул чир, әллә шул тир дигәндәй, ни зәхмәттер, шундук хәле бетә, үз гәүдәсен үзе чак күтәреп йөрер хәлгә кала башлады. Әлерәк кенә, разъездның ике башындагы стрелкаларны кардан арындырып, поездлар йөрешенә иминлек биреп торучыларның эшен күзәтеп кергәннән соң, шул хәлсезлектән интеккәнгә күрә урын өстенә ауган кеше ул. Чак кына ташкүмер исе аңкытып, такта бүлмә аша урын-җиргә жылы бәреп торган мич янәшәсендә төрле юк-бар күңелсезлекләрне уйлап ята-ята Зәкәрия бастырылып ук киткән. Юкса бит өстәлендә аны бер атналык кәгазь эше дә көтә. Бүген, ял көненә, тартмыйсузмый гына шуларны эшләп ташлармын дип күңеленә беркетеп куйган иде.

Дулап-дулап телефон шылтыравын ишетүгә, ул бая җепшек карда йөреп иңбашлары дымлана төшкән тунын өстеннән алып ташлады да ялгызак бүлмәнең түр башына таба атлый-йөгерә китте. Ни булган тагын? Ял көне дә бераз гына хәл алырга бирмиләр бит. Маруськасы белән әрепләшүдән туйган мастеры шулай тансыклагандыр инде. Нишләп атналык сводканы һаман хәбәр итмисең, дип бәйләнергә ниятлидер.

— Туйдым, гарык бу эштән. Бер ял күргән юк! — дип зарлана-зарлана ул өстәл янына килде, телефон трубкасын алды.

— Әлү! Бригадир тыңлый!— диде ул телефон трубкасына.

Станциядән шалтыраталар икән. Тик бу юлы мастерлары түгел, баш диспетчер үзе булып чыкты.

— Хәлил кичүе янында рельсагыз сынган. Обходчик Хисмәт шунда, поездны туктатып әйткән. Чарасын күр, бригадир! Ашык!— дип боерды бу.

Диспетчер әйткәнчә, рельс «сынган» булса, поездлар йөрмәскә тиеш иде. Ә бит ул яктан әле генә состав үтте. Димәк, бөтенләй үк шартлап сынмаган, чатнаган гына булырга тиеш. Зәкәрия өчен аның һич югында чатнаган гына булуы хәерлерәк. Сынса, эш хәтәррәк, хәрәкәт туктала, бригадир өстенә шелтәләр, комиссияләр ява башлаячак.

Кичә генә борынны өзеп алырдай суыклар иде, бүген әнә җепшек кар ява — бер төндә җил көньякка авышып өлгерде. Моның нәтиҗәсе — корыч рельс, гадәтенчә, бу хәлгә сизгеррәк булып чыккан. Хәер, кеше дә шулай бит, нәкъ корыч шикелле, алын-ялын белми эшли-эшли дә, көтмәгәндә генә кылт итеп сынып та куя.

Күңелендә шундыйрак уйлар, ә үзе ашыга-ашыга киенә Зәкәрия. Бригададан кемнәр өйдә соң бүген? Ирле-хатынлы Карәмәтләр, Маһинур булыр. Тагын... Жәл, Вәлиәхмәтләр юк. Үзе дә, олы улы да туйга дип сорадылар. Зәкәрияне дә бик кыстаганнар иде.

Вәлиәхмәт бабайга үпкә юк, барсын, йөрсен, рәхәтләнеп туй итсен. Өч-дүрт көн элек алар, икәүдән-икәү генә, шушындый ук хәтәр хәлгә тарыкканнар иде. Ул чакта диспетчер аны, Зәкәрияне, шулай ук төн уртасында йокыдан торгызды. Хәвефле итеп:

— Харап булдык, Зәбиров, җиде йөз алтынчы километрда полувагон сүтелгән, юлга бүрәнәләр коелган! Поездларны җибәрми торам! Бригадаң белән тизрәк шунда ашык!— дип хәбәр салды. Шунда ук Зәкәрия каударрак холыклы Серафима Петровнага шалтыратты:

— «Четный» әкренләп каршыга чыга торсын, ул-бу булса, шунда көтәр. Без киттек,— диде.

Андый вакытта икеләнеп торып эшне сузарга ярамый шул. Юлдагы хәлне белгәч тә нидирәк корал, ничә кеше аласы хәл ителде. Ул вакытта Зәкәрия, иптәшкә бер кеше җитәр дигән фикердән чыгып, шул казармада яшәүче Вәлиәхмәт картны гына уяткан иде. Алай-болай тагын берәрсе кирәксә, чиратлашып юл карап йөрүчеләрдән кем дә булса очрар әле дип тә өметләнде ул.

Әйе, ялгышмаган икән, караңгыда атлый-йөгерә, абына-сөртенә өч километр ярым юл үтеп, ак кар өстенә сузылып яткан нарат баганалары янына килеп җитсәләр; Апанасова инде анда иде. Көче дә юк инде бичара карчыкның, ә бит үз постында, чара күрергә тотынган. Аңа рәхмәт дими, ни дисең. Юл караучы Настя Апанасова белән Вәлиәхмәт картка булган рәхмәтен иртән Зәкәрия бөтен бригада алдында да кабатлады. Кешенең яхшы эше бервакытта да онытылмаска тиеш.

Ихлас күңелле, күндәм холыклы Вәлиәхмәт бабайны бригадир аеруча хөрмәт итә иде. Тик әле пенсия яшенә дә җитмәгән кешегә барысының да шулай «карт» дип, «бабай» дип эндәшүенә генә баштарак бик аптырады. Бу хәлгә әллә тегенең сүрәнрәк йөз-кыяфәте, әллә балачагасының күплеге сәбәпче иде инде, белмәссең. Шунысы хак, «бабай да бабай» дип, аяк астында чуалган оныклары таш казарманың ике бүлмәсен тутырырлык. Анда-монда җиңел эш эзләп йөреп гомерен әрәм-шәрәм итмичә, юл карауга багышлаган, ни кушсаң, шуны җиренә җиткереп, кабат тикшереп тормаслык итеп эшли торган намуслы кеше.

Димәк, аның «актив»ы да — иң якын торганы — Шәмселбану апакай. Кар көртләрен ера-ера, ул рәттән торган ике озын казарманы үтеп беренче «частный» өй ишегенә барып төртелде. Чоланның аргы башындарак Шәмселбануның нәселле кәҗәләре, вак энҗе тешләре белән печәнне кемерт-кемерт иттереп күшәүдән тукталдылар. Хуҗабикәләрен затлы шәллек йон һәм куе каймаклы сөт белән тәэмин итеп торучы шушы нәзберек җаннарны өркетмәс өчен кояш баеганнан соң бу йортка аяк басмам дип ант иткән Зәкәрия менә бүген тагы керергә мәҗбүр булды.

Атнага алты көнен эштә уздырган кешене ял көнендә дә эшкә чакыруы, билгеле, ансат түгел. Текә Ярда исә бу хәл тагын да четереклерәк. Һәркемнең үз малы, үз хуҗалыгы бар. Димәк, аларның ашыгыч эштән баш тартыр сәбәпләре дә җитәрлек. Сыерым бозаулап тора, кәҗәм сырхау, дияргә була...

Зәкәрия атылып-бәрелеп ишектән килеп кергәч:

— Әйдә, Шәмселбану апа, эшкә! Киен тизрәк!— дип әйтте дә салды. Вакыт тар, озаклап аңлашып торыр чак түгел иде.

Шәмселбану апакаең андый ашыгуларны гына күргән кеше шул. Иң әүвәл ул, фәләндә-фәләндә булдыңмы дип, һәркемнең кайдалыгын барлап чыкты, аннары гына:

— Әһ, хәерсез дә эш булды инде... Әүвәлрәк хатын-кызны төннә йөртмәс иеләр... Кадалгыры, бак тутырып кер куйган ием, ул нишли инде хәзер,— дип зарланырга кереште. Һәм керен дә, дөньясын да «сыйфатлап» алды, ә Зәкәрия тизрәк чыгып ычкынды. Эшләр кеше булса, бригадир аңа кагылыр идеме, ни дип пыр тузына инде?

Билгеле инде, Маһинуры да аны көтеп тормаган. Ул да аңа:

— Хәзер колхозда да болай куаламыйлар. Көн эш, төн эш...— дип сөйләнә-сөйләнә киенер-киенмәс кенә ишекле-түрле йөренде.

Зәкәрия дә үз чиратында: «Алайса колхозыңа әйләнеп кайт», дип чак ычкындырмады. Кендекләре колхоздан күптән өзелгәннәрне рәнҗетү булып кына яңгырар иде шул.

Башкаларга әйтәсе тиргәү, битәрләү сүзен үзенә таба борды Зәкәрия. Бу кадәрле дә мәшәкатьләрне үз өстенә алырга кем кушты соң? Үз мокытлыгы аркасында гына килеште түгелме соң бирегә бригадир булып килергә. Зәбиров иптәш, сине шундый-шундый җаваплы бүлеккә башлык итеп җибәрмәкчебез, янәсе. Чөнки син андагы җирле халыкның телен дә беләсең, җитәкчелек тәҗрибәң дә бар. Как-никак, хәрби хезмәттә дә отделение командиры, ефрейтор булгансың. Белемең дә җитәрлек, янәсе. Ә тәҗрибәне эшли-эшли туплыйлар аны... Алын, эшлә, баш бул. Шулай мактап башын әйләндерделәр Зәкәриянең. Ме-

нә булдың инде «баш», үз башыңа! Партадаш малае Вася, әнә контора гап-гади техник вазифасын үтәп йөрсә дә, менә дигән зур станциядә, кеше арә ында яши. Сигез сәгатен тутырып кайта да рәхәтләнеп ял итә, ичмасам. Эштән буш вакытын һәрчак үз иркендә. Танцыларга, киноларга йөрим, дигән әнә. Мен рәхәттә яши малаең. Зәкәрия кебек көн-төн мондый җәһәннәм базында иза чикми, чиләнми, талашмый.

Талашу дигәннән, эштә уң кулы, ярдәмчесе саналган Карәмәт белән соңгы көннәрдә аралары салкынаеп китте әле аларның. Ә бүген аңардан башка адым да атларлык түгел. Бар өмете — Карәмәттә. Килеләнмәсә, аяк өсте булса — уңарлар. Бәхете булмаса — Зәкәриягә әлеге ике-өч пенсионер апакай белән төн ката җәфа чигәргә генә кала. Кыш уртасында рельс алыштыру уен эш түгел — көч тә, куәт тә кирәк аңа. Җитмәсә, ул ярты тонналы тимерне биш чакрымга сөйрәп барасылары да бар бит әле.

Зәкәрия тиз генә кул сәгатенә күз төшереп алды — чыгып чапканына нибары сигез минут үткән. Димәк, Хисмәт янында ул-бу булмаска тиеш. Менә-менә берәр поезд гөрелтесенең кайтавазын Кыя тау ишеттерер. Кыя тау ул авыл мәйданына куелган репродуктор кебек: аңда тепловоз сызгыртса — сулдан кычкыртып киләдер сыман.

Ир уртасы Карәмәт — бригадирның тоткасы. Эшкә бар яктан да уңган кеше. Дуамалланып тотына да, башкалар алай-болай иткәләгәнче, ялт иттереп үз эшен очлап та куя. Күршесе Хисмәт, үртәлү һәм соклану катыш бер хис белән: «Җен бит ул. Өендә ни кыланганын күрмисез әле сез аның»,— дип тикмәгә әйтми, ахры. Дөрестән дә җен менә, бер тотынса, көч-кодрәт соралган берни аңа түзми. Әмма яман чире — киреләнү гадәте бар. Бер кирегә китсә, аңа ялынмавың хәерлерәк — ул чакта игелек көтмә инде аңардан. Балта-көрәген күтәрер дә өенә кайтып китәр. Үз бәһасын белә кеше!

Менә шул Карәмәт белән алар беркөнне бик каты сүзгә килештеләр. Бер сәбәпсез диярлек. Ул көнне Зәкәрия үзен болай да җил уңаена бөтерелеп очкан кар бөртегедәй хис итә иде. Иртәнге якта мастер белән дә шактый гына усал сүзләр әйтештеләр. Бер карасаң — икесе дә хаклы сыман: разъездның юл араларына өелгән кар-бозны кая да булса алып ташлыйсы бар. Бик тә комачаулап ята ул анда. Мастер әйтә: күптән инде әз-әзләп берәр яры көрәп ташлый алган булыр идегез, көчегезне кызганасыз, ди. Ә берничә көн генә элек ташыр урын да калмаган, казарма араларына тутырып булмый ич инде, бөтенләй читкә чыгарып ташлау өчен берничә вагон кирәк булыр, дип киңәштеләр үзләре. Зәкәрия, вагон-платформалар турында сүз кузгатса да, тегеләр эндәшмәде. Алай итсәң, мастерның үзенә дә мәшәкать туа, начальниклардан ялынып-ялварып платформа сорыйсы, тепловозын табасы, аның юлда булу сәгатьләрен көнлек диспетчерлык графигына «кыстырасы» — кимендә бер-ике көн фәкать шуның белән шөгыльләнәсе, телефон төбендә утырасы була. Алай эшләүгә караганда, билгеле инде, «бригаданы симертү өчен тотасыңмы әллә, бераз селкенсеннәр» дип, бригадирга җикеренүе ансатрак.

Нәкъ менә мастер белән тарткалашкан көнне Карәмәт тә киреләнде. Ул көнне Зәкәрия дежур торучылардан калган бригада белән сул як семафор каршындагы стрелканы сүтеп җыярга тиеш иде. Аның бер ягы иңә төшкән — поездлар авырлыгы белән шпалларны кисеп кергән иде. Шул урында берәр машинист, егетлек күрсәтеп, тизлекне арттыра төшсә — баш китәрлек эш булырга мөмкин.

Карны көрәп, себереп чыккач шул шпалларны аркылы йөзле, кулга җайсыз «француз балталары» белән юнырга керештеләр. Кызу эш вакытында өч балтадан икесенең сабы сынып чыкты. Бригадада коралларны карап, көйләп тоту Карәмәткә йөкләнгән, аның өчен ул укучы

малае исеменә өстәмә эш хакы да алып тора иде. Бу хәл инде күптән килә, Зәкәрия дә, бригадада да аның хезмәтеннән әлегә бик канәгатьләр — эш кораллары тәртиптә, бу эштә атасына малае да һәрчак булыша торган иде. Башкалар, эш сәгатен тутырып, өйләренә таралганда, алар һәр көн диярлек корал сарае янында калалар, сынган, тупасланган һәр нәрсәне әзерләп куярга тырышалар иде.

Кызып эшкә керешкәч кенә әлеге кәкре балталарның саплары сынып китүгә ачуы килеп, Карәмәткә Зәкәрия кычкырыбрак сүз әйтте, «тизрәк бул» дип ашыктырды.

Менә шуннан соң ярсып китте дә инде Карәмәт. Ачуының яман шеш кебек тулышкан чагы булды, күрәсең. Ташладым да киттем эшеңне, ди. Эш коралы алачыгында бүгеннән эзем булмаячак, ди. Хисмәт ише татлы телләләр белән генә дус та әшнә син, ди. Бригадада хәзер шулар гына мактаулы, шулар гына эшчән санала, имеш. Зәкәрияне шулай байтак битәрләде Карәмәт. Дөрестән дә, юл караучы Хисмәткә ул узган атнада гына рәхмәт боерыгы язып элгән иде.

Дөрес, аның сүзләрендә дә хаклык бар: ара-тирә Хисмәт белән бергә-бергә кич уздыралар алар. Укыган-күргәнне сөйләшеп, Маһинур апакай кыздырып биргән «симәнкәләрне чиртkәләп» утыргалыйлар.

### III

Зәкәрия килгәндә, Карәмәт мунчада иде. Ишек аркылы гына сөйләштеләр.

— Хәлил кичүендә рельс сынган, алыштырасы бар... Синең кәефең ничек?

— Җыенып чыга торыгыз, куып җитәрбез,— диде Карәмәт.

Карәмәт мунчасыннан Зәкәрия турылап кына үз казармасына килеп чыкты. Ерактан тыныч кына ишетелгән гүләү тавышына сөенеп куйды. Каршы яктан поезд килә. Шул мизгелдә үк күңелен тырнап: килүен килә, үтәрме? дигән уй узды. Хисмәт бик иренеп китмәсә, эш рәтен белә, әлбәттә. Поездларны хәвеф-хәтәрсез генә үткәреп җибәрә торса ярар иде. Чөнки бригада бик ашыкса да, әле берәр сәгатьсез аның янына барып җитә алмаячак.

Кирәк-яраклар куелган алачык ишеге ачык, фонарь яктысында Маһинур белән Шәмселбану озын әрҗәгә төрле инструментлар тутырып яталар иде. Рельс кисү станогы бер читтәрәк — ул барыбер әрҗәгә сыймый, үзенә аерым йөк авыр, җайсыз нәрсә, гадәттә аны алып йөрисе килми.

Зәкәрия иң беренче эш итеп келәт почмагыннан «шайтан арбасы»н сөйрәп чыгарды, юлга бастырып куйды. Сыңар сап-тәртәле, сыңар рельстан йөрергә көйләнгән бу арба модерон өстенә теге әрҗә белән станокны салдылар да рельс алырга киттеләр.

Өйләр, казармалар ышыгыннан ераклашкан саен, җил тагын да көчәйгән кебек тоелды. Зәкәрия инде авар хәлгә җиткән рельслы арбаны көч-хәл белән генә туктатып, тиз-тиз генә плащының башлыгын башына урап, бәйләп куйды. Болай ярыйсы ук җылы, тик поезд якынлашуын ишетми калуың бар, башны уңга-сулга ешрак каергалап, күзәткәләп барырга туры киләчәк. Хисмәт бу җилгә ничекләр түзеп тора икән? Ул бит инде кимендә утыз-кырык минутлар бер урында таптанадыр. Кәефе кырылса, башкалар кебек тозлап-борычлап сүгенүдән битәр, кычкырып җырларга керешә торган гадәте бар аның.

Менә семафор турысыннан да узып баралар. Шәмселбану утыз-кырык адымнар алда, Маһинур артта, кулларына кызыл утлы фонарь тотып киләләр. Ә җепшек кар киемгә сырыша, барасы юлны каплый, күзләрне томалый. Төн караңгысы да инде тирә-юньгә күптән ябыры-

лып, бар дөньяны басып киткән. Сакта торган текә-текә таулар да, юл белән тау арасындагы сыек урманчык та күзгә чалынырлык түгел. Зәкәрия бары тик Шәмселбануның ирләрчә эре-эре атлап узган эзен генә шәйләп бара.

Менә Текә Ярның ике-өч юлы бергә кушылган урыннан әллә ни ерак та китеп өлгермәделәр, баядан бирле анда-монда шуышкалап барган рельс Зәкәрия кулыннан капылт кына арба сабын суырып алды да «лап» итеп йомшак карга чумды. Аның артыннан иләмсез кисү станогы белән корал әрҗәсе икесе ике җиргә очып барып төштеләр. Тегеләр куып җитмиме дип, Зәкәриянең артка каерылып караган чагы туры килде ахрысы, рельсның читкә үк авышканын сизми дә калды.

Бу хәлне күреп торган Маһинур:

— И-и, чукынган, әллә бөгелгән рельс туры килгәнме?— диган булды.

Кышка бөгелгән рельс калдырырга ул хәтле фәкыйрь заманнар түгел. Зәкәрия белеп тора, аны юатыр өчен генә әйтте инде Маһинур бу сүзләрне. Болай чакрым саен авып янсә поезд үткәреп торсалар, төн уртасына да барып җитә алмаслар. Менә-менә кичке скорыйның үтәр вакыты да җитеп киләдер инде. Соңламаса... әйе, соңламаса, тагын дүрт минут чамасы калып бара икән. Димәк, арбаны күтәреп азапланасы да юк.

Ул арада Текә Яр каралтылары ягыннан ике шәүлә күренде. Төптәй нык, түгәрәк гәүдәле Кәрамәт белән Кәримә апакай шулай «тәгәрәшеп» киләләр ахры. Ни хикмәттер, бу тирәнең халкы нык бәдәнле, уртачадан түбәнрәк буйлы, таза, табак битлеләр. Арада керәшен Настя карчык кына нәни орчыкише юка сөякле дә, Хисмәт солдат, өрәңге арасындагы ак тирәктәй, ерактан ук калкып, күренеп тора. Буйга-сынга ул Зәкәрия белән бер тиң диярлек. Ара-тирә Хисмәт шаярткалап: «Сахалин селедкасы үстерде мине. Җиде ел хезмәт итеп, солы боткасы белән беләк буе селедканы әз ашадыммыни мин»,— диярга ярата.

Шаулап, каударланып скорый поезд үтеп китте. Төн тәрәзә аша сирпелгән елтыр ут яктысы белән җылы төтен исе генә күңелләрне кытыклап, кайдадыр якты дөньялар барын, җылы тыныч тормыш һәм әллә ниткән сихри мәхәббәт-сөюләр барын искәртеп, күңелне әрнетеп алган кебек тоелды. Яннарыннан әле генә өермәдәй үтеп киткән ул җылы һәм якты вагоннарда тирбәлеп баручы халыкның берсе дә юл читендә җилгә арка куеп хәл җыеп торган Зәкәрия белән Маһинурлар, Хисмәт белән Кәрамәтләр турында уйлап карамагандыр.

Авыр рельсне азаплана-азаплана арбага салып бетергәндә генә Кәрамәт килеп җитте. Артыннан фонарь тотып килүче аның кызы булып чыкты.

Арба сабын тегендә-монда эткәләп, тигезлек сакларга тырышып, көчәнә-көчәнә Зәкәрия тагын күпмедер ара үтте. Хәерсез «күсәк»нең чайкалуын алай гына баса алмагач, тагын тукталды. Кәрамәт шунда аның авырткан бизенә баскандай бер турылык белән:

— Бир әле үземә, бригадир, никтер ул бүген сине тыңламый,— дип арбаны аның кулыннан алды. Һәм үзе, гадәтенчә, бер якка янтая төшеп, арбаны шактый иплә генә келтерәтеп алып та китте.

## IV

Кәрамәтнең үзе кебек үк юантык, йомры-таза кызы каяндыр ялга дип кайткан икән. Зәкәриянең аны бирегә эшкә килгәннән бирле күргәне булмады шикелле. Хәер, күреп тә игътибар итмәгәндер. Кара-

мәтләргә тиктомалдан килеп керү гадәте юк Зәкәриядә. Никтер күнегелмәгән.

Кыз, сигнал фонарен тотып, алдан бара. Ник бер артка әйләнеп карасын. Бик алга да үтми, артка да калмый.

Дилүсә исә үзе яшь бригадирны күз алдына китереп бара иде. Абау, бигрәк каударлы, бигрәк сөмсере коелган инде егетнең. Әллә ни булган диярсең. Юл булгач, анда ул-бу булмый тормас, Текә Ярда беренче рельс алыштырулары түгел. Ә бәлки бригадирның атасы Карәмәткә булган ачуы әле дә бетмәгәндер. Әнисе әйтә бит, сүзгә килешкән көнне бик ачуы чыкты бригадирыбызның, ди, рәтле-башлы исәнләшми дә, ди. Әле дә әнә йөзе чытык, маңгай астыннан гына карап алды бая Дилүсәгә.

Бүген бригада белән чыгарга атасыннан ул үзе сорады. «Мунчадан соң әнкәйгә килешмәс», дигән булды. Дилүсә никтер юл эшен үз итә. Бигрәк тә поезд каршыларга, аны ерак, билгесез тарафларга озатып калырга бик ярата. Текә Ярда ике көнгә бер туктала торган пассажир поездын ул аеруча бер өмет, түземсезлек белән көтеп ала. Нинди генә эше булмасын, аны каршыларга юл буена йөгереп чыга, кул изәп озатып кала иде. Поездның төрле сәбәпләр аркасында Текә Ярда тоткарланып торуы исә аның өчен зур шатлык була. Андый чакта, бигрәк тә җәй көннәрендә, яшел, затлы вагоннарда баручы яшьләр җиргә сикерешәләр, биек Кыя тауларга күтәрелеп карый-карый сокланалар, кызыксыналар, йөренгәләп алалар иде.

— Ah, бу текә тау! Ah, бу кыялар!..— диешәләр.

Кайберсе, Дилүсә янына килеп, аны-моны сораштырган, кызыксынган була. «Әй, чибәркәй, әйдә алып китәм үзеңне еракка!» дип үртәшеп тә куйгалыйлар. Яшертен бер соклану белән бер читтән төбәлеп карап торучыларны да кыз күңеле сиземли башлаган чак иде инде.

Дилүсәнең сихри поездлар артыннан карап калулары бала чакның кызыклы уенын искә төшергән татлы төш кебек тоелдылар хәзер. Ераклаша барган поезд артыннан чайкалучы утлар аны, хыялый бала-чактан аерып, әллә кая, читкә алып киттеләр. Оҗмах кебек Текә Ярыннан аердылар. Ә бит рәхәт чаклар монда да булган икән ич. Әйе, дүрт-биш ай үтү белән, Дилүсә бу кечкенә разъездны шулкадәр сагыныр дип кем уйлаган! Зур шәһәргә, олы дөньяга барып әләксә, ул аны бөтенләй дә исенә төшермәс кебек тоелган иде ич. Баксаң, шушы моңсу гына разъезд да үзен шулай сагындыра икән! Зур калада, бер ялгызың булгач, шулай ук моңсу да, ямансу да була икән ләбаса. Аннан да туя икән кеше баласы.

Дилүсә шуларны уйлый-уйлый бригада алдыннан атлый. Беленер-беленмәс кенә җепләр булып сузылган юл аның саен озыная, алга йөгерә, ашыктыра.

## V

Җил өрә дә өрә. Кар һаман ява. Дөнья тәмам карангыланды. Инде юл буендагы гүләп торган баганалар күренмәс үк булдылар. Хисмәт тыны кысыла-кысыла Текә Яр ягына озаклап карап тора. Төн һәм буран аша хәтта Кыя тау да күренми башлады. Хисмәт сәгатьтән артык инде бер урында таптана. Ул әле бияләен бияләйгә суккалап ала, әле әрле-бирле йөренгәләп килә. Шулай да үзе тапкан ватык рельс яныннан ераклашмый. Поезд уты күренү белән, фонарен болгарга, аларны туктатырга керешә. Аннары, вагоннар астына ук иелеп, сынып төшкән рельс кыйпылчыгын көрәге белән бастырып тота да бу хәтәр җирдән поездларны җай гына үткәреп тора. Яхшырак ишетелсен өчен бүрегенең бер колакчынын күтәребрәк куя, тәгәрмәчләр

таптый-таптый ямьшәеп беткән күрәгенең сабын ычкынмаслык итеп ике куллап тота, аннан машинистка:

— Әйдә!— дип кычкыра.

Хәвефле урынга әкрен генә килеп кергән тәгәрмәчләр, тора-бара ашыга башлыйлар, күрәк астындагы кыйпылчык менә-менә сикереп чыгар сыман тоела. Хисмәт исә һаман тешләрен шыгырдатып, бил сызлавын онытып, озын составның үтеп беткәнен көтеп, кырыкка бөгелгән килеш басып торуын белә. Соңгы вагон үтеп киткәндә, ул инде, башы әйләнеп, егылыр дәрәҗәгә җитә.

Дөрес, поездларны болай җибәреп тору катгый тыела. Инструкция буенча мондый очракта юл бөтенләй ябылырга, поездлар йөрмәскә тиеш тә бит, алай гына эшләп булмый шул. Аңа күп вакыт китәчәк. Аннары юлны ябык тоткан өчен бераүне дә мактамаячаклар, зур тавыш чыгачак. Билгеле, ул тавышның юл карауччы Хисмәткә кагылмавы да ихтимал. Киресенчә, аны әле, вакытында чара күргән дип, мактап та куюлары бар. Ә бригадирга ни әйтерләр?

Шулай да ул бригадир һәм мастерлар ничек кенә укымышлы булмасын, юл эшен Хисмәт бер дә алардан ким белми, анысы факт. Хәзер генә ул җиңел эштә — юл карауччы исәпләнә. Әнә, кайниште Карәмәт тә аның белән йөри-йөри генә остарган малай, үзен бик белдекле санап, бригадир ярдәмчесе булып йөрсә дә, барыбер Хисмәт кадәр белми әле.

Шуларны күңеленнән кичереп, өши-туңа ялан кырда таптанып тора Хисмәт, килгән-киткән поездлар гына аның уйларын бүлгәлиләр.

## VI

Килү белән бригада дәррәү эшкә тотынды. Хисмәт, бригада килгәнче үк, карларны көрәп, алыштырасы рельсның баш-башындагы болт-гайкаларны, чөйләрне әзерләп куйган. Маһинур, Шәмсебанулар хәзер өстән яфрак-яфрак төшкән юеш карга да, җил улавына да әһәмият итмиләр. Бүген, шушы сәгатьтә, менә шушы эшне тиз һәм төгәл генә башкарып чыксалар, иртәгәдән үзләрен оҗмах рәхәтлекләре көтеп тора диярсең. Шундый янып-көеп тотындылар эшкә, тын да алмыйлар, ник бер сүз ишетелсен!

Көчле җил белән өермәләнеп-өермәләнеп очкан кар бураны туктаусыз алар өстенә ябырыла, итәкләрдән тарткалый, төн чабуларын каера.

Фонарь яктысында Зәкәрия рельсларны үлчәде.

— Киселәсе өлеш зур, пычкы белән азапланмыйбызмы әллә,— диде Карәмәт.

— Әйе шул, ул станокны җайлаганчы, кисеп азапланганчы, тагын кимендә ярты сәгать үтәчәк. Бәлки сындырып кына карарга дыр.

Акбур эзеннән зур кискеч белән туң тимергә сай буразна ясап чыктылар.

Баштарак Зәкәрия шул чаклы калын рельсны гадәти кискеч ярдәмендә кисеп булырына ышанмый иде, практика үткәндә моңа бик гаҗәпләнгән иде. Соңрак аңа бу ысул белән дә очрашкаларга туры килде.

Карәмәт зур чүкеч белән сугып торды, Зәкәрия, озын саплы кискечне рельсның «муен астыннан» йөртеп, тирән эз салып чыкты. Шуннан соң Карәмәт:

— Бирегә килегез!— дип, башкаларга эндәште.

Әлегә кадәр шпал өсләрен чистартып, чөйләрне кузгаткалап йөргән Хисмәт, Маһинур, Шәмсебанулар тезелешеп рельс янына бастылар. Карәмәт кисәк-кисәк кенә әмер бирә башлады:

— Иеләбез!.. Бергә күтәрдек!.. Аякларыгызны саклагыз! Ташладык!!!

Шпал өстенә аркылы салынган лом сыртына ике-өч мәртәбә шулай күтәреп ташлаганнан соң рельстан, ниһаять, «зыңк» итеп бер сөямлек кисәк җиргә өзелеп төште. Билгеле, Зәкәрия укып-өйрәнгән инструкцияләр рельсны бу ысул белән кисүгә каршы иде. Әмма да ләкин болай эшләү эшне бермә-бер тизләтә. Һәм шуның өчен кайвакыт андый юк-бар «кушмауларны» онытып торырга туры килгәли.

Эшли-эшли тирләгән, кызган Зәкәрия башта калын брезент накидкасын салып ташлады, аннары тун төймәләрен бөтенләйгә чишеп җибәрде. Дилүсәнең юеш бияләйләре дә, карасу-көрән тап булып, аяк астында ауныйлар иде. Ул, алсуланган бармакларын чеметтерә-чеметтерә, туң болтларны, гайкаларны алып, җайлап-көйләп урыннарына беркетә тора. Зәкәрия аларны ярты аршинлы, озын саплы ачкыч белән ныгытып борып бара иде. Рельсның аргы башында Кәрәмәт белән Шәмселбану шундый ук эш башкаралар. Ә Хисмәт белән Маһинур, бер-берсенә булыша-булыша, уртада кайнашалар. Хисмәт исә туңып каткан бармаклары белән шпал кабыргаларына очлы чөйләрне авызландыра тора. Маһинуры авыр чүкече белән киерелеп-киерелеп ирләрчә кизәнә дә чөйләрне кагып куя.

Зәкәрия бая ук Хисмәтне кайтарып җибәрмәкче иде.

— Туңгансыз, күшеккәнсең, Хисмәт абый, кайт син, җылына тор,— дип тә карады. Китмәде Хисмәт. Бергә-бергә кайтырбыз, диде.

## VII

Зәкәрия белән Дилүсә озын рельсның бер башына туры килделәр. Кызның кайнар сулышы хәзер Зәкәриянең болай да янып, ялкынланып торган битенә кагылып-кагылып киткәли. Кызның фонарь яктысында тиз һәм житез кыймылдаган тылсымлы бармакларына кагыласы, бер генә мизгел булса да учта тотып торасы килә.

— Сез, балтасын бәкегә төшергән кеше кебек башыгызны аска иеп кенә йөрисез икән.

Дилүсәнең кинәт сүз башлавыннан Зәкәрия бер ара айный алмыйча, аптырабрак торды.

— Күтәрелеп карасам, өстемә Кыя тау ишелмәгәе дип куркасыз ахрысы.— Дилүсә шулай диде дә үзе уйлап тапкан шаян сүздән беренче булып сөйкемле генә көлеп тә куйды.

— И-и, сеңелем, һаман шул рельс белән шпалларга карап йөргәнгәдер инде ул,— дип куйды Зәкәрия ярым шаяртып.

Аннары кыз җитдиләнә төште:

— Сез әткәйгә теге көн өчен үпкәли күрмәгез инде, бик уз күрә ул Сезне,— диде.

Зәкәрия аңа сүз әйтергә өлгермәде, шул вакыт ерактан ук кычкыртып, поезд килгәне ишетелде. Прожектор уты Хәлил кичүе ягыннан шуышып аларга якынлаша башлады. Һәм менә ул кар диңгезе уртасында каралып торган бер төркем кешеләрне караңгылык эченнән йолкып алды. Хисмәт, солдатча төз басып, юл кырыенда ук тора. Кулындагы фонаренең яшел уты, «юл ачык, узып кит» дигәнне белдереп, поезд килгән якка таба каратылып куелган иде. Бу минутта Зәкәриянең дә күңелендә гүя яшерен бер өмет булып яшел ут кабынган иде.

## Рөстәм Кутуй

### Шагыйрь

Үз-үзеңне ничек хәйләләмә,
Үз-үзеңнән ничек яшермә —
Язмыш сиңа үзе кушкан, шагыйрь,
Әрнүләргә түзеп яшәргә.

Әрнү сиңа тугры юлдаш булыр
Соңгы көнең килеп җиткәнче.
Бар табышың кешенеке булыр,
Башкаларга булыр, беткәнче.

Шуны таны, шагыйрь: ниләр генә
Бүлешмәсен синең малыңны —
Бармакларың кояш нурын тота,
Гөлләр сыйпый синең җаныңны!

Челтер-челтер көлеп сулар ага
Һәм җылыга чыга бөҗәкләр.
Күз алдыңда синең бар табигать,
Беркем күралмаган бизәкләр.

Бер көн килеп, әйтик, болар бар да
Йөрәгеңнән синең җуелса?
Син — бер шәүлә. Димәк, моннан ары
Яшәвеңә нокта куела.

### Көтүче Ибраһим карт догасы

«Бисмиллаһи рахман и рәхим...»
Үлсәм иде, раббем, ирдә.
Сулышым калсын иде җилләрдә.
Бик картайды колың Ибраһим,
«Бисмиллаһи рахман и рәхим...»

Алма мине күккә, раббем,
Дошманнарым куанмасыннар.
Балаларым кеше булсыннар,
Мин — бер колың синең — Ибраһим,
«Бисмиллаһи рахман и рәхим...»

Сукырайсын әнә ябалак,
Күз нурларым минем китмәсен.
Улларымны ятим итмә син,
Йоклап йөрмәс тере Ибраһим.
«Бисмиллаһи рахман и рәхим...»

Чукраклансын әнә, бүреләр,
Зирәк калсын минем колаклар.
Тупырдашса юлда тояклар,
Йөз чакрымнан сизсен Ибраһим,
«Бисмиллаһи рахман и рәхим...»

Башкалардан артык җирем юк,
Аксак аттан кимрәк мин хәтта.
Шуны гына ал син җәннәткә,
Җирдә торсын колың Ибраһим,
«Бисмиллаһи рахман и рәхим...»

●

Кич. Эңгер-меңгер эчендә
Яфраклар көйри кебек.
Ә курай җиһан турында
Хикәят сөйли кебек.

Күзләрен ачып куя карт,
Ә алар шундый тирән.
Бу төпсезлекне, күрәсең,
Сабыйлык таңы биргән.

Ишетәм, бу курай түгел.
Бу — чишмәләр тавышы,
Күк гөмбәзен чайпалдырып
Мәңгелекнең агышы.

## Чыгышым

Кайда булдым, кайда йөрдем икән,
Бу дөньяга килердән элек.
Минем бабам нинди далаларда
Ат уйнаткан икән җилкенеп?

Учак ялкынына кушылгандыр
Күзләренең соңгы нурлары...
Миңа хәтле булган,
Миңа хәтле булган болары.

Тугангача, белмим, йолдыз яки
Бөркет булып гомер иткәнмен,
Яу-дауларның барын кире кагып,
Ханга хәнҗәр кайрый-кайрый һаман
Килүемне җиргә көткәнмен.

Атлар куып йөргән төрки кызын
Зәңгәрсу ай күктән күзәткән.
Ялларына ябышып атка менгәч,
Төрки кызы айга күз аткан.

Күзләремдә яшен уйнаганда
Җаным кушкан чакта: «Иярга!»
Кирәк түгел мине үгетләргә,
Кирәк түгел «Китмә!»— диярга.

Көл астында күмер кала бит ул,
Бабам кебек мин дә усалдыр,
Бу йөрәгем аның мирасыдыр —
Чакма итеп чак та, ут алдыр

Өр генә син көлгә — тирә-якка
Эссе бәрер, очкын сибелер.
Авызлыгын чәйнәп, иярләнгән
Ярсу атым янда тибенер.

Барын ташлап, барына күз йомып,
Омтылырмын офык читенә.
Җанымдагы кутырларны юып,
Яңгыр бәрсен әйдә битемә.

Күзләремдә яшен яшьнәгәндә
Сабыр ит син, көт син азрак...
Кулы белән тезген капшый-капшый,
Үлеп бара миндә «азиат».

Зиннур НАСЫЙБУЛЛИН тәрҗемәләре

Игорь Ляпин,
рус шагыйре

## Йөрәк

Таныш ярда — җанга якын сөйләш.
Тик мин аны күптән югалткан.
Басулары — гөрләп, ә шәһәре
Каршы ала гүләп еректан.

Малайчакта бергә уйнап үскән
Һәр ихата, һәр җыр, һәр каен,
Поездларның һәр балкыган уты
Искә төшә икән һәр даим.

Туган җирең белән туганлык ул
Туганлыкның иң зур үрнәге.
Берәм-берәм шигыремә керә
Туган якның таныш үрләре.

Ватанымны ничә урап чыктым,
Күпме күрдем җәен-кышын да...
Ә йөрәге булса Туган илнең,
Йөрәге дә, ахры, шушында.

## УТ

Утта дәрт тә, утта дәрман да бар —
Бир син аңа бары хут кына!
Тик ул явыз, яхшы була алмый —
Кеше түгел бит ул, ут кына.

Кабызганда яна ялкынланып,
Сүндергәндә сүнә шунда ук.
Ут кешенең турылыклы дусты!
Кайда тереклек бар — шунда ут!

Мичтәге ут, беләсегез килсә,
Кеше җаны белән бер заттан.
Бабайларның яккан учаклары
Оныкларны дәшкән еректан.

Мужик сөргән, мужик иген иккән,
Ул икмәккә, җиргә табынган.
Нәфрәтләре исә бай йортында
Кызыл әтәч булып кабынган.

Мин санитар вагоннарын беләм.
Күз алдымда тора ут биеп!
Еш ишетәм тупчы-командирның
Саташканын: «Огонь! Ут!»— диеп.

Туңганда да, чылanganда да гел
Ялкын тулы безнең йөрәктә.
Ут алыгыз безнең йөрәклərдән,
Кабызырга шырпы кирәктә.

Яктыра уч шырпы сызылганда.
Ут — яктылык бит ул, ут — күңел...
Кирәк түгел нәрсә янса әгәр,
Без гаепле аңа, ут түгел!

●

Үз язмышым мине кыерсытмый.
Ләкин һәрчак бирер бәндәнең
Кирәктә дә, кирәкмәгәндә дә
Тоям, сизәм бирер ярдәмен.

Күрсәтеп тә, хәтта астыртын да
(Каян гына алар табыла?!)
Көпә-көндез ярдәм тәкъдим итеп
Опекуннар миңа агыла.

Күреп торам — алар тиргә бата
Мин башкалар белән узганда,
Читләр өчен тостлар күтәргәндә,
Башкаларга кулны сузганда,

Я аларның дустын хуп күрмәсәм,
Алар белән бергә азмасам,
Алар укыганны укымасам,
Алар теләгәнчә язмасам!

Алар тиргә бата, әгәр дә мин
Шигырь бирсәм башка журналга.
Күп сорамый алар ут күршеңне,
Хатыныңны хәтта хурларга.

Синең өчен алар әзер тота
Агуын да, татлы балын да.
Сиңа алар барсын оештыра,
Синең өчен эшли барын да.

Ә элегрәк алар күренмәде.
Мин аларга хәзер ни диим?
Кайда булган алар мин ач чакта,
Ачыкканда апам, әнием?!

Менә шундый туган-тумачалар!
Мин аларны аңлар идем дә,
Тик берсе дә күренмәде күзгә
Тилмергәндә мин бер тиенгә...

Егылсам да мин еламам хәзер.
Дөресрәге, юкка егылмам.
Ышанам мин тик үз йолдызыма
Һәм атлыйм мин тик үз юлымнан!

## Татьянага

Ул бит миңа беркем түгел.
Ә шулай да... кем белә?!
Карашыннан җан — томанга,
Я яктыга күмелә.

Сокланып карый тормышка
Аның якты күзләре.
Чәчәкләрнең телен ача
Аның якты сүзләре.

Үзенә сокланганнарын
Күрә ул, күрми түгел.
Яктылыкка әйләнү дә
Аңарга берни түгел.

Язмышым ул! Юкса мине
Бәхетле итмәс иде.
Ул булмаса, миңа мәңге
Мәхәббәт җитмәс иде!

●

Бөтенесе килә синең кулдан,
Үз дигәнеңне син итәсең.
Киткән чакта якты күңелемне
Сагыш белән юып китәсең.

Кагылганда кабат иңнәремә,
Җырлый башлый бәхет — җанымда:
Мин бөтенләй башка кеше кебек
Син булганда минем янымда.

Әйләндер син мине йөзгә, меңгә,
Бик теләсәң, акка, карага...
Тик кералмый беркем — хәтта син дә —
Шигырь белән минем арага!

Роберт МИҢНУЛЛИН тәрҗемәләре

Марат Әмирханов

# СОҢГЫ ҖЫР

хикәя



Рәхимҗан капка төбендә бүрәнә каезлый. Кулындагы балтасы көзгегә кунган кояш нурларыдай ялт та йолт килә. Зәңгәр буй төшкән аксыл күлмәгенең изүләре ачык, җиңнәре сызганулы. Хуш исле кайры тасмаларын телем-телем кискәләп, кер шикелле киртә өстенә элә. Элә дә күпне күргән саргылт салам эшләпәсен баш өстенә шудырып куя. Аннан соры күзләрен кыса төшеп, башын аз гына кырын салып, шәрә калган нәфис усак сыннарына карап тора: чибәрләр, һәй чибәрләр!

Рәхимҗан мөкиббән китеп, тәм, ләззәт табып эшли. Авызында һаман җыр булыр. Әле дә яраткан җырын көйләп җибәрде:

Бакчадагы гөлләремнең тамырлары бер генә шул,
Зәйнәбем...

Шул чак күршеләрдә «шайтан әрҗәсен» уйната башламасыннармы! Тәүлекләр буе ач торткан көтүне утардан чыгаралармыни: кычкырышалар, бакырышалар, ваталар, җимерәләр... Вәт сиңа моң! Кем уйлап чыгара диген. Колагың гына түзсен. Хәер, яшь-җилкенчәкнең үзенә дә ошап җитми бугай әле, бөтерчектәй бөтерелеп биеп китә алмыйча җәфаланалар бит әле, суыргыч атыдай һаман бер урында әйләнәләр.

Әүвәл чакта армиягә болай китмиләр иде, юк, әүвәл бөтенләй башка иде.

Бүрәнәгә тиеп киткән саен балта көмеш тәңкәдәй чыңлап куя. Рәхимҗанга ул моңлы җыр булып ишетелә.

...Кырык бернең җәе иде. Көн кичкә авышып бара. Көтү каршыларга иртәрәк әле иртәрәген, тик бала-чага клуб янына җыелып өлгергән инде: кыз-кыркын таган атына, олырак малайлар турник янында кайнаша. Рәхимҗан кебек бәләкәйрәкләр туплы уйный. Һәркемнең үз эше. Чыр-чу киләләр, урам шау-гөр килеп тора.

— Некрутлар!— дип кычкырып җибәрде шунда кемдер.

Башта кыңгыраулар чыңлавы ишетелде. Аңа гармун авазы кушылды. Калын тавышлы берәү, аз гына калтыранып, җыр башлады:

Үскән чакта үскән идек
Тал тамырлары кебек...

Җырны яртысыннан башкалар күтәреп алды:

Үсеп житкәч аерылышабыз
Кош балалары кебек...

Малайлар, юл тузанына чумып утырган кош-кортларны пыран-заран китереп, некрутларга каршы йөгерделәр. Рәхимҗан да аларга ияргән иде, тыкрыктан олы урамга борылган бизәкле арбаны күреп, туктап калды. Вәт ичмасам тамаша! Кызыл парча белән уралган киң дуга башларында, тәртә очларында чыгуле сөлгеләр җилферди. Аяк-ларын арба эченә сузып утырган егетләр бертуктаусыз кулъяулык болгыйлар. Ул атлары?! Озын муеннарын көянтәдәй кәкрәйтеп, җыр көенә керт-керт басып килүләрен күр син. Бакчы, чуклы шлияләрен-дәге җиз төймәләр ничек җемелдәшә, йөзек кашындагы асылташмыни.

Бизәкле-чуклы арба янына әледән-әле каралудан кайтучыларның әниләре килеп сарыла. Уллары белән нидер пышылдашалар да, яулык очлары белән күзләрен сөртә-сөртә, юл читенә тайпылалар. Җиңгиләр-нең үз мәшәкатьләре: кайсы әйрән, кайсы катык тутырылган тустаган күтәреп килә.

Менә пар ат биек коймалы нарат йорт янына килеп җитте, шундук тәрәзә пәрдәсе ачылды, анда ай кебек якты бер чибәр йөз пәйда бул-ды. Җебеп торамы соң егет мондый чакта, җырга кеше кесәсенә ке-рәсе түгел лә:

Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде — каласың.
Мин киткәчтен кемнәр сөяр
Син сандугач баласын.

Клуб янында егетләр җиргә сикереп төштеләр. Гармунчы бию көен уйнарга тотынды. Кызлары да шунда гына булган икән. Бер пар тук-тауга, икенчесе атылып чыга, башкалар такмак әйтә:

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява
Өй түбәсе калайга.
Каласыз, кызлар, каласыз,
Шар уйнаган малайга.

— Әттә генәсе!
— Маладис! Янсын дошман йөрәге.
Калдырырсың кызларны җавапсыз:

Урам буе тәрәзәгез
Яшелләргә буягыз.
Пожалысты, үзегезне
Әллә кемгә куймагыз.

— Менә шулай, әйт кирәген.

Берничә көннән сугыш чыкты. Бу хәбәр авылны зур хафага салды. Сугыш. Аның кулы озын, ул бер капканы да читләтеп үтми. Әмма кеше, гадәттә, үз өстенә төшәчәк авырлыкны күрмәмешкә салышырга тырыша: кем белсен, бәлки зыянсыз-нисез үтеп тә китәр. Шуңа күрә кичләрен капка төбендә тәмәке пыскытучы ирләр, вакыт-вакыт сугыш турында онытып, Түбән болында булган өермә хакында гәп сатып ала-лар иде.

— Менә дә әкәмәт хәл булды ул, малай,— дип, кич саен юан Сә-лим бер балык башына тотына.— Мөкәррәмә апа күлмәк итәкләрен җилфердәтеп аш өлгертеп йөри ие, Хөсни бабай ит бүлә. Шул чак, мин сиңа әйтим, капылт кына кояш сүнмәсенме. Ихлас менә. Котым боты-ма төште, малай. Нидер сызгыра, ыжгыра, ут чәчә. Чыкты гарасат.

Мәхшәр көне, валлаһи. Баш бетте, замана ахыры килеп җитте ахры дип, белгәнне укырга тотынган гына идем, дөнья яктырды да китте. Карасак, иттән җилләр искән, аш — казаны-ние белән юк.

— Синдә гел шул тамак кайгысы булыр инде,— диде Рәхимҗанның этисе Тимерхан.

— Өстенә бастың, әүлия икәнсең.

— Сезгә авыз ерырга гына булсын, әйтеп торам лабаса. Кабан күленең аждаһасы күккә инде дип. Менә хикмәт нәрсәдә!

— Ике аждаһа бер дөньяга сыярмы?

Көлешә торгач яннарына авыл Советы председателе Хәйдәргалинең килеп җитүен күрми дә калганнар.

— Рәхәткә чыккансыз, ә? — диде ул коры гына.— Сугыш, егетләр, фашист котырына.

— Нибуч, Кызыл Армия андыйларны гына күрмәгән.

— Немечне әйтәм, тач мөгезсез сыер, һаман тыкшына ди бит, ә?

— Иптәш Сталин ирек бирмәс.

— Пумышка әллә үзебез китәбезме?— дип көлде юан Сәлим, күзләрен мутландырып.

— Туры килер,— диде председатель,— бу атнада авылдан егерме кеше җибәрәчәкбез. Тимерхан, сиңа иртәгә үк чыгып китәргә, мә, повесткаңны кул куеп ал.

Авыл чын-чынлап сугыш хәсрәте белән яши башлады. Ләкин бу кечтә сугыш дигән афәт китергән хәсрәтнең нинди булачагын тәгаен генә берәү дә белми иде әле. Хатын-кыз түккән яшьләр дә кайгыдан түгел, юк, алар күбрәк ярату, иркәләнү, назлану яшьләре генә иде. Бары еракта, бик еракта сугыш бара, тик ул озакка сузылмас, ак финнарны, әнә, бик тиз тоттылар бит.

Авылда хәбәр бик тиз таралучан. Рәхимҗаннар биләмнән кайтып кергәндә, кардәш-ыру, күрше-күлән җыйналып өлгергән иде инде. Әтисе кич буе уен-көлке сөйләп кешеләрне көлдереп утырды. Әнисенә дә моңаерга ирек бирмәде, такмаклап кына дәште:

> Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем,
> Бигрәк сылу йөзләрең.
> Калган ашны кая куйдың,
> Алып бирче, Зәйнәбем.

— Хет бүген адәмчә сөйләшер идең,— диде ана әнисе үпкәләп.

— Һи, карчык, уйнамагач та көлмәгәч тә, бу дөнья нәмәрсәгә? Гитлерны аны ә дигәнче әйләндереп ташлыйбыз. Бетте-китте, вәссәлам.

...Әҗәкүл пристанена алар бик тиз килеп җиттеләр. Рәхимҗанның күзләре шар булды, бу кадәр халыкны әле беркайчан да күргәне юк иде аның. Бишбүкән базары бер якта торсын. Ул тәртәләрен күтәртеп бәйләп куйган арба-тарантас — чутына чыгам димә!

Әтисе атны тугарып арбага бәйләде дә, нидер белешергә дип, түбә кыегына кызыл флаг кадакланган биек йортка кереп китте. Рәхимҗан яр буена килде. Агыйделнең өсте ак җәймәдәй чип-чиста иде. Тыныч, бик бер дулкын әсәре булсын. Бары су читенә чылбырлап куелган көймәләр генә, агым суга каршы тора алмыйча, әле бер якка, әле икенче якка чайкалалар. Ара-тирә, канат очларын суга манчыштырып, акчарлаклар очып уза, чуртаннан куркышып сикерешкән вак балыкларның көмеш тәңкәләре ялтырап китә.

Әтисе озак тормады:

— Их, кармак булса, эткәй!—диде Рәхимҗан, суда сикерешкән балыкларга күрсәтеп.

Тимерхан сүзсез генә улын күтәреп алды, кочагына кысты.

— Әнкәңне тыңла, акыллы бул,— диде ул ниндидер ят тавыш белән.

— Әткәй, миңа өйрәтелгән эт алып кайт, яме,— диде Рәхимҗан, кул аркасы белән күмәчтәй кабарып торган бит очларын сөртә-сөртә. Нигә соң әле аның бите юеш. Ул аз гына читкә каерылды.

— Әткәй, эчең авыртамыни? — диде ул куркып.

— Улым, кадерлем...

Искәрмәстән сузып-сузып пароход кычкыртып җибәрде. Моңсу да, шомлы да, ашкынулы да иде бу тавыш. Яр буе, туздырылган умарта күчедәй, гөжли башлады. Кемдер сулкылдап куйды, кайдадыр җыр суздылар, гармуннар моңланды. Кочаклашулар, елашулар, көлешү — барысы бергә кушылды.

Рәхимҗан әтисенә елышты, чытырдатып аның чабуыннан эләктереп алды.

— Әткәй, кайтаек, әткәй...

Шунда ук команда яңгырады:

— Тез-зе-лергә!

Тимерхан иңенә биштәрен асты, бил каешын рәтләп кысты да иркәләп Зәйнәбенең башыннан сыйпады, улын кочаклап үпте.

— Исән-имин торыгыз,— диде ул һәм, артына да борылып карамыйча, нык-нык атлап, сафка барып басты...

Яр буе тынып калды. Сыгылмалы басма өстендә дөбердәшкән авыр аяк тавышлары аермачык ишетелеп торды.

Рәхимҗанның күзләре пароходта. Кая соң аның әтисе, нигә күренми ул?

Менә ян-ягыннан пар төтене өрдереп, пароход усал ат шикелле пошкырып куйды, тегермән ташыннан да зуррак көпчәк канатларын әкрен генә суга шапылдата башлады. Шул чакны пароходта кемнәндер моңлы җыры ишетелде.

Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул...

— Әткәй, әт-кәй!— дип кычкырырга тотынды Рәхимҗан үзен-үзе белешмичә. Аның йөгереп барып әтисен кочаклыйсы, җил-яңгырда каралган кытыршы йөзен үзенең нәни куллары белән сыйпыйсы, иркәлисе, яратасы килде. Кая ашыга бу пароход? Соң әле аның бик күп, бик күп сүзләре әйтелмичә калган лабаса...

Рәхимҗан бу минутта оясыннан егылып төшкән кош баласы кебек өзгәләнә, талпына иде.

Караңгы төн, болытлы көн,
Без айрылган көн бит ул.

Тимерханның бераз басынкырак, әмма йөрәк әрнетерлек, бәрхеттәй йомшак тавышы озатучы халыкны әсир итте. Ашкынулы моң, ярсу дулкын булып, яр читенә бәрде; акчарлакка әверелеп, зәңгәр күккә күтәрелде; сагыш булып, күңелгә сыланды. Аерылышу җыры иде бу.

Аннан соң нәрсә булгандыр, Рәхимҗан аларын анык кына хәтерләми. Ул күзләрен ачып җибәргәндә, төн иде инде. Караңгы. Бәлкем әле уянмаган да булыр иде, ниндидер үтә сагышлы, күңелгә бик якын бер моң сискәндереп җибәрде аны.

— Караңгы төн, болытлы көн...

— Әткәй...

— Йокла, улым, йокла...— диде әнисе, Рәхимҗанның өстенә ябынган бишмәтен рәтли төшеп,— сугышка китәләр, юл тулы халык, хәерлегә генә булсын.

Көз яңгырлы килде. Иртәнге якта гына аяз булып тора да, төш вакыты җиттеме, күк йөзен аксыл томан сарып ала. Баксаң, ул инде болытка әйләнгән. Шуннан күп тә үтми, дымлы җир өстенә вак яңгыр сибәли башлый.

Рәхимҗан көннәр буе өйдә ялгызы утыра. Әнисе бер караңгыдан икенче караңгыга диярлек эшли. Ә әтисе һаман юк та юк. Пароход тукталганчы кайтып җитмәсә, бүленеп кала бит инде. Аннан көт син боз акканны...

Малайның уйларын бүлеп, кемдер тәрәзә какты.

— Өйдәләрмү-ү-ү?

Рәхимҗан Пучты Мөхлисәнең тавышын шунда ук танып алды, йөгереп күтәрмә башына чыкты.

— Бие, үскәнем, сөенче!— диде Мөхлисә, зур кара сумкасыннан ниндидер кәгазьләр актара-актара.

— Мин бии белмим...

Почтальон гаҗәпләнеп Рәхимҗанга текәлде.

— Тимерхан булсын да, өйрәтмәсен дә...

Кара, кара, каян барысын да белә бу Пучты Мөхлисә. Әтисе морякча биергә дә өйрәтте аны. Тик...

— Я, ярар, киттем алайса, биючеләр табылыр әле,— диде хат ташучы аптырап торган малайга илтифат итмичә генә.

— Җук-җук... хәзер.

Рәхимҗан яңгырдан бүртеп киткән күтәрмә идәненә чапыр-чапыр басып, кулларын әле күкрәгенә, әле ялан аякларына суккалап, бөтерчектәй әйләнергә тотынды.

— Әллә кайчан шулай кирәк иде,—диде Мөхлисә, малай тукталып калгач,— әткәңнән хат бар, мә!

Рәхимҗан өч почмаклы солдат хатын кулыннан төшермичә әнисен көтте, түземе беткәч, капка төбендәге өянке ышыгына чыгып басты.

Зәйнәп үзе дә көне буе җилкенеп йөргән иде. Иртәдән бирле сул күз кабагы тартты. Аны сөенечкә юрап, әллә нинди хыялларга бирелде. Сугыш бетәр дә, Тимерханы әйләнеп кайтыр кебек тоелды аңа, ниндидер көч һаман өйгә әйдәде, йөрәге жу итеп китте.

— Ни булды, улым?— дип кычкырды ул үрсәләнеп.

— Сөенче, әткәйдән хат!

Зәйнәп кабалана-кабалана хатны ачты, йотлыгып укырга кереште.

— Әткәй кайчан кайта?— диде Рәхимҗан, әнисенең җиңеннән тарткалап.

— Сиңа бик күп сәлам әйткән, улым,— диде Зәйнәп,— өйгә кергәч кычкырып укырмын.

Кич буе гел Тимерхан турында, хат турында гына сөйләштеләр. Яткач та бик озак күзләренә йокы кермәде...

Тышта, тәрәзә пыялаларына бәреп, яңгыр ява. Агач яфракларын өзгәли-өзгәли җил уйный. Башка чакта шомландыра иде мондый төн, Рәхимҗан әнисенә елышыбрак ятарга тырыша иде. Бүген исендә дә юк. Ул шактый вакыт әле сүнәргә өлгермәгән күмер башларының мичтә җемелдәшүен карап ятты. Аннан сорашырга тотынды:

— Хаттагы җырны әткәй үзе чыгарганмы?

— Аныкын белмәссең.

— Җырлап күрсәт әле.

— Исәрләнмәчәле.

— Пучты Мөхлисә хатны биемичә бирмәде. Әткәй җыры ла ул...

Зәйнәп улын кочаклап үпте. Бераз тынычлангач, басынкы күкрәк тавышы белән җырлап җибәрде.

Кайчан да бер кавышырбыз,
Белмим көннәрен генә шул, Зәйнәбем...

— Фронт нәрсә ул, әнкәй?
— Әткәң фронтка китәм дигән бит, сугышның иң авыр җиредер, башлап йөрергә дисәң, аны куш.
— Герой ул, иеме?
Рәхимҗан кинәт, ут шикелле атылып, урыныннан сикереп торды.
— Әнкәй, утны яндыр әле,— диде ул.
— Ни бар тагы?
— Кул янына йолдыз ясыйм.
Малай әтисенә язылган хатны ачтырып, үзенең кул сурәте төшерелгән кәгазьне алды, аның бер почмагына зур итеп йолдыз ясап куйды.
Төшендә ул әтисен күрде. Тимерхан, ак атка атланып, каурыйсыман кабарып торган ак болытлар өстеннән кылычын уйнатып чабып килде дә Рәхимҗанга дәште:
— Улым, матур бисең, карап тордым,— диде.
— Әткәй, хатыңда миңа да җыр яз, яме.
Әнкәң җырын җырла...
— Әткәй, җиргә төш, сагындым...
— Мин фронтка барышлый гына. Фронт сугышның иң авыр җире. Хуш, улым...
Ак атның тояклары астыннан ак кар йомарламнары сибелеп китте, болытлар эченнән Тимерханның җыры ишетелде:

Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем...

*
* *

Бер елдан Рәхимҗан укырга керде. Хәзер хатка кул сурәте генә төшермәс иде, чын хат язарга да кулыннан килә, тик әтисеннән генә башка хәбәр булмады. Анысына да түзәр иде, хәбәрсез югалучылар авыл тулы. Кара кайгы аларга бөтенләй көтмәгән яктан килеп сукты.
Яңа кар төшкән көн иде. Авылның бар бала-чагасы белән бергә Рәхимҗан да тау шуарга чыкты. Очынып, дөньясын онытып уйнады ул. Мамыктай йомшак карны ерып, чаңгы алга омтылганда, күңелдә ниндидер генә хисләр тумый. Канатларын киң җәеп очкан бөркеттәй хис итәсең үзеңне. Бу минутта бит очларын чеметтергән салкын да, култык асларына кадәр үтеп кергән әче җил дә, бөтерелеп яуган таңкә карлар да, хәтта чыр-чу килеп әүмәкләшкән бала-чага тавышы да — барысы-барысы тирә-якны чолгап алган моң-аһәңнең сихри авазлары булып яңгырый.

Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем,
Атны кайда бәйләдең...

Рәхимҗан зур-зур сикәлтәләрне коштай очып үтә, артыннан җил генә выжылдап кала. Оста чаңгычы ул. Бу юлы да аннан өстен чыгучы булмады. Юан Сәлим малае Хәсәннән көлә-көлә эчләре катып бетте малайның. Шулай булмыйча, тау төшкәнче ике-өч кат егыл әле син.
— Бик борыныңны күтәрмә, әтиең полицай синең, белдеңме,— диде Хәсән, гарьлегенә чыдый алмыйча.
Кай арада чаңгыларын салып өлгерде Рәхимҗан, ә дигәнче Хәсәннең муеныннан эләктереп алды. Тегесе дә бирешә торганнардан түгел, төптән юан, тиз генә егып салырмын димә. Алай да Рәхимҗан, җаен туры китереп, искәрмәстән генә янга тартылды һәм, уң аягын алгарак чыгарып, бар көченә Хәсәнгә төртеп җибәрде. Малай артка ауды, әмма Рәхимҗанны да үзеннән калдырмады, икәү бергә гөрселдәп шугалак өстенә килеп төштеләр...

— Тотыныгыз! Тотын...

Ләкин соң иде инде. Малайлар әүмәкләшкән килеш шома боз өстеннән яр астына тәгәрәделәр.

Берсенең аягы, икенчесенең биле имгәнде...

Зәйнәп авыл Советы юлын аз таптамады. Улы өчен дә йөрде, ире өчен дә. Рәхимҗаны ярый инде, рәтләнеп килә хәзер. Тимерхан белән нишләргә? Хәсрәт хатынны тәмам чыгырдан чыгарды, тәкатен алды.

— Аңла син, апай,— диде аңа председатель Хәйдәргали, бер килүендә,— сәвиткә язу-фәлән килмәде. Пособие аласың...

— Гайбәте бит, Хәйдәргали абзый...

— Бәй, апай. Сәлимнең хатын малае табып укыганга мин виноватмыни? Әнкәсенең колагына киртләгән нем, вакытлы-вакытсыз чыгара күрмә дигән нем. Дус бар, дошман бар дигәндәй... Тегесен әйтер нем, апай, тапкан фронттан язар сүз.

— Ничек язган не соң, Хәйдәргали абзый?

— Бәй, дошман тылыннан чыккан бер әрмис Тимерханны күреп калган ди, ул солдатның иптәше Сәлимгә сөйләгән, ди.

— Бер дә харап икән.

* * *

Юан Сәлимгә дә туган җиргә әйләнеп кайту насыйп булмады, хәбәре килде. Еллар үтте. Еллар үтү белән сугыш авырлыклары акрынлап онытылды, кешеләр яңа мәшәкатьләр белән яши башладылар. Авырлыклар онытылды, әйе, әмма йөрәктәге яра төзәлмәде. Рәхимҗан әтисен еш ак та искә ала торган булып китте әле. Ул аның полицай булуына бервакытта да ышанмады.

Ватан сугышында һәлак булган, хәбәрсез югалган авылдашлар истәлегенә һәйкәл ачу тантанасыннан ул аеруча күңеле төшеп кайтты.

Әлеге дә баягы шул Юан Сәлим малае инде. Бөтен халык алдында: атаңның фамилиясен сыздырмасам, исемем Хәсән булмасын, дип бәйләнә башламасынмы. Теге вакыттан соң тәки каныкты бит.

— Әткәйнең бер документы да юкмыни соң?— диде ул әнисенә, өйгә кайткач.

— Язу-фәлән килмәде шул, улым,— дип җавап бирде Зәйнәп көрсенеп.

— Кеше ни сөйләмәс...

— Аңлыйм да...

— Элегрәк бер дә кузгатмадыңмыни, әнкәй?

— Кузгатмаган кая. Ваенкум язып та карады.

— Шуннан?

— Очына чыга алмаганнардыр инде.

— Болай кул кушырып утырып булмый лабаса.

Рәхимҗан мотоциклын кабызды да районга төшеп китте.

Хәрби комиссар, урта яшьләрдәге какча йөзле кырыс кеше, Рәхимҗанны бүлдермичә дикъкать белән тыңлап утырды. Ләкин кайтарып берни сорашмады, ниеткәненнән ары берни белән кызыксынмады.

— Хатында фронтка китәм, дип язган не, кырык беренченең көзе...

— Ул гына дәлил була алмый,— диде военком.— Вакыт та күп үткән, 30 ел.

— Италиядә көрәшкән Полетаевны да ачыкладылар бит әнә.

— Полетаев икенче мәсьәлә.

Военком өстәл читенә беркетелгән ак төймәгә басты. Шунда ук бусагада секретарь кыз пәйда булды.

— Әхмадишин Тимерханның делосын табып кертсеннәр әле,— диде ул.

Делода Рәхимҗанны тынычландырырлык бер кәгазь дә юк иде.

— Әниеннең үтенече буенча кабат запрос ясалган. Менә җавабы,— диде комиссар.— Хәбәрсез югалган, бездә башка мәгълүмат юк.

— Үтенеп сорыйм сездән...

Военком Рәхимҗанны тыңлап бетермәде, урыныннан торды, сәгатенә карады, каядыр ашыга иде булса кирәк.

— Газетага язып карарга киңәш итәр идем, бәлки әтиегезне белгән кеше табылыр,— диде военком фуражкасын кия-кия,— сугыш вакытындагы архивка гына ышанып булмый...

Җавап әллә ни озак көттермәде, газетада игълан басылып чыгуга атна-ун көн үттеме-юкмы, Рәхимҗан исеменә хат килеп төште. Башкортстаннан иде ул.

«Әхмәдишин Тимерхан атлы иптәш белән бер ротада сугыштык,— дип язган иде фронтовик.— Чолганышта калганнан соң да партизаннарга бергә килеп кушылдык. Аны разведкага алдылар. Шуннан ары мин аны күрмәдем. Бер заданиене үтәгәндә һәлак булган икән, дип ишеткән идем, кызганычка каршы, дөреслеген тәгаен генә әйтә алмаем. Безнең отрядның Киевта ветераннар советы бар, шунда мөрәҗәгать итеп карагыз».

Шатланырга, сөенергә генә инде, югыйсә. Әтисенең исеме дә, фамилиясе дә туры килә. Юк. Нигәдер көч бу шатлыкка бөркелеп китәргә ирек бирми. Ничә еллар юллап очына чыга алмаган иде бит, өмете сүнеп, күңеле суына башлаган иде инде. Хәер, исем-фамилия туры килүгә карасаң, беткән ди Әхмәдишиннар, бу якта уң кешенең берсе — Тимерхан.

Шикләнде, икеләнде Рәхимҗан, әмма йөрәге күкрәк читлегенә сыеша алмыйча ярсып типте, өмет барыбер бу шикләнүләрдән күпкә өстен иде. Ә нәрсә язып кәгазь әрәм итәргә, тотам да председательдән ял сорап иртәгә үк юлга чыгам. Шундый карарга килде ул.

Рәхимҗан кичкә таба, кешелеккә кия торган күлмәк-чалбарын киеп, өйдән чыгып китте һәм, озак та тормый, юан Сәлим малае Хәсәнне ияртеп кайтты. Хәтсез вакыт сөйләшеп, аңлашып утырдылар, кычкырышып та алдылар әле. Бераз кыза төшкәч, Рәхимҗан җыр сузды:

...Караңгы төн, болытлы көн
Без аерылган көн бит ул.

Төшендә ул әтисен күрде. Тимерхан нәкъ моннан утыз ел элек күргән ак атка атланып килеп түшәгедәй кабарып торган ак болытлар өстеннән чабып килде. Кулында кылычы.

— Әткәй, мин сине бик озак эзләдем,— диде Рәхимҗан.

— Рәхмәт, улым...

— Әткәй, әнкәй җырын җырлале.

Тимерхан улына сагыш тулы күзләре белән тутырып карап торды да әйтте:

— Улым, мин хәзер җырлый белмим.

— Теге чакта җырлаган иең...

— Ул чакта исән ием, улым... соңгы җырым булды ул... үзең җырла...

Рәхимҗан иң башта ак күлмәгенең җиңнәрен сызганып куйды, аннан кулына гармунын алды да җырлап җибәрде:

Һавадагы аккошларны...

Тимерханның ак аты зур аккошка әйләнеп шикәрдәй ак болытлар өстеннән очып китте, канатлары очыннан ялтыр-йолтыр килеп энҗе бөртекләре сибелеп калды.

— Әткәй, китмә!
— Улым, син миннән зур инде хәзер... хуш...
— Әткәй... әт-кә-ә-әй!

Рәхимҗан уянып китте. Күзләрендә яшь, үзе шыбыр тиргә баткан иде. Ләкин тәне җиңел, башы саф. Ул тәрәзә янына килеп басты. Ак-сыл нурларын ялтыратып Сөн аръягыннан кояш күтәрелеп килә иде. Тыныч. Моржалардан чыккан төтенне тибрәтерлек тә җил юк. Ап-ак чәчәктә утырган купшы алмагачлар тирә-якка иләһи бер матурлык биреп балкып утыралар.

Иртәнге тынлыкны бозып урамда мотоцикл тавышы ишетелде. Менә Хәсән дә килеп җитте, ул хәзер аны пристаньга төшереп куячак...

*
* *

Рәхимҗан балтасын түмәргә чабып куйды, эшләпәсе белән йөзен җилләтеп алды. Ифрат та әйбәт сәфәр булды ул, отрядның разведка начальнигы белән очрашу үзе генә ни тора. Баксаң, әтисе бер дә хәбәрсез югалмаган икән ләбаса, Богдановка дигән авыл янындагы туганнар каберлегендә аның да исеме бар, кара гранит ташка уеп язылган. Военкомга рәхмәт, әйбәт киңәш бирде... Ул арада, кулларына магнитофон тотып, аны бар булган көченә уйнатып, егетләр урам әйләнергә чыгып киттеләр.

Әйе, әүвәл армиягә болай китмиләр иде. Хәерлегә булсын...

## Укучының күңел дәфтәренә

### Немец мәкальләре һәм әйтемнәре


*Бәла бәлага кил бирә.*
*Күпләр күп белә, барысын да беркем дә белми.*
*Дөреслек — иң көчле корал.*
*Ашыгып ярдәм итүче — ике ярдәм күрсәтә.*
*Бүген алдаган кешегә иртәгә ышанмыйлар.*
*Кисәтеп куелган кеше — яртылаш коткарыла.*
*Үзен-үзе мактаучының күршесе булмый.*
*Итенә күрә шулпасы, башына күрә бүрек.*
*Ызгыш усаллык эшләтә.*
*Вакыт — иң яхшы дәва һәм иң яхшы киңәшче.*

Солтан Шәмси

# ҖӘЙНЕҢ КЫЛ УРТАСЫНДА

хикәя

## I



Алар Айсылу белән көтмәгәндә күргәзмә залында очраштылар. Аны күргәч, Рөстәм хәтта югалып та калды, күпмедер вакыт читтән генә карап торды да, бераз тынычлангач, янына килде. Айсылу иптәш кызы белән иде.

Рөстәм белән Айсылу кайчандыр курсташ иделәр. Өченче курска күчкәч, кызны уйлап, ел ярым инде эчтән янып йөргән егет, ниһаять, аның кылларын чиртеп карарга булды. Әмма берни дә барып чыкмады. Егет сүз кузгаткан саен, тегесе гел шаярды-көлде, уенга борды, тирәнгә кереп сөйләшергә теләмәде. Шулай итеп ике-өч очрашу белән, аралары өзелде. Әллә аңламады кыз, әллә юри аңламамышка салышты — анысын ходай белсен. Кыскасы — бу талпынудан егет күңелендә ниндидер салкын юшкын утырып калды. Һәм ул, дөньясына кул селтәп, үзенә бикләнеп, үҗәтләнеп, бар көчен, игътибарын укуга бирде. Аны тиз күреп алдылар, аспирантурага калырга тәкъдим иттеләр. Ул риза булды. Ә Айсылу дүртенче курста ук кияүгә чыкты, кулына диплом алгач та ире белән каядыр еракка, Себер якларына китеп барды. Вакыты җиткәч, Рөстәм дә өйләнде. Әмма барыбер Айсылуны искә төшергәли иде. Шулай яшәп ятканда, инде тынычлана төшкән, күп нәрсә белән килешкән күңелен кузгатып, менә кабат Айсылу пәйда булды.

Күргәзмә залыннан алар бергәләп чыктылар. Нича ел инде күздән югалып торган Айсылу белән бер сөйләшеп утырмыйча аерылышасы килмәде Рөстәмнең, һәм ул аларны кафега чакырды.

Рөстәм шампанскины пышылдатып кына ачты да бокалларга тутырды.

— Әйдәгез, кызлар, очрашу хөрмәтенә,— дип, күбекләнеп торган бокалын күтәрде, чәкештерер өчен башта янәшәсендәге Айсылуга, аннан каршыда утырган Луизага сузылды. Бокаллар чыңлады, беренче йотым телләрне куыргандай итте, салкынча рәхәтлек тамакны иркәләде.

Луиза дигәне урта буйлы, озынчарак йөзле, дулкынланып иңенә төшкән саргылт чәчле егерме сигез тирәләрендәге кыз иде. Кайвакыт ул сөрмәләнгән озын керфекләрен күтәреп сиңа күз сирпеп ала, шунда

зәңгәрсу томанда өртелгән моңсу күзләре күренеп китә. Хәрәкәтләрендә, үзен тотышында назлылык, йомшаклык сизелә. Ул нигәдер уйчан иде.

Залның гөмбәзләнеп күтәрелгән түшәменнән тын гына музыка агыла. Поль Мориа оркестры уйный. Яшерелгән динамиклардан ишетелгән көй сине бишеккә салып тирбәтә, тынычландыра, иңеңә баса башлаган еллардан арындыра, сине үзеңә кайтара. Һәм тыңлаган саен яшәрә, яшәрә генә барасың... Менә син элекке кебек җиңел-җитез, бәхетле һәм әле берни дә югалтырга өлгермәгәнсең...

Рөстәм терсәгенә таянып утырган Айсылуга ара-тирә күз салгалап ала, әчемлекнең тәнгә тарала барган тәэсире гөмбәздән агылган музыка белән кушыла, зәңгәрсу пәрдәләр аша кафе эченә кояш нурлары сирпелә, онытыла барган хисләрне уята. Айсылу хәзер ялгыз икән — иреннән аерылып, менә ярты ел инде биредә, әнисе янында яши.

...Менә галәм чиксезлегендә куллар табыша. «Ул хисләр миндә һаман яши микәнни?— дип уйлый Рөстәм, үз-үзенә гаҗәпләнеп һәм Айсылуның кулын кыса.— Нигә ел үтте югыйсә...» Айсылу аңа борыла, ул үзгәргән дә, үзгәрмәгән дә кебек. Тик күз әйләнәсенә берничә җыерчык кына кунган, күзләрендә упкын карасы. Упкын сине тарта, башларны әйләндерә...

Шул вакыт баядан бирлениндидер уйларга бирелеп утырган Луиза кинәт сулкылдый башлый. Алар икесе дә кызга борылалар. Луиза, башын ия төшеп, кулъяулыгын эзли, сөрмәле керфекләреннән берәм-берәм күз яшьләрен ала. Ә үзе аларга карамыйча гына:

— Зинһар, игътибар итмәгез, хәзер үтәр,— дип, гафу үтенә, көлемсерәргә тырыша. Көлемсерәү зәгыйфь чыга. Ә күз яшьләре аны тыңламыйлар.

— Тагын Равилне исенә төшерде,— дип пышылдый Айсылу.

— Кайсы Равилне?

Айсылу аңа дустының фамилиясен атый.

— Ни булды? Нигә җылый ул?

— Яратканга,— ди Айсылу, Луизадан күзләрен алмыйча.

— Ә Равил?

— Ә ул, минемчә, болай гына йөри, кызганып кына...— Бу Рөстәм өчен яңалык иде.— Луиза аның аспиранты,— дип өсти Айсылу һәм үзен кулга алырга өлгергән Луизага өстәл аша елмая: бирешмә, молодец, янәсе.

Рөстәм аны кызганып куя, ә эченнән: «Ничек яхшы аңлыйм мин сине, кызый»,— дип уйлый. Аның кызга ярдәм итәсе килә...

Тагын күпмедер утыргач, алар урамга чыгалар, акрын гына трамвай тукталышына таба китәләр. Көн әле кичкә авыша гына башлаган, шәһәрнең бу өлешеннән күренеп торган Идел өстендә су таңкәләре җемелди, ара-тирә көймәләр күзгә чалына.

Чатка җитеп сөйләшеп торганда, Луиза аларны, ире белән көньякка ял итәргә китеп барган иптәш кызының квартирына кереп, чәйләп утырырга чакыра. Рөстәм бу тәкъдимне шундук кабул да итә һәм Айсылуга карый. Ул да риза була.

— Алайса, киттек,— ди Луиза, ялгыз калмавына сөенеп.

— Мин хәзер киләм,— ди Рөстәм һәм йорт почмагына сыенган телефон-автоматка таба атлый.

## II

Равил дә килде. Алар бер сәгатькә якын инде бүген үзләре карап чыккан Ислам Каратаев күргәзмәсе турында гәпләшә-гәпләшә чәй эчәләр иде. Бәхеткә каршы, Равил дә күргәзмәдә булган һәм, рәссам-

ны якыннан белгән кеше буларак, ара-тирә фикерләр «ыргыткалап» утыра. Айсылу үзе катнашмый гына бәхәсне тыңлый, дикъкать белән рәссамның күргәзмәдә кулга төшергән каталогын актара.

— Шул-шул менә, егет елдан-ел үзенә бикләнә, камерныйлана бара,— диде Равил. Сүз рәссамның соңгы елларда пейзаж һәм натюрморт белән мавыгуы хакында иде.— Әлбәттә, сәнгать тирәсендә чуалган хатын-кызлар моны, тырыша-тырыша, лиризм, тирәнәю, рәссамның эзләнүләре, дип исбатларга тырышалар. Ә минемчә, бу барыбер офыкларның тараюы, камерность.— Ул суынган чәен эчеп куйды да кул аркасы белән кара сакалына тоташып үскән мыегын сөртеп алды.

— Бәлки кеше чыннан да эзләнәдер,— дип каршы төште Рөстәм.— Хәтереңдәме, ул ничек башлады?

— Әлбәттә,— диде Равил, башын кагып.— Ул чакта егеттә көч, масштаб һәм шул ук вакытта заманны, кешене тою бар иде.— Ул, үрелеп, Айсылуның кулыннан каталогны алды да рәссамның эшчеләр тормышына батышланган баштагы эшләрен ачып-ачып күрсәтте. Аннан каталогны Айсылуга кире бирде.— Нинди ихлас иде ул. Кайберәүләр борын җыерып йөргән хезмәт темасында да әйтер сүзен тапты, ихлас булып кала белде.

— ...һәм шуның белән алдырды да,— дип куйды Луиза һәм тантаналы карашын Равилгә төбәде.

Равил бер мизгелгә аңа тукталды, беленер-беленмәс кенә елмайды да:

— Әйе, шуның белән алдырды,— дип, кызыйның сүзен җөпләде,— әмма беренче чиратта, әлбәттә, үзенең кабатланмас стиле, житлеккән фикере, кыюлыгы, осталыгы белән алдырды.

— Ул чакта рәссам боларны үзе дә аңлап бетерми иде шикелле,— диде Рөстәм уйчан тавыш белән. Ул бал кашыгы белән чәен болгатып алды.— Рәссамның әйтәсе килгән сүзе белән заман таләпләренең туры килүе иде ахрысы бу.

— Бик мөмкин. Минем бу хакта уйлаган юк иде әле,— диде Равил.

— Минем колакка кайдадыр әләгеп калды: теге картинасын Ленинград сатып алгач, ай буе ышанмыйча йөргән, имеш,— диде Луиза.

— Күрәсеңме, минеке дөрескә чыга шикелле,— дип куйды Рөстәм.

— Күргәзмәне караганнан соң миңа, мәсәлән, әйберләрне сайлаганда Исламга таләпчәнлек житеп бетмәгән кебек тоелды. Әйберләр чынлап та күп, ләкин арада ашык-пошык эшләнгәннәре дә очрый. Син моны ничек аңлатыр идең?— дип сорады Айсылу Равилдән.

— Төп сәбәп, минемчә, картиналарның остаханәдә җыелып ятуында. Рәссамның бит аларны сатасы килә. Ә кешегә күрсәтмичә ничек сатасың. Менә шуңа күрә дә яхшысын да, начарын да дигәндәй, күргәзмәгә куйган. Кемнең күңеленә нинди хуш килә бит,— диде ул, сүзен тәмамлагандай итеп.

Тынлык урнашты. Краннан тамган су тавышы ишетелде.

— Сез монда аның баштагы эшләрен мактап утырдыгыз,— Айсылу ачык килеш алдында яткан каталогка жинел генә чиртеп алды.— Ә хәзер, үзегез әйтмешли, ул таррак, камерныйрак планда эшли икән. Сәбәбе нәрсәдә соң?— Сорау, атап бирелмәсә дә, моңарчы күбрәк башкаларны тыңлап утырган Рөстәмнең үз фикерен әйтәсе килде. Күргәзмә залында ул инде бу хакта уйлаган иде.

— Нәрсәдә дип... аның сәбәпләре күптер инде. Шулай да хикмәт, минемчә, рәссамның бик тиз күтәрелүендә. Чыннан да, ул бик тиз калкып чыкты, актив эшләде, күргәзмә саен яңадан-яңа эшләре күренеп торды, һәм алар гел нинди дә булса яңалык алып килләләр иде. Әмма бу ашкыну ниндидер бер этапта аны туйдырды шикелле, аның туктап уйланасы, үз асылына кайтасы, күңеленең нечкәрәк кылларын

тартып карыйсы килгәндер, күрәсең. Иҗатында күбәеп киткән туган як табигате, авыллар, лирика нәкъ менә шул хакта сөйли кебек.

— Ә минемчә, ул үзенә хас сыйфатларны елдан-ел югалта бара,— диде Равил, урыныннан калкынып.

— Киресенчә, елдан-ел ачыла гына бара,— Рөстәм кулы белән һаваны ярып төшерде.— Синеңчә, ул гомере буе бер юнәлештә эшләргә тиеш, шулаймы?..— Һәм кечкенә генә паузадан соң дәвам итте:— Дустым!.. Ул бит эзләнүчән кеше, төрле алымда, төрле техникада үзен сынап карый һәм дөрес эшли дә. Менә күрерсең, бу эзләнүләре белән ул киләчәктә башка яктан ачылып китәчәк. Шуны онытма: сәләтле кеше гел үзгәреп тора, бервакытта да үз-үзен кабатламый. Кабатлый башлады исә — художникны бетте дип исәплә (киң мәгънәдә әйтәм). Ислам Каратаев — сәләтле егет. Ә сәләтле кеше, нәрсәгә генә тотынса да, сәләтле инде ул.

— Белмим, белмим,— диде Равил, Рөстәмнең һөҗүмгә күчүеннән бераз аптырап калып.— Киләчәк күрсәтер тагын.

— Вот именно!— дип кычкырды Луиза һәм урыныннан сикереп торды.— Җитәр бәхәсләшергә, әйдәгез, танцевать итәбез.

## III

Равил белән Луиза Глория Гейнорның күкрәктән чыккан назлы тавышына бер-ике әйләнделәр дә, Рөстәм белән Айсылуны ялгыз калдырып, күрше бүлмәгә чыктылар, аннан балкон ишеге шапылдады, Луизаның онытылып көлүе ишетелде. Көйләрнең кайберсе танец өчен артык җитез, кызу ритмда булганлыктан, аяк өсте генә тыңлап, бүлмәне күзәттеләр.

Мондагы җиһазларның бер як стенаны каплаган стенкадан башкасы барысы да борынгы, затлыдан иде. Идәнне зур кызыл келәм каплаган, җиз тоткалы, кара агачтан уеп-сырлап эшләнгән биек ишекләр, шүрлекләрдә Майсен фарфоры, ялтыратылган кызгылт Бетгер керамикасы, алтын рамнар эчендә ике-өч картина, үткән гасырдан калган затлы урындыклар, күпертмә бизәкле түшәм уртасында матурлыгы белән бүтән әйберләрдән калышмаслык зур люстра эленеп тора. Луизаның аңлатуына караганда, бу квартирада карт юрист яшәгән. Ул моннан өч ел элек үлеп киткән, квартирада аның бердәнбер кызы — Луизаның иптәш кызы — утырып калган. Ә бай кызларга, Луиза әйтмешли, кияү тиз табыла.

Рөстәм кабат Айсылуның кулын учына алды, икенчесен аның биленә салды да кара күзләренә караган килеш музыка агышына бирелде. Икесен дә җиңелчә дулкынлану биләп алды. Рөстәм аны сак кына үзенә кысты, ул каршылык күрсәтмәде, читкә дә борылмады. Ир башта аның кашларына кагылып узды, аннан иреннәреннән үпте һәм күкрәгендә дөрләгән ялкынга буйсынды. Рөстәмнең карашы аны иркәләде.

— Алай карама, зинһар,— диде Айсылу.

Җавап урынына Рөстәм елмайды гына.

— Нишлим соң, карамыйча булдыра алмыйм.

— Ә син ихтыярыңны җик.

— Әйтүе җиңел.— Ул кабат елмайды, хатынның биленнән ныграк кысты.— Син миңа һәрвакыт ошый идең.

— Ошый идем?— диде Айсылу, белмәгәнгә салышып.— Без күп очрашмадык ич.

— Очрашмадык шул...

— Яшь чаклар, җүләр чаклар,— диде хатын, шаяруга борырга теләп. Бераз дәшми торгач, шулай да әйтте:— Ул чакта бөтенләй башкача иде. Хәзер мин дә нәрсәнедер аңладым шикелле.

— Әйе, тормыш аңлата. Мин дә күп нәрсәне аңладым, әмма...

— Нәрсә «әмма»?— диде хатын, шул «әмма» артында ниндидер мөһим нәрсә ятканын сизеп.

— ...үзгәрә генә алмадым ахрысы.

Айсылуның кара күзләре аңа төбәлделәр, алар торган саен җылына, дымлана баралар иде. Шулай күпмедер күзләрен тутырып карап торгач, ул кинәт Рөстәмнең күкрәгенә капланды. Шул вакыт хатынның ялгызлыкта зарыккан йөрәге уянып китте, канатларын җәеп очарга талпынды.

— Белсәң иде, белсәң иде кешегә бәхет ничек аз бирелгәнен.— Аның иңнәре тетрәнеп алды.— Мин арыдым, шулкадәр арыдым... Рәхмәт сиңа.

Бу минутта Айсылу үзенең бик тә кадерле, бик тә кыйммәтле нәрсәгә юлыгуын аңлады. Ул нәрсә — Рөстәмнең еллар буе саклангач тугры хисләре иде. Әлеге хисләрне бер генә дә югалтасы, ялгыш кына чайпалдырып, түгеп җибәрәсе килми иде аның. Әмма беренче дулкын үтеп, исенә килгәч, сорады:

— Синең кем, малаймы?

— Малай,— диде Рөстәм.

— Ә минеке — кыз.

Рөстәмнең аны кабат чәчләреннән сыйпап иркәлисе, йомшак иреннәрен татыйсы килде. Әмма Айсылу үзен тиз кулга алды, аның иреннәрен кулы белән каплады.

— Җирәкми. Әйдә, тегеләр янына,— диде Айсылу.

Бер кулына суыткычта торган сыра шешәләре, икенчесенә юка стаканнар тотып, Рөстәм балконга чыкканда анда ни турындадыр кызып-кызып сөйләшәләр иде.

— Бер акыл иясе әйткән: бәхетле буласың килсә, була күр, дигән. Тагын ни кирәк?— диде Равил.

— Бу бит җавап түгел, җаваптан качу гына,— диде Луиза.

— Дөрес,— дип сүзгә кушылды Рөстәм һәм Равилгә стаканнарны сузды. Тегесе аларны балкон култыксасына тезде дә сыра агыза башлады.

— Барысын да анализлаучы кеше гомумән бәхетле була ала микән ул? Декарт әйткән бит: мин уйлыйм, димәк, мин көн итәм, дигән. Игътибар ит: яшим түгел, көн итәм. Икенче төрле итеп әйтсәк: анализым белән үз бәхетемне җимерәм,— диде Равил.

— Күп вакыт кеше үзенең бәхетле икәнен аңламый. Барысы да соңыннан, вакыт үткәч ачыклана,— диде Рөстәм.

— Юк һәм тагын бер тапкыр юк,—дип каршы төште Луиза, ул сыралы стаканын култыксага куйды.— Кеше, минемчә, һәрвакыт мин бу минутта бәхетле яки бәхетсез дип әйтә ала.

— Бөтен нәрсә чагыштырганда белеңә,— диде Равил, фәлсәфи урталыкны сайлап.

— Ә кемдер әйткән: бәхет кешенең үз кулында. Ә кемнендер түгел. Ул вакытта соңгысына нишләргә? Язмышка үпкәләп яшәргәме?

Рөстәм: Үзең булып калырга. Бердәнбер юл.

Луиза: Ягъни эчке гармониягә омтылырга. Шулаймы?

Равил: Эчке гармония ул әле бәхет түгел. Кайбер очракларда бәхетне алыштыра алса да...

Айсылу: Ә минемчә, бәхет ул стихия кебек, булса була, булмаса булмый гына. Аны берни дә алыштыра алмый.

Рөстәм: Ә син фаталистка икәнсең?

Айсылу аңа карап елмаеп куйды.

— Ә кем миңа әйтә ала: нәрсә ул бәхет? — диде Луиза һәм балкондагыларга күз йөртеп чыкты.

Тынлык урнашты. Һәркем үзенекен уйлый иде. Рөстәм исә бәхетнең менә кул сузымында гына басып торуын, ара-тирә аңа күз сирпеп алгалавын күрә, хәтта башкаларга сизелмәгән җылысын да тоя иде.

Ә Луиза, итәккә ябышкан тигәнәк кебек, үзенекен итте.

— Ник дәшмисез?— диде ул, бер селтәнүдә барысын да әйләндереп салгандай.— Ә бәхәсләшкән буласыз. Әйдәгез, лучше чәй эчик.

Алар кире урамга чыкканда, кояш инде Иделнең каршы ягындагы тау өстендә иде: менә-менә төшеп югалырга тора. Җәяүләп кенә Кольцога төштеләр, аннан, юллар чатында тукталып, бераз сөйләшеп тордылар, гүя бүтән кануннар һәм хисләр хөкем сөргән дөньяга әйләнеп кайтасылары килми иде.

Беренче булып Айсылу кузгалды. Трамвайга утырыр алдыннан ул шәфәкъ алсулыгы йөгергән күккә күз салды да, ниндидер уйларына елмайгандай:

— Беләсезме, бүген бит җәйнең кыл уртасы,— дип куйды.

«Гомернең... гомернең...» дип уйлады Рөстәм һәм ул утырып киткән трамвайны карашы белән озатып калды.

Аның күнегелгән, җайга салынган тормышында бүген нәрсәдер үзгәрде кебек. Тик бу минутта ул үзен ниләр көткәнен дә, ниләр буласын да, күңелендә кузгалган хисләр йомгагын киләчәктә ничек аралап чыгасын да — берсен дә, берсен дә ачык кына белми иде.

Күз бәйләнә башлаган иде инде — урамнарда бер-бер артлы утлар кабынды.

## Укучының күңел дәфтәренә

### Серб мәкальләре һәм әйтемнәре

*Көчле янгын да кечкенә уттан чыга.*

*Кирәк чакта кызу чап, чапсаң — борын җимермә.*

*Рәхмәт сүзе — ярдәмнән зур.*

*Кеше битенә чүп атсаң — үз битеңә сугарлар.*

*Биеккә менсәң, күбрәк күрәсең.*

*Алтын быргы күп кычкырган җирдә гаделлек пычракта ята.*

*Юләрнең юләр икәнен юләр сорау белдерә.*

*Артык комсыз булмасаң, булган ни барың җитә.*

*Кан коючы явыз затлар йөрәк ярасын күрми.*

*Тамырына күрә агачы.*

*Алданган кеше урлый, урлаучы алдый белә.*

*Җир сөргән төрән тутыкмый.*

## Фәннур Сафин

### Туган җир

Юкка гына әйтмиләрдер:
— Үзеңнеке — үзәктә.
Туган җир һәр мизгел безнең
Яшәешне күзәтә.

— Танып-үлчәп кара,— ди ул,—
Табигатьтә юк хата.
Һәр яфракта, һәр үләндә
Синең киләчәк ята.

Һәр тамчы чишмә суында
Киләчәгең-килерең.
Беркайчан да язмышның тик
Сайлый күрмә җиңелен...

Һәм каушама дөрләп янган
Утларга кергәндә дә,
Йөз яшьлек имәнне егып
Давыл тилергәндә дә.

Тез чүкмә, килсә дә афәт
Җирең-Ватаның өчен.—
Гасырлар буе яулаган
Исмеңне акла, Кешем!

### Сабыр итсәң дә...

Тыныч кына сабыр итсәң дә
Я очсаң да елгыр аргамакта,
Бу дөньяның шушы өлеше
Тулысынча синең карамакта.

Синеке ул бүген, синеке:
Урмандагы якты аланмы ул,
Нәни генә кызыл баланмы,
«Мәммәм!» дип кул сузган балаңмы,—
Синеке ул, бары синеке!

Һәм син аны бәлки дөньяга
Нур сирпегән алсу гөл итәрсең.
Яки көек исе ерактан
Күзгә кергән күмер-көл итәрсең...

Күпме хикмәт, нинди язмышлар
Безнең кулда, безнең карамакта! —
Юл тотар ул безнең дәвамнар
Кай тарафка, нинди аргамакта?..

## Күңел нишләр?

Язлардан соң язлар килеп
Гомерләре ялганса;
Таңнардан соң таңнар туып
Киң офыклар алланса?

Нишләр күңел, алкышлармы
Гомернең балкышларын;
Иңнәргә үк кунып кына
Сайраган таң кошларын?

Теләр мәллә көзләрне ул,
Кышкы чал бураннарны;
Өши-өши әйләнергә
Буранлы урамнарны?

Ни булса да, сагындырыр
Борчулы наз йөрәкне.
...Җан табынган давыллардан
Ничек качыйм икән соң дип
Өзгәләнү кирәкме?..

●

Кылганнарың, кылмаганың
Уйланып йөргән чакта,
Нинди моңсу, нинди рәхәт,
Җырлыйсы килә хәтта!

Ниндидер моңлы ышаныч
Торадыр җанда сакта:
Кемдер сүгеп, кемдер сөеп
Сөйли күк безнең хакта.

Гомер бакый без булмаган,
Без күрмәгән бер якта
Безне сагынып сөйлиләр күк,
Төреп сафлыкка-акка.

Кылганнарың, кылмаганың
Уйланып барган чакта,
Нинди моңсу, нинди рәхәт,
Елыйсы килә хәтта!..

Кырлар кебек давыллана Ыгым
Безнең яшьлек калган тугайда.
Ник ярсыйсың шулай, тымытыгым,
Йөрәк тыныч түгел болай да.

Ул бөрлегән җыеп йөргән болын
Су астында инде күптәннән.
...Юатам күк һаман назлап кулын:
— Берни булмас,— дип,— бер үпкәннән.

Ә дулкыннар сикерә күкрәгемә:
— Үкенмә,— дип,— егет, үпкәнеңә,
Ул иреннәр,— дип,— ал бөрлеген.

Дулкын үзе яшь кыз кебек кача...
Ә мин судай аккан еллар аша
Хәтер елгасына үреләм...

## Учак яктык

Яктык учак, кордык куыш
Идел буе-үзәндә.
Балкыр иде дөньям тагын,
Сине тик бер күрсәм дә.

Төштә генә түгел иде
Ул балкулар, янулар.
Бер-береңне якыным дип,
Алтыным, дип танулар.

Кайда ул көн? Табылмастыр
Еласаң да, көлсәң дә.
...Яктык учак, кордык куыш
Идел буе-үзәндә...

## Яки шул ук...

Чиксез бөекләр без Җир шарында!
Яки гади татар малае...
Без карыйбыз күккә горур, җитди
Я карыйбыз җиргә елмаеп...

Син дә, мин дә үстек. Онытылды
Йөргән чаклар чабата киеп.
Үткәннәрне ләкин еш уйлыйбыз,
Я атлыйбыз башларны иеп.

Җирдә һаман шул ук яңгыр, я кар,
Татлы төтен, шул ук — иртәнге.
Кулын болгап шул ук ак каеннар
Карап калыр безнең китkәнне!..

## Лена Шакирҗанова

### Сәмәрканд базары

Шәрык! Шәрык! Көмеш арык!
Юмарт кояш, көләч халык.
Кавын-карбыз, хөрмә-җимеш:
карап торма, әйдә, җитеш!
...Бармый калма, диләр иде
Сәмәркандның базарына,
Онытылмаслык җырлар төяп
кайтырсың дип Казаныңа...
Шаулый базар, гөрли базар,
көләч йөзләр, шомырт күзләр.
Җанга рәхәт булып китә,
ишетелгәч таныш сүзләр...
Агыла җыр бертуктаусыз —
дөньябызны онытабыз:
Язып алып сүзләрен үк
бер әкәдән җыр отабыз...

«Михманларга — хөрмәт», диләр,
карамыйлар ятлар итеп.
Үзбәк егете түбәтәен
салып бирде ядкарь итеп.
— Авыз итми китмәгез,— ди
Сәмәркандның кабартмасын...
Бигрәк кунакчыл як икән —
ничек итеп яратмассың!
Ашап туя торган түгел
мантыйлары, лагманнары.
Аяк бөкләп күк чәй эчсәң,
бетә бөтен арганнарың.
Өем-өем киштәләрдә
парча-парча кызыл маллар:
«Менә бусы җәдә затлы —
Казан кызы, алмый калма!..»
Бер сылуның чәчләренә
һәммәбез дә хәйран калдык.
Үзе сизмәгәндә генә,
толымнарын санап алдык...
Артык озак булмый йөреп,
вакыт бик тар, вакыт тыгыз.
Кунак ашы кара-каршы —
кичен сезгә концертыбыз.
Сәлам алып килдек сезгә
Татарстан, киң Иделдән.
Җырларыбыз — дулкын шавы,
чакырабыз чын күңелдән!
Шәрык, Шәрык! Көмеш арык!
Кояшыдай юмарт халык.
Ап-ак мамык кырларыгыз,
ап-ак кайтыр юлларыбыз.
Йөрәкләргә сеңеп калды
аллы-гөлле моңнарыгыз...
...Бармый калма, диләр иде
Сәмәркандның базарына —
Якын дуслар таптым анда
һәм җырларын отып калып
алып кайттым Казаныма.

### Җир белән күк арасында түгел мин

Җир белән күк арасында түгел мин.
Кичә җирдә икән — күктә бүген мин.
Я иң аста, иң түбәндә, иң-иң төптә.
Я түбәдән карап торам, бик биектән.
Бер мәл язмыш сөйри мине гел тирәнгә,
һәм мәтәлеп тәгәрим мин чокырларга.
Әмма кабат таулар дәшеп, чакырып ала...
Кайчак менеп җитәм генә дигән чакта
Ычкынам да упкыннарга барып төшәм.

Тик яңадан үрмәлим мин бөтен көчкә:
Барыбер, дим, күтәрелеп чыгам өскә!
Үрмәле гөл кеби, кояш нурларына
Үрелә-үрелә, үрлим үргә, югарыга.
Әкияттәге сәмруг коштай күккә ашам,
Үзем менгән яңа биеклекне ачам...

Җир белән күк арасында түгел мин!

## Уйлану

Тәпи йөрер чагы җиткән —
идәнгә төшкән бала.
тирбәтеп, назлап үстергән
бишеге кемгә кала?..

Газиз әнкәмнең әнкәсе
толымын үргән тарап,
учымда — талир тәңкәсе —
бу төсе кемгә кала?..

Күрәген куеп бер читкә,
ил карты уйга кала:
чишмәсен казыды, суын
эчәргә кемгә кала?..

Бер-бер артлы оланнарны
үзенә тартты кала.
Ата-баба гомер иткән
төп нигез кемгә кала?..

Тергезеп торганда гына
учаклар дөрли, яна.
Тукайлы, Такташлы иткән
бу телем кемгә кала?..

Җайга искән җил көенә
уйга талган киң дала:
Бу тынлык кемнәр кулына,
бу киңлек кемгә кала?..

Офыклар манчылган нурга,
төн ишегён таң кага.
Без китәрбез шәфәкъ байгач,
ә Кояш кемгә кала?..

Һәр мизгел көтә күк җавап,
замана сорау ала:
бу тормыш кемнәр иңенә,
бу дөнья кемгә кала?!

## Үзе чакырып алыр...

Дускай, нишлик, әллә дим
монда калабызмы?
Әллә инде яшьлеккә
кире кайтабызмы —
дәшеп торган чагында
кайнар кайтавазы?..

Әйт, синеңчә кайда без
кирәгерәк икән?
Кайда безнең кебекләр
сирәгерәк икән?..
Әллә йөгереп үтикме
калган чакрымнарны —
бик теләсә яшь гомер
үзе чакырып алыр...

Әйдә, очыйк еракка
икәү, канатланып,
Сагынсак та үткәнне,
бүтән кабатламыйк...
Сүндермәсәк йөрәктә
дәртле чаткыларын,
Яшьлек безне кирәктә
үзе чакырып алыр...

●

Кайгы мине, күрәмсең,
озак эзләгән инде.
Бүген сугып ега язды —
кичә кизәнгән иде...

Бәхет безнең арадан
күптән югалган иде.
Бүген килеп кулын бирде —
кичә елмайган иде...

## Мөдәррис Вәлиев

# ДӨНЬЯ ДИГӘН ЙОРТЫБЫЗ

### Сөйләде таш...

Бер ялгызым япан кырда торам,—
Зур мәйданда биниһая мәгъруо
Александр колоннасы сыман.

Миңа нигә аксөяклек саны,
Миңа нигә тәкәбберләр даны!
Газиз бары маңгайдагы сырлар...
Һәр сыр — ядкарь,— орышлардан калган.
(Булганмындыр бәлки соңгы калкан!..)

Туфрагымда череде ханнар даны,
Күз яшемдә эреде яулар даны..
Кайнар җанда — күккә кадәр оран,—
Александр колоннасы сыман,—
Әверелеп камертонга, яңгыра:

Охшасам да оешып каткан канга,
Охшасам да кисәү төсле җанга,
Нахак белән рәнҗетмәгез мине:
Халкым куенындагы таш түгелмен!

...Чорлар — урам.
Мин бер чатта торам
Утлар-сулар кичкән солдат сыман.
Гасырлардан күчкән өмет сыман!

●

Йолдызларын кабыза да,
Йоклый безнең ярымшар,
Үз сәгатен көтеп кала
Хак эшләр һәм ялгышлар...
Мин генә уяу; сөнгедәй
Керфекләр сафта тора.—
Һөҗүм итәргә дип түгел,
Мин бары сакта торам:
Безнекеләр ял иткәндә,
Төн һәм көн авышканда,
Йоклап кала күрмәсеннәр,
Дим, теге ярымшарда!

## Ленинград. Пискарев каберлеге.

Кулларымны чират,
Күкрәгемне зират
итеп күз алдына китердем...
Мин Блокаданы кичердем.

Хәсрәт күз яшеннән,
Нәфрәт кургашыннан
әверелеп Язгы Тамчыга,
Күзләреңне юар идем, Дөнья!—
Хәтер уты җанда:
ян, чыда!
Мин Блокаданы кичердем...

Катламнарны ярып,
Шул нигезгә
барып чыга, берегә тамырым.
Мин бәхетле: бүген үзебезнең
Баррикадаларны таныдым.

●

*— Әти, ә атлар ни турында сөйләшә?*
*— Үтелгән юл турында, улым...*
(Шәһәр урамында сөйләшү)

Авызын яба алмый урам,—
Мине кемгә саный!
Адым саен кызыл күзе
Шелтә белән карый.

Заманнан артта калган дип,
Каш җыерма, кала:
Утка табынып кына мин
Кеше була алмам.

...Трамвайлар эре генә
Узып киткән була;
Ерак китеп буламыни
Кемдер салган юлдан?!

Яшел уттан — яшел утка
Дөнья күрә, имеш...
Кайвакыт атка карап та
Гыйбрәт алу тиеш...

●

— Җәйге төн шикелле җылы толымыма
Чит-ят күздән сине генә качырыр идем...
Бер тамчы сер калган булса күңелеңдә,
Мин төнбоек булып шунда ачылыр идем.

Җәйге төн шикелле җылы күзләреңә
Керфек итеп мине генә алсаң иде...
Бер яфрак хис калган чакта күңелеңдә,
Мине кәккүк сурәтендә танысаң иде.

...Җәйге төндә сине шулай иркәләрмен,
Горурлыгым яшерермен дә толымыма:
Мәхәббәтнең синең кебек гадилеген
Йолдызлы күк гел искәртеп торыр миңа...

●

Җиләкле алан... Соңгы чык
Эри чалгы йөзендә.
«Таңда килермен, көт! Таңда-а!..—
Сагынуга син түз генә...»

Ак томан шаһит,— ак чатыр:
Борылдым ярты юлдан!—
«Ул мәлдән китмәс идең шул,
Курыксаң югалтудан».

Чал нарат шаһит,— карт буйдак,
Ылысын коя аска:
«Көткән — сабыр, көтү — авыр,
Юлыңны үлән басса...»

«Таңда килермен»,— дип киттем.
Өнсез җыр — моңсу алан.
...Өзелгән чыклар дисбесе
Таралган да югалган...

## Адәм белән Хава

Син мине сәерсенеп, бер
туйганчы көләсеңдер...
Көл, сиңа көлү килешә,—
үзең дә беләсеңдер.

Канатлан, оч та кул изә
офыклар арасыннан;
Ә минем әле кояштан
бераз ут аласым бар.

Көнләшмә, эземне күреп
офыкта... И аппагым,
Әйтмәдеммени Җир мине
иртәрәк яратканын?..

Кил әле учак куенына,
үкенмә узганына!
Ачкыч эзлик Дөнья диган
йортыбыз йозагына.

●

Олы фикер җиргә иңде
Кечкенә бер кеше сурәтендә...

Үзен кая куярга белмәде кеше...
Үзен кемгә тыңларга белмәде кеше!

Ә мин куркам:
җил уңаена китмәсме?
Караңгы почмакта үзен
усал зат харап итмәсме?

Олы фикергә
кечкенә бер кеше сурәтендә
җиргә иңү бик хәтәр бит!

●

*Сак бул!*
*Сары яфрак аска тарта.*

**Хайнал ГАБОР,**
венгр шагыйре

Сагынуымнан сары яфрак булдым,—
күмеп китте ак кар.
Өзелгән яфраклар еламый да,
Яңадан кайтуны уйламый да
өзелгән яфраклар.

...Күтәрелдем кайнар бозлар булып,
салкын суга актым.
Дулкын кире какты сагышларым,
Әрнүләрем, хата-ялгышларым
дулкын кире какты.

...Әверелдем туган яктан килгән
ялгыз бер болытка:
Сары төнбоеклар яуды кичен,
Тар бүлмәмнән киң дөньяга күчте
сары төнбоеклар.

## Язмыш

Мин — диңгездән киткән тамчы идем,
Диңгеземә кабат кайтыр идем,
Диңгеземә бер кайтасым килә!

«Кайтар...»— диеп мин ялвардым җилгә,
«Кайтар!»— диеп мин инәлдем Җиргә.

Дулкын канатында бер өн килде:
«Тамчы булсаң, кире кайтыр идең...
Үзең диңгез булгач — кайту юк...»

*1978—1980*

## Ркаил Зәйдуллин

●

Ташларгамы җанны чиксезлеккә,
Йолдыз белән кыскарсын дип арам?
...Юк шул, юк шул, сәгать саен мена
Туган туфрагыма иңә барам.

Бик гадәти шул мин — Җир малае,
Бик гадәти нәни, соры оем.
Йоклыйм, шунда ипи ашыйм — бусы
Туган җирем белән үбешүем.

Буразнадан бәреп чыккан нәсел,
Җан асрыйм бик гадәти якта.
Тарту көчен җиңүчеләрне дә
Күз алдыма китералмыйм хәтта.

Мин үземә шундый охшаганмын,
Талпынырга юк куәтем, чарам.
Береккәнмен җиргә шулкадәр дә —
Туфракка әверелә барам!

...Үзең — үзең инде, ә бит җаның?
Ул бит күккә аша, дисездер дә...
Җан дигән сүз матдә түгел, әмма
Беләм: ул да иңә бара җиргә.

### Исемсез кеше

Аның исемен хәзер бер кеше дә белми.
Кулны тыгып актарсаң да,
Юк беркемнең хәтерендә.
Шулай яши ул карт, дәгъвасы юк...
Ә иртәгә менә ул исемсез килеш
Тыйнак кына иңәр каберенә.

Карт-корыдан сорыйм:— «Ул ни атлы?» димен.
Чордашлары аның — алар инде белә.
— Ник белмәскә, соң, әлбәттә, энекәш!
Хәерниса түти малае ул,— диләр.

Егетләрдән сорыйм: «Кем ул, ни атлы?»— дим.
Карт турында миңа бәлки алар сөйләр?
— Нишләп сөйләмәскә? Соң, әлбәттә, инде...
Чибәр Хәдичәнең әтисе ул,— диләр.

Тере кешенең исемен онытканбыз,
Архивлардан эзләп буладыр да, беләм.
Кем эзләсен ләкин? Беркем кызыксынмый,
Кем йөресен, юләр, буш мәшәкать белән...

## Әби

Нидер көйли бер почмакта, намазлык өстендә,
Шул безелдәү генә болай тып-тын йортта...
Кайчан гына
Ике өйне бер итеп йөгереп йөргән хатын —
Дәү әнием — шулмы соң бу кортка?

Мине искәрми дә, утырган да бер почмакта
Иренәнә кысып Коръәннең бер аятен.
Ике өйне бер итеп хәзер яшь килен йөгерә,
Моның
Бер намазлык — бөтен вилаяте.

●

Кырмыска оясына кулны суздым.
Кырмыскалар учым буйлап йөгереп узды.
Гөжләп куйды бөтен бер ил!

«Кем ул анда тынычлыкны бозып йөри?»
Җанны асраганда, мәгънә күреп
Кыса эчендәге яшәештән!
(Бөтен бер ил карап тормый булыр
Ярдәм көтеп табигатьтән, өстән.)

Һәрбер нәрсә канунлашкан монда,
Һәркемнең үз эше үз йортында.
Мөмкин кадәр тизрәк,
Мөмкин кадәр күбрәк күтәрәсе.

Юк монда моң төшенчәсе!
Яшәү өчен яшерен көрәш бара,
Куәтсезләр бәлә, куәтсезләр үлә...
...Никтер шушы кырмыска оясын
Таяк тыгып болгатасы килә.

................

## Рәниф Шәрипов

●

Сүнгән чакта җир өстендә учак уты
Хәлсезләнеп, җилдә соңгы сулыш ала.
Күптән түгел ялкын җылы биргән җирдә
Салкын, сүнгән көл өеме генә кала.

Салкын көлне җил күтәреп һәм тузгытып,
Иксез-чиксез кырлар буйлап җиргә сибә.
Куе үскән яшел, кыргый үлән булып
Башка тормыш тирә-якта инде тибә.

Чүп үләннәр каплый алмый ут оясын.
Әле һаман да буш учак янган урын.
Ут гомере бер кечкенә мизгел иде,
Галәмнәрне гизеп йөри якты нуры...

### Көз

Алмаларын җиргә коеп
Узып бара чәчәк иле.
Берәм-берәм яфрак өзә
Агачлардан төньяк җиле.

Җәйләр үтә... Кошлар китә...
Ә Җир юлын дәвам итә!
Бары тик бер җәебезне
Юллар җиле өзеп китә...

### Яңа туган балага

Яшәү өчен кыен Җир бу.
Я давыллар, я кышлар...
Җир баласы адәмнәрдә —
Кимчелекләр, ялгышлар.

Язын кирәкле яңгырлар
Ява урак өстендә.
Яшь чакта кирәк җиңүләр
Килә китәсе көндә.

Төрле илләр, төрле телләр,
Төрле әхлак бу Җирдә.
Камиллеккә илткән юлда
Адым саен мең киртә.

Шушы менә без торган йорт.
Алдыңда мең төрле юл.
Җәннәт түгел гүзәл бу Җир —
Сынауларга әзер бул.

### Алмагач җыры

Яфрак ярып мин озатып калдым,
Язгы ташу шаулап йөгерде.
Сулар тынып, җилләр кибүгә үк
Чәчәкләрем атып өлгерде.

Язлардан соң килде җәй аены
Сөю кебек кызу җиллесе.

Коелдылар җиргә ак чәчәкләр —
Яз шатлыгы, яшьлек билгесе.

Җәй җылысын имгән бөреләрдә
Көз бәйрәмен көтү тынлыгы.
Җимеш биреп, исбатларга иде
Койган чәчәкләрнең чынлыгын...

Тәүфикъ Әйди

# ТЫЛСЫМЛЫ КӨЧ

**«...Республиканың казанышлары зур... Алар — Совет Үзбәкстанының миллионнарча эшчеләре һәм колхозчыларының тырыш, еш кына хәлләрдә героик хезмәте нәтиҗәсе».**

**Л. И. БРЕЖНЕВ**

«Бахор» бию ансамбле дөньяның меңләгән сәхнәләрендә чыгыш ясаган инде. Нинди генә биюләр башкармаган ул: әзербәйҗан, гарәп, казакъ, рус, таҗик, эстон, япон... «Азатлык», «Көтүче», «Мамык бәйрәме», «Нәмәнган алмасы», «Фиргана робагые»... Бу биюләргә Мисыр, Венгрия, Һиндстан, ГДР, Сингапур, Тунис кебек дистәләгән илләрдә кул чабалар. Ансамбль Швециядә генә дә җитмеш ике концерт бирә, билетлар ике сәгать ярымда сатылып бетә. Яшьлек дәрте, хөрлек рухы, шатлык хисләре бөркелеп торган биюләрне күреп, таң калып: «Сез кайсы илдән?» — дип сорасалар, «Бахор»:

— Без — ак алтын иленнән! — дип җавап бирә.— Исемебез — Яз. Адресыбыз — СССР, Үзбәкстан.

Күпләр «Бахор» ватанына — яз иленә бик теләп сәяхәткә чыгалар. Бохарадагы әлегәчә бер кирпече дә алыштырылмаган меңьеллык Исмәгыйль Самани төрбәсен, дошман яуларын да хөрмәт белән баш ияргә мәҗбүр иткән Калян манарасын, мәһабәт мәдрәсәләрен, Сәмәркандтагы биш гасырлы тарихка ия булган, бүгенге галимнәрне дә гаҗәпләндерерлек Олугбәк обсерваториясен, билгесез осталар салган гүзәл сарайларны күрү кемнәрдә генә Үзбәкстанга мәхәббәт тойгылары уятмый икән?!

Әйе, элек тә талантлы, булдыклы, уңган кешеләр яшәгән монда. Алар замандашларыбызны бүген дә сокландыра торган гүзәл сарайлар корган, атаклы галимнәр Әл-Бируни, Әбугалисина, Олугбәкләрне үстергән, Нәваи шикелле мәшһүр шагыйрьләргә канат куйган. Ләкин миллионнарның хезмәт җимешен аз санлы югары катлау вәкилләре генә үзләштерә торган феодаль җәмгыять «кара» халыкка беркайчан да бәхет китерә алмаган. Җитмәсә, ханнар, әмирләр, бәкләр, морзалар үзара да тату яшәмәгән, тәхет һәм байлык өчен бетмәс-төкәнмәс ызгыш-талашлар, кан коюлы сугышлар чыгарганнар. Бу көрәшләрдә әрәмтамаклар мәнфәгатен яклар өчен хезмәт иияләре тагын чебен кебек кырылган, бик күп әдәбият, сәнгать җәүһәрләре харап ителгән, сарайлар ишелгән, гыйлем учаклары туздырылган һәм, хәтта, мәгърифәтне, фәнне яклаган Олугбәк патша үзе дә шәфкатьсез төстә үтерелгән. Аннары инде бөтен Урта Азия дәһшәтле урта гасырлар караңгылыгына чумган һәм элекке казанышларын да берәм-берәм югалта башлаган [1].

Бөек Октябрь революциясе менә шушы артка тәгәрәүгә кискен чик куя, колониаль изелү кичергән халыкларга азатлык китерә, хезмәт ияләрен сыйнфый бөлгенлектән чыгара, якты матур тормышка киң юллар ача.

Бүгенге Үзбәкстан халкы буенча СССРның алты процентын гына тәшкил итсә дә, бөтен илебездә җитештерелгән газның — чама белән унөч, дөге һәм туку станоклары-

[1] Беренче татар романнарын иҗат иткән мәшһүр язучыбыз Заһир Бигиев моннан туксан еллар элек хәзерге Үзбәкстанны тәшкил иткән Әмударья белән Сырдарья елгалары арасындагы җирләргә сәфәргә чыга һәм анда күргәннәрен «Мавәраәннәһергә сәяхәт» кульязмасында теркәп калдыра.

ның — егерме ике, каракүл һәм ефәк чималының — утыз биш, мамыкның җитмеш проценты бирә. Мамык чәчү, җыю, чистарту машиналары исә СССРда бары Үзбәкстанда гына ясала. Кадак сорап, күршегә мөрәҗәгать иткән Мавәрәэннәһер хәзер корыч коя, суыткычлар, экскаваторлар ясый. Биредә эшләнгән продукция хәзер дөньяның җитмешләп иленә озатыла. Бары сугыштан соңгы дәвердә генә дә миллион ярым гектар сугарулы җирләр булдырыла. Элек кеше аягы басмаган чүлләрдә Нәваи, Зарафшан, Газлы кебек баһадир калалар үсеп чыга, гөлбакчалар тамыр җибәрә.

Заһир Бигиев бөтен Бохара әмирлегендә русча язу танырлык бер кеше дә табылмавы турында аптырап язса, хәзер һәр җиденче үзбәк рус телен яхшы белә. Инглиз, француз, немец, гарәп, фарсы, һинд һәм башка дистәләрчә телләрне әйбәт аңлаучылар саны да меңнәр белән исәпләнә. 1893 елда Бохара әмирлегендә ун меңләп шәкерт була, әмма шәкертләр генә түгел, аларның мөгаллимнәре, мөдәррисләре арасында да математика, физика кебек дөньяви гыйлемнәрне белүче затлар очрамый. Заһир Бигиев сәгатьче Миршәриф атлы кешенең генә укымышлылыгын канәгатьләнерлек тапкан. Хәзер исә Үзбәкстанның кырык өч югары уку йортында 278 мең, 222 урта махсус уку йортында 238 мең студент белем ала. Нәваи исемендәге республика китапханәсендә — сигез миллион китап тупланү да совет власте елларының нинди колачлы җиңүләр китерүе хакында сөйләсә кирәк.

Заһир Бигиев Бохарада газета чыгарырга тәкъдим иткәч, әмирнең уң кулы булган вәзир аны «сәер» ниятеннән бик тиз суындыра. Шәһәрнең укымышлылары дөньяда газета дигән нәрсәнең барлыгын күз алдына да китермиләр. Хәзер исә үзбәк телендә 197 газета, 23 журнал, ел саен меңгә якын исемдә китап басыла. Үзбәк совет язучылары әсәрләре белән бергә классик мирас та даими чыгарыла. Алишер Наваиның үзбәкчә унбиш, русча ун томлыклары бастырылу — моңа ачык мисал. Үзбәкстан Фәннәр академиясе составындагы утыз фәнни-тикшеренү институты һәм гыйльми учреждениеләр, үзбәк телендәге тапшырулары гына да тәүлеккә дистәләрчә сәгать тәшкил иткән радио-телевидение, егерме сигез театр һәм башка культура учакларыннан тыш бүген Үзбәкстанны күз алдына китерү дә читен. Республикадагы өч киностудия 1980 елда гына да алты тулы метражлы нәфис, җиде мультипликацион, 84 документаль фильм, киножурналлар төшергән...

Кыскасы, Заһир Бигиев күргәннәр белән бүгенге көннәрне чагыштырсак, аерма җир белән күк арасы кебек. Үзбәк мәкале раслаганча, айны итәк белән каплап булмый. Шунлыктан, туган илебезнең казанышларын меңләгән чит ил туристлары да танырга мәҗбүр. Алар бүгенге Мавәрәэннәһердә йөргәндә Үзбәкстанның Азия, Африка илләре өчен социализм маягы, социализмның капитализмнан өстенлеген күрсәтүче мисал икәнлеген бигрәк тә ачык тоялар.

Бу казанышларга ничегрәк ирешелгән соң?

Быел унынчы бишьеллыкны яхшы йомгаклаган өчен Үзбәкстанга Ленин ордены тапшырганда, КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Л. И. Брежнев бу сорауга да җавап бирде. «Совет Үзбәкстаны,— диде ул,— нәкъ менә СССРдагы барлык тугандаш халыклар белән кулга-кул тотынышып, тыгыз сафларда баруы аркасында гына элекке артта калганлык дәрәҗәсеннән шулай тиз күтәрелә һәм күп яктан үскән, чәчәк атучы республикага, көнчыгыштагы иң алдынгы дәүләтләрнең берсенә әверелә алды».

Әйе, халыклар дуслыгының тылсымлы көче Мавәрәэннәһердә канат җәйгән торгынлыкны җимерүдә дә, дини томаналыкны юкка чыгаруда да, белемнәр таратуда да, сыйнфый изүне бетерүдә дә, культура һәм экономиканы үстерүдә дә, берьюлы алты миллион квадрат метр туракны юкка чыгарган җир тетрәү фаҗигасын җиңүдә дә, кыскасы, Үзбәкстан тормышының һәр тармагында имтихан тотты һәм үзенең могҗизалар тудырырга сәләтен раслады. Без моны Урта Азиягә килеп урнашкан якташларыбызның кардәш милләтләр белән аралашуы һәм хезмәттәшлек итүе мисалында да ачык күрә алабыз.

Академик В. В. Радлов расланганча, Россиягә кушылган чорда Төркестанда биш мең чамасы татар яшәгән. Алар тупланган урыннар арасында Ташкентның көньягында шәһәр үзәгеннән егерме чакрымнарда урнашкан Нугайкорган авылы аеруча атаклы.

Хәзер Үзбәкстан башкаласы эчендә калган бу авылга Казан ягыннан килгән якташларыбыз нигез салган. Үзбәкләр аларны «Нугай» дип атаганнар. 1866 елда П. И. Пашино язганча, шул Нугайкорган Төркестан краенда бәрәңге үстерүче бердәнбер урын була.

«Урта гасырларда Идел буйларында культура Бохара һәм Хивадан китерелә иде,— ди В. В. Бартольд «Мөселман мәдәнияте» дигән хезмәтендә.— XIX гасырда Русия аркылы Европа культурасы белән танышкан Идел буе татарлары Төркестандагы дин кардәшләрен үзләре агарта башлый».

Җәдит мәктәпләре ачылу мәгърифәтне яңа баскычка күтәрә. Шундый мәктәп-мәдрәсәләрнең беренчеләре 1890 еллардан соң барлыкка килә. Ш. Мохтар, З. Габделваһап кебек татар мөгаллимнәре үзбәк балаларын да укыта башлыйлар.

1905 елгы революция тәэсирендә Урта Азиядә дә вакытлы матбугат чыгару ишәя. 1906—1908 елларда Ташкентта чыга башлаган прогрессив газеталарда тулысынча диярлек Идел буе татарлары эшли. Сәмәрканд, Ташкенттагы беренче типографияләрне Габдулла Сәгыйтов оештыра, аңа бу эштә икенче якташыбыз Габдулла Мохтар килеп кушыла. Гасырлар буе яктыга, белемгә сусаган үзбәк, казакъ, кыргыз, төрекмән, таҗиклар шул матбугатка тартыла. Патша администрациясе исә саклану чаралары күрә: газета-журналларны бер-бер артлы яба, татарларга башка милләт балаларын укытуны тыя башлый. Якташларыбыз «Җәмгыяте хәйрия»ләр оештыргач, колониаль чиновниклар, җирле халыкны берләштерүе мөмкин, дип аның эшенә дә киртәләр сала. Ләкин хәрәкәткә килгән барлык көчләрне хәзер инде бөтенләй бастыру мөмкин булмый. Мәсәлән, гасыр башында Туктар Диникәев Иске Бохарада европача беренче аптека ача. Бу хәл Төркестанда дәвалау эшенең яңаруына, фармацевтика үсешенә сизелерлек этәргеч ясый.

1914 елда «Садои Төркестан» газетасы чыга башлый. Аның редакторы якташыбыз Рәүф Мозаффаров була. Шушында «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаган Мирмөхсин Ширмөхәммәдиев тә хезмәт итә.

1917 елның 25 апреленнән Урта Азия татарлары җәмгыяте бюросы органы «Олуг Төркестан» газетасы дөнья күрә. Берничә айдан «Чаян» сатирик журналына да нигез салына, аның егерме биш саны чыга. 1917 елның 25 июненнән Төркестан мөселманнары үзәк советы чыгара башлаган «Киңәш» газетасын оештыручы һәм аның беренче редакторы Әхмәт Вәлидов була. 1918 елның 21 июненнән исә Урта Азиядә «Иштиракиюн» («Коммунист») газетасы чыга башлый. Бүгенге «Совет Үзбәкстаны»ның башы саналган бу басманы якташыбыз Гариф Келибиев оештыра. 1919 елда Казанның «Өмет» ширкәте Төркестан матбугаты өчен гарәп шрифты коеп җибәрүне үз өстенә ала. 1920 елда инде Ташкентта дүрт татар мәктәбе эшли, һәм аларда 928 бала ана телендә белем ала. Хәзерге Төрекмәнстанның эчкәре бер почмагы саналган Красноводск шәһәрендә дә татар балалар бакчасы, мәктәбе һәм профессиональ театр труппасы барлыкка килә. Бу мәгърифәт учаклары үзләре бераз тернәкләнү белән кардәш халыклар өчен таянычка әверелә. Татар мәктәбен тәмамлаучылар башка халыклар телендә дә мәктәп, театр, матбугатка нигез сала һәм җигелеп эшли башлыйлар. Бүгенге Каттакурган үзбәк драма театры, мәсәлән, композитор Салих Сәйдәшев оештырган якташларыбыз труппасыннан үсеп чыга.

Бу чорда язучы якташыбыз Шәһит Әхмәдиев, татар артистлары Нури Сакаев, Габдрахман Исмәгыйлевләр Үзбәк труппасын оештыру белән мәшгуль. Төркестан шәрык институтында татар теле укытыла, Татар мәгариф институты ачыла.

Тәрбиячеләр әзерләү өчен 1920 елда Төркестан крае мөселман хатын-кызлары курсларын (мөдире — шагыйрәбез Гыйффәт Туташ) утыз ике кеше, шул исәптән, унсигез үзбәк, унбер татар, ике уйгыр һәм бер казакъ тәмамлый. Шул ук елны оештырылган бүтән бер курстан утыз биш кеше укып чыга.

Егерменче еллардан башлап Урта Азиядә идеология фронтында эшләүче Габдулла Уразаев сөйләвенчә, Төркестанда җәдит мәктәпләрен ачучыларның барысы да татарлар була. Алар укучыларны төрле һөнәрләргә дә өйрәтәләр. Сәмәркандтагы беренче җәдит мәдрәсәсенә нигез салучы Бәдри Исмәгыйлев үзе сәгать төзәтү остасы була. Бу мәктәпкә революциядән соң аның исеме кушыла. Яңа типтагы мәдрәсәләрдә белем алган күп санлы башка милләт шәкертләре соңрак үзләре мәгърифәт тарату эшенә керешә.

Бохарада якташларыбыз ачкан җәдит мәктәбе таҗик һәм үзбәк совет әдәбиятларының булачак классигы Садретдин Гайнигә бик яхшы тәэсир калдыра. Ул үзе дә шул мәктәпнең эшенә катнаша һәм, татар дәреслекләреннән файдаланып, әлифба төзи. Татар матбугаты, Тукай, Гафури әсәрләрен укып, әдәби әсәрләр иҗат итәргә дәртләнә. Курсави, Мәрҗанилар эшчәнлеге аның мәгърифәтчелек хезмәте башлануга этәргеч бирә. Татар җәдитчеләренең фидакарьлеген ул соңыннан «Бохара җәлладлары» хикәясендә ачык гәүдәләндерә.

Егерменче-утызынчы елларда Үзбәкстанның партия-совет органнарында җаваплы урыннарда эшләгән Шәриф Булатов, Үзбәкстан партия мәктәбе директорлары Зыя Гыймадиев, Вәли Мирсәлимов, Урта Азия коммунистик университеты ректоры Исхак Хансуаров, татар мәгариф институты ректоры Гариф Алпаров, Бохара тарихын язган профессор Булат Сәлиев, педагогия фәннәре докторы, профессор Нурмөхәммәт Таканаев һәм Габдрахман Сәгъди исемнәрен искә төшерү, аларның да җирле халыкларны укытуга зур өлеш керткәнен әйтү дә урынлы булыр.

Татар театры үзбәк халкын сәхнә сәнгате белән таныштыруны революциягә кадәр үк башлый. Бу турыда «Үзбәк ССР тарихы» дигән күптомлы басмада да языла. Анда «Сәяр», «Нур» труппаларының 1911 елдан Төркестанга килә башлаулары, татар һәм азәрбайҗан театрлары үрнәгендә үзбәк һәвәскәрләренең дә сәхнәгә менүләре хәбәр ителә һәм 1916 елда азәрбайҗаннар куйган спектакльдә Мәгъсүмә Кариева катнашуы мисалга китерелә. Соңыннан аңа Үзбәкстанның халык артисткасы исеме бирелә.

Мәгъсүмә Кариева үзбәк профессиональ театрында хезмәт иткән бердәнбер якташыбыз түгеллеген алдарак та күрдек. Өргәнеч, Ташкентның Хәмзә исемендәге театрлары режисеры Исхак Һилалов, Коканд һәм Наманган үзбәк яшь тамашачылар театрының баш режиссеры Фуат Саллави, Әндиҗан үзбәк театры режиссеры Гомәр Исмәгыйлов, балетмейстер Гали Ордобус, РСФСРның атказанган артисткасы Фатыйма Камалова, Дөрри Байбулатова, Мәгъсүмә Бариева кебек осталар кардәш халык сәхнәсенең ныгуына булышалар. Үзбәкстанның атказанган артисткасы Фаузия Файзи, республиканың халык артисткалары Марьям Якупова, Зәйнәп Садриева, Камәрия Борнашева, СССР халык артисткасы Галия Измайлова иса үзбәк сәнгате үсешенә бөтен гомерләрен багышлыйлар. Якташларыбыз Дик Сабитов, Хәмзә премиясе лауреаты Равил Батыров — «Үзбәкфильм»да режиссер, Дилшат Фәтхуллин оператор булып эшли. Аларга кадәр Төркестанда профессиональ театр барлыкка китерүдә Камал I (Төрекмән театрына нигез сала), Гомәр Девишев, Хәлил Әбҗәлилев, Салих Сәйдәшев (үзбәк театрлары оештыралар) кебек талантлы якташларыбыз яшь милли кадрларны тәрбияләүче педагог буларак танылалар. Үзбәкстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ләлә Абдуллаева шикелле рәссамнарыбыз иса әле дә спектакльләрне бизәүгә өлеш кертә. Димәк, традицияләр нык һәм дәвамлы икән!

Алдарак инде телгә алынган «Совет Үзбәкстаны» газетасында Гариф Келиблиев, Әхмәт Донскойлардан соң төрле елларда редактор сыйфатында якташларыбыз Мөхәммәт Хәсән, Габдулла Уразаев, Касыйм Сорокин, Габдулла Хәсәнов эшли. Хорезм большевиклар партиясе Үзәк Комитеты секретаре Шәрәфетдинов Хорезм совет республикасы органы «Инкыйлап куяшы» газетасына нигез сала, соңрак бу басманы язучыбыз Афзал Таһиров һәм Шариф Булатовлар редакцияли. «Хорезм хакыйкате» газетасының беренче редакторы Фатыйх Сөләйман, Төркестанның беренче үзбәк, кыргыз яшьләр газеталарын оештыручы Рәшит Вәлидов, Самаркандтагы «Михнаткәшләр укыйй» газетасының редколлегия әгъзасы Заһидә Борнашева кебек дистәләрчә татар журналистлары каләм көче белән дә, оештыручы рәвешендә дә Урта Азиядә совет властен ныгыту, аң-белем таратуга көчләрен кызганмаган. Хәтта Төрекмәнстан матбугатын оештыручы беренче кеше дә якташыбыз Хөсәенов була.

Үзбәкстанның сәламәтлек саклау комиссары Гыйззетдин Сәйфелмөлековнең туганнан-туган энесе исемен без хәзер үзәк газеталарда һәм телевидение тапшыруларында еш күрәбез, еш ишетәбез. Фарит Мостафа улы Сәйфелмөлеков халыкара мөнәсәбәтләрне яктырта. Аны искә төшерү безгә бер хакыйкатьне ачык күрсәтә: татар журналистларының яңа буыны өлкәннәрнең лаеклы алмашы була алган, аларның хәрәкәт сферасы тагын да киңәя генә төшкән икән!

Гражданнар сугышы чоры һәм егерменче елларда татар культурасының Төркестан һәм аның үзәге Ташкент белән бәйләнеше бермә-бер көчәя. Бу бәйләнешләр еш кына гаиләләргә дә үтеп керә — казакъ, үзбәк егетләре укымышлы татар кызларына өйләнәләр. Төркестан Компартиясе Үзәк Комитеты секретаре Нәзер Түрәколов, мәсәлән, хатыны Мәрьямнән татар теленә өйрәнә һәм Кәрим Тинчурин, Шәриф Байчуралар белән хатлар алышып тора.

Меңләгән татарларның Урта Азиягә эшкә җибәрелүе дуслык бәйләнешләрен көчәйткән икенче сәбәп була. 1918 елда РСФСР Милләтләр Халык Комиссариаты вәкилләре Йосыф Ибраһимов, Гариф Келиблиев Төркестанда милли мәсьәлә буенча ясалган хаталарны төзәтүдә булышыр өчен Ташкентка җибәрелә. Алар монда Советларның бишенче край съездын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнаша. Съезд Төркестан АССРны оештыру хакында карар кабул итә. Ибраһимов һәм Келиблиевнең уңышлы эшчәнлеге Совет дәүләте тарафыннан югары бәяләнә — В. И. Ленин алар исеменә һәм съездга котлау телеграммасы суга.

1919 елның декабренда Беренче Идел буе татар бригадасы Урта Азия җиренә аяк баса. Аның сафларындагы алты меңнән артык якташыбыз Фирганә үзәнлегендә басмачыларга каршы көрәштә зур батырлык күрсәтә, үзбәк, кыргыз, таҗик, казакъ хезмәт ияләренә, Бохара коммунистларына ярдәм кулы суза. Бригада политбүлеге карамагында туксанлап агитатор, театр труппасы халык арасында аңлату эшләре алып бара, хезмәт ияләренең революцион чыныгуын тизләтә.

1920 елда Кызыл Армия сафларында Төркестан халыкларының милли гаскәрләре оештырыла башлагач, патша Россиясендә хәрби хезмәткә чакырылмаган Урта Азия милләтләре командирларга һәм хәрби белгечләргә зур кытлык кичерә. 1920 елның сентябрендә Төркестан Мөселман Хәрби берләшмәләренә йөзләп татар командирлары җибәрелә башлый. Гражданнар сугышы тәмамлангач, кызыл гаскәриләрнең күбесе совет органнарын ныгытуда, хуҗалык, культураны аякка бастыруда нәтиҗәле эш алып бара.

Халкыбызның Урта Азия хезмәт ияләренә булышуына басым ясап, академик И. П. Трайнин болай дип яза: «Октябрь байрагын югары күтәргән шәрык халыкларының беренчесе татар хезмәт ияләре булды һәм алар бу байракны... Идел ярларыннан Бохарага, Персия чикләренә кадәр алып барды».

Бу сүзләрне мәгариф, әдәбият-сәнгать дөньясындагы мисаллар да тәэсирле рәвештә раслый. Мәсәлән, Шәһит Әхмәдиев — Төркестан Халык Мәгариф комиссары, Касыйм Сорокин — Төркестан Компартиясе Үзәк Комитеты бюросы члены, Хәсән Мөхәммәтҗанов — Хива Халык Республикасы политидарәсе начальнигы, Хәниф Борнашев Үзбәкстан Компартиясе Үзәк Комитеты члены булалар. Шагыйрь Фәрит Ибраһимов — Сәмәркандта тел-әдәбият профессоры, Габдрахман Сәгъди — Ташкент университеты профессоры, Бари Шиһабетдинов — Бохара Республикасы Хәрби министры, Нәҗип Хөсәенов — Бохара Компартиясе Үзәк Комитеты секретаре, Хәниф Борнашев Дәүләтплан председателе була. Татбригада командиры Йосыф Ибраһимов — Төркестан Фронты Хәрби Советы члены, Нигъмәт Еникеев Бохара Халык Совет Республикасы Политидарәсе башлыгы итеп билгеләнә. 1920 елда «Кызыл шәрыкъ» агитпоездында Мәскәүдән килгән Искәндәр Фәйзуллин, Мустакый, Госман Мәҗитов, Мәхмүт Бәдәйли, Фәрит Солтанбиков, Хафиз Чанышов, Вәкыйф Җәләл, Гариф Латыйф кебек укымышлылар Совет Төркестаны, Бохара һәм Хива республикаларында төрле җаваплы эшләр башкаралар. Зариф Бәшири, 1919 елда Ташкентка килеп, мәгариф учакларында, газета-журнал редакцияләрендә эшли, университет рабфагында үзбәк, уйгыр әдәбиятларын укыта. 1926 елда Үзбәкстан җәмәгатьчелеге аның егерме еллык әдәби хезмәтен билгеләп үтә. Зыя Ярмәки, Чәнәкәй, соңрак Әмирхан Еники шикелле язучыларыбыз да Үзбәкстанда байтак еллар төрле тармакларда хезмәт итәләр.

Урта Азия халыклары татар фронт труппалары куйган спектакльләр аша драматургиябез белән дә танышалар. Беренче Идел буе татар бригадасының Мулланур Вахитов исемендәге клубында 1921 елның февраль аенда гына да унҗиде спектакль куела. Җирле халык Татбригада китапханәсе һәм уку залына да ияләшә, доклад һәм әңгәмәләрне кызыксынып тыңлый. Активрак үзбәк егетләре исә бригада политбүлеге оештырган курсларга йөреп белемен күтәрә. Җирле халык татар кызылармеецлары өчен чыгарылган «Кызыл Армия», «Кызыл Идел», «Кызыл йолдыз» хәрби газета-

лары аша совет-партия политикасы белән таныша. Халык концерт белән килгән С. Сәйдәшев, Г. Әлмөхәммәтев, С. Габәши чыгышларын яратып кабул итә.

Шагыйрь Һади Такташ исә 1918 елда Бохара революциясендә катнаша, 1921 елдан Ташкентта «Белем йорты» журналында секретарь вазифасын үти, Төркестан эшче-дийканнар коммунистик университетында дәресләр бирә, гаскәри отрядта җирле халык егетләрен укырга-язарга өйрәтә, аларның телләрен, гореф-гадәтләрен үзләштерә.

Һади Такташ белән үзбәк язучыларыннан Гафур Голәм, Гайрәти, Хәмит Галимҗан-нар якыннан аралаша. Ташкентта җыйналган татар әдәби көчләре башта түгәрәк, аннары аерым-аерым секция булып оеша. «Без, әдәбият түгәрәге членнары, әледән-әле шигърият кичәләре оештыра идек. Һади Такташ чыгышлары безнең кичәләрнең дәрәҗәсен ифрат күтәрә иде. Әдәби кичәләргә үзбәк, уйгыр, каракалпак яшьләре дә йөри иде. Алар арасында яшь язучыларны, укытучыларны, артистларны күрергә мөмкин иде»,— ди Шәриф Булатов.

1921 елгы шундый кичәләрнең берсе Габдулла Тукайга багышлана, һәм анда үзбәк совет әдәбиятына нигез салучы Хәмзә дә катнаша.

1929 елда Ташкент татар пролетариат язучылары оешмасында егерме өч член исәпләнә, алар арасында ГаязСитдыйков, Вахит Мәхмүт, Зәйтүнә Сөнгатова, Сания Хисамова, Хәлимә Бәширова, Газизә Сабирова кебек яшь көчләр дә була, аларның әсәрләре татар һәм үзбәк матбугатында басыла.

1928 елда татар культурасы белән ныграк танышу өчен бер төркем үзбәк язучылары Казанга килә, кунаклар арасында Гафур Голәм дә була. Ул бу хакта матбугатта түбәндәгечә язып чыга: «Һади Такташ белән без 1919 елларда Ташкентта ук аралаштык. Икебез дә дәртләребез ташып торган, типсә тимер өзәрлек егетләр идек. Озак еллар буе хыялланып йөргән теләгемә 1928 елда ирештем... Казанда мин яшьлек дустым Такташны очраттым. Ул безне шәһәр белән иркенләп таныштырды». Үзбәк язучылары бу килүдә Г. Кутуй, Д. Фәтхи, Ш. Усманов, А. Шамов, К. Нәҗми, М. Җәлил белән очрашалар.

Такташ иҗаты Гафур Голәм, Хәмит Галимҗан, Госман Насыйр, Солтан Җура кебек үзбәк шагыйрьләренә зур йогынты ясый. Алар, Такташ иҗатына ияреп, аның исемен телгә алып, байтак әсәрләр язалар, Гафур Голәм исә 1933 елда дусты Һади Такташ шигырьләрен үзбәкчәгә тәрҗемә итеп, аерым китап бастырып чыгара.

Татар әдәбиятын Миртимер, Уйгын, тагын бүтән үзбәк язучылары да якын итә. Хәмзә Пушкинның кайбер әсәрләрен дә татар телендә укуын белдерә. Бу уңайдан Хәмзәнең яшьтән үк татар дәреслекләре аша белем алуын, әдәбиятыбызны һәм «Вакыт» газетасын укырга һәваслеген искәртү дә урынлы булыр.

— Хәмзә Хәкимзадә Ниязи җырларыбызны мандолина чиртә-чиртә җырларга, татарча сөйләшергә ярата иде,— ди шагыйрьнең замандашы Зиннәт Фәтхуллин.— Ул минем кешегә күрсәтергә оялган беренче әсәремне очраклы рәвештә үзе табып укыган иде. Рухымны күтәреп, пьесамны төзәткәләп сәхнәгә менгерүгә дә ул сәбәпче булды һәм һәрвакыт туганнарча игътибар күрсәтте. Аның Идел буеннан килгән егеткә һәм бүтән якташларыбызга мондый җылы мөнәсәбәте әнисенең һәм хатынының татар кызлары булуына да бәйледер мөгаен.

Бу чорда мондый кан кардәшлеге булмаган үзбәк әшнәкләре дә безнең хаят белән ихлас кызыксына. 1934 елда, мәсәлән, Татарстан язучыларының беренче съездына кунак булып Зыя Сәет, Шакир Сөләйман, Габдулла Кадыйри килә, алар республикабыз сәнгате белән танышуга зур әһәмият бирәләр.

Татарстан язучыларының дүртенче съездында үзбәк язучысы Әсгать Мохтар:

— Борынгы дастаннарыбызның уртак исемнәре, риваятьләребезнең уртак вакыйгалары безнең кардәшләрчә культура мөнәсәбәтләребезнең бер тамырдан үсеп чыгуына дәлил булып тора,— дип чыгыш ясый.

Егерменче-утызынчы елларда Үзбәкстанның әдәби тормышын һәм анда якташларыбыз уйнаган рольне характерлау өчен 1934 елда Ташкентта басылган «Литературный Узбекистан» альманахының беренче китабы кызыклы. Ул — СССР язучыларының оештыру съезды уңае белән чыгарылган һәм үзбәк әдәбиятын рус телендә шактый тулырак күрсәткән җыентык. Монда күренекле авторлардан Гафур Голәм, Айбик, Хәмит Галимҗан, Уйгын кебек шагыйрьләр, Садретдин Гайни, Габдулла Кадыйри

Габдулла Каһһар кебек прозаикларның әсәрләре, шулай ук халык иҗаты үрнәкләре дә урын алган.

Җыентыкта якташыбыз Фатыйх Бәкернең «Луиза» хикәясен дә укырга мөмкин. «Гадәти тарих» әсәре белән катнашкан Мәҗит Госман да — татар әдәбияты вәкиле. Ул Оренбург ягыннан, Казан укытучылар мәктәбендә белем алган егет.

Якташыбыз Дәрҗия Аппакова альманах өчен Теләханова һәм Юлдашев әсәрләрен үзбәкчәдән русчага тәрҗемә иткән. Ф. Бәкернең «Луиза»сын тәрҗемә итүче Рөстәм Агишев бу альманахның редакторы була. Җыентыкка кергән әсәрләрнең өч чиреген диярлек ул тәрҗемә иткән.

Әдәби бәйләнешләр, дуслык... Аның тамырлары бик ерак дәверләргә барып тоташа. 1366—1465 елларда яшәгән бөек үзбәк шагыйре Лотфыйның «Гөл вә Наврүз» поэмасы бердәнбер нөсхәдә Лондон шәһәре музеенда саклана дип исәпләнә иде. Күптән түгел аның икенче нөсхәсе Татарстанда табылды. Димәк, ата-бабаларыбыз да Лотфыйны яратып укып кына калмаган, буыннан-буынга мирас итеп саклаган, безнең көннәргә дә китереп җиткергән.

«Минем яратып укый торган китапларым Казан, Оренбург, Бакуда басылган була иде,— дип яза атаклы үзбәк шагыйре Гафур Гөләм.— Мин бигрәк тә Казан китапларын кызыксынып укыйм. Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Риза Фәхретдин, Галимҗан Ибраһимов һәм башкаларны шул чагында ук танып алган идем. Казан минем күңелемдә кәгъбәдән дә югары булып күренә иде».

1969 елда Татарстанда үзбәк әдәбияты һәм сәнгате көннәре уздырылганда, бездә Камил Яшен, Зөлфия, Уйгын, Хәмит Гөләм, Мирмөхсин, Нәзер Сәфәрев, Рәмез Бабаҗан, Ибраһим Рәхим, Сергей Бородин кебек язучылар, Камил Ярматов, Галим Хуҗаев шикелле артистлар, җәмәгать эшлеклеләре кунакта булды. Атаклы «Бахор» татар биюен биеде, Үзбәкстанның сәнгать белгечләре «тамбурлы чигүләренә татар йогынтысы тию» турында яздылар. Дуслыгыбыз хакында СССР дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Рәмез Бабаҗан:

— Безнең культурабызга татар әдәбияты һәм сәнгатенең дә уңай йогынтысы хакында әйтми үтәргә мөмкин түгел. Үзбәк халкы татар әдәбиятын күптәннән яратып укый... Үзбәкстанның әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре өчен сезнең әдәбиятыгыз һәм сәнгатегез һәрвакыт игелекле дуслар булдылар. Алар безне тормышка якын килергә, андагы яңалыкны күреп алырга һәм шушы яңалыкка юл ярырга өйрәттеләр,— диде.

Үзбәкстанга барган якташларыбыз кардәш халыклар арасында туган як культурасы белән уртаклашып кына калмый, шунда үзләре дә җиң сызганып хезмәт итә. Зиннәт Фәтхуллин, Әсгать Мохтар, Җәүдәт Ильясов, Рәүф Галимов, Сергей Бородин исемнәрен Үзбәкстанда белмәгән кеше юк. Хәзер бу исемлеккә Равил Мирхәйдәров, Сәлим Фатыйхов шикелле яшь буын вәкилләре килеп кушылды.

Үзбәкстанның борынгы архитектура һәйкәлләре һәрвакыт зур кызыксыну уята. Совет дәверендә исә аларга республиканың йөзен үзгәрткән бик күп яңа гүзәл корылмалар өстәлде һәм хәзер тагын күбрәк өстәлә тора. Соңгылары арасында якташларыбызның бай фантазиясе, матур зәвыгы, белеме һәм осталыгы салынганнары да шактый.

Егерме өч ел буе республика башкаласының алыштыргысыз баш архитекторы, ун ел буе Үзбәкстан Архитекторлар Союзы җитәкчесе вазифаларын үтәгән күренекле практик, танылган галим Мидхәт Булатов исеме Урта Азиядән читтә дә күпләргә мәгълүм. Сәмәркандта Габдрахман Җәми белән Алишер Наваи һәйкәле, Регистан мәйданындагы тарих музее бинасы, башкаладагы «Ташкент» кунакханәсе, Комсомол һәм Җиңү парклары, «Пахтакор» стадионы һәм башка корылмалар аның проекты буенча төзелгән. Профессор Мидхәт Булатов йөзләгән яшь белгечләр дә тәрбияли һәм шәрык архитектура гыйлеменең мәшһүр һәйкәлләр шикелле үк борынгы тарихка ия икәнлеген исбатлаган фәнни хезмәтләр дә яза.

Ташкентка юлы төшкән сәяхәтчеләр Революция скверында ял итмичә һәм сәгатьле манара янынннан узып китмичә калмый. Ташкент халкының олысы-кечесе сәгатьле манараны шәһәрнең горурлыгы, үзенчәлекле архитектура һәйкәленнән саный. Ул әле генә үзгәртеп корыла башлаган иске шәһәр йортлары арасында үзенең нәфислеге,

җыйнаклыгы, камиллеге һәм шәрык стилен үзенчә чагылдыруы белән игътибарга лаек. Аның иҗатчысы — архитектура өлкәсендә уңышлы эшләп килгән якташларыбызның берсе Әдһәм Мөхәммәтшин. Әдһәм егерме биш ел буе Ташкентның баш архитектор урынбасары вазифасын башкарган. Ул, байтак биналар корып, җәмәгатьчелекнең эчкерсез ихтирамын казанган. Ташкент шәһәр Советы күптән түгел вафат булган бу белгечнең исемен яңа урамнарның берсенә кушып, аның исталегеν мәңгеләштергән. Ташкенттагы үзәк мәйданнарның берсендә, опера театры каршындагы яшел сквер уртасына урнашкан «Зәңгәр гөмбәзләр» ресторанын безнең якташыбыз Вил Моратов корган. Хәмзә премиясенә лаек булган талантлы архитектор хәзер яңа проектлар иҗат итә.

Шагыйребез Һади Такташның Үзбәкстанда үскән улы Рафаил, Үзбәкстанның ялкынлы язучысы Хәмзәгә мәхәббәтен чагылдырып, байтак сурәтләр иҗат иткән. «Шагыйрь иртәсе» әсәрендә бер кулына — китап, икенчесенә каләм тоткан Хәкимзадә уйланып тора. «Хәмзә Шаһимәрдәндә» рәсемендә ул иңбашына китмәнен салып, юлдашын тыңлый-тыңлый, дәртле халык арасында эшкә бара. Теш кайраучы карагруһлар төркеме кырыйдан гына аларга ачулы карашларын төбәп кала. Һәр ике әсәрдә шагыйрьнең актив фикер иясе булуы, халык белән бер тән, бер җан рәвешендә яшәве, Хәмзә гомер иткән чор матур чагылыш таба.

Рафаил Такташ шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын бүтән рәсемнәрендә дә сурәтли, 1969 елда исә Хәмзәнең Кокандтагы мемориаль музеен коруда катнаша. Рафаил гыйльми-педагогик эше белән дә күпләргә танылган — сәнгать фәннәре докторының яңа хезмәтләрен укучылар көтеп ала.

Үзбәкстанда яшәүче сурәтче якташларыбыз арасында Үзбәкстанның халык рәссамы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Чыңгыз Әхмәров игътибарга аеруча лаек. Шәрык миниатюра сәнгатенә яңа сулыш өргән, республиканың биналарны бизәү сәнгатенә сокланырлык үрнәкләрен биргән бу художникның кабатланмас үз йөзе бар. Аның хезмәтләрен Сәмарканд һәм Мәскәү, Красноярск һәм Сочи, Казан һәм Днепропетровск кебек бик күп шәһәрләребездә тамаша кылырга мөмкин. Профессор Ч. Әхмәровнең фәнни-педагогик эшчәнлеге — үзе зур бер дөнья.

Хезмәтен берничә тармакка җәеп җибәргән кешеләр арасында Фатыйх Бәкер исемен дә телгә алырга тиешбез. Заманында ул «Сәйяр» труппасына суфлер һәм актер сыйфатында килеп кушыла, аннары күп кенә пьесалар иҗат итә, аларны татар, үзбәк, рус сәхнәләрендә куялар. Соңыннан ул хокук өлкәсендә күренекле галим булып җитешә. Урта Азиядәге гореф-гадәтләрне, хокук гыйлеме үсешен фәнни яктан өйрәнә, яшь республиканың суд-прокуратура органнарында эшли, Ташкент университетының юридик факультетын үстерүдә катнаша, гыйльми тикшеренүләр, укыту кулланмалары, киң катлаулар өчен аңлаешлы китаплар яза, белгечләр һәм фәнни кадрлар әзерли.

Шунысы күңелле, Үзбәкстанның фән дөньясында Фатыйх ага Бәкер кебекләр күп алар. Язучы Зиннәт Фәтхуллин Ташкентта эшләүче якташларыбыздан гына да егерміләп фән докторын санап бирде. Алар арасында тагын бер юрист — Үзбәкстан Фәннәр Академиясе член-корреспонденты Шәүкәт Уразаев та бар. Авыл хуҗалыгы институтының кафедра мөдире, Үзбәкстанның атказанган фән эшлеклесе профессор Хәлил Еникиев биология өлкәсендә эшли. Медицина буенча кафедра мөдире, Ленин премиясе лауреаты Фазыл Әмиров, әниле-кызлы Зөлфия Өметова һәм Хөршидә Янбаевалар фәнни-педагогик эшчәнлек алып бара. Экономика фәннәре докторы Әмин Борнашев, геология фәннәре докторы Фәттах Раҗапов та яшь белгечләр әзерләү белән мәшгуль. Кибернетика институтында эшләүче физика-математика фәннәре докторы Фаради Әбуталипов матбугатта йөзләп гыйльми хезмәт бастырган. Химиклардан Фәннәр Академиясенең химия институты лабораториясе мөдире профессор Наил Әбүбакиров, политехника институтының кафедра мөдире Фуат Таҗиев, фармацевтика институтының кафедра мөдире Исхак Мортазаевлар да Үзбәкстан җәмәгатьчелегенә яхшы таныш. Биология фәннәре докторы Харис Хайретдинов халык хуҗалыгына гаять зур файда китерә торган ачыш ясаган. Имүдән үләп ашарга күчкәндә бозауларның кырык процентка якыны үлә яки зәгыйфьләнә икән. Харис аганың тикшеренү һәм

тәҗрибәләре, ул тәкъдим иткәнчә, үләнне үт сыекчасы белән эшкәртеп бирү бу югалтудан тулысынча котылырга мөмкинлек тудыра.

Ташкентта яшәүче якташларыбыз фәннең кайсы гына тармагына юл салмаган! Казан кызы Разия Мөэминова, мәсәлән, тарих чоңгылларында күмелеп калган серләрне ачу белән мәшгуль. Ә ул серләр, төрки халыкларның борынгы чор тормышы белән кызыксынган саен, арта бара. Тарих фәннәре докторы Разия ханымның «Уналтынчы гасырларда Сәмәрканд һәм Бохара һөнәрчелеге тарихы буенча очерклар»ы менә шуңа күрә дә зур игътибарга лаек. Ул йөзләгән архив чыганаклары, кульъязмалар, археология һәм скульптура һәйкәлләрен еллар буе җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә Сәмәркандта 130 һөнәр булганлыгын ачыклый! Ул һөнәрләрнең онытылган технологиясен ачыклау һәм тасвирлап бирү тарихны белү өчен генә түгел, бүгенге һәм киләчәк тормыш өчен дә практик әһәмияткә ия.

Академик Хәлил Әхмәт улы Рәхмәтуллинның механика өлкәсендәге тикшеренүләре дә җитди игътибарга лаек. Хәзер Мәскәүдә эшләүче бу галимнең хезмәтләре турында өч тапкыр Ленин ордены белән бүләкләнүе, Үзбәкстанның Бируни, СССР Фәннәр Академиясенең Ломоносов исемендәге һәм СССР Дәүләт премияләренә, Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булуы да ачык сөйләсә кирәк.

Сәмәрканд университетының зоология кафедрасы мөдире, профессор Габдулла Сәгыйтев, Төрекмәнстан Фәннәр Академиясенең гыйльми секретаре, физиология фәнни-тикшеренү институты директоры, академик Фазыл Солтановның да тормышы һәм эшчәнлеге дә Үзбәкстан белән бәйләнгән.

Үзбәкстанның бүгенге казанышлары анда яшәүче бүтән барлык милләт эшчәннәренең дә уртак тырышлыгы нәтиҗәсе ул. Республиканың караңгылыктан яктылыкка әнә шулай гаять зур сикереш ясавында бөтен илебез халыкларының эчкерсез ярдәмен аеруча билгеләп үтәргә кирәк.

1925 елда Бөтенсоюз старостасы М. И. Калинин Бохарага килгәч, аны шәһәрнең дәрәҗәле пионеры итеп сайлыйлар, үзбәк малае Мохтар Рахманов хөрмәтле кунакның муенына кызыл галстук бәйли. Күпне сөйли торган факт: хәзер шул малай — профессор, техник фәннәр докторы!

Бекабад металлургия комбинатына килгән журналист корыч коючы Нуретдиновны күрергә теләгәч, аңа: «Кайсысын?» дип сорау бирәләр. Чөнки Социалистик Хезмәт Герое Сәетнең өч энесе дә абыйлары юлыннан атлый. Элек гади игенче, бакчачы яки сәүдәгәр булган халыкның уллары хәзер йөзләрчә яңа һөнәр үзләштереп дан казана.

Мамык игүне әйткән дә юк инде. Туган илебез ихтыяҗын тулы канәгатьләндерүдән тыш, Үзбәкстан бу кыйммәтле чималны күп санлы чит илләргә дә чыгара. Аны үстерүче Социалистик Хезмәт Герое, СССР Верховный Советы Президиумы члены, Ленин премиясе лауреаты Торсынай Ахунова кебекләр хәзер бик күп бирерә!

Бу уңайдан, кайчандыр аш өеннән чыга алмаган, кеше алдында пәрәнҗәсез йөрмәгән, иҗтимагый тормышта бөтенләй катнашмаган Төркестан хатын-кызларының бүгенге язмышына күз салу да гыйбрәтле. Хәзер Үзбәкстанда һәр өченче — инженер, һәр икенче укытучы — хатын-кыз. Алар врачларның җитмеш биш, Үзбәкстан Верховный Советы депутатларының утыз дүрт процентын тәшкил итә. Колхоз председателе, Социалистик Хезмәт Герое Миһрениса Гобәйдуллаева, Ташкент шәһәр советы башкарма комитеты председателе урынбасары Хасият Якупҗанова, юстиция министры Мәмләкәт Васикова — үзбәк халкы тормышындагы куанычлы үзгәрешләрне сурәтләү өчен бик матур мисаллар.

Моннан туксан ел элек хөрмәтле язучыбыз Заһир Бигиев Бохарада мәчетләр күплегенә, диндарлык чәчәк атуга игътибар итә. Хәзер бу шәһәрнең шөһрәте илебезгә бөтенләй башка яклары белән билгеле. Моннан башланган газүткәргечләр буенча Европа үзәгендәге дәүләтләргә Үзбәкстанның күңел җылысын хәтерләтеп, зәңгәр ягулык ага. Шуның белән бергә Үзбәкстан БАМ төзүгә дә, кара туфраклы булмаган өлкәләр хуҗалыгын ныгытуга да, Төмән нефтен үзләштерүгә дә булыша.

Нефть, газ сүзләре чыктымы, Татарстан егет-кызларын тагын искә төшерми булмый. Үзбәкстанга бу яңа эшне җайга салышырга да киләләр алар. Ике республика, татар һәм үзбәк хезмәт ияләре дуслыгы һәм барлык СССР халыклары хезмәттәшлеге әнә шулай елдан-ел ныгуын дәвам итә.

Любовь Коваленко,

украин язучысы

# ИҢ КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕК



Күптән түгел мин үсмер чагымда фронттан кечкенә генә сөенечле хәбәр кисәге алуны зарыгып көтә-көтә яшәгән якларга гаҗәеп бер сәяхәт ясадым...

Сугыш еллары иде. Салкын җилле сентябрь киче. Без, Украинадан эвакуацияләнгән хатыннар һәм балалар, Куктәкә исемле тып-тын авылга килеп төштек. Нибары ике урамлы бу авыл салам түбәле кечкенә агач йортлардан тора икән. Бәрәңге бакчаларын, безнең Украинадагы кебек үк, читән белән уратып алганнар. Вак-вак тәрәзәләрдән тоныкс сары яктылык күренеп кала. Аякларына чабата, өсләренә иске бишмәт кигән, башларына җылы шәл бәйләгән хатыннар авыл Советы янына җыелганнар да безгә ишарәли-ишарәли акрын гына сөйләшәләр.

Әнием белән мине өлкән яшьтәге кешеләрнең кеп-кечкенә өенә урнаштырдылар. Без ай буе юлда булган идек. Юлыбыз исә бик хәвефле иде: Иделгә җиткәнче, безне фашист самолетлары «озата килде». Аларның җан өшеткеч тавышларын ишетү белән эшелоныбыз туктый, без, вагоннардан сикереп төшеп, юл читендәге әрәмәлеккә кереп сыенабыз... Шул рәвешле Ютазыга килеп җиткәч, арык кына ат җигелгән арбаларга төялештек. Илле чакрым араны көне буе килдек. Арытты, тизрәк ятып ял итәсе иде. Әнием идәнгә урын рәтли башлады. Өйдә өстәл белән ике урындыктан башка җиһаз юк, шуңа күрә идәндә йокларга туры киләчәк.

Хуҗа апабыз безгә зур ястык белән корама тышлы юрган бирде. Үзе берөзлексез сөйләнә иде ул. Берни дә аңламавыбызны сизгәч, сүзгә карты да кушылды. Ул русчалап:

— Йокламагыз әле сез! — диде. — Тамак ялгамыйча ятарга ярамый!

Аның сүзен карчыгы күтәреп алды, дөрләп янган мичкә куллары белән күрсәтә-күрсәтә, аш куйганлыгын, безне шуның белән сыйларга теләвен аңлатты.

Безнең ашыйсы килми иде, безнең берөзлексез еласы гына килеп тора: туган җиребез еракта калды, аны немец фашистлары таптый, яндыра, җимерә, шартлата — уйлавы да куркыныч.

Сукыр лампаның бәләкәй ялкыны җилпенеп куйды — ишектән кулларына төенчекләр тоткан ике хатын килеп керде. Безгә күчтәнәч китерүләре икән: йомыркалар, бер чүлмәк сөт...

Ул кичне төн уртасына кадәр безнең өйдән кеше өзелмәде. Киләләр дә киләләр, безгә ашарга китерәләр. Шул беренче кичтә очраткан хатыннарның моңсу карашлары, сулыгып калган йөзләре күз алдында әле дә тора. Алар, туган җирләребезнең бик еракта калуын чамалап, безне кызганалар, үз туганнарының, ирләренең фронтта булуларын телгә алып, офтаналар, сабыр гына нидер сөйлиләр, безне тынычландырырга тырышалар иде. Әнием бер янчыктан шикәр шакмаклары алып аларга өләште. Аны безгә озын юлга чыгар алдыннан биргәннәр иде. Кунаклар шул шикәргә дә сабыйларча шатландылар, елмаюдан йөзләре балкып китте, рәхмәт укырга тотындылар. Шикәр шакмакларын исә, өйдә утырып калган балаларына каптырыр өчен, кесәләренә яшерделәр.

Ул кичтә безнең өйгә авылның барлык кешеләре кереп чыкты шикелле. Сүзләребез аңлашылмый иде: алар — русча, без татарча белмибез, әмма ягымлы елмаюлар, дусларча кул кысышулар, аркадан сөюләр һәртөрле матур сүзләрдән аңлаешлырак тоелды. Аларга ияреп без дә елмая башладык.

Безгә карата беренче көннән үк күрсәтелгән мәрхәмәт бу татар авылында яша-

гән еллар буенча дәвам итте. Кайчак берәр йомыш белән: я балта, я көрәк, я утлы күмер, я ул елларда алтын бәясенә калган бер чеметем генә тоз сорап күршегә керәсең. Иң элек өйләрдәге чисталык күзгә ташлана. Идәннәре кырып юылган, шунлыктан аяк киемнәрен тышта салып калдыралар. Бу гадәткә мин дә ияләндем, чабаталарымны тышкы ишек төбендә үк сала торган идем. Чабата дигәннән, авылдагы барлык дус кызларым чабата киеп йөриләр, аны мин дә бик тиз яратып өлгердем. Бердән, чабатаны табуы җиңел, аны авылның барлык картлары да, малайлары да үрә белә; икенчедән, арзанлы, үзе аякка да бик җайлы. Йон оекбаш өстеннән аяк чолгавы да урап җибәрсәң, шактый җылы да ул. Җәен без аны юка оекбаш белән генә кия идек: җиңел дә, аякны да тирләтми.

Мин чабатамны салып азапланган арада, Хәсбиҗамал апа өстәлгә самоварын китереп куя: «Әйдә, чәй эчәбез!» — ди. Кышкы салкын көндә бер-ике чынаяк кайнар чәйдән кем баш тартсын инде?! Утырабыз.

Әллә кай заманнардан калган булса да, көзгедәй ялтыратылган самовар «җырлап» җибәрә, хуҗабикә кура җиләге, карлыган кебек кипкән җиләк-җимешләр салынган кружкага кайнаган су агыза. Ул елларда чын чәйне күрергә дә юк иде. Бераз сөт өстәгәч, җиләк чәе бик тәмле була ул. Хуҗа чәйгә өстәп арыш кабартмасы да суза: «Аша, Люба, аша!» — ди.

Икенче яктагы күршебез Мәсрүрә апа хәтергә башка бер вакыйгага бәйле рәвештә кереп калган. Бер көнне ул безгә тавык күтәреп килеп керде. Тавык тары кебек түм-түгәрәк җирән күзләре белән безгә аптырап карап тора, кыркылдый, без исә үзебезчә гаҗәпләнәбез: «Нәрсә бу? Сатмакчы була микән әллә? Безгә андый акча каян килсен инде?!»

Мәсрүрә апа кесәсеннән йомыркалар да чыгарды. Аңлаштык. Бу — утыра торган тавык икән. Күрше апа, хөрмәтләү йөзеннән, безгә йомыркалары-ние белән шушы тавыкны бирергә ниятләгән. Яхшы гына тәрбияләп торсак, тиздән безнең үнлап чебиебез булачак икән. Чыннан да, озак көттермичә, тавыгыбыз кеп-кечкенә сап-сары чебиләр чыгарды. Алар бераз бергә йөрделәр, аннары тавык койма астыннан гына Мәсрүрә апа ягына чыгып качты. Чебиләр минем тәпиләрне чукый башладылар, аларны мин карарга тиеш булып калдым.

Безнең кебек эвакуацияләнеп килгән хатын-кызларны колхозның яшелчә бакчасына эшкә билгеләделәр. Иртән бригадир Фатыйма апа Абдуллина керә, хәл-әхвәл сораша да: «Әйдә, эшкә киттек»,— ди. Үзе кесәсеннән алып киндер орлыгыннан пешергән кайнар сумса бирә. «Аша, Люба, аша!» — ди. Ул сумсаның тәмлелекләрен белсәгез иде!

Төшен без кыр ашханәсенә җыелабыз. Ап-ак яулык бөркәнгән, беләнә чуар альяпкыч бүган алсу битле яшь пешекче Әсма Зәйнуллина коштабакларыбызны тотырып аш сала, аннары сөткә генә пешкән тары боткасы белән сыйлый: «Аша, Люба, аша!..»

Авылда берәр кеше итле токмач пешерсә, ул табынга, һичшиксез, безне дә чакыралар иде. Кунаклар кырып юылган идәнгә тезелгән табын тирәли утыралар. Уртада — хуш исле аш салынган табак. Без агач кашыклар белән сабыр гына ашыйбыз. Аннары иң мөхтәрәм кунак ит турый башлый, телеңне йоттырырлык калҗаларны барыбыз да авыз итәбез...

Печәнгә төшкән көн миңа иң күңелле бәйрәм кебек тоела иде. Хатыннар, кызлар иң матур күлмәкләрен кияләр. Мине алырга Кәримә, Галия, Шәмсеруй, Саҗидә исемле дус кызларым керә. Болынга җиткәнче җырлап барабыз. Картлар, олырак яшьтәге хатыннар печән чаба, без — кызлар, балалар — алар артыннан өелеп калган печәннәрне әйләндерә-әйләндерә киптереп йөрибез.

Ул чакта инде колхоз безнең үзебезгә бушап калган йортлардан урын биргән иде. Бакчабызны да сукаладылар, бәрәңге, кабак, чөгендер утыртырга булыштылар. Хезмәт көненә бер капчык арыш онын алгач, без үзебез яккан мичне тутырып ипи салдык.

Ипи камыры гел оннан гына басылмый иде. Күршеләр аңа пешкән бәрәңге кушарга өйрәттеләр. Андый ипинең тәмлелеген хәзер ни белән дә чагыштырып булмый. Миңа аның бер бөтенен бер утыруда ашап бетерергә мөмкиндер кебек тоела иде, тик алай сабырсызланырга ярамый, ипине атна буена җиткерергә кирәк. Кай-

чак әле күршеләр дә керә: «Ярты ипи биреп тормассызмы икән?» — дип үтенәләр. Андый йомышны, үз авызыңнан өзеп булса да, кире кага алмыйсың. Монда гадәт шундый: һәрнәрсә уртак, кайгысы да, шатлыгы да бергә-бергә кичерелә. Берәрсе фронттан кайгылы хәбәр алса, бу хәсрәтне авыл күмәкләшеп күтәрә. Әгәр берәр йортка фронттан кеше кайтса, авылны шатлык тутыра иде.

Радиодан ишетелеп торган хәбәрләрне дә без бөтенебез бергә уртага салып аңлаша идек. Дөрес, радио юк. Мин һәркөнне авыл Советындагы телефонга йөрим. Телефонны исә билгеле бер сәгатьләрдә радиога тоташтыралар. Мин трубкадан ТАСС хәбәрләрен, Совинформбюро яңалыкларын тыңлыйм. Соңыннан тын да алмый көтеп торучы авылдашларыма кайсы шәһәрнең фашистлардан азат ителүен, кайсы фронтта хәлләрнең ничеклеген сөйләп бирәм.

Көннәрнең берендә колакларыма ышанмый торам: безнең Днепропетровск шәһәренең азат ителү хәбәрен ишетеп алдым. Дөньябызны күптән күтелгән шатлык биләде...

Күктәкәдән без кышын китеп бардык. Аяз салкын көн иде. Юлга чыгар алдыннан гына мин авырый башладым. Әнием борчыла, эссем дә кимемәгән килеш, яфрак кына калынлыгы бишмәт киеп кышкы юлга ничек чыкмак кирәк? Станциягә кадәр илле чакрым араны арык ат җигелгән чанада үтәргә туры киләчәк бит. Тәвәккәлләми дә ярамый, чөнки Ютазы тимер юлчылары эвакуацияләнгән гаиләләр өчен, бөтен авырлыкларга күз йомып, берничә җылы вагон биргәннәр. Аларга әлләкми калсаң икенче мөмкинлек тиз арада гына эләкмәячәк.

Җыенабыз. Безне озатырга бөтен авыл кузгалды. Кәйсы ипи тотып килгән, икенче берәүләре кабак бәлеше пешергән, кыздырылган көнбагыш, йомырка, ак май йомарламы... Колхоз идарәсе бер капчык он бирде. Бу инде зур байлык иде.

Кузгалып китәбез дигәндә генә, авылның аргы очыннан берәүнең абына-сөртенә йөгерүен күреп алдык. Ул үзе кулын болгый, безгә сабыр итәргә куша иде. Көтеп тордык. Мәрьям апа икән. Ул, бабасына барып, минем өчен толып сораган. Мине баштанаяк шул бинһая зур, җылы толыпка төреп утырттылар. Әниемә дә ккез итекләр, сырган бишмәт кидерделәр. Атлар сабыр гына кузгалды. Без, күздән югалганчы, шәфкатьле авылдашларыбызга кул болгап бардык. Алар да, без дә тын гына елый идек... Кечкенә авылыбыз кар өемнәре артына күмелеп кала башлагач, күңелемдә кинәт шигъри юллар туды. Юл буе шул шигырь тәэсирендә булдым. Аның берничә юлы гына истә калган: «Сау бул инде, минем изге авылым, сау бул инде, мәңге-мәңгегә!..»

Бәхеткә каршы, «мәңгегә» дигән сүз дөрес ук булып чыкмады. 1981 елның эссе җәендә мин яшь шагыйребез Наталка Никулина белән бергә Татарстан һәм Башкортстан якларына иҗади сәяхәткә чыктым. Сәфәребезнең төп максаты бу ике республика белән танышу булса да, минем җанда Күктәкәне кабат күрү теләгеннән дә көчлерәк хис юк иде.

Кулымда — эвакуация елларына, ул чакта очраткан дусларыма багышланган «Калаш» исемле китабым. Ул әле яңа гына басылып чыккан иде. Әсәремдә мин шул авылыбызның шәфкатьле кешеләре, сөйкемле картлары, киң күңелле хатыннары, ирләр вазифасын үтәүче малайлары, фронттагы егетләрен көтеп яшәгән кызлары турында сөйләргә тырыштым.

Кырык ел вакыт үткән. Ниһаять, мин кабат шул юлдан Күктәкәгә кайтам. Тик транспортыбыз зарлангандай өзлексез шыгырдап баручы иске арба түгел. Партиянең Азнакай район комитеты безне Бөгелмә аэропортында каршылап торырга махсус «Волга» җибәргән. Авылыбыз элек Тымытык районына керә иде, хәзер Азнакайга берләшкән икән.

Машина асфальт юлдан очып кына уза. Мин күп нәрсәне күрә алмый калам, күзгә чалынганнары да танырлык түгел. Чип-чиста зәңгәр күк, күгелҗемләнеп торучы таулар да иксез-чиксез иген кырлары гына нәкъ элеккечә үк сакланганнар.

Калганнары барысы да әр-яңа: шоп-шома, киң юллардан машиналар чаба, яшәү өчен бөтен шартлары тудырылган поселоклар, юл буендагы сиртмәле насослар... Нефть җыеп утыручы бу җайланмалар янында ук бодай дулкынлана. Гаҗәеп бердәмлек бу: табигать һәм техника, иген кыры һәм нефть. Алар бер-берсе белән бик тату яшиләр кебек.

Мин, түземсезләнеп, Күктәкәне күрү мизгелләрен көтәм. Ул арада безне каршы алырга килгән Әминә Сафина көлә-көлә: «Менә Күктәкәгә дә җиттек!» — дип әйтеп куйды. Күзләремә ышана алмыйм торам. Җиләк-җимеш бакчалары эченә күмелеп утырган оҗмах шикелле йортлар — шул минем Күктәкәнекемени соң? Кая киткән аның каралып беткән бүрәнәләрдән салынган, кеп-кечкенә тәрәзәле, салам түбәле өйләре? Ташпулатларының яшел, кызыл, сары калай түбәләре, ачык төсләргә буялган тип-тигез коймалар авылны бәйрәмгә әзерләнгән кунак йорты кебек иттергән.

Гомер-гомергә шунда яшәүчеләр авылның бу кадәр танымаслык булып үзгәрүен искәрми дә калганнардыр, бәлки. Ул бит, һичшиксез, бер көн эчендә генә шулай матурланмагандыр, авырлыклар аша, җан тирләре агызып тырышканнан соң ямьләнгәндер бу яклар. Миңа исә авылымның ул кыен хезмәт елларын күрергә туры килмәде. Кичә генә иске, җимерек, ач авылдан киттем кебек, бүген әнә гөлбакчалы кунак өенә кайтып төштем.

Наталка белән мине өйдән-өйгә кунакка йөрттеләр. Йортларда кырыгынчы еллардагы кебек үк чисталык күзгә ташлана: теге чакта кырып юыла торган идәннәр ялтыратып буялган, аларда тузан бөртеге дә юк, бик әйбәтләп юып чыгарылган. Стеналарга келәмнәр кадакланган, бүлмәләр затлы җиһаз белән тулган, суыткычлар, телевизор, радио, магнитофон... Ишегалларында — «Жигули»лар, «Волга»лар, мотоцикллар. Әс-башларына карап та, үз-үзләрен тотышларыннан да күктәкәләрне илнең иң зур шәһәрләрендә яшәүчеләрдән һич аерып эла торган түгел.

Башта мин сагаеп калдым. Курка-курка гына уйлап куйдым: «Байлык, тышкы матурлык артыннан куып, авылдашларым теге авыр елларны, бүгенге бәхет хакына җаннарын аямаган сугышчыларны хәтерләреннән сызып ук ташламадылар микән!..» Шикләремнең урынсыз булуына ышангач, сөенечем эчемә сыймады. Юк, юк, юк! Күктәкәдәге дусларым сугыш елларының бер генә газабын да, фронтта батырлык күрсәткән бер генә якташларын да онытмаганнар. Алар хәтерендә барысы да апачык саклана, ихтирам белән искә алына.

Авыл үзәгендәге мәйданда мәһабәт һәйкәл бар. Гранит тактага Бөек Ватан сугышында һәлак булган җитмеш бер каһарманның исем-фамилиясе язылган. Һәйкәл гөлләр эчендә утыра. Җәйнең коточкыч коры булуына карамастан, чәчәк түтәлләре дымлы, димәк, аларны кадерләп үстерәләр.

Күктәкәдә безне — ерак Украинадан эвакуацияләнеп килеп, өч ел буе шунда яшәгән кешеләрне — онытмаган булып чыктылар. Әлбәттә, кырык ел гомер үзенекен иткән: теге вакыттагы яшь кызлар тормышның төп җаваплылыгын иң өстендә тотучы хатыннарга әйләнгәннәр, урта яшьләрдәге хатыннар әбилеккә чыккан, балалар да тормыш иясе булып өлгергәннәр. Тик салкын кышларны ничек уздырулар да, колхоз кырында җан тартышып эшләүләр дә, ун яшьлек балаларның сабан сөрүләре дә, төнге сменаларда ашлык сугулар да аларның хәтерендә бүгенгедәй ачык саклана. Ул еллардагы бер малай, хәзер инде чәчена чал керә башлаган ир уртасы кеше, минем янга килеп: «Славка исән-саумы ул?» — дип сорады.— Кайткач, миннән күп итеп сәлам әйтегез үзенә!..»

Эзләп таптым мин аны. Станислав Александрович Куцый тимер юлда машинист булып эшли. Күктәкәдәге Зариф дустыннан сәлам ишеткәч, шатлыгыннан нишләргә белмәде.

Мин күңелемнән үземне танымаслар дип шикләнебрәк кайткан идем. Анысы да урынсыз булып чыкты. Танымыйлар димени?! Хәтта кеп-кечкенә укучыларымның хәтерендә дә сакланганмын. Мин ул ерак елларда Күктәкә балаларына рус теле дәресләре биргәләдем. Педагогикадан һичнинди хәбәрем булмаганлыктан, укытучылык эше миңа бик авыр тоелган иде. Мәктәп директоры Мөсәлбиха апа Гайнанова ярдәм итмәсә, укыта да алмас идем, мөгаен. Ярдәм иттеләр. Миңа хәтта мәктәпнең җыештыручысы Банат апа Сөләйманова да булыша иде. Шул кадерле ярдәмчеләремне кабат күрү мине җиде кат күкләргә күтәрде!

Бергә печән чабып йөргән дус кызларымның гына күбесе авылдан китеп барган икән. Кәримә Җамалиева гына калган. Ул хәзер дә элеккеге кебек үк җор телле, сизгер күңелле, житез. Ишектән ул җилдәй килеп керде дә күкрәгемә капланды.

Үбештек. Елаштык. Бераздан ул безне үз өенә алып китте. Мунчасы да ягылган икән инде. Төне буе сөйләшеп яттык...

Юк, без кичергәннәрне чуар келәмнәр, «Жигули»лар, ташпулатлар гына күмеп калдыра алмый. Авылдашларым бүген дә ил шатлыгын уртак итә, халыклар өстенә килгән һәр кайгыны үзенекедәй авыр кичерә. Минем яңа китабым чыгу шатлыгын Куктәкәнең мине белгән һәр кешесе үз сөенечедәй кабул итте. Әниемнең дөньядан китү хәбәрен ишеткәч, алар тизрәк минем кайгыны җиңеләйтердәй сүзләр эзләп азапландылар.

Авылымның кунакчыллыгы арта гына төшкән сыман. Кайсы гына өйгә керсәк тә, Наталка белән мине ачык йөз, тәмле сүз, мул табын каршылады. Өстәлдә — кайнар коймак, сап-сары май йомарламы, суыткычтан гына алынган салкын каймак, үтә күренмәле хуш исле бал, төрледән-төрле вареньелар, мичтән генә чыккан гөбәдия... Колхозчыларның каралтысы тулы терлек-туар, кош-кортларның исәбенә чыгарлык түгел, бакчаларында җиләк-җимеш агачлары, яшелчәләр гөрләп үсә. Бу муллыкта мин, ихтыярсыздан, 1941 елны беренче тапкыр кунарга кергән кечкенә йорттагы кечке ашыбызны искә төшердем. Бабай мич башыннан иске киез итек алды. Аның эчендә вак кына помидорлар пешеп ята икән. Берсен миңа сузды. Бу минем өчен иң тансык күчтәнәч булды, чөнки ул елларда татар авылларында яшелчә үстерү гадәте юк иде әле. Хәзер әнә өстәл тулы — сабагыннан әле генә өзеп алынган помидорлар, кыярлар, чия, карлыганы, алма... Сыйның үзәгендә бүген дә — чәй. Куе итеп ясалган хуш исле сөтле чәй! Суын гына электкечә самоварда кайнатмыйлар. Борынгы самоварларны чәйнек алмаштырган. Газ плитәсенә генә куеп алалар. Ялтыратылган самоварлар иң югары киштәгә кунаклаган, хезмәт юлын намуслы үтеп чыккан ветераннар кебек.

Бригадир Фәиз Таҗиев безне хәтерләми, сугыш елларында ул сабый бала гына булган. Аның әнисе Әсма апа белән исә без бер-беребезне, карашларыбыз очрашуга ук, танып алдык.

Бригадир йортында да чәй эчтек. Сүзләр күп иде әле. Тик Фәиз хуҗалык белән таныштырырга теләгән белдергәч, Наталка да, мин дә урыннарыбыздан сикереп тордык. Күбрәк күреп каласы килә иде. Кәримә дустым да бездән аерылмады. Янымда аның булуы күп нәрсәне искә төшерергә ярдәм итте. Үзем генә барын да чамалый алмас идем, мөгаен.

— Хәтерлисеңме, Люба, менә бу басуга без көлтә бәйләргә йөри идек. Хәзер көлтәнең ни икәнен дә белмиләр.

— Монда салам эскертләгән идек! Әйеме?

— Люба, бу турыда синең теге атың...

Мин аның әйтеп бетергәнен дә көтеп тормастан, үткәндәге бер тамашаны искә төшереп көлеп җибәрдем: ул көнне атны үзем җиккән идем мин. Арбага кукка тәрәлердәй итеп көлтәләр төядек тә шулар өстенә үзем дә менеп утырдым. Әй кычкырам атка: «Әйдә, малкай, әйдә-ә-ә!» — дим. Дилбегәмне кагып кына җибәргән идем, атым салмак кына атлап китте дә барды — арбам кузгалмый. Җигүем шуның төсле булган икән, атым туарылган, тәртәләрем җирдә ята. Әй китте көлү, китте шаяру! Хәтта шул вакыйгага багышлап шаян такмаклар да чыгарып өлгерделәр...

Машина тәрәзәсеннән күзелне аера алмыйча карап барам. Хуҗалыкның үзгәрүен сөйләп кенә аңлатырлык түгел. Элек монда кечкенә генә колхоз иде. Карабодай, тары, арыш белән бодай чәчәләр. Авыл башында кечкенә генә сыер фермасы бар иде. Эш өчен башлыча ат җигәләр. Техникадан сугу машинасы, атка җигә торган чәчкечләр һәм триер истә калган.

Бүгенге «Авангард» колхозында җитәкчеләрнең сөйләшүләре үк башкача. Бригадир Таҗиев:

— Без бозаулар үстерү буенча специальләшәбез, комплексыбыз өч мең башка исәпләнгән,— дип аңлата.—... Техникага килгәндә, зарланырлык түгел, бер безнең бригадада гына да егерме биш трактор бар...

Колхоз шушындый дүрт бригаданы берләштерә. Гомуми байлыкны исәпли башласаң, исең китәр.

— Монысы — көтүлекләребез,— дип, Таҗиев таныштыруын дәвам итә.— Печәнне

су сибеп үстерәбез. Катнаш үлән чәчкән идек, әйбәт чыкты. Корылыктан да курыкмады, хатфә кебек.

Без үскәндә, авыл читендәге печәнлекләрне язын ташыган Ык елгасы сугарып калдыра иде. Су чигенгәч, болын зәңгәр чәчәкләргә күмелә. Елганың ике як яры да зәп-зәңгәр җәләм кебек ерактан ук күренеп тора. Без кичләрен шунда уенга җыела идек...

Машина бодай басуы буена тукталды. Шундый коры җәйдә да бирешмәгәннәр, башаклар шактый тулы күренә. Мин истәлеккә берничә бодай сабагы өзеп алдым. Алар хәзер дә Татарстан җиренең алтынсу, җылы тосен хәтерләтеп, минем иң затлы вазамда утыралар.

Бригадир Таҗиев:

— Без бодай да, арыш та, карабодай да игәбез,— дип сөйләде.— Силос өчен кукуруз да чәчәбез. Барысы да җитәрлек безнең, зарланырлык урын юк. Белгечләр кирәксә, яшьләрне укырга җибәрәбез, стипендияне колхоз түли. Тырышып эшләгәннәренә орденнар, медальләр бирелә. Әнә әле генә үз машинасы белән үтеп киткән егеткә игътибар иттегез микән? Әнәс Гарипов. Сезнең укучы ул. Аның Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бар...

«Сезнең укучы!» дигән сүзләр йөрәгемә май булып ятты.

Кыр ашханәсенә дә тукталдык. Колхозчылар тамак ялгап, ял итеп киткәннәр икән инде. Безнең үзебезгә генә табын әзерли башладылар. Шул чак мин, ниһаять, колхозга килгәннән бирле беренче тапкыр ат күреп алдым. Аны туарганнар, алдына солы салганнар. Мин малкайның ялларын сыйпый башладым. Ул, күтәрелеп, миңа карады. Карашлары шундый ягымлы, шәфкатьле һәм бераз моңсу кебек. Мин теге елларда өйрәнеп калган татарча сүзләремне кабатлыйм: «Исәнме, малкаем, исәнме, Имтихан!» — дим.

Пешекчеләр дә, Кәримә белән Фәиз дә елмаеп куйдылар. Сугыш елларында колхозда Имтихан атлы искиткеч матур, төндәй кара тулпар бар иде. Җигүле килеш тә, атланып йөрергә дә шәп иде ул. Әмма ләкин бөтен сбруйларын азат итеп, иреккә җибәрсәң, Имтихан әкиятләрдә генә сөйләнә торган серле бер җан иясенә әйләнә: җай гына йөгертеп китә, көлтәдәй койрыгы, озын ефәктәй яллары җилдә тузгый, ул, моңлы бер җыр сузгандай, кешнәп куя. Әңгер-меңгер төшкән җәйге, тын дала киңлегендә шашынып чапкан Имтихан безгә тиздән ирешеләчәк бөек җиңү, рәхәт көннәр, матур киләчәк билгесе булып күренә. Имтиханны һәрвакыт колхоз председателе Ибраһим абый Рәхмәтуллин җигеп йөри иде. Тик көннәрдән бер көнне ул да фронтка китеп барды һәм... һәлак булды. Имтихан да күптән юк инде. Шунлыктан ат ялын сыйпавым, аңа «Имтихан!» дип эндәшүем һәм куанычлы, һәм моңсу иде.

Мин кыр ашханәсенә якын гына әрәмәлектәге бер чишмә булуын искә төшердем. Бәхеткә каршы, ул әле дә саф килеш сакланган икән. Бу тирәләр миңа яхшы таныш: чишмәсе дә челтерәп ага, аны ышыклап үсүче усак та шаулап утыра. Алар — бер-берсен афәтләрдән саклаучы тугры дуслар шикелле.

...Тагын аерылышу минутлары килеп җитте. Моннан кырык еллар элек озаткандагы кебек үк безне тагын юлга әзерлиләр. Хатын-кызлар күчтәнәчләр күтәреп килгән. Безнең элеккеге бригадирыбыз Фатыйма апа үзе салган ипине суза. Кап-кайнар, ап-ак, күпереп пешкән күмәч! Кадерле кунакларны каршылаганда да, озатканда да ипи күтәреп чыгу — барлык халыклар өчен уртак бер гадәт бит ул. Нинди күркәм гадәт! Ипи — тормыш, ипи — шатлык һәм бәхет, ипи — хезмәт һәм сәнгать чыганагы...

Мин машинаның арттагы тәрәзәсеннән күземне алмыйм. Менә Күктәкәнең иң кырый өе. Тәрәзәләрендә ут балкый. Кулымны соңгы тапкыр болгыйм. Алда — борылыш. Күктәкә күздән югала.

Аралар тагын ераклаша. Татарстан, яшьлегем һәм бүгенге тормышым арасына тагын вакыт белән ераклык килеп керә. Юк! Еллар арасында элемтә бетми, киресенчә, мин ул бәйләнешнең ныгый баруын тоям. Ә ара ераклыгы? Анысы, безнең чор өчен — бөтенләй вак мәсьәлә. Хәтерләр сафлыгы, истәлекләрнең рәхимлеге, дуслыкның ихласлыгы гына яшәсен!

Миңа КПССның Азнакай район комитеты секретаре Фәүзия Әминова: «...Җәен тагын кайтыгыз, сабан туйларын күреп китәрсез!» — дип хат яза.

Күктәкә укытучылары да чакырып торалар. «...Бөек Ватан сугышы елларында бездә яшәгән украин һәм рус кешеләре авыл тормышына яңа бер сулыш алып килгәннәр иде. Без аларны һич тә онытмыйбыз»,— диләр.

«Исәнмесез, Люба апа! — дип яза күршебез Мәсрүрә апаның төпчек улы Рифкат.— Без әлегә исән-сау яшибез. Мин фермада эшлим. Балалар укый. Әнинең дә сәламәтлеге яхшы...»

Кәримә дустым еш кына телеграммалар да суга. Сәгыйдә Мөхәммәтшина менә мондый хат җибәргән. «...Сезнең Азнакай район газетасына язган ачык хатыгызны кат-кат укыдым. Кырык ел үткән булса да, мин сезне яхшы хәтерлим. Сез торган өй безгә каршы гына иде. Сезнең кебек үк эвакуацияләнеп килгән Паша түтиләрне дә беләм мин. Аның Слава исемле улы, Аня, Рада исемле кызлары бар иде. Аня белән без бик дус идек. Ул исәнме икән, шуны беләсем килә. Аня татарчага бик тиз өйрәнгән иде... Сезне озату бик кыен булды. Атларыгыз кузгалып киткәч, без барыбыз берьюлы еларга тотындык.

Кадерле Люба апа! Аня белән Рада турында белә алсагыз, языгыз әле, зинһар өчен. Аннары, барыгыз бергә җыелып, безгә кунакка кайтыр идегез...»

Ике арада хәбәрләр йөреп тора. Һәр сүз минем якты ышанычымны куәтли: безнең ил халыклары арасындагы мөкатдәс дуслык мәңге какшамас ул. Чөнки бу дуслыкның нигезе нык, чыганагы — мул сулы чишмә кебек. Аны безнең бабайлар үзәкиденче елгы канлы көрәшләрдә яулап алганнар, аны безнең әтиләр фашизм тырнагыннан да коткарып калдылар, ул дуслык безнең социалистик Ватанның тормыш законына әйләнгән. Без исә аны тагын да ныгыту өчен көчебезне кызганмаска тиешбез. Бу дуслык — балаларыбызга, оныкларыбызга кала торган иң кадерле истәлегебез, иң изге мирасыбыз.

Кояш ТИМБИКОВА тәрҗемәсе

## Укучының күңел дәфтәренә

### Тан (снам) мәкальләре һәм әйтемнәре

*Мәхәббәт бердәм итә, ә ялган сүз үтерә.*
*Ташка килеп бәрелүдән йомыркага файда юк.*
*Канатлылар илендә бик ашыгып атлама.*
*Үзең кискән агачың үз өстеңә аумасын.*
*Акылсызга күз дә булышмый.*
*Диңгезгә чык суы ташый.*

### Көрд мәкальләре һәм әйтемнәре

*Дөньялыкта намуссызлык — кабер ташыннан авыр.*
*Ходай тәгалә итне ник тешсезләргә генә бирә икән?*
*Йомырка чәлүче дә, үгез урлаучы да карак.*
*Акрын барсам — бәла куып тота, тиз атласам — бәланы тотам.*
*Караңгы төн бер генә, караклар ник чиксез күп?*
*Ялгыз кеше — канатсыз кош: очып күккә менәлми.*
*Җырлый белә, табышы юк.*
*Начар акыл кәкре юл сайлый.*

Кукуруз һәм көнбагышның иртә һәм уртача өлгерә торган гибридларын... югары продуктлы сортларын... булдыруга аеруча игътибар итәргә.

«1990 елга кадәрге чорга СССРның азык-төлек программасы»ннан.

Хәмзә Бәдретдинов

# АВЫЛЫМ КАҺАРМАННАРЫ

ОЧЕРК

Туган авылында кан-кардәшләре юклыгын яхшы белсә дә, аның Янгилдене күрәсе килә иде. Балачак сукмакларыннан тагын бер генә тапкыр булса да үтәргә теләде ул.

Көннәр көзгә авышкан чак иде. Күренекле галимнәрне, шул исәптән аны да — Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, кукуруз үстерүчеләрнең Бөтенсоюз мәктәбе директоры ВАСХНИЛ академигы Гайфетдин Сәләхетдинович Галиевне Казанга чакырдылар. Монда, Идел буендагы халыкара яшьләр лагеренда, ВЛКСМ Үзәк Комитеты яшь галимнәр семинарын (1973 ел) үткәрә иде. Өлкән белгечләр алар алдында чыгыш ясарга тиешләр.

Аксыл чәчен таслап янга тараган, озын буйлы, ашыкмыйча, аңлаешлы итеп сөйли белүче академик «Гетерозис» дигән темага, ягъни гибридларның үз чыгышларын тәэмин итүче нәселләренә караганда күчлерәк үсеш бирү мөмкинлеге турында лекция укыды. Орлыгыннан — он, ярма, крахмал, спирт, комбиазык; яралгысыннан — май; коры сабагыннан — кәгазь, ленолиум ясалган, яшел массасы терлек азыгы өчен кулланыла торган кукуруз мисалында фәнни ачышларның отышлылыгы турында сөйләде.

— Бу гибрид — генетик яктан тордәш булмаган формаларны кушылдыру нәтиҗәсендә туа. Аның беренче буынына гетерозин күренеше, ягъни аеруча көчле үсү, бик зур уңыш бирү хас,— диде академик.— «ВИР-42» сорты — шуларның берсе. Орлыкны муг бирә торган гибрид ул. Әмма аны тиешенчә киптереп, дөрес сакларга кирәк. Язын тагын чәчәрсең, кукурузга баерсың.

Монысы — хәзерге күренеш. Элек кукурузны зур көч түгеп үстерделәр. 500 меңгектарлы мәйданлагы һәр үсемлеккә туктальп, очындагы себеркәчләрен сындыралар иде. Бу эшкә гектар саен унар кеше бүленә. Аларның һәрберсе әлеге участокта икешәр атна эшләп йөри. Ил буенча исәпләгәндә, кызу урак өстендә, кылны кырыкка ярырдай вакытта, шушы шөгыльгә миллионнарча кеше тартыла иде.

Башка чарасы табылмады, себеркәчләрне сындырып йөрмәсәң, кукуруз сабакка гына котыра, кыйммәтле чәкән орлыкланмый кала, уңыш булмый. Өстәвенә, рәт арасыннан бик игътибар белән үтсәң дә, кайбер үсентеләрнең башында берничә «солтан» барыбер кала, бу хәл исә кайбер төпләрнең чәкәнсез калуына, уңышның кимүенә сәбәп була.

Киләчәктә дә кукурузның «яшәешен» бу ысул белән дәвам итү мөмкин түгел иде. Селекционерлар һәр сабакны капшап йөрүдән котылу ысулларын эзләп баш ваттылар.

Гайфетдин Сәләхетдинович та бу зур максатка ирешү өмете белән күп тапкырлар тәҗрибә үткәрде, тикшерү алып барды. Хәтерендә: бер көнне ул басуга чыкты. Шунда үзенчәлекле кукуруз үсентеләре күрде — себеркәчләрнең кайберләрендә серкәләр юк. Ә үзе башкалар белән бертөрле, зур буйлы булып үсә. Галим шуны аңлап алды: бу төр кукурузларга, чәчәк ату өчен, күрше үсентенең серкәсен «татырга» кирәк.

Селекционер «җитлекмәгән» культураны гадәти кукуруз белән кушылдырды. Нәтиҗәдә үрчергә сәләтле селеркәчле токым өлгерде. Галим моңа үзе дә гаҗәпләнде. «Бу нәрсә була инде?! — диде Гайфетдин үзалдына.— Моңарчы мәгълүм булган нәсел закончалыгы бозыла түгелме соң?! Без бит, моңарчы үсемлектә аталык һәм аналык сыйфатлары берьюлы барлыкка килә дип белә идек. Ә бу гибридлы кукуруз аталык үзенчәлекләрен кабул итәргә «теләми». Нәрсә бу? Ачышмы?..»

Әйе, ачыш иде бу! Ләкин... чәчәк атарлык нәселдәше юк бит әле аның. Шунлыктан Галиев, тикшеренүләрен дәвам иттергәндә, аларга яңа юнәлеш тә бирде. Эзләнүләр тагын бер яңа төр китереп чыгарды, кукурузның аналык үзенчәлеген нәселдәннәселгә күчерердәй кодрәте булган яңа гибриды табылды. Галим, хромосомолар төзелешенә үзгәреш кертеп, үсемлеккә чәчәк ату кодрәте «индерде». Бу — «орлыкны биологик атасызландыру» ысулы исеме астында кулланышка да керде.

Дөрес, мондый фикер кукуруз үстерүче Галим Михаил Хаджинов күңеленә 1931 елда ук килгән була. Ләкин, практик әһәмияте күзгә бәрелеп тормаганлыктан, ачышка игътибар итмиләр. Бу турыда матбугатта бер хәбәр дә чыкмый. 1953 елда, илдә гибридлы кукуруз игелә башлагач исә Гайфетдин Сәләхетдинович беренче булып ачышны яңартып җибәрә. Ә аннары, М. Хаджинов белән киңәшеп, кушылдыру системасын камилләштергән.

«Идел» лагерена җыелган яшь галимнәргә дә академик нәкъ шул хакта сөйләгән. Семинар тәмамлангач, үзе яшәп ята торган Краснодар краена киткәнче, туган авылын — Апас районындагы Янгилде авылын күреп китәргә ниятләгән.

Алар бу юлга «Волга» машинасында, Казан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты хезмәткәре (хәзер Кубань тәҗрибә станциясе директоры) Владимир Сочено белән бергә чыга. Кулларында — Татарстан картасы. Казан-Янгилде арасын тоташтыргыч сызыкка күз салганнар. Ара ераклыгын 100 километрлар чамасы дип исәпләп чыгарганнар. Машина алга чаба. Бару юнәлешен исә ялгыш билгеләп Чувашстан ягына таба китәләр. Сугыш елларында бабаларыбыз ат белән ашлык ташыган Тәрләмә станциясенә җитәләр. Тукталып сорарга булалар.

— Янгилдегә еракмы әле?

— Биш чакрымнар чамасы. Сулга борылыгыз!

Күрсәтелгән ара бетә. Авылга керәләр. Беренче йортның ишеген кагалар. Каян кайтуларын сөйлиләр. Аннары сорып куялар:

— Галиев Сәләхетдин нигезе кайсы тирәдә икән?

Карчык уйга кала:

— Сәләхетдин дигән кеше яшәмәде кебек безнең авылда...

Гайфетдин дә икеләнә башлый.

— Безнең авыл бу кадәр зур да түгел иде... Адашып йөрибезме әллә без? Бу Апас районымы соң?

— Юк. Апас арырак ул. Аннан безнең аша Свияжскига терлек китерәләр ит комбинатына...

Икенчесе дөрес юлны аңлатып бирә.

— Сезгә туп-туры көньякка таба барырга кирәк.

— Моннан еракмы?

— Сиксән километрлар.

— Ерак икән,— диде Гайфетдин.— Иртәгә Краснодарга да очасы бар. Билет кесәдә...

Аннары бераз уйланыбрак торды да, иптәшенә дәште:

— Барыбер кайтмыйча ярамас. Юлга чыкканбыз икән, эзләп табыйк инде без Янгилдене. Үкенечкә калуы бар...

— Менә монысы — мин туган авыл, ичмасам! — диде Гайфетдин, Янгилдегә җиткәч.— Әнә, аның урамнары да әүвәл генә. Безнең балачакның иң рәхәт минутларын искә төшерүче елга әнә! Урамнар әле дә — чирәм генә...

Ялтырап торган «Волга» авылга керде. Югары очка үттеләр. Инеш янына туктадылар. Чишмәсеннән тәмләп су эчтеләр.

Гайфетдин чирәм өстенә утырды.

— Мәрхүм әнкәй, шул чишмәнең суын кайнатып, безне чәй белән сыйлый торган булгандыр,— дип, әнисе Гөлниса турында сөйләп алды.

Әнкәсе бик эшчән булып кереп калган Гайфетдин күңеленә. Ул бит, әтиләре Сәләхетдин читтә йөргәндә дә, җиде баланы — Низам, Әкмал, Хәдичә, Әкрам, Нуретдин, Ярхамне һәм Гайфетдинне ач-ялангач итмәде. Эш сөяргә аларны әниләре өйрәтте. Исендә әле: әнкәсе улларына арба тарттырып, авылдан ерак булмаган урманга җибәрә иде. Малайлар корыган ботак җыялар, аларны таслап төйиләр, әйбәтләп бәйлиләр. Аннары тауга түбән йөгергәләп, арбаны тартып төшәләр. Кайткач, кыскакыска итеп турыйлар һәм кыш буена җитәрлек итеп өеп куялар. Дөрес, Гайфетдингә эләкми бу эшләр. Ул абыйларына ияреп кенә йөри, чөнки аңа ул чакта нибары биш кенә яшь иде бит әле...

Берникадәр уйланып утыргач, Гайфетдин, әкрен генә атлап, авыл кырыендагы нарат йорт янына килеп туктады. Тәрәзәгә чиертте...

Көттермичә, капканы ачып, әнкәседәй ябык бер хатын урамга чыкты.

— Мин үзем бу авылныкы,— диде аңа Гайфетдин.— Тик 57 ел инде кайтканым юк иде. Миңа биш яшь чакта, 1916 елны әтием Сәләхетдин янына, Грозныйга күчеп киткәнбез. Нигезебезне күрергә дип кайтуым иде...

— Белмим шул,— дип җавап кайтарды аңа хуҗабикә. — Ирем Габделхәй әйтсә генә инде...

Ул йөгереп өенә кереп китте.

Алар урамга икәү — тимердәй нык, озын буйлы ир белән чыктылар. Габделхәй килүчеләргә кулын сузды. Таныштылар. Хәтта үзләренең өченче буын туган икәнлекләрен дә ачыкладылар. Сәләхетдин абый йортының нигезе дә нәкъ шушы төштә икән.

Каршыда өянкеләр үсә — шул заманнардан бирле шаулап утыручы өянкеләр... Ә тирә-юнь — чирәмлек. Яңа танышлар шунда утырдылар.

Гайфетдин авылдашыннан:

— Үзең кайда эшлисең? — дип сорады.

— Комбайнда. Менә алтынчы сезон инде «СК-6» белән урдырам. Зөфәр исемле олы улымны да үзем белән алып йөри башладым әле. Өйрәнсен!

— Авылда механизаторлар күпме соң?

— Шактый. Орденлы тракторчы Василий Аверьянов минем күршедә генә яши. Сәмикъ Галимов чөгендер чәчә, кукуруз үстерә.

— Кукуруз? Уңышы күп чыгамы?

— Гектарына 200 әр центнер яшел масса алган еллар була.

— Аз бу...

Шулай гәпләшкән арада хуҗа хатын Хәнифә дә газ плитәсен чожлатып җибәргән, чәен кайнатып, бәрәңгесен пешереп өлгергән иде.

— Әйдәгез инде, өйгә керегез! — дип чакырды ул.— Табын янында сөйләшерсез.

Түргә уздылар. Чәй эчкәндә, сүз дәвам итте.

— Бу арада авылда кунаклар еш күренә әле,— диде Габделхәй елмаеп.— Күптән түгел генә Советлар Союзы Герое Салават Кәримов кайтып китте.

Владимир Соченкога әңгәмәгә кушылыр җай чыкты:

— Кара аны,— дип елмаеп җибәрде ул,— кечкенә генә, илле йортлы авылга ике Герой бит!

— Мин берсен генә беләм, икенчесе кем соң?

— Анысы менә, табынында утыра. Туганың Гайфетдин Сәләхетдинович — Социалистик Хезмәт Герое! Кукурузны әйбәт үстергән өчен бирделәр...

Озак сөйләштеләр алар. Авылның һәр гаиләсе язмышына кагылып үттеләр. Аннары, көн кичкә авышкач, китәр вакыт җитте, дип, кочаклашып саубуллаштылар, хатлар язышырга вәгъдәләр биреп аерылыштылар.

Кунаклар киткәч, Габделхәй, карт өянке төбенә утырып, озак кына уйланып торды. «Моңа чаклы бер-беребезне белмичә яшәгәнбез бит, дип, үз-үзен битәрләп тә алды, Кубаньда герой туганым яшәп ята икән бит?!»

Академик Гайфетдин Галиев турында шуннан артыгын ул белми дә калды. Үз-үзен тотышы бик гади булган әлеге кешенең дөньякүләм танылган галим икәнлеген башына да китермәде.

Комбайнчы Габделхәй Краснодар китап нәшриятында «Лауреатлар» исемле кызыклы китап басылып чыкканлыгын, анда Н. Аксюк диган авторның «Иҗат эволю-

цияce» исемле очеркы да урнаштырылганлыгын, могаен, белмәгәндер. Очерк исә танылган совет селекционеры, Ленин исемендәге Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы академиясе академигы, Апас районының Янгилде авылы егет Гайфетдин Сәләхетдинович Галиев эшчәнлегенә багышланган.

Галимнең үзен күреп сөйләшкәч, бу гаҗәеп бай иҗат юлы тагын да яңа якларыннан ачыла. Дөрес, бу тормышны һәрьяклап тасвирлап бирү мөмкин түгел. Укучыга аңлату өчен кайбер сәхифәләргә генә тукталып үтәргә кирәктер.

...Грозныйда ул укырга кергән. Укый-яза белгәнлеген һәм исәп-хисапка осталыгын чамалап, аны турыдан-туры икенче класска кабул иткәннәр. Малайны укырга нефтьче әтисе Сәләхетдин агай өйрәткән булган. Алдагы елда беренче классны тәмамлаган апасы Хәдичәдән дә күп нәрсәгә өйрәнгән ул.

Кечкенәдән үк күп белергә омтылган. Мәктәптә дә тырышып укыган. Беренчеләрдән булып пионерга кергән. 1924 нче елны, яше тулмаса да, әйбәт укуын, үрнәк тәртибен истә тотып аңа комсомол билеты тапшырганнар. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, комсомолның район комитетына инструктор итеп эшкә алганнар. Бер үк вакытта ул кичке мәктәптә дә укыган.

1928 елда Краснодар селекция һәм орлыкчылык институтының агрономия бүлегенә керә. Практика чоры җиткәч, аны Татарстан тәҗрибә станциясендә эшләргә Казанга җибәрәләр. Гайфетдин монда мәкнең чәчәк ату биологиясен өйрәнә. Шул темага диплом эше яза. Станциядә ул елларда ук егетнең мөстәкыйльлегенә сокланалар.

1936 нчы елдан ул Воронеж өлкәсе Талов районының Каменно-Степная дәүләт селекция станциясендә кече фәнни хезмәткәр булып эшли башлый. Тик яшь галимгә монда да озаклап эшләргә туры килми — сугыш башлана. Ул үзе теләп кулына корал ала.

Гайфетдин, сугыш тәмамлангач, Краснодарга, хатыны һәм ике баласы янына кайтты. Берничә ел шунда яшәделәр, аннары ул, өстеннән офицер киемен дә салмаган килеш, Кубань тәҗрибә станциясенә килде. Кукуруз бүлеге мөдире Иван Кожухов белән очрашты. Иван Васильевич аны:

— Рәхим итегез! Безгә Сездәй белгечләр бик кирәк! — дип, шатланып каршылады.

Бүлек мөдире аны кукуруз белән таныштырды, һәм бу үсемлек Гайфетдинне үз дөньясына алып керде дә китте! Кукуруз селекция һәм генетика өчен искиткеч кызыклы объект булып чыкты: себеркәчен сындырдыңмы, үсемлек үзен-үзе серкәләндерә башлый, орлык бирә. Аның холкындагы сыйфатларны да шактый җиңел генә ысуллар белән үзгәртеп була. Эзләнүләр нәтиҗәне дә тиз бирәләр, өч-дүрт ел үтми, хезмәтеңнең нәрсәгә китереп чыгаруын күрәсең. Төрле культуралар өчен уртак булган гомуми генетик закончалыклар да ачылып-ачылып куя...

Болары — үткәндәге хатирәләр. Галим бүген эшли торган тәҗрибә станциясе Краснодар краеның Гулькеев районында икән. Мәйданы әллә ни зур да түгел — мең гектар. Шунда ук теплицалар. Ярдәмче хуҗалыкның фермалары йөзләп сыер, дуңгыз асрыйлар. Техника паркы бар. Шулар белән идарә итүчеләр һәм фәнни хезмәткәрләр яшәү өчен, газ белән су кертелгән, икешәр һәм өчәр катлы йортлар. Поселокта 450 ләп кенә кеше яши. Шуларның йөзесе — фәнни-техник хезмәткәрләр. Араларында крайком члены, крайком Советы депутаты, бер академик — Гайфетдин Сәләхетдинович Галиев бар. Үзе тыйнак, сабыр, гади. Монда аны баласы-чагасы да белә икән.

— Яшем арткан саен эшем күбәя, фикерләр яңара бара, өстәмә резервлар ачыла кебек,— дип сөйли Гайфетдин Сәләхетдинович.— Латин Америкасында кукурузның 16 меңләп примитив төре бар. Селекционерлар өчен никадәр байлык бу! Чынлап торып шөгыльләнә башласаң, әллә нинди сортлар туачак! Орлыкның генетик потенциалын киңәйткәндә, уңыш та артачак, аны гектарына 100—150 центнерга җиткерергә мөмкин!

Әлеге кыргый кукуруз орлыкларының күбесе җыеп та куелган инде. Алар илнең алтын фонды булып саналучы, дөньяда иң зур генетик банкта тупланганнар. Бу уникаль байлык та шушы поселокта саклана.

Селекционер анда еш була. Коллекцияләрне өйрәнә. Иртә өлгерүчән, суыкка чыдам, аксымга бай, күп чәкәнле кукурузлар үстергәндә, алардан файдалана. Шуларга

таянып, үзенең аспиранты, Мексика егете Рафаэль Ортего белән дистәләгән тәҗрибәләр үткәргән ул.

— Илдә кукурузчылыкны алга җибәрү өчен чит ил галимнәре белән бәйләнештә тору да бик кирәк,— ди Гайфетдин Галиев.

Ул үзе дә кукурузның туган иле — Америкада берничә тапкыр булган. Европа селекционерлары ассоциациясе конгрессында катнашкан, Югославия, Франция, Болгария, Швейцариядә тәҗрибә уртаклашкан. Кайбер илләр белән орлыклар алмашкан. Станцияләренә кайткач, яңа төр бөртекләрнең составын өйрәнгән.

Югославия, ГДР, Болгария, Чехословакия кукуруз институтлары белән Кубань тәҗрибә станциясе рәсми бәйләнештә тора һәм Экономик Ярдәмләшү Советындагы килешүләр юнәлешендә эшли. 1978 нче елда, мәсәлән, СССР һәм ГДР селекционерлары «Бекось-215» гибридын сынадылар. Хәзер аны ике ил басуларында да үстерәләр. Бу хезмәт өчен Германия Демократик Республикасының Авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе Гайфетдин Сәләхетдиновичны үз член-корреспонденты итеп сайлаган.

Академик Омскидан Киевка кадәрге шәһәрләрдәге селекционерларның «Төньяк иҗади берләшмәсе» белән җитәкчелек итә. Берләшмәнең фәнни программасы булдырылган.

— Илдә хәзер 22 миллион гектар кукуруз игелә,— дип сөйли Гайфетдин ага.— Шул мәйданның 68 проценты төньяк өлкәләргә туры килә. Анда кукуруз бары тик силос өчен генә үстерелә. Анысының да уңышы түбән. Аны, һичшиксез, күтәрергә кирәк. Бу — безнең хуҗалыклар һәм белгечләр алдында торучы иң зур проблема. Мин, Ленин исемендәге Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы академиясенең кукуруз секциясе председателе буларак, шул хакта уйландым. Әлеге эшне көньякта гына хәл итеп булмаячак. Украинадан Омск өлкәсенә чаклы сузылган өч мең чакрым арада тиз өлгерүчән, сөтсыман балавыз хәлендәге чәкән бирүчән кукурузларны сынап карарга булдым. Сорауга җавап эзләдем: кайсы өлкәдә нинди төр гибридны чәчү отышлырак? Эшне ничек оештырырга? Кай якка күпме орлык җибәрергә?..

«Төньяк берләшмәсе» Идел буе өлкәләрен дә үз эченә ала. Татарстан тәҗрибә станциясендә Шәрәф Вәлиев беренче булып көньяктан җибәрелгән орлыкларны сыный башлаган. «Коллективный 6 ТВ» гибридын районлаштыру белән шактый мавыгып шөгыльләнгән. Ләкин матур башлангыч ярты юлда туктап калган. Соңгы елларда республикада кукурузчылык тармагына бөтенләй кул селтәгәннәр, селекция эше туктатылган.

— Менә шуңа күрә Татарстан тотрыклы уңыштан да мәхрүм,— дип аңлата Гайфетдин Сәләхетдинович.— Татарстандагы географик шартларга тиз ияләшүчән гибридлар сайланмаса, киләчәктә дә алга китеш булмаячак. Терлекчелек сусыл азыкка кытлык кичерәчәк. Сөт һәм ит җитештерү һаман да кыен хәлдә булачак...

Академик әнә шундый уйлар белән мәшгуль. Гомеренең нәкъ яртысын — утыз биш елын — кукурузчылыкка багышласа да, әлегәчә чишелмәгән мәсьәләләр аны бер генә минутка да тыныч калдырмый. Ул һаман эзләнүләр, яңа ачышлар белән канатланып яши.

- Буш вакыты бөтенләй юк аның. «Арыганчы хезмәт итәм,— ди ул,— ә аннары икенче эшкә алынам. Сайлап кына газета-журналлардагы мәкаләләрне укыйм. Телевизор карыйм. Бакчада казынам. Ике балабыз читтә тормыш корганлыктан, хатынга өй эшләрендә дә булышырга туры килә. Кайбер кичләрдә, фотоаппараттагы пленкаларны эшкәртәм, фотолар ясыйм. Иң яраткан шөгылем — рәсем ясау. Анысына вакыт җитми, киндергә төшерәсе образларым күз алдымда тора...»

1981 нче елның 18 ноябрендә Гайфетдин ага җитмешен тутырды. Әмма, аны күргәч: «Ул сигезенче дистәне ваклый башлаган»,— дип әйтергә батырчылык итмисең. Гайфетдин Сәләхетдинович төскә-биткә шактый яшь күренә. Хәрәкәтләре җитез.

Социалистик Хезмәт Герое Гайфетдин Галиев әле дә яңа тәҗрибәләр белән мавыгып яши. Юбилей көнендә хезмәттәшләре аңа, вакуум эченә урнаштырып, өстенә: «Сез бер чәкәнне ике иттегез!» дигән сүзләр язылган сәер кукуруз тапшырганнар. Бу символик бүләккә карап, Гайфетдин ага: «Ике чәкән генә азрак, бер чәкәнне өчкә әйләндерәсе иде!» — дип ашкынып иҗат итә.

*Краснодар — Апас.*

Рәис Сабиров

# ШЛИССЕЛЬБУРГ ТОТКЫНЫ

1904 елның томанлы сентябрь иртәсе. Салкын Балтик диңгезе ягыннан сөякләргә үтәрдәй булып җил исә. Нева елгасының агымына каршы баручы кечкенә генә пароход палубасында басып торучы ханым исә боларның берсенә дә игътибар итми. Ул — кинәт кенә бөтен барлыгын биләп алган тойгылар әсирлегендә. Бу мизгелдә аңа һәр нәрсә тансык кебек: менә бу пароход та, аның көпчәкләре астында дулкыннар чупылдавы да, еракта төсмерләнә башлаган, томанга өртелгән шәһәр силуэтлары да, палубадагы кешеләрнең салмак кына сөйләшүләре дә. Янда басып торучы жандармнар — күнегелгән нәрсә.

Чәче-башы чаларган, тәмам алҗыган-өшәнгән, бөкресе чыккан, арестант киеме кигән бу карчыкны һәр эшне башлап йөрүче, җор сүзле, чая, шук, кызу канлы, бердәр үзсүзле Верочка дип элекке танышларыннан берсе дә әйтмәс иде. Шактый чибәр, толымнарын баш тирәли ураган утыз ике яшьлек ханымны, моннан нәкъ егерме ел элек Россия империясе тәхетендә утыручы Александр икенчегә һөҗүм итүдә гаепләнеп, суд алдына баскан Вера Николаевна Фигнер дип тә тану мөмкин түгел.

Әйе, 1904 елның сентябрь иртәсендә «Палундра» пароходының палубасында Петербургка кайтучы пассажир — легендар ханым, атаклы революционерка — народоволка, Александр икенче үтерелгәннән соң ике ел дәвамында патша шымчыларыннан эз яшереп йөргән Вера Фигнер була.

Вера Николаевна Шлиссельбург крепостеның бер кешелек кысан камерасында егерме ел утырганнан соң иреккә чыга. Әйе, сүз нәкъ шул крепость — Россиядә патша режимын үз итмәүче политик тоткыннарның йөрәгендә дәһшәт уятырга исәп тотып, «бирегә керергә генә мөмкин, чыгу юлы юк» дигән фикерне аңлату өчен, капкасы өстенә зур ачкыч беркетеп куелган, бөтен дөньяга мәгълүм Шлиссельбург крепосте турында бара. Һәм менә ул, кечәге тоткын, 1905 елгы революциядә патша самодержавиесе белән якага-яка килергә җыенучы демократик көчләрнең басымы астында азат ителеп, материкка юл тота. Егерме елдан соң! Әйтергә генә ансат! Исемеңне бер генә тапкыр да ишетә алмыйча, аның урынына «унберенче тоткын» дигән кушамат белән мөрәҗәгать итүләренә түзеп, материк белән, дуслар-туганнар белән бернинди элемтәсез, надзирательләрдән гайре бернинди җан иясе күрмичә, фикер уртаклашырга, хәтта кешечә сөйләшүне ишетергә интизар булып үткән егерме ел! Нәкъ аныкыдай бер кешелек, юеш, тынчу камераларда таныш һәм таныш булмаган көрәштәшләрнең бу коточкыч шартларга, начар ашауга, ә барыннан да бигрәк, ялгызлыкка түзә алмыйча бер-бер артлы үлүен, акылдан язуын белеп-ишетеп үткәргән егерме ел!

Жандармнар, сине дә шундый ук үлем көтә, дип Вера Николаевнага көн саен тукып килгәннәр, «биредән кеше үз аягы белән чыкмый, биредән кешене күтәреп кенә алып чыгалар»,— дип әйтә торган булганнар. «Ә өстәвенә,— дип яза Вера Фиг-

---

* Дәвамы. Башы журналның [illegible] саннарында.

нер үзенең «Запечатленный труд» дигән атаклы китабында,— халыкның, җәмгыятьнең безне, народоволецларны аңламавын, безне якламавын тою авыр иде».

Шулай да бу олы рухлы революционерка барлык сынауларны-киртәләрне җиңеп исән кала.

Татарстан хезмәт ияләре һәм казанлылар өчен бу гаҗәеп кешенең истәлеге аеруча кадерле. Вера Николаевна — безнең якташыбыз. Ул Казан губернасында, Тәтештән ерак түгел Никифоровка авылында туа. Соңрак аның әтисе Мамадыш өязендә урманчы булып эшли. Вераның балачагы шунда үтә. Әтисе, Вера Николаевна сүзләре белән әйткәндә, балаларын «крестьян хезмәтен хөрмәт итү рухында» тәрбияли, «ашауда да, кием-салымда да артыклыкка» юл куймый.

1863 елдан 1869 елга кадәр Вера Фигнер Казандагы Родионов институтында (аның тулы исеме: «Затлы нәселдән булган кызлар өчен Родионов институты» — Р. С.) укый. Пугачев гаскәрләренә каршы сугышта үтерелгән полковник Родионовның тол хатыны биргән акчага 1841 елда дворян кызлары өчен махсус оештырылган бу уку йортында (бүгенге Суворов училищесы бинасы) шактый ук кырыс тәртип урнаштырылган була.

Югарыда әйтелгәннәрнең барысы да булачак революционерның характеры формалашуда зур роль уйнаган.

Родионов институтын тәмамлаганнан соң Вера шул ук институтны бер елга соңрак тәмамлаган сеңелесе Лидия белән берлектә Казан университеты каршында оештырылган акушерлык классы дәресләренә йөри, һәм ул студент яшьләр арасында бик популяр демократ профессор Петр Францевич Лесгафтның кызыклы лекцияләрен тыңлый. Азатлык сөю идеяләре белән сугарылган бу лекцияләр апалы-сеңелле Фигнерларга уңай йогынты ясамый калмаганнар, әлбәттә. Вера Николаевнада врач булу һәм бөтен тормышын халыкка хезмәт итү теләгенең уянуы да нәкъ менә шул вакытларга туры килә. Әмма бу теләкне Россия шартларында тормышка ашырырга мөмкин булмаганлыктан (ул чакта хатын-кызларга университетта уку тыела), Вера Фигнер Швейцариягә китә, Цюрихтагы университетка керә. Бирегә язмыш аны рус революционерлары белән очраштыра, һәм алар йогынтысында ул революцион көрәш юлына баса. 1876 елда ул, үзенең яңа дуслары үтенече белән, Цюрихта укуын ташлый һәм турыдан-туры халык арасында эш алып бару өчен Россиягә кайта. Шул ук елның җәендә, фельдшер булып эшләү өчен Ярославльдә, ә бераз соңрак, акушерлык хокукы өчен, Петербургта имтихан тапшыра.

«1876 елның көзенә,— дип яза ул инде телгә алынган китабында,— мин тормыш мәшәкатьләре белән исәп-хисапны тәмам өздем. 24 яшемнән бирле минем бөтен тормышым бары тик Россия революцион партиясе язмышы белән генә бәйле».

Кулында акушерка һәм фельдшер дипломы булган Вера Николаевна народникларның төп көрәш формасы булган «халык арасына керү» хәрәкәтенә кушылып китә. Самара, Саратов губерналары авылларында эшли. Ләкин тиздән бу эштән тәмам күңеле кайта, чөнки әлеге хәрәкәтнең җиңелүгә дучарлыгын, кысыр хәрәкәт иканлеген үз күзе белән күреп тора. Народниклык хәрәкәте таркалып, мөстәкыйль ике агым хасил булгач — халык арасында эшләүне дәвам иттерү ягында торучылар «Кара бүлешү» җәмгыятенә, террорны, беренче чиратта патша үтерүне алга куючылар «Халык иреге» партиясенә берләшкәч,— Вера Фигнер соңгыларына кушыла. Тиздән ул партиянең күренекле эшлеклесе булып китә, Башкарма комитет члены итеп сайлана. Халык ирекчеләренең югары органнары составына кергәндә берниндн да хосусый милеккә ия булмаска, барлык физик һәм рухи көчен, кирәк икән, тормышын да, революция эшенә бирергә, революция хакына барлык туганлык элемтәләрен, шәхси симпатияләрен, ярату-яратмауларны, мәхәббәтне, дуслыкны онытырга ант итә. Һәм шул антына ахырга кадәр турылыклы булып кала. 1870 елны яратып кияүгә чыккан һәм Казанда ярәшкән суд тикшерүчесе Алексей Викторович Филиппов белән аерылыша. Шул революция хакына кыз туганнары һәм энесе белән арасын өзә.

Вераның сеңлесе Лидия Николаевна апасы белән бергә Швейцариягә дә китә, андагы университетта укый башлый, анда шулай ук народниклар белән элемтәгә керә, Россиягә кайтып, революцион хәрәкәткә катнаша, народникларның «Москвичлар» группасы җитәкчеләре белән бергә кулга алына һәм 1887 елда «50-ләр процессы» дип аталган суд процессында 5 ел каторга эшенә хөкем ителә.

Вера Николаевнаның энесе Николай Фигнер да — Россиядә шактый танылган кеше. Ул озак еллар хәрби диңгез флотында хезмәт итә, аннары отставкага чыга һәм җыр сәнгате белән мавыгып китә. Неапольгә барып, Италия осталарыннан музыкага, җырга өйрәнә, аннары туган илгә кайта һәм 1887 елдан башлап утыз ел буена Мариинский опера театрында эшли. Россиядә драматик тенор тавышлы иң яхшы опера җырчыларыннан санала, П. И. Чайковскийның «Пики дамасы» операсында Герман партиясен беренче башкаручы буларак та танылa.

Вера Николаевна исә «Халык иреге» партиясе Башкарма комитетында атаклы революционерлардан Софья Перовская, Степан Халтурин, Андрей Желябов, Вера Засулич, Николай Кибальчичлар белән кулга кул тотынып эшли.

Вера Фигнер Александр патшага һөҗүм оештыруда иң актив катнашучылардан була. 1881 елның 1 мартында халык ирекчесе Гриновицкий ташлаган бомбадан император каты яралана. Заманының иң яхшы табибларыннан саналган лейбмедик Сергей Петрович Боткинның зур осталыгы да бу очракта ярдәм итә алмый. Жандармнар патшаны үтерүдә катнашучыларның күбесен шунда ук кулга алалар. «Халык ирекe» партиясе Башкарма комитеты членнарыннан Вера Фигнер гына шактый вакыт иректа кала. Ләкин ике елдан соң, 1883 елның 10 февралендә хыянәтче Сергей Дегаевның әләге буенча ул да кулга алына, ә 1884 елның 14 сентябрендә Петербург хәрби округы суды каршына баса һәм үлем җәзасына хөкем ителә. Бераздан соң (Вера Николаевнаның әнисенең үтенече буенча) император галиҗанапларының «мәрхәмәте» белән бу җәза сроксыз каторга эше белән алыштырыла. Күпмедер вакыт Петербургның Петропавел төрмәсендә тотканнан соң Вера Фигнерны Ладога күлендә, Нева елгасы үзенең агышын башлаган урыннан ерак түгел җирдә, кечкенә генә Орехов утравындагы Шлиссельбург крепостена күчерәләр.

Егерме ел буена бер кешелек 26 нчы камерада яшәү артта калган. Ә алда — тулы билгесезлек. Вера Николаевна бөтен көчен, тормышын багышлаган народниклык идеяләре инде күптән тарих карамагында. Ә 1905 ел революциясенә хәзерләнүче рус пролетариаты үзенең байрагы, төп кулланмасы иткән марксизмны кабул итәргә әле ул әзер түгел. Шулай да Вера Николаевна, менә шундый шартларда бик тә табигый булган каушауны, төшенкелекне җиңеп, тормышта яңадан үз урынын таба, башыннан үткәннәрне яза башлый. Җиде томлык хезмәтләрендә ул үзенең тормышы, пролетариат дәверенә кадәр булган революцион хәрәкәттә катнашуы турында сөйләп кенә калмый, халыкны азат итү өчен көрәшнең бөтен бер этабын сурәтләп бирә [1].

Вера Николаевна Фигнерны язмыш шактый озын гомерле итә. Ул өч рус революциясен кичерә. Октябрь җиңгәннән соң Татарстан АССРның Тәтеш шәһәренә килеп урнаша, мәгърифәтчелек белән шөгыльләнә, хезмәтләрен яза. Гаҗәеп язмышлы, батыр рухлы хатын 1942 елда 92 яшендә вафат була.

## ПУШКИН КАЗАНДА

Александр Сергеевич Пушкин Казанда ике тәүлек тә җиде сәгать була. Бу — шагыйрьнең «Пугачев тарихы» дигән китап (бу исем соңрак патша кушуы буенча «Пугачев бунтының тарихы» итеп үзгәртелә) өчен материал туплап йөргән чагы була. Ул Петербург белән Казан арасын 19 көндә үтә, безгә Чабаксар, Түрләмә, Свияжск, Васильево аша килә. Аның Васильевода кичке сәгать тугызда булганы билгеле. Васильеводан Казанга хәтле ат белән ике сәгать ярымлык юл дип исәпләсәк, ул Казанның үзенә төнге уникеләрдән дә соңга калмыйча килеп җиткән булырга тиеш. Шәһәргә ул элекке Ягодный бистәсе аша килеп керә, Проломный (хәзерге Бауман урамы) буйлап үтә дә хәзерге Ирек мәйданындагы (ул чакта Театр мәйданы дип аталган) авиация институты урынындагы төп почтамт бинасы артына урнашкан почта

---

[1] «Запечатленный труд».

станциясенә күтәреләә. Шагыйрь төнгә Петропавловск урамындагы (хәзерге Рәхмәтуллин урамы, 6) дворяннар җыелышы кунак йортында туктала.

1826 елда шул ук кунак йортында, декабрист ире Сергей Волконский янына сөргенгә барышлый, Александр Сергеевичның бик яхшы танышы, эчкерсез бер хис белән яратып йөргән кешесе Мария Николаевна Волконская да туктаган икән. А. С. Пушкин аның белән 1820 елда әле ул кыз чакта Төньяк Кавказда кызның әтисе генерал Раевский өендә танышкан була. Шагыйрьнең:

> **Җан газабым — тик син... Аны бүтән**
> **һичбер сагыш борчый, изә алмый,**
> **һәм йөрәгем тагын янып сөя,**
> **Сөймичә ул чөнки түзә алмый**[1]

дигән юллары нәкъ менә шул Мария Николаевнага багышланганнар.

Шулай итеп, Александр Сергеевич Казанга 1833 елның 5 сентябреннән 6 сентябренә каршы төндә килеп төшә һәм кунарга... Менә бу урында инде Пушкинның тормышын, аерым алганда аның Идел буена, Уралга сәяхәтен тикшерүчеләр арасында аерымлыклар башлана. Казан тарихын яхшы белүче һәм шәһәр турында бик яхшы күрсәтмә язып калдырган Николай Загоскин, шагыйрь Казанга килеп төшкәч ук Кече Проломный урамында (хәзерге Профсоюз урамы) үзенең яхшы танышы, Казанның ул чактагы танылган әдибе, Пушкинны Петербург буенча белүче Эраст Петрович Перцов өенә тукталган, дип саный. Ә менә безнең замандашларыбыз Н. Ф. Калинин, Е. Г. Бушканец, В. А. Климетовский һәм башка кайбер авторлар, Казанда А. С. Пушкин дворяннар җыелышының кунак йортында тукталуны кулайрак күргән һәм өч төннең өчесен дә шунда үткәргән, дигән фикердә торалар. 1980 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган «А. С. Пушкинның Идел буена һәм Уралга сәяхәте» дигән китап авторы Ю. Л. Славянский исә өченче бер фикерне алга сөрә. Ул болай ди: әйе, ул Казанга килеп җиткәндә вакыт соң булу сәбәпле, шагыйрь чыннан да дворяннар җыелышының кунак йортында тукталырга мәҗбүр булган. Ләкин икенче көнне, ягъни 6 сентябрьдә, иртән үк үзенең якын дусты, атаклы шагыйрь Евгений Абрамович Баратынский каенатасы генерал-майор Энгельгардтлар өенә күчкән. Шул ук Ю. Л. Славянский раславынча, бу өй Грузинский (хәзерге Карл Маркс урамы) урамындагы ул чактагы Грузинский чиркәвеннән (хәзер 15 нче элемтә бүлеге бинасы) якында гына урнашкан.

Александр Сергеевич Евгений Абрамович Баратынскийны киң күңелле кеше итеп тә, талантлы шагыйрь буларак та югары бәяләгән.

> **Чын алтындай чыңлый һәм ялтырый**
> **һәрбер шигырь синең повестьта! —**

Пушкинның күренекле замандашы һәм каләмдәше иҗатына карашы әнә шундый.

1831 елда «Современник» журналының редакторы һәм нәшире, танкыйтьче П. А. Плетневка уртак дусларь, әдәбият сөючеләргә таныш әдип А. А. Дельвигның вакытсыз үлүе уңае белән җибәргән хатында А. Пушкин менә ничек яза: «Аңардан башка без ятим калгандай булдык. Бармак белән саган кәра әле, без ничәү калдык: син, мин, Баратынский — вәссәлам!» Евгений Абрамович Казанда килә-китә күп тапкырлар булган, ә 1831—1833 елларда озаклап яшәгән.

Ничек кенә булмасын, Александр Сергеевич Пушкин белән Евгений Абрамович Баратынский безнең шәһәрдә очрашканнар. Бу очрашу һич кәтмәгәндә һәм, әлбәттә, бер-берсен озак күрми торган, бер-берсенә карата рухи якынлык хисе саклаган чын дуслар кавышкандагыча шатлыклы булган. һәм Евгений Баратынский дустының Казанга килүе файдалы һәм нәтиҗәле, күңелгә ятышлы, истә калырдай булсын өчен кулдан килгәннең барысын да эшләргә тырышкан. Ул Пушкинны Казан интеллигентлары арасында бик ихтирамлы кешеләр — ирле-хатынлы Карл Федорович һәм Александра Андреевна Фукслар белән таныштыра. Милләте белән немец булган

---

[1] Язмалардагы шигырь өзекләрен Зәки Нури тәрҗемә итте.

профессор Карл Фукс үзенең бөтен аңлы гомерен диярлек Казан университетында эшләүгә бирә. Үзе медик булса да, тарих, этнография, крайны өйрәнү белән кызыксына. Аның татар чуваш халыклары тарихы, аларның гореф-гадәтләре, көнкүреш үзенчәлекләре турындагы хезмәтләре бүген дә әһәмиятләрен югалтмыйлар. 1829 елда бөтен Идел буен баскан ваба эпидемиясе вакытында университет ректоры Н. И. Лобачевский белән берлектә бу афәткә каршы көрәштә күрсәткән гражданлык батырлыгы белән ул казанлылар арасында аеруча зур авторитет казана. Ул университет профессорлары арасыннан гына түгел, шул чактагы югары катлау казанлылар арасыннан да беренче булып, бу даирә кешеләренең гаепләүләренә, аңардан йөз чөерүләренә игътибар бирмәстән, даими яшәү урыны итеп Татар бистәсен сайлый, хәзерге Киров һәм Галиәсгар Камал урамнары чатында өй сатып ала, шул тирәдә яшәүче татар хезмәт ияләре белән якыннан аралаша, аларны дәвалый, гореф-гадәтләрен өйрәнә. Фукслар — Карл Федорович үзе һәм аның хатыны, үз заманында урта кул шигырьләр бастырып чыгарган Александра Андреевна (кыз чагында фамилиясе Апехтина) — университетта эшләүче татар галиме Николай Мисаилович Ибраһимов оештырган «Ватаныбыз әдәбиятын сөючеләр җәмгыяте»нең актив членнары булалар, Казанда чыга торган «Заволжский муравей» журналына актив язышалар. Аларның өе озак еллар буена шәһәрнең үзенә бер төрле иң популяр әдәби салоны ролен уйный. Анда Казанның атаклы кешеләре, әдәбият һәм сәнгать сөючеләр җыела торган була.

Бирегә Пушкинның Казанда үткәргән сәгатьләрендә кайларда булуын бәйнә-бәйнә санап чыгу кирәк булмас. Шагыйрьнең Суконный бистәсендә йөрүе һәм биредәге сукно фабрикасы эшчесе Василий Петрович Бабиновның аңа Пугачев турында үзе ишетеп белгән хәлләрне сөйләве, Пушкинның шәһәр читендә Пугачев гаскәрләренең сугышлары белән бәйле урыннарны карап чыгуы, пугачевчыларда әсирлектә булган сәүдәгәр Крупенников белән сөйләшүе укучыларга күптән билгеле. Пушкин Эраст Перцовларның Кече Проломныйдагы өендә төшке ашта була, бер кичен Фуксларда үткәрә. Шулай ук Александр Сергеевичның 8 сентябрьдә бик иртән Казаннан китүе, китәр алдыннан хатыны Наталья Николаевнага кыска гына хат кисәге салуы турында да күптапкырлар язылган. Менә ул хаттан өзек: «Мин Казанда бишесеннән... Хәзер Сембергә юл тотам, мине анда синең хатың көтәдер дип өметләнәм. Бирегә мин героемның карт замандашлары белән маташтым, сугыш булган урыннарны карадым, сораштым, язып алдым — һәм бу якларга килүемнең тикмәгә булмавына бик канагатьмен».

1965 елда «Лобачевский» дигән китапның авторы Н. Колесников А. Пушкин килүе уңае белән Карл Федорович Фукс өендә уздырылган мәҗлесне тасвирлый. Монда Эраст Перцовтан башка тагын университет ректоры Н. И. Лобачевский, шул ук университетның адъюнкты, Казан тарихы турында укучыларга таныш китапларның авторы драматург М. С. Рыбушкин һәм «Ватаныбыз әдәбиятын сөючеләр» җәмгыятенең секретаре профессор Г. С. Суровцев та булган. Александр Сергеевич үзенең күптәнге танышы княжна Абамелекны да күргән, дип языла. Бу фараз кылуларның кайберсенең нигезе бар. Пушкинның университет ректоры профессор Н. И. Лобачевский турында күз күргән, аралашкан кешесе — урта кул шагыйрь И. Е. Великопольскийдан ишеткән булуы мөмкин, чөнки ул Лобачевскийның хатыны Варвара Алексеевнага туган тиешле кеше. Ираклий Андрониковка тагын бер мөрәҗәгать итик. Аның язмаларында Иван Великопольскийга Казаннан килгән бер хаттан өзек китерелә: «Без Фукслар өендә әдәби кичәдә булдык... Н. И. Лобачевский м-ме Фукс язган шигырьләрне укыды һәм берничә тапкыр кычкырып көлеп җибәргә язды... Баратынский һаман аска карап утырды». Димәк, Н. И. Лобачевский Фуксларда моңа кадәр дә булгалаган, шуңа күрә Пушкин килгән вакыттагы кичәгә чакырылуы бер дә гаҗәп түгел.

Бөек шагыйрь, әйткәнебезчә, Казанның ул чакларда шактый популяр публицисты һәм драматургы М. С. Рыбушкинны да белгән. Әлеге Рыбушкин Иван Грозныйның Казанны алуы турында уңышсыз пьеса яза һәм бу уңайдан басылган тәнкыйть мәкаләләрен чиксез хурланып, ачуланып кабул итә. Александр Сергеевич шуннан соң шаян эпиграмма яза.

Булган элек шундый геройлар:
Ут-су кичеп яуда йөргәннәр,
Җиңеп кайткач, кылыч-хәнҗәрне
Өй түренә горур элгәннәр.
Ә бездә бер трагик Бурун бар,
Күпме кара эрәм итеп инде
Сугышты да... башын тиз иде —
Кикрик, димәк кинәт тиз шиңде.

Ә менә княжна Абамелек белән очрашу мәсьәләсендә Н. Колесников бераз ашыгып нәтиҗә ясаган. Ул вакытка инде шагыйрь Евгений Баратынский абыйсының хатыны булырга һәм аның фамилиясен алырга өлгергән Анна Давыдовна Абамелек Казанда безнең шәһәргә А. С. Пушкин килеп җиткәннән соң унбиш еллап үткәч, ире губернатор булып торган чакларда гына яши.

Пушкин һәм Казан турында сүз барганда, патша самодержавиесенең бөек шагыйрьгә һәм татар культурасы үсешенә мөнәсәбәтен ачык чагылдыручы бер фактка тукталасы килә. 1902 елда патша хөкүмәтенең цензура комитеты А. С. Пушкинның «Поп һәм аның хезмәтчесе Балда турындагы әкият»енең татарчага Енакиев ясаган тәрҗемәсен басып чыгаруны тыя. Бу комитет «юк-бар татар грамотейларының үз мәсләктәшләрен рус халкы һәм аның әдәбияты белән таныштыру өчен аларга рус кешесеннән мыскыллап көлү өчен форсат һәм материал булырдай» нәрсәләрне генә сайлауга булган тенденциясен кирәксез һәм зарарлы дип саный.

Йомгак ясыйк. Александр Сергеевич Пушкин Казанда тулар-тулмас өч тәүлек вакыт яши. Әмма бу шагыйрьгә дә, шәһәрнең ул чактагы алдынгы фикер ияләренә дә һәм хәтта безгә дә күп нәрсә бирә. Пушкин үзенең Казандагы дуслары белән элемтәсен өзми. Аның Александра Андреевна Фукска язган берничә хаты безнең көннәргәчә сакланган. Шулай ук аның М. С. Рыбушкинга «Пугачев бунты тарихы» дигән китабын җибәргәнлеге мәгълүм. Казанлылар да шагыйрьне онытмаганнар, аның белән очрашуны рәхмәт хисе белән искә алып яшәгәннәр. Алар Александр Сергеевичның Дантес тарафыннан үтерелүен зур югалту итеп, тирән кичергәннәр.

А. С. Пушкинның Казанда булуы турындагы язманы ул чакларда Казан университеты студенты булган атаклы язучы П. И. Мельников-Печерскийның истәлекләреннән алынган юллар белән гәмамларга мөмкин:

«1837 елның 5 февралендә, җомга көнне, сәгать иртәнге сигездә әдәбият факультетының өченче курсында рус әдәбиятыннан лекция булды. Профессор Суровцев, гадәте буенча, аудиториягә нәкъ сәгать сукканда килеп керде. Без, менә ул, гадәтенчә, аз гына аксап кафедрага менәр, утырыр, кемнең лекциягә килмәвен күрер өчен, студентларга күз йөртеп чыгар, көмеш табакеркасын алыр да уң ягына, фуляр кульяулыгын чыгарып сул ягына куяр һәм гадәттәге сүзләре белән лекциясен башлар, дип көткән идек... Ләкин алай булмады. Григорий Степанович кафедрага менде дә, кесәсеннән газета битен — хәтердә, «Рус инвалиды»н чыгарды,— аны өскә күтәрде һәм, аудиториягә тиз-тиз күз йөртеп чыкты да, кычкырып: «Торыгыз!» — диде. Без, профессорга гаҗәпләнеп караган килеш, аягүрә бастык. Ул дулкынланудан калтыранган, ачы күз яше ишетелеп торган тавыш белән берничә генә юллы хәбәрне укыды. Аның беренче сүзләре хәтердә: «Поэзиябезнең кояшы батты — Пушкин инде юк». Аудитория бер тавыштан «аһ» итеп куйды, үксеп елый башлаган тавышлар ишетелде... Профессор үзе утырды һәм көмештәй ак, чал башын кафедрага куйды да каты итеп елап җибәрде... Берничә минут үткәч, ул аягүрә басты да болай диде: «Рус шагыйрьләренең кнэзе — табутта. Аның үле гәүдәсен Петербургтан каядыр еракка алып баралар. Бәлки ул әле җир куенына кермәгәндер дә. Пушкинның табуты әле ябылмас борын рус әдәбияты турында сөйләргә ничек җөрьәт итәргә! Лекция булмаячак...»

## ГАЛИМ, РЕКТОР, КИТАПХАНӘЧЕ

Лобачевский турында, ватаныбыз фәненең горурлыгы булып танылган, аның данын бөтен дөньяга тараткан бөек галим турында Казанда күп нәрсә сөйли.

Николай Иванович җитәкчелегендә, аның турыдан-туры катнашы белән төзелгән мәһабәт университет бинасы. Аның үлемсез исемен йөртә торган урам. Гаиләсе белән ул яшәгән элекке ректор йортының һәм химия корпусының стеналарындагы истәлек такталары. Аларның берсе бу кешенең 1827 елдан 1846 елга кадәр 19 ел буена бу университетта ректор булып торганлыгын хәбәр итә. Һәм, ниһаять, рус скульпторы Мария Диллонның таланты һәм иҗади фикере җимеше — Н. И. Лобачевскийның бронзадан коелган бюсты, шәһәр халкының бу бөек шәхескә мәхәббәте һәм ихтирамы билгесе, инде 80 елдан артык бүгенге Ленин һәм Лобачевский исемендәге урамнар чатын, республика китапханәсе һәм Фәннәр академиясе филиалы бинаЛары янәшәсендәге кечкенә бакчаны бизәп торучы һәйкәл. Һәйкәлне Николай Ивановичның тууына 100 ел тулу уңае белән шәһәр кешеләреннән һәм дөнья галимнәреннән җыелган акчага салганнар. Акча җыю комитетының почетлы членнары Италия математигы Эудженио Бельтрами, немец физигы Герман Гельмгольц, француз математигы һәм философы Жюль Пуанкаре, инглиз математигы Джеймс Сильвестр кебек дөньяга билгеле галимнәр булган.

Үз бәясен белеп горур иелгән баш, киң маңгай, төксе, кырыс йөз, җыерылган каш. Үлемсезлеккә атлаган, көчле рухлы бу кеше, нигә шундый тирән сагышлы соң? Бер уйлаганда, бу фани дөньяда ирешергә мөмкин булганнарның барысына да ирешкән бит инде ул. Нижний Новгородның вак чиновник улы Николай әнисенең тырышлыгы аркасында энеләре Александр һәм Алексей белән берлектә Россиядәге иң өлкән урта уку йортларының берсе һәм император гимназиясе дип аталырга хаклы булганнарының бердәнберенә — Казан гимназиясенә керү бәхетенә ирешә. Инде зур авырлыклар белән (ул чакларда гимназияләрдә казарма тәртипләре яшәгән) үткәрелгән уку еллары артта калган. Инде университет курсы да уңышлы үтелгән (хәер, бу уку йортына керү аның өчен бик ансат булмаган, чөнки ул кабул итү имтиханнарын беренче тапкырында бирә алмый). Дөрес, горур мөстәкыйльлеге, ачы теле, яңадан-яңа шуклыклар уйлап табудагы тапкырлыгы белән ул укытучыларның һәм инспекторларның тәңкәсенә тиеп бетә. Чыннан да, кирәк бит шул хәтлегә барып җитәргә: акчага һәрвакыт мохтаҗ булган студент Николай Лобачевский үзе белән бер группада укыган сабакташы — бай малае Дмитрий Перевозчиков белән бәхәсләшә дә, күпмедер вакыт университетның ректоры да булып торган математика укытучысы Г. Никольский баскычтан төшеп барганда, аның башы өстеннән сикереп үтә.

Математикага сәләте бик көчле булганга, Николай Лобачевский унсигез яшендә инде зур галим булып җитлегә. Ул елларда шактый танылган профессор Бартельсның аны укуын бетерер-бетермәс приват-ассистент сыйфатында педагогия эшенә тартуы тикмәгә генә түгел. Бик әшәке кеше, гимназия директоры һәм инспекторы И. Ф. Яковкинның (шунысы кызык: ачылган көненнән алып 1814 елга кадәр ун ел буена Казан университеты «гимназия каршында» була), ә соңрак Казан уку-укыту округының попечителе карагруһ карашлы, һәр җирдә полиция тәртипләре урнаштырырга омтылучы кеше М. Л. Магницкийның төрлечә киртә коруларына карамастан, кандидат дәрәҗәсен узмыйча гына, егерме ике яшендә адъюнкт (профессор ярдәмчесе) була, ә 1816 елны, егерме дүрт яшендә экстраординарный профессор итеп сайлана.

1827 елда ул инде — университет ректоры. Бу уку йортының төп корпусын, астрономия обсерваториясе, фәнни китапханә, физика һәм химия лабораторияләре биналарын, анатомия театрын, кыскасы, үзенең камиллеге белән бүген дә һәркемне таң калдыра торган университет ансамблен төзүгә күпме көч салынган! Университеттагы китап саклау урынын тәртипкә китерү, аны Россиядәге университет китапханәләренең иң яхшыларыннан берсенә әверелдерү буенча күпме эш башкарылган! Ул ректор булып эшли башлагач та үзенең 1825 елдан бирле яратып һәм намус белән үтәп килгән китапханәчелек вазифасыннан баш тартмый гына түгел, әле тагын ун ел буена шушында тырышып эшләвен дәвам иттерә. Демократ-галим һәм халык мәгарифенең зур белгече буларак ул югары уку йортының бурычын студентларны укытуда гына түгел, алардан җәмгыятькә файдалы гражданнар тәрбияләүдә дә күрә һәм бу эштә китапханәгә зур урын бирә. Китапхана өчен рус әдәбиятының күренекле әсәрләрен, Пушкин, Гоголь, Грибоедов китапларын ул үзе сайлап

ала торган була, ул заманнарда прогрессив матбугат органнарыннан саналган «Современник» журналын алдыра. Аның теләге буенча университетта китапларның беренче каталогы төзелә.

Һәм болар барысы да югары уку йортындагы төп вазифасыннан — лекцияләр укудан, берьюлы берничә фәнне, аерым алганда, аналитик механика, гидромеханика, эксперименталь физик математика һәм хәтта астрономияне алып барудан тыш башкарыла. Күп вакыт, көч һәм тырышлык таләп итүче тәрбия эшен дә истә тотарга кирәк әле. Белгечләр хәзерләү эшен уйсыз ятлаудан, схоластикадан арындыру турында 1828 елда ул сөйләгән «Тәрбиянең иң мөһим мәсьәләләре турында речь» безнең көннәрдә дә үзенең әһәмиятен югалтмый. Ул университет биналарын төзү комитетының житәкчесе постында үзе кебек үк талантлы, үзе кебек үк эшенә җаны-тәне белән бирелгән архитектор П. Г. Пятницкий, ә соңрак, шундый ук талант иясе М. П. Коринфский белән иңгә-иң торып, зур эшләр башкара. Шул ук вакытта ул авыл хуҗалыгы мәсьәләләре белән шөгыльләнә торган ирекле экономик җәмгыятьнең IV бүлекчәсе җитәкчесе дә була.

Һәм шул ук галим ватаныбыз фәненең горурлыгы булырдай бөек ачыш ясый: Эвклид геометриясеннән үзгә геометрия иҗат итела. Бөтен дөньядагы математиклар ике мең ел буена баш ваткан нәрсәгә, ниһаять, тулы ачыклык кертелгән. Эш менә нәрсәдә: Борынгы Греция галиме Эвклидның унбиш китаптан торган, «Башлангычлар» дип аталган хезмәтендә аңлатылган постулатларның, ягъни аксиомаларның абсолют күпчелеге бик тә аңлаешлы һәм алар бераудә дә шик-фәлән уятмыйлар. Чыннан да «бер бөтен әйбер өлештән зуррак» яисә «аерым-аерым өченче бер нәрсәгә тигез булган зурлыклар үзара да тигезләр» кебек аксиомаларга кем генә шикләнер икән? Әмма параллель туры сызыклар турындагы тәгълиматның нигезендә ята торган бишенче постулат бәхәсле. Бу постулатны дөрес дип санасаң, туры сызыктан читтә яткан нокта аша бу сызыкка параллель булган бер генә, фәкать бер генә сызык үткәреп була. Чыннан да кара акыл белән уйлаганда, болай әйтүдә искитәрлек бернәрсә дә юк. Геометрияне аз-маз гына белүче һәр кеше кәгазьгә сызып карау белән моңа ышаначак. Ләкин геометрия фәне беренче караштан соң ук туган тәэсирләргә нигезләнми, сиземләүләргә һәм тойгыларга ышанмый. Николай Иванович Лобачевский да, Эвклидның турыдан-туры алынган тәэсирләр буенча һичшиксез дөрес дип саналган әлеге бишенче постулатының абсолютлыгын шик астына алганда, үзе тапкан яңа геометрияне хәзергә әле турыдан-туры тәҗрибә белән түгел, бары тик фараз кылу, күз алдына китерү юлы белән генә аңларга мөмкин икәнлегеннән чыгып эш итә. Шуңа күрә ул аны «фараз кылына торган», «гөман ителә торган» геометрия дип тә атый. Эвклид геометриясенең тел-теш тидергесез бүтән положениеләренә кагылмыйча, ул борынгы математикның бишенче постулатын үзенең яңа аксиомасы белән алыштыра. Һәм ул яңа аксиома менә нинди: бер нокта аша бирелгән туры сызык белән кисешми торган бик күп туры сызыклар үткәрергә мөмкин. Шунысы әһәмиятле: Лобачевскийча, бер-берсе белән кисешми торган сызыклар һәм параллель сызыклар — бер үк нәрсәләр түгел. Лобачевский тәгълиматының белгечләргә генә аңлашыла торган бүтән нечкәлекләренә кагылмыйча, тик шуны гына басым ясап әйтеп үтик. Аның геометриясе, пространство — ул материянең яшәү формасы дигән материалистик хакыйкатьне тануга нигезләнгән.

Әйе, Лобачевский гигант эшләр башкарган. Тик бронза бюст булып урам мәйданына чыгып баскан бу титанның үзе нигә шулай борчулы, нигә шулай ваемлы соң әле? Бу сорауга бер генә сүз белән җавап биреп булмый. Иң төп сәбәп шунда — безнең даһи озак вакыт танылмаган. Математика өлкәсендәге Колумб дип, Коперник дип ихтирам белән аны әле шактый соңрак, үзе үлгәч кенә, атыйлар. Үзе исән чакта, Н. И. Лобачевский юк-бар белән маташучы сәер кешедән санап йөртелә. 1826 елның 11 февралендә университетның физика факультеты утырышында сөйләгән, Эвклид геометриясеннән үзгә геометриянең нигезләрен аңлаткан докладын аның үз хезмәттәшләре үк кимсетүле елмаю белән каршы алалар. 1829 елда «Казанский вестник» журналында басылып чыккан «Геометриянең башлангычлары турында»гы мемуарлары Россиядә һәм чит илдә игътибарсыз калдырыла.

Хәер, игътибарсыз ук түгел икән. Яман атлары чыккан карагруһчылар, фәндә,

әдәбиятта, сәнгатьтә булган һәр алдынгы фикергә агулы ук җибәрергә әзер торган журналистлар, еллар буе матбугат битләрендә дәһи Пушкинның «канына тоз салып» килгән кешеләр — Булгарин белән Греча — Николай Ивановичны да «игътибарсыз калдырмыйлар». Үзләре нәшер иткән «Сын отечества» журналының 41 санында (1834 ел) Казан галимен хурлый, кимсетә торган, аның әле генә без телгә алган мемуарына пычрак аткан чәнечкеле пасквиль басып чыгаралар. «Һәр укытучы кеше галим ук булмаса да, һич югында сәламәт акылга ия булырга тиеш,— дип язалар алар.— Ә менә яңа геометриядә бу соңгысы да җитенкерәми».

Юк, шәхси данга омтылмый Николай Иванович Лобачевский. Файда, дәрәҗә, шөһрәт турында уйлау — аның өчен ят бер нәрсә. Аңа башкасы тынгылык бирми. Күп еллар баш ватуның нәтиҗәләре, киеренке иҗат җимеше — яңа геометриясе шулай ук озак еллар буе фәнгә, җәмгыятькә файдасыз булып калыр микәнни?

Бәлки аның йөзенә чыккан борчуларның сәбәбе — ялгызлыктыр? Ихтимал. Дөрес, Казан уку-укыту округының попечителе, зур алпавыт, Спас өязендәге Бездна авылының — крестьяннары күп ел соңрак Антон Петров җитәкчелегендә патшаның җир реформасына каршы көрәшкә күтәреләчәк авылның хуҗасы М. Н. Мусин-Пушкин, элекке попечитель Магницкийдан үзгә буларак, аны яклый, аңа ярдәм итәргә тырыша. Дөрес, аның яраткан кешесе, хатыны Варвара Алексеевна, балалары, туганнары бар. Хәер, соңгы вакытларда бу терәк чатный, ярыла башлый. Һич көтмәгәндә яраткан улы Алексей үлеп китә. Кечесе Николай да, әтисенең сүзен тыңламыйча, университетны ташлый. Энесе Алексейның тормышы уңышлы ук булып чыкмый.

Студент чактан ук дус кешесе Иван Симонов та шунда — Казанда, университетта. Бу — аның белән бергә университет тәмамлаган, аның белән бер үк көнне магистр булган, адъюнкт булган, бер үк көнне экстраординар профессор дәрәҗәсе алган, аннары Ф. Ф. Белингсгаузен һәм М. П. Лазарев җитәкчелегендә дөнья әйләнә сәяхәттә катнашып, бөтен дөньяга танылган астроном Симонов. Тик аның якынлыгы да җиңеллек китерми хәзер Лобачевскийга. Әллә нәрсә булды әле аның дустына, әлеге сәяхәттән соң Иван Михайлович кинәт үзгәреп китте. Үзенең даны-шөһрәте белән тәмам исереп йөри, ректор креслосы турында хыяллана, шуңа күрә бу урынга Лобачевскийның куелуын гарьләнеп каршы ала, хәтере кала. Николай Ивановичны әллә аңламый, әллә аңларга теләми. Аңласа, үз итсә, Лобачевскийның бөек ачышын тизрәк фән хәзинәсе итү өчен көрәшмәс, авыр чакларда аның таянычы булырга омтылмас идемени?! Кыскасы, безнең бөек галимебез ялгыз. Чын фикердәше, мәсләктәше юк аның, эчен бушатыр кешесе юк.

Бәлки Николай Ивановичның йөзендә сагыш та, кайгы да түгелдер? Бәлки бөек галим-геометрның титан  гакылы әле һаман үзе  ачкан фәннең  киләчәге турында уйлыйдыр? Бик ихтимал. Ничек кенә булмасын Россиядәге беренче хатын-кыз скульптор Мария Диллонның иҗат җимеше — геройның үзенә тиң. Алай булмаса, без университет каршындагы бакчадан Николай Иванович һәйкәле янышнан үтеп киткәндә ясса сүзсез генә аның янында басып торганда, үз ватанына, үз халкына, алдынгы фәнгә хезмәт итүгә багышланган кешеләрнең үлемсезлеге турында тирән уйланмас идек.

Газиз Иделле

# ДУСЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ ТУРЫНДА

Хәзер без, гомумән, бик күп укыйбыз: үз әдәбиятыбызны, тугандаш халыклар әдәбиятын, дөнья халыкларының бүгенге һәм классик әдәбиятларын... Чорларын да, телләрен дә, жанрларын да санап кына бетерерлек түгел аларның... Шундый күп төрле рухи байлык арасында йөргәндә, кайчак, бер дә көтмәгәндә диярлек, үтә кызыклы китапларга да тап буласың. Укучыларыбыз кулында хәзер шундыйларның берсе — «Арал дулкыннары». Каракалпакстан әдипләре әсәрләрен туплаган, Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган күләмле бер китап. Без аны бик кызыксынып, дулкынланып укыйбыз, халкы һәм аның катлаулы тарихи юлы белән, әдипләре һәм әдәбиятлары белән танышабыз.

Каракалпакстан, Үзбәкстан ССР составындагы, Арал диңгезе һәм Амударья буена урнашкан шундый автономияле республика бар. Каракалпаклар хакында әлегәчә бөтен белгәнебез шул иде дисәк тә дөреслектән ерак китмәгән булырбыз. Һәрхәлдә үз халкыбызның күпчелеген, ягъни бүгенге укучыларыбызны күз алдында тотып әйтүем бу. Китаптагы кереш сүздә китерелгән кыскача мәгълүматларга караганда исә аларның татарлар, башкортлар белән танышу-аралашуларының күптәнге тарихы бар икән. Ә 1980—1981 елларда Татарстан һәм Каракалпакстан әдәбият һәм сәнгать әһелләре делегацияләренең, бер-берендә кунак булулары исә ике арадагы дуслыкны яңартып җибәрде, тагын да үстерде, тирәнәйтте.

Каракалпак, Каракалпакстан... Кайдан килә бу исем? Төрле энциклопедияләрне дә актардым, әмма аларда да моңа ачык кына җавап юк икән. Шуңа күрә Ибраһим Йосыповның бу җыентыкка кергән шигырьләрен укыганда «Каракалпак хакында сүз» дип исемләнгәненә аеруча игътибар иттем.

**Кара табан, кара күн итек —**
**Бабам бик гайяр кеше булган, ди.**
**Киеме ак, калфагы кара,**
**Яуга чапкан ул, көчле булган, ди.**

«Олы яуга чыгар алдыннан атасы әйткән сөеп улына: «Бер васыять алып кит яуга — турылыклы бул син калфагыңа!» Каракалпаклылар шул көннән башлап калфак белән үк туалар, диләр. Дусмы — дошманмы, һәркем алдында гел калфак киеп куялар, диләр. Күпме заманның утлы кояшын күрсә дә, калфак агармый һаман. Каракалпак күп байлык югалтты — каракалфагы югалмый һаман. Алдап-йолдап та, янап-көчләп тә, ханнар да аны салдыра алмаган. Илгә ташланган иң-иң дәһшәтле яулар да аны салдыра алмаган. Дошманның һәрчак ачуы чыккан, бу кыюлыкка хәйран калган ул. Каракалпаклар бер генә җирдә бу гадәтеннән чигенә ала — бөек Ленин мавзолеена кергән чагында калфагын сала».

Бу символик шигырь каракалпак халкының үткән героик тарихына гына түгел, ә бүгенге бәхетле тормышына да дан җырлый.

Гомумән, барлык шигырьләрдә дә диярлек авторлар Ленин идеяләренә, бөек Ватаныбызга, халыклар дуслыгына үзләренең иң ялкынлы юлларын багышлаганнар.

«...Вакыт үткән саен, Ленин сүзләре ишетелә бара һаман еракларга. Авыр чакта безгә көч һәм илһам биреп яңгырый алар шәһәрләрдә, кышлакларда» (Җулдашбай Дилморатов). «Илдә күңелең көр булыр, ике битең гөл булыр. Илкәеңнән аерылсаң, гөлдәй битең көл булыр» (Олымәмбәт Хуҗаназаров). Шагыйрьләр иҗатында интернационализм рухының үзәк урын алуы табигый.

«Ирек җырларын яңгыратып аккан ал таңым минем, туган җир белән бәйләгән газиз Ватаным минем. Әй нурланган, әй гөлләнгән нурлы бостаным минем, сөекле туган илем, Каракалпакстаным минем. Күп милләтле дус семья әгъзасының берсе син — Каракалпакстаным минем» (Бабаш Исмаилов).

Безнең татар халкы белән аеруча якынлыклары турында да язалар алар. Шагыйрь Җолморза Айморзаевның «Хушлашу», «Дуслык атавы», «Казан кызына» шигырьләрендә шул мотив җырлана. «Кыз алышып, кыз бирешеп, кода булып һаман да, яшәдек без татар белән шулай борын заманнан...». Таҗетдин Сәетҗанов та аңа кушылып җырлый: «...Бүген гүя бергә кушылды Амударья белән киң Идел».

Татарстан әдәбият-сәнгать вәкилләреннән зур төркем Каракалпакстанга барганда Бердах белән Тукайның Казан рәссамнары ясаган портретларын Каракалпакстан язучыларына истәлек итеп тапшырганнар иде: «Бәйрәмебез тантанасына ике аксакал килде Казаннан: икесе дә туган халкына иң сөекле һәм олуг җаннан. Берсе — Тукай, ә берсе — Бердах, түргә уздылар алтын рамкада. Илһам чәчеп карап тордылар — уртак шатлык итте тантана» (Таҗетдин Сәетҗанов). «Кояш кызсын, нуры житсен татарның Тукаена... Кабул ит син бик күп рәхмәт, Тукай булганың өчен, кара нан ашап, шигырьдә ап-ак калганың өчен... Нәләт әйтәм син яшәгән заманның җәберенә, әгәр син терелер булсаң, мин ятыйм кабереңә» (Ибраһим Йосыпов). «Сезне дуслар безгә китерде Тукайлардан калган пар атлар. Бер ананың игез баласы — татарлар һәм каракалпаклар» (Таҗетдин Сәетҗанов).

Гомумән, зур күләмле бу китапта 34 шагыйрьнең һәм 24 прозаикның күп төрле һәм актуаль темаларны эченә алган шигырьләре, повесть-хикәяләре урнаштырылган. Аларны татарчага тәрҗемә итүдә безнең күренекле язучыларыбыздан 43 иптәш катнашкан (Китапны төзүче Л. Хәмидуллин). Шундый игелекле һәм җаваплы хезмәтне, бөтен көчләрен, осталыкларын эшкә җигеп, уңышлы башкарып чыкканнар. Шуңа күрә «Арал дулкыннары» — каракалпак һәм татар әдипләре бергәләп тудырган гүзәл иҗат дулкыннарының тәэсирле-моңлы шавы, дип тә әйтергә нигез бар.

Әҗинияз (1811—1878), Бердах (1827—1900). Узган гасырда яшәгән бу әдипләр дә, аларның иҗаты да — Каракалпак халкының ерактагы аянычлы тарихы. Урта гасыр башларыннан алып Совет чорына хәтле дошманнар тарафыннан изелеп, җәберләнеп килгән каракалпак халкы, үзен саклап калу көрәшләрендә урыннан-урынга куылып йөртелеп, кайларда гына булмаган! Украина далалары дисеңме, Идел буйлары, Урал яклары дисеңме, Төркестан, Казагыстан киңлекләреме... һәркайда изүчеләргә каршы авыр көрәш... Шуңа күрә язучыларның ул чор турындагы иҗатларында да—зар-моң...

«Мин шат идем, көлә идем дус белән,
Гел яхшы сүз төште татлы телемнән,
Дошман хәзер куа туган илемнән —
Без китәбез инде, данлы Бозатау [1].

Гашыйк — ярсыз, былбыл — гөлсез, киек — чүлсез, торна — күлсез булган кебек, йортсыз-нисез йөри Зиуар [2] юләрсыман» (Әҗинияз).

«...Өендә ач балалары,
Иртәдән ач карыннары,

[1] Әҗиниязның туган җире.
[2] Псевдонимы.

**Күзләрдән акты яшьләре,**
**Ай-яй кыен булды салым.**

Байбәтчәләр, ишан-мулла... Аларга салым нигә юк? Күздән яшьләр кибәрме бер! Килерме бу көткән хаклык?.. Каракалпак гел таркалды, юл адашты, гел ач калды, күпләре юлда югалды — халкым бәхет табалмады» (Бердах).

Хыялда гына булган бәхет исә каракалпак халкына фәкать илдә Октябрь таңы аткач кына, Совет власте елларында гына килә. Әдәбият-сәнгать үсеше дә шуннан башлана. Әҗинияз белән Бердахтан башка, китапта урын алган барлык авторлар — совет чоры язучылары. Чөнки Каракалпак халкының язма әдәбияты совет чорында гына туа, шуңа кадәрге шагыйрьләр — чәчән шагыйрьләр. Ә проза әсәрләре исә бөтенләй булмый. Бүген инде без каракалпак әдәбиятының барлык жанрлары киң күләмдә үсеп баруын, еш кына башка телләргә тәрҗемә ителүен дә беләбез.

...Ерактан килә торган катлаулы тарих. Ирек өчен көрәш. Хатын-кызлар язмышы. Советлар властеның беренче еллары. Яңалыкның искелек белән көрәше. Ватан-ана. Ленин. Партия. Республиканың экономикасы, табигате, кешеләре... Халыклар дуслыгы... Китапта урнаштырылган шигырь һәм поэмаларны, хикәя һәм повестьларны укып чыккач та, аларда әнә шул җитди темаларның теге яисә бу күләмдә чагылышын, әдәби тасвирлануын күрәсең, тоясың. Менә, мәсәлән, Дәүлен Аетморатовның «Каракалпакстаным» исемле шигыре:

**Каракалпак, казакъ, үзбәк, татар, руслар —**
**Бертугандай яшь сиңдә, бар да дуслар.**
**Һәйкәл салып матур-матур эшләр белән,**
**Яши алар бердәй үйлар, хисләр белән,**
**Шатлакалар уңышыңа дусларың,**
**Каракалпакстаным!**

Сәйфелгабит Мәҗитовның:

**Ханнар дәверендә сиңа,**
**Булдымы сан, каракалпак!!**
**Кайда ул сан, хәтта өең**
**Булды зиндан, каракалпак.**

дигән юллар белән башланып киткән «Каракалпак» исемле шигырендә, берничә строфадан соң ук:

**...Кара көнең батты синең,**
**Яраларың япты синең,**
**Коммунистлар тапты синең**
**Дәртка дәрман, каракалпак, —**

дип укыйбыз.

Теләүбирген Җумаморатов та:

**Күптән бетте канлы богау, бай камчысы,**
**Партиябез һәр җиңүнең илһамчысы —**

дип, шул ук хисләр белән илһамланып иҗат итә.

Ләкин моңа ирешү юллары да җиңел булмаган, Нәҗим Дәүкараевның «Балалар йортында», Сәфәрбай Сәлиевның «Дошман» исемле хикәяләренә генә мөрәҗәгать итү дә урынлы булыр. Дәүкараев башта заманына хас йөрәк тетрәткеч күренешләрне тасвирлый... Ханнар хакимлеге еллары. Җомабай — хан куштаны. Җир байлыклары шундыйлар кулында, һәм алар җирсез-сусыз калган Торымбит кебек барлык ярлы-

ябагайларны рәхимсез изәләр, көне-төне эшләтеп, тиешле хакын да бирмичә җәфалыйлар. Әнә шундый бер бәрелештә Җомаш тарафыннан ерткычларча кыйналган-җәзаланган Торымбит үлә...

...Менә, нәни кызчыгын күкрәгенә кыскан, 11 — 12 яшьлек улын артыннан иярткән, өсте-башы тузган бер бичара хатын. Үле дала буйлап көч-хәл белән атлап бара ул. Авылда бик күп җәфа чигеп тә яшәү рәте калмагач, шулай ерак шәһәргә китеп барулары аларның. Авыр юл газаплары. Ә шәһәрдә яңа тормыш дип сөйлиләр. Ләкин анда да әле Советлар власте урнаша башлауның беренче еллары гына. Көн итү җиңел түгел. Ачлык. Нәни кызчык үлеп китә... Төрле бандитларның котырынып, талап йөрүләре... Урам. Базар. Өс-башлары тузган, тәрбиячесез калган ач балалар төркеме... Әлеге бичара хатынның улы Төреш тә шулар арасында. Тегене-моны чәлдереп тамак туйдыралар... Советлар власте беренче башлап шундыйлар турында кайгыртучанлык күрсәтә, алар өчен махсус йортлар ача, ашата-эчертә, киендерә, укыта... Төрешне дә шунда урнаштыралар. «Монда яшәп була икән!» — ди ул, һәм тиздән әнисе дә шунда аш-су хәзерләү эшенә урнаша. Алар өчен яңа тормыш башланып китә.

Ташкынбай Халморатовның «Каен сере» — тирән мәгънәле, оста язылган хикәяләрнең берсе. Булып үткән Бөек Ватан сугышы каһарманнары да, бүгенге тыныч көннәрдә ил сагында торучы яшь солдатлар да, аларның онытылмаслык очрашулары да бар анда. Зифа каеннар үсеп торган бер тугайдагы лагерьда яшь танкистлар хәрби чыныгу алалар. Авыр походлар да, күңелле ял да, мәхәббәт тә бар. Кыскасы, чын тормышның үзе.

Каеннар турында риваять: ...Немец танклары ябырылып һөҗүм итеп килә. Югалтулар... Авыр чигенүләр... Нәкъ шулчак әлеге тугаебыз каеннарына җан керә: ботакулларын як-якка киереп җәяләр дә солдатларыбызның шинельләренә сарылалар һәм... «Туктагыз! Туган җирне ташлап китүчеләргә нәфрәт һәм үлем!» — дип, чигенеп барган сугышчыларның җаннарын тетрәтеп, тирә-якны яңгыратып кычкырып җибәрәләр. Шунда чигенү туктала, солдатлар кире борыла, һөҗүмгә күчә һәм — җиңүгә ирешә...

Әлеге яшь танкистларыбыз уйчан бер карт белән очрашалар. Аның күкрәгендә орденнар, медальләр... «Сәлам, бәркетләр! — дип эндәшә ул яшь танкистларга, — бүген мин шат, баламнан хат алдым, ул да сезнең кебек солдат хезмәтендә». Шунда, шаулап үсеп торган каеннарга карап, тирән уйга бата ул. Нәрсә уйлый? Нигә борчыла?..

Әсәр реаль кушкаен турында да сөйли. Әлеге танк часте хәрби өйрәнүләр үткәрә. Моторлар гүелди. Туры үзәнгә төшеп, елганы кичү бурычы куелган. Кушкаен нәкъ шул юл өстендә. Танк туп-туры шуңа таба бара. Әмма танкист егет каенны таптап китә алмый, чөнки алдында таныш карт басып тора. Ул кушкаенны кочаклап «Туктагыз», дип ишарә ясый. Командир үзе, танктан төшеп, карт белән сөйләшә. Юнәлеш үзгәртелә. Кушкаен исән кала...

Соңрак, яшь танкистлар, карт ветеран белән яңадан очрашалар. Сөйләшеп киткәч, тирән уйга бирелеп тынып калалар... Дусты Морза белән бергә әсирлеккә дучар булганнар икән алар. Чатнама салкын... Фашистлар чокыр казырга кушалар, ә алар казыган булып маташалар гына. Аларны каты җәзалыйлар — өсләренә салкын су сибеп катыралар. Ниһаять, катып үлделәр, дип ташлап китәләр. Ә алар үлмәгән әле. Совет армиясе һөҗүмгә күчкәч, үлемнән котылып калалар. Госпитальдә дә алар Морза дусты белән бергә. Ул өеннән хат ала. Үзең киткәч туган балаңны күрсәтергә дип, госпитальгә аның хатыны килә. Фронт әле якын. Килеп төшкән бер дошман снарядыннан яшь ана белән бәби һәлак була. Нәкъ менә шушы кушкаен төбенә күмелгән алар...

Яшьләр хәрби хезмәт срогын тутырып кайткач та шул кушкаен төбенә утырып тирән уйга чумалар.

Хикәяне укып чыккач, анда тасвир ителгән вакыйгалар, кешеләр, язмышлар турында, үткәннәр һәм бүгенгеләр турында уйланудан тукталмыйбыз.

Байнияз Каипназаровның «Иман» исемле шигыре дә шушы әсәр белән аваздаш булып яңгырый.

Кырык өченче ел... Окоплар...
Өченче ел без яу кырында...
Уйлый солдат илнең язмышы,
Җирнең киләчәге турында.
Көн дә һөҗүм... Дошман яңадан
Безнең өскә килә котырып.
Бетон стенага әверелеп,
Каршы бастык иңгә-иң торып...

Шигырьләр Каракалпакстанның кырыс та, бай да табигатен һәм халык рухын чагылдырган поэзия булып истә калалар. Катлаулы социаль-экономик тарихы, очсыз-кырыйсыз дала һәм чүлләре, түбәләре кар-боз белән капланган биек таулары, «адәм чыдамаслык» эсселәре, салкыннары, мул сулы Амударьясы, күп балыклы, шау дулкынлы Арал диңгезе булган — кыскасы, әнә шундый табигать һәм хезмәт фонында туган һәм үскән, көчәя барган: мәхәббәте дә, лирикасы да җитәрлек булган оптимистик поэзия белән танышабыз без биредә. Аларда батырлык, патриотизм, интернационализм, хезмәткә, хезмәт кешесенә мәдхия яңгыравын ишетми калу мөмкин түгел.

Кемнең кемлеге тик эштә беленер,
Эше белән аңа бәя бирелер,
Хезмәт мәйданында әгәр дан тотса,
Кешенең асылы, күрке күренер.

(Байнияз Каипназаров)

Эшнең җиңеле юк, булма сабырсыз,
Рәхәт күрмәк булсаң, кулың кабарсын.
Михнәт күрми торып, татлы гомер юк,
Төнсез көнне, әйт син, кайда табарсың!

(Теләүбиргән Жумаморатов)

Хикәя һәм повестьларда, шигырь һәм поэмаларда үткәндәге һәм бүгенге көн кешеләре, вакыйгалары да әнә шулай теге я бу күләмдә, теге я бу алымда күрсәтелә килә. Әмма, табигый ки, бүгенге көн темасына язылганнары күбрәк. Үткән авыр чор турында сөйли торган әсәрләрдән: Гөләйшә Есеморатованың «Үткәннәр искә төшкәндә», Шәүдербай Сәетовның «Качак», Мирзагали Дәрибаевның «Меңнәрдән берсе», Сәфәр Хуҗаниязовның «Камәр хыялы», «Сәфәрбай Сәлиевның «Дошман», Нәҗим Дәүкараевның «Балалар йортында» исемле хикәяләре бар. Аларда һәм башка хикәяләрдә хатын-кызларның үткәндәге чорына хас авыр язмышы чагылу тапкан. Шунда ук куанып әйтеп үтик: бүген инде Каракалпак әдипләре арасында лаеклы урын алган Сарыгөл Баһадирова, Гөлстан Шаһморатова, Гөләйшә Есеморатова, Гөләем Торсынова кебек хатын-кыз язучыларын да биредә аеруча горурлык уята: тарихи кыска вакыт эчендә бу өлкәдә дә сокланырлык үзгәрешләрнең булуы әһәмиятле күренешләрнең берсе бит!

Бүгенге Каракалпакстан тормышы турындагы хикәяләр чын совет кешесенә хас булган төп сыйфатларның беренче урында торуы белән югары бәя алуга хаклылар. Исмәгыйль Корбанбаевның «Алмаш» хикәясендәге бөтен гомерен хезмәттә үткәргән балта остасы Галим картның һәм аның үзенә алмаш итеп үстергән төпчек улының эштәге уңышлары, Гөләем Торсынованың «Яшәү яме» хикәясендәге өметсезлеккә бирелгән бакчачының эчке кичерешләре һәм яңадан хезмәт шатлыгын кичерә башлавы, Тордыморат Нәҗимовның «Алтын кәсе» хикәясендәге Бикән аганың мамык чистартуда көн-төн тырышып эшләве, авыр хәлдә калган хезмәттәшләренә гел ярдәмгә килүе һәм башка образлар югарыда әйтелгән фикерне тулысынча аклап торалар.

Әбдиморат Атаҗановның «Җәйраннар» хикәясе дә көчле тәэсир калдыра... Очсыз-

кырыйсыз киң дала. Бушлык. Кыш. Салкын. Җил-буран. Җир белән күк бергә тоташкан... Шундый табигать котырынуы шартларында җәйраннар көтүе җылы якка таба чаба — халык торган якка ашыга алар. Кыен хәл. Бигрәк тә көтү башлыгына авырга туры килә. Юл ерып бара бит ул — «көтүнең бәхет кояшы, җаны, көче». Әгәр ул аяктан егылса, көтүнең горурлыгы да, көче дә китәчәк. Шуңа күрә ул егылган җиреннән торып китәргә ашкына — арыганлыкны җиңәргә! Ниһаять — авылга килеп җиту. Караңгы төн. Ә монда совхоз. Тәмам хәлдән тайган җәйраннар дөгесе инде дәүләткә озатылып беткән ачык амбарга кереп сыеналар.

Бу мавыктыргыч хикәяне укып бетерергә ашыгабыз. Ул кырыс экзотика гына түгел, ә тирән эчтәлекле актуаль социаль хикәя икән. Оста каләм белән иҗат ителгән бу әсәр — җыентыктагы иң әйбәт хикәяләрнең берсе. Кәраметдин Солтановның «Бөркет булсаң да», Амәт Шаһморатовның «Юлбарыс белән очрашу» исемле хикәяләре дә әлеге хикәягә якын торалар. Бу төр хикәяләрдә батырлыкка, киң күңеллелеккә мәдхия җырлау, ә явызлыкка, комсызлыкка нәфрәт уяту хас.

Җыентыкта урнаштырылган проза әсәрләре, гомумән, укучыны кызыксындырмый калмыйлар. Башта әйткәнебезчә, аларның бер өлеше революциягә кадәр, икенчеләре бүгенге көннәрдә барган вакыйгаларга нигезләнеп язылганнар. Һәркайсы безнең өчен яңа һәм истә калырлык. Чөнки аларда көрәш, хезмәт, мәхәббәт, гаилә, әхлак кебек һәрвакыт актуаль булып торган мәсьәләләр яктыртыла.

Җыентыктагы әсәрләр барысы да бер үк дәрәҗәдә, бер үк югарылыкта тора, дип тә әйтә алмыйбыз. Хәер, һәр әдәбиятта, һәр әдип иҗатында шулай инде ул — иҗат процессындагы табигый күренеш. Мисал өчен, бер үк темага язылган, бердәй үк сюжетка корылган өч хикәягә игътибар итик. Алар — Мәмбәтали Каиповның «Үз каным», Алпышбай Солтановның «Фоторәсем» һәм Алмания Азизовның «Без әле очрашырбыз» исемле хикәяләре. Өчесендә дә зур тормыш дәрьясында яңарак кына колач җәеп йөзә башлаган яшьләр... Беренче күрешү-танышуларда ук гашыйк булулар, мәхәббәт ялкынында янулар һәм өйләнешүләр. Һәр өч егет тиздән армия хезмәтенә алыналар... «Үз каным»дагы Амангилде сөекле Айгөле белән нибары ике ай гына бергә яшәп кала, ә «Фоторәсем»дәге шофер егет белән Гөлзарның беренче бәбиләре дә була инде. Шофер егет белән Амангилде өйләренә кайталар. Егет — хезмәт срогын тутырып, Амангилде — кыска сроклы ялга. Ә «Без әле очрашырбыз»дагы Булатның эше Гөлзибә белән якын мөнәсәбәтләргә барып җиткән булса да, ул әле рәсми өйләнмәгән килеш армиягә китеп барырга мәҗбүр.

Башта санаган ике хикәядәге ике егетебезне өйләрендә гаилә бәхете түгел, ә кайгы-хәсрәт көтеп торган икән. Һәр ике ситуация аяныч та, сәер-серле дә, чөнки Амангилденең Айгөле дә, шоферның Гөлзары да өйдә юк — ташлап китеп барганнар. Гөлзар баласын да үзе белән алып киткән. Нәрсә булган монда дип өзгәләнә егет... Ә Амангилденең әнисе кулында... яшь бәби! Оныгы белән шатланып мәж килә ул. «Мә, балаңны иркәлә әзрәк, ди аңа әнисе. Баланы кулына алган Амангилде аптыраша: «Тукта, кемнән бу — вакытсыз туган бала?..» Шулай итеп, һәр ике егетебез аңлаешсыз сораулар алдында төртелеп калалар.

Бу сорауларга беркадәр җавап бирү өчен, мәхәббәт вакыйгаларының ничек башланып китүен, ничек дәвам итүен күзәтик. Хикәяләр агышыннан аңлашыла: Амангилде — яңа гына урта мәктәпне тәмамлаган тәҗрибәсез яшь егет, ул алдан уйланылган мәкерле хәйлә тозагына килеп капкан.

Ярый, бик шартлы рәвештә генә фараз итик: Амангилде белән Айгөл бер-берена тиң булып чыкмадылар, ди. Амангилденең кыска вакытлы ялга кайтуы сәбәбе дә шул: өзелеп сагынудан нишләргә белмәгән солдат көн саен хат яза, ә Айгөл ләм-мим! Нибары бер хат яза ул, анысы да бик коры, хәтта үртәүле әле: «хатларың белән туйдырып бетердең мине...». Солдатның бөтенләй рухы сына. Мондый хәлне взвод командиры да борчылып күзәтә һәм аңлашып килү өчен кыска вакытлы ял бирдерә.

Ә менә икенче хикәядәге егет белән Гөлзар вакыйгасын ничек аңларга? Берсе әйбәт шофер, икенчесе ерактагы совхоз фермасында эшли. Ни җитмәгән тагын аларга? Бер-берен яратып, саф мәхәббәт нәтиҗәсендә гаилә корып җибәрделәр бит алар һәм беренче балалы булу бәхетенә дә ирештеләр инде. Бу хикәя үзара аңлашу белән тәмамланса да, укучыда, гомумән алганда, канәгатьсезлек хисе туа. Чөнки ике араның

бозылу сәбәбе — бер фоторәсем генә. Ә аның тарихы шушыннан гыйбарәт: бер хатында әнисе: «Сине бик сагындым улым, бер карточкаңны җибәрмәссеңме?» — дигәч, егет дуслары белән бергә төшкән фоторәсемне җибәрә. Очраклы рәвештә Мария исемле бер кыз белән танышкан була ул. Кызның туган көненә багышланган мәҗлестә дуслары белән бергә ул да катнаша. Егет әнисенең хатына җавап итеп, шундый бер очрашуда төшкән фоторәсемне җибәргән икән... Ә Гөлзарга, аерылып китү өчен, әллә нинди ят кызлар белән бергә төшкән әлеге фоторәсем җитә кала...

Егет кайткач та фермага, Гөлзар янына чаба. Гөлзарның кире кайтуына хәтта егетнең әнисе дә бик үк ышанып җитми. Ләкин мәсьәлә бик җиңел хәл ителә: егетнең үзе генә кайткан булуын күргәч, алар килешәләр. Уллары Марат белән өчәү бергә өйгә кайтып керәләр.

Бик йөгерек язылган кыска гына бу хикәядә ашыгычлык үзен сиздерми калмый. Тормышта моңа охшаш, «маҗаралы мәхәббәт романнары» да булуы ихтимал. Әмма андый катлаулы-сикәлтәле вакыйгаларны бик кыска хикәя (нибары 7 бит) үз эченә һич тә сыйдыра алмый... Алтынбай Солтанов — соңгы елларда гына да дүрт китап бастырып чыгарган, югары белемле, тәҗрибәле автор, дип тәкъдим ителә кыска биографиядә. Димәк, бу җыентык өчен аның мул иҗатыннан бик үк уңышлы әсәр сайланып алынмаган.

«Үз каным» шулай ук, зур хикәя түгел — 10 бит кенә. Ләкин ул укучының игътибарын тик бер мәсьәләгә — тормышның Амангилде белән усал шаяруына юнәлтә. Тормыш аның кем икәнлеген сыный... Кулындагы бәби кемнән? — шул уй аңа тынгылык бирми.

Башта авыр хисләр тудыра торган бу хикәя, шулай да, оптимистик тәгәлләнә. Амангилденең әнисе үзенең беренче оныгы булуга бик шатлана, егет үзе дә балага тартыла, үз итә башлый. Ул Айгөленең ташлап китүен дә гафу итү кебек югарылыкка күтәрелә. Хикәя дәвамында Амангилде уй-хисләренең, кичерешләренең психологик осталык белән һәм ышандырырлык итеп, төгәл сүзләр белән тирән мәгънәле итеп сөйләп бирелүе укучыда да эчке бер җылылык тудыра.

Инде Аманияз Азизовның кыска гына, шома гына язылган «Без әле очрашырбыз» исемле хикәясе турында. Ул да берникадәр канәгатьсезлек тойгысы калдыра, тик социаль планда. Булат белән Гөлзибә — капма-каршы идеал белән яшәүче ике гаилә балалары, ике төрле тәрбияләнгән яшьләр. Булатның әтисе Сабир Әхмәтов — җаваплы урыннардагы фидакарь хезмәте белән бөтен республикага танылган карт коммунист, хәзер инде лаеклы ялда. Гөлзибәнең әтисе Сәли Сәлиевич — югары учреждениеләрнең берсендә җитәкче булуга үрмәләгән һәм кыек эшләре белән череп баеган бер паразит. Булат мәктәпне тәмамлагач та, әтисенең бик акыллы киңәшен тыңлап, шәһәр элемтә челтәренә ярдәмче монтер булып урнаша. Ә иркә Гөлзибә мәктәпне ничек бетергәндер — билгесез, тик әтисе Ташкенттагы мединститутта эшләүче бер әшнәсе ярдәме белән аның студент булуына ирешә. Монда да кызның укуга әллә ни дәрте булмый. Ә каникулда студентлар белән бергә мамык җыю эшенә җибәреләчәген белгәч, әтисе аны үз янына чакыртып ала. Нәтиҗәдә — кызны институттан чыгаралар. Һәм Гөлзибәнең белем алуы шуның белән тәгәлләнә дә...

Булат бер дустының туган көн мәҗлесендә Гөлзибә белән таныша. Егетебез аңа тәмам гашыйк була. Аларның шаккатырырлык бай тормышта яшәүләренә гаҗәпләнә Булат. Үзләренең тыйнак яшәүләре белән чагыштыра, уйга кала. Әмма Гөлзибәнең чибәрлеге аны әсир итә, буйсындыра. Кызның әти-әниләре курортта икән. Икәү генә утырып еш кына сыйланалар алар. Шунда кунып та калгалый егет. Әтисе исә, моны сизеп алгач, бик тузына. Чөнки алар күптәнге танышлар икән. Элекке елларда әлеге Сәли Сәлиевич зур гына бер урын биләгән булган, шунда үз файдасына төрле махинацияләр эшләгән. Аның шундый җинаятьләрен тикшерү эше ул елларда халык контролендә эшләгән Әхмәтовка тапшырыла. Нәтиҗәдә, Сәлиевич урыннан алып ташлана. Шуннан соң күп еллар үткән. Бактың исә — ул яңадан зур түрә! Димәк, аның яклаучылары, «ярдәмчеләре» табылган! Хәзер ул пенсионер Әхмәтов кебекләр алдында да күкрәген киереп йөри... Кызын да алар белән аралашудан тыя... Ә Булат? Юк, аның Гөлзибәгә мәхәббәте тамчы да кимеми, сүнми. «Үтердең, пычаксыз суйдың... — ди әтисе улына. — Әнкәсе, әнә таң атып киләме? Шушы бүгенге таңнан башлап безнең тормышыбыз кыяматкә әйләнәчәк...»

Хикәядә иң борчыганы — Булатның үзен тотышы, «фәлсәфәсе». Гөлзибә белән очраша алмыйча армия хезмәтенә китеп бара ул. Поездда болай уйлана: «Инде менә йөрәк януына дәва таба алмаган килеш китеп барам. Әгәр дә мине чынлап яраткан булса, әтиләребезне аерган сукмакка гөлләр үстерә алмас идекмени? Чын мәхәббәт әллә нинди сукмакларны да кушарга сәләтле ләбаса...» Бу — ут белән суны бергә кушарга хыяллану түгелме соң? Тик шулай да, Булатның большевик әтисе башлаган тәрбияне Совет армиясе дәвам итәр диган ышаныч безне беркадәр тынычландыра...

Җыентыкта кыскартылып басылган хикәя, повестьлар турында да берничә сүз әйтәсе килә. Мирзагали Дәрибаевның «Мәңнәрдән берсе». Революцион көрәш елларын, төрле каршылыклы вакыйгаларны, образларны художество чаралары белән киң күләмдә тасвирлый башлаган автор, кызганычка каршы, бу әһәмиятле повестен тәмамлый алмыйча вафат булган.

Шәудербай Сәетовның «Качак» дип аталган өзегендә киң дала, аның кырыс табигате, кешеләрнең бер-береннән үч алу өчен куу-чабышулары, бәрелешләр, кемнең нәрсәгә омтылуы, үтереш-кырылышлар һ. б. кебек күз алдыннан китми торган хәтәр куркыныч вакыйгалар бик тә җитәрлек, әмма аларның гомуми бөтенлеген, нәрсәнең нәрсә белән очлануын чамалау укучы өчен авыррак булып кала. Сәфәрбай Сәлиевның алда инде телгә алынган «Дошман» исемле өзегендә дә төп герой Мулланәпәснең чын йөзе ачылмый кала кебек. Ярый, ул карт белән кызны елга аша иреккә качырып җибәрде — бу аның чын йөзен күпмедер ачуга ишарә итә сыман. Әмма — аз бу! Чөнки үзе һаман шул бичара әсирләрнең явыз дошманы булып калуында дәвам итә бит. Аның ахыргы язмышы да ачыграк күрсәтелергә тиеш иде кебек.

Проза турында сөйләгәндә, сүзне Түләпбиргән Каипбиргәновтан башларга кирәк иде. Ә мин аны аңлы рәвештә ахырга калдырдым. Каипбиргәнов — республиканың иң зур прозаикларыннан берсе. Күп санлы хикәя, повесть, романнар авторы. Ул Үзбәкстанның Хәмзә, Каракалпакстанның Бердах исемендәге премияләре лауреаты, республиканың халык язучысы.

Тик бу җыентыкка Каипбиргәнов хикәя дә, повесть та түгел, ә «Үз-үзем турында» дигән автобиографик язмалар тәкъдим иткән. Үткән тормыш юлы турындагы тирән уйланулары белән дә, шулай ук хикәяләү формасы белән дә җыентыкта урнаштырылган күп кенә проза әсәрләреннән аерылып тора бу язмалар. Әдип тормышка, тарихка, әдәбиятка, иҗат эшенә кагылышлы мәсьәләләр турында сүз йөртә. Үз халкының бүгенгесе дә, тарихы да нык кызыксындыра аны. Шулай да ул — үзенең киң полотнолы тарихи әсәрләре белән аеруча танылган язучы. Бу турыда ул үзе: «Тарихи роман язу — җир куенынннан бүгенге һәм киләчәк буыннар өчен файдалы байлыклар эзләүгә охшаш хезмәт»,— дигән иде. Үзбәкстанның халык шагыйре Камил Яшен исә, бу фикерне дәвам итеп, болай ди: «Үз халкының уйларын, хыялларын, омтылышларын гәүдәләндереп, — ә Каипбиргәновның таланты нәкъ шул ягы белән көчле, — ул күп кенә бүтән халыкларның да уй һәм омтылышларын гәүдәләндерүче булды»[1].

Әдипнең тирән фикерләре... Әдәби остазлары — Толстой, Чехов, Достоевский, Шолохов турында уйланулары... Гомумән, бу йөгерек язмаларда китерелгән кызыклы фактлар, аңгәмәләр, бәхәсләр, легендалар һ. б. — болар барысы бергә чын әдәби әсәр булып тора дияр идем. Мин аны берничә тапкыр укып чыктым, укыган саен үзем өчен кыйммәтле яңалыклар ача бардым. Совет халкының аерылмас бер өлеше булган үз халкының үткәне; бүгенгесе, киләчәге белән рухланып яшәүче, әнә шул чыганаклардан бай рухи азык алучы әдипнең иҗаты чын мәгънәсендә сокландырды мине.

Әйе, каракалпак дусларыбызның бай иҗаты безнең күз алдыбызда. Ул әле тагын да үсәр, совет халыкларының тугандаш әдәбиятлары гаиләсендә тагын да гөрләбрәк чәчәк атар. Ышанам!

---

[1] Бу ике өзек К. Степанян мәкаләсеннән китерелә — «Литературная газета», 29 июль, 1981 ел

Рафаэль Мостафин

# «ШАГЫЙРЬ КОМПОЗИТОР БУЛЫРГА ТИЕШ...»

«Шагыйрь композитор булырга тиеш,— ди Һади Такташ үзенең «Иҗадиятем турында» (1923) исемле шигъри манифестында.— Ул яза башлаудан әүвәл үзенең халәте рухиясенең музыкасын табып, шигыренә шул музыканы кушып язарга һәм аның шигыренең нинди халәте рухия вакытында язылганлыгы аңкып торырга тиеш» [1].

Бу сүзләрне ничек аңларга? Бары шигъри сөйләмнең музыкальлегенә өндәү дип кенәме? Алай уйласаң, бераз гына алдарак шагыйрь үзе үк традицион силлабик шигырьнең «көйлелегеннән» баш тартырга чакырган бит: «Иске өслүбтә иң алда тотылган такмаклап язу юлы бетәргә, аның урынына «тон» белән «сөйләп» язу юлы кертелергә тиеш» [2].

Шулай итеп, автор, бер яктан, сөйләм теленең гадилегенә һәм табигыйлегенә чакыра, икенче яктан, шагыйрь бер үк вакытта композитор да булсын, үз иҗатында музыка законнарына да таянсын, ди. Капма-каршы характердагы мондый фикерләрне ничек бергә бәйләргә?

Һ. Такташның шигырь төзелеше өлкәсендә мәшһүр реформатор булуы — мәгълүм нәрсә. Безнең шигърияттә «гарәп арузы»на нигезләнгән көйле шигырьдән халыкчан шигырьгә, «тон» белән «сөйләп» язуы юлына, җанлы сөйләм интонацияләренә корылган шигырьгә кискен борылыш ясау аның исеме белән бәйләнгән.

Шагыйрь композитор да булырга тиеш дигәндә, Такташ «җан, күңел музыкасын», башкача әйткәндә, шагыйрьнең үз-үзен, үз рухи халәтен, үз эмоциональ хәлен тулырак чагылдыруны күз уңында тоткан, дигән фикер яши. Чыннан да, Такташ шигыре эмоциональ яктан искиткеч бай эчтәлекле булып, ул автор күңелендәге рухи халәтнең иң нечкә төсмерләрен (шатлык, кайгы, моңсулык, мәхәббәт, нәфрәт һ. б. ш.) белдерә. Әмма шулай да Такташның тезисы бер «күңел музыкасы»н гына күздә тотмый.

Шигърият өлкәсендә Такташ — чын композитор, чын реформатор була. Ул шигырьләрендә, һәм бигрәк тә поэмаларында, контрапункт, рефреннардан, төп «мелодия» белән үрелеп барган «музыкаль темалар»ның үзара чиратлашып килүеннән киң файдалана, башкача әйткәндә, үз иҗатында симфонизм принципларына нык таяна. Заманында моңа «Музалар туганлыгы» исемле мәкаләсендә әдәбият белгече Н. Юзиев та игътибар иткән иде (дөрес, ул бу фикерен ачып, конкретлаштырып тормады).

Симфонизм принцибы дигәндә нәрсә күз алдында тотылганын ачыграк аңлау өчен, Такташның аеруча нык танылган һәм сәнгатьчә камил әсәрләренең берсе булган «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927) поэмасына мөрәҗәгать итик. «Мәхәббәт тәүбәсе» — мәхәббәт турындагы поэма. Асылы белән буржуаз характерда булган «яңача мәхәббәт»,

[1] Һ. Такташ. Пьесалар, хикәяләр, мәкаләләр. Казан, 1953, 227 бит.
[2] Шунда ук.

«ирекле сөю» кебек «теорияләр» яшьләр арасында киң таралу сәбәпле, егерменче елларның урталарында һәм икенче яртысында әлеге мәңгелек тема ифрат дәрәҗәдә актуаль бер төс ала. Чөнки «яңача мәхәббәт», «ирекле сөю» дигәннәре еш кына гаилә каршындагы җаваплылыктан, ата һәм ана өстенә төшкән вазифалардан азат, ирекле булу төсендә аңлатыла. Үз вакытында Һ. Такташ поэмасы — яшьләрдә коммунистик әхлак нормалары тәрбияләүдә булсын, модага кереп барган әлеге «теорияләрне» фаш итүдә булсын — искиткеч зур роль уйный.

Аннан бирле ярты гасырдан артык вакыт узды. Ә «Мәхәббәт тәүбәсе» укучының күңеленә бүген дә бик якын. Ул масштаблыгы ягыннан тар мәгънәдәге актуальлектән күп өстен тора — популярлыкның сере әнә шунда булса кирәк. Зөбәйдә белән Мәхмүтнең мәхәббәт тарихы мисалында шагыйрь зур фәлсәфи мәсьәләләр кузгата, әхлакның гасырлар буена килгән мәңгелек нормалары хакында уйлана. Иң мөһиме тагын шунда, моны ул искиткеч тәэсир көченә ия булган югары сәнгать чаралары ярдәмендә хәл итә, нәтиҗәдә поэма геройларының хисләре Шекспирча тирәнрәк һәм күп мәгънәлелек төсмерен ала. Бүгенге шагыйрьләргә Такташтан күп нәрсәгә өйрәнергә мөмкин.

Поэманың композициясенә генә мөрәҗәгать итеп карыйк. «Мәхәббәт тәүбәсе» керештән һәм җыйнак-җыйнак җиде бүлекчәдән тора. Фикернең колачы ягыннан никадәрле генә масштаблы булып тоелмасын, поэма бик тә җайлы, нибары 375 юлдан гыйбарәт, бу — бүгенге татар поэмаларының уртача күләменнән берничә тапкырга кыскарак дигән сүз. Поэманың керешен үзенә күрә музыкаль әсәрнең увертюрасы дип карарга мөмкин. Монда поэманың төп темасы — гомернең фанилыгы яшьлекнең кабатланмас гүзәллеге билгеләп узыла, кыска һәм кабатланмас булганы өчен дә яшьлекнең кадерен белергә кирәк, ди шагыйрь:

**Яшьлек,**
**Гомерең кыска синең,**
**Шундый кыска булып тоела,**
**Кичен чәчәк аткан була,**
**Ә таңында инде коела...**

Буйдан-буйга сузылып килгән әлеге сурәтле фикер әсәрнең лирик линиясе — шагыйрьнең үз яшьлеген, үз мәхәббәтен искә төшерүләре белән («Янган яшьлек, үткән мәхәббәтләр алар мәңге миндә терелмәс») тыгыз үрелеп бара. Автор лиризмны, әсәрдәге киеренкелекне киметеп, укучы хыялындагы куркынычны «йомшарта» торган җылы юмор белән чиратлаштырып бара («Гакыл башлык булгәң көннән алып, көнтөн елый мескен йөрәгем; һәр көн ызгыш, һәр көн йөрәгемә гакыл-башлык бирә кирәген...») Шул рәвешчә, кереш-увертюрада әсәрнең төп яңгырашы, поэмадагы мелодик сурәтнең төп үзенчәлекләре билгеләнгән.

Шунысы кызык, авторның үз сүзләренә карагандә, кереш иң ахырдан, поэманың төп кисәкләре язылып беткәннән соң язылган. Димәк, ул әсәргә нидер җитмәвен сизенгән, поэмада сурәтләнгән вакыйгаларга карата шәхси мөнәсәбәтен белдерү кирәклеген аңлаган. Поэманың беренче строфасы, музыкаль камертон кебек, әсәргә тон бирә һәм, лейтмотив буларак, өч тапкыр кабатланып, бөтен поэма буйлап сузыла. Беренче тапкыр кабатланганда, бераз моңсулык төсмере булса да, ул тыныч хикәяләү тонында яңгырый. Икенче тапкырында эмоциональ киеренкелек нык көчәя, чөнки ул сүзләр инде авторның үзенә дә кагыла:

**Их син, яшьлек,**
**Их син, тиле яшьлек!**
**Шундый кыска булып тоелдың,**
**Кичен чәчәк аткан булдың,**
**Ә таңында...**
**Ә таңында инде коелдың...**

Эмоциональ киеренкелек кабатлаулар һәм эндәш сүзләр ярдәмендә дә, шагыйрьнең үз-үзенә мөрәҗәгать итүләре белән дә («тоела», «була», «коела» кебек битараф

сүзләр урынына «тоелдың», «булдың», «коелдың» шикелле сүзләр куллану) көчәйтелә. Өченче тапкырында әлеге строфа «үзе сөйгән, үзе көчләнгән» Зөбәйдәгә мөнәсәбәттә кулланыла, шуңа күрә ул юлларда бәгырьне телгәли торган ачы әрнү яңгырый. Һ. Такташ рефреннары, кабатланган саен, яңа яңгыраш ала баралар, аның әсәрләренә хас үзенчәлекләрнең берсе әнә шунда. Шагыйрь иҗатын тикшерүче Х. Госман дөрес билгеләп үткәнчә, Такташ рефреннары градация тәртибендә, ягъни лирик хиснең үсә-көчәя бару (яки сирәк кенә кими баруы) рәвешендә урнашалар (Х. Госман. Егерменче елларда татар поэзиясе. Казан, КДУ нәшрияты, 1964 ел).

Поэманың төп өлеше драматик жанр законнарына нигезләнеп язылган. Әсәрдә төенләнеш тә («Ул бер наборщикны ярата»), вакыйганың үстерелеше дә, героиняның хисләр киеренкелеге иң югары ноктасына җиткән бер мизгелдә кульминация дә һәм, ниһаять, чишелеш тә бар («Алар килештеләр, ә биш көннән загс белән тормыш башланды»).

Поэманың үзенчәлеге шунда: әсәрнең төп сюжет сызыгы күп төрле чигенүләр, беренче карашка төп сюжет сызыгы белән бәйләнмәгән кебек күренгән, әмма ләкин авторның төп фикерен ачыклауга хезмәт итүче ярдәмчел темалар белән чиратлашып үрелеп бара. Әйтик, беренче бүлекчә үк лирик характердагы чигенү белән башлана:

> Кайчак шулай бер-бер иптәшеңдә
> Утырып сөйләшер сүз тапмыйсың.
> Өстәленнән альбом кебеген алып,
> Рәсемнәрен мактый башлыйсың.

Чит кеше альбомындагы рәсем турында бу чигенү керештәге лирик сызыктан Зөбәйдә белән Мәхмүтнең мәхәббәте хакындагы хикәягә «күпер салу» өчен кирәк. Беренче бүлекчә параллелизм принцибына корылган: башта билгесез бер матурның рәсеме хакындагы хикәя китерелә, аннары хикәяләүченең альбомындагы Зөбәйдә рәсеменә күчәбез. Шул чак кызыклы бер хәл барлыкка килә. Автор Зөбәйдәнең портреты хакында берни әйтмәсә дә, билгесез матурга караган детальне — «Кара болыт кебек түзган чәчләр хыялыңа кереп чормала» — укучы, үзе дә сизмәстән, Зөбәйдә портретына күчереп куя. Шул рәвешчә, әлеге рәсем «күпер» хезмәтен генә үтәп калмый, төп героиняның портретын тудырырга да булыша.

Башта хикәяләү тыныч, җиңелчә ирония (барыннан да элек авторның үз-үзенә булган мөнәсәбәтендә) һәм хәзергә әле артык көчле булмаган моңсулык белән еретелгән салмак тонда ага. Керештә үк башланган фәлсәфи тема дәвам итә, үстерелә. Логик төстә, автор фикеренең яңадан-яңа кырларын ачу төсендә генә түгел, ә бәлки образлы, интонацион, музыкаль төстә дә үстерелә: «Мәхәббәт тә — нәфис матур чәчәк, ләкин үзе гаҗәп гомерсез. Кайчак загс белән соңы бетә, Ә кайчакта яхшук күңелсез...»

Күрәсез, монда шул ук гүзәл сулучан традицион чәчәк образы кулланылган. Образның халык иҗатындагы мәгънәсенә таянып («Тиңләр идем сине гөлгә, гөлнең гомере аз гына» дигән җыр, мәсәлән), симфоник әсәрдәге музыкаль тема кебек, автор аны үзгәртә һәм үстерә бара. Китерелгән строфаның синтаксик төзелеше, аның интонацион сурәте, мелодикасы үзе аерым турындагы төп рефрен белән турыдан-туры аваздаш яңгырый. Әмма «соңы кайчак загс белән бетә, ә кайчакта яхшук күңелсез» дигән сүзләрдә инде алда булачак драматик хәлләргә ишарә бар. Беренче бүлекчәдә барлыгы 46 юл шигырь булып, шуларның 6сы гына турыдан-туры поэма геройларына карый. Тик авторның уйлануы темага фәлсәфи яктан яктылык нуры сибә, ул нурлар әсәрдәге төп геройларның образларын да яктыртмый калмый, билгеле.

Үзенә кадәр язылган эпик әсәрләрдән аермалы буларак, Такташ, вакыйгаларны эзмә-эз тасвирлап барудан катгый баш тартып, гүя күзгә ташланып торган «буяулар» белән генә эш итә. Детальләштерүдән качып, шагыйрь укучы хыялына киң мәйдан калдыра. Берничә юл шигырь белән чикләнә:

> Сандугачлы таңнар,
> Зур урманнар
> Аның гыйшкын бизи алмады,

Язгы зәңгәр күкнең йолдызлары
Матурланып күктә янмады...
Аның гыйшкы күзен чәчәк атты
Эштә,
Собраниедә,
Урамда.
Күңел язы шаулап үтте аның
Тәңкә карлар яуган буранда...

Күрәсез, автор хәтта төп геройның һөнәрен, эш урынын да әйтми (ул, күрәсең, Мәхмүт белән бергә типография тирәсендә эшлидер). Әмма сөйләм югарыда китерелгән юлларда күпмәгънәле. Аңардагы берничә катламны аерып күрсәтергә була: хәзер генә карап узган мәгънә йөгеннән тыш, мәхәббәтне матур табигать кочагында гына сурәтләргә яраткан язучылар белән яшерен бәхәс төсмере дә бар. Автор арзанлы шигърият белән дә, укучының кабул итү рәвешендәге шаблонлык белән дә һәм, ниһаять, үз-үзе белән дә бәхәсләшә. Тагын да төгәлрәк итеп әйткәндә, реалист Такташ монда «Урман кызы»н язган дәвердәге романтик Такташтан яшертен генә көлә.

Шуның белән бергә, тышкы яктан күпме генә көлмәсен, сандугачлы таңнар, язгы зәңгәр күк, якты йолдызлар кебек сурәтләр, образлы параллелизм законнары нигезендә, Зөбәйдә образына һәм аның мәхәббәт тарихына да үзенең поэтик яктысын сирпи. Мәсәлән, «Аклы ситсы күлмәгемнең табалмадым ишләрен...» дип җырлаганда, аклы ситсы күлмәк образы безнең күңелдә Рәйхан образын да шигърилəштерә. Тыштан Такташ үз героеның эштә, җыелышта чәчәк аткан мәхәббәтен «прозалаштыра». Ләкин шунда ук әлеге саф һәм фидакарь мәхәббәт хакында теләсә нинди матур сүзләргә караганда күп тапкыр көчлерәк яңгырый торган яңа, көчле шигъри сурәт тудыра: «Күңел язы шаулап үтте аның тәңкә карлар яуган буранда...»

Героиняны читләтеп характерлаучы деталь буларак, тәңкә карлар темасы бөтен поэма буена сузыла. Ул — хисләрнең сафлыгы, пакьлеге символы. Әлеге образ (югарыда китерелгән мисалдагы кебек), әле ассоциация, әле контраст рәвешендә килеп керә. Мәсәлән: «Бүлмә уты сүнгән, алар икәү төнге караңгыда калганнар... Төн караңгы булган... төн буенча аппак карлар җиргә яуганнар...»

Автор караңгылык турында хәбәр итү белән генә чикләнеп калмый, ахырдан кискен һәм ачык «буяулар», читләтелгән юл белән Зөбәйдә образын характерлый торган тәңкә карлар күренешен бирү өчен, ул турыдан-туры укучыда караңгылыкны тою хисен арттыра бара (юл башында «төн» сүзен рәттән өч тапкыр кабатлау да шуның өчен кирәк). Әле «тәңкә карлар», әле «аппак карлар» дип, я булмаса буран яки кар дип кенә алып, автор образны гел төрләндерә тора, ахырга җиткәндә, героиня күңелендә сүнәр-сүнмәс өмет уты кабынгач, образ да үзгәрә: «Тышта соңгы карлар ява, алар инде кышкы карлар кебек туңмыйлар».

Шул кадәресен дә әйтергә кирәк, «тәңкә карлар» — матур бер чагыштыру гына түгел, ә бәлки поэманың үзенә күрә музыкаль лейтмотивы да. Башта Такташ поэмасын «Кышкы карлар» дип атарга уйлаган, аның бу образга нинди зур әһәмият бирүен шуннан да чамаларга була. Бу исем безнең алда образның тагын бер ягына яктылык нуры сирпи. Сүз кышкы салкын турында бара. Зөбәйдәнең мәхәббәте берьяклы, җавапсыз мәхәббәт — аның фаҗигасе беренче чиратта әнә шунда. Мәхмүт йөрәге баштан ук мәхәббәткә салкын кала, бары тик соңрак кына салкынлык бераз «эри» башлый.

Зөбәйдә һәм Мәхмүт линиясе белән янәшә бөтен поэма буена кызыл җеп булып, лирик линия сузылып бара. Без даими тоста янәшәдә генә авторның булуын тоеп барабыз, ул читтән торып гади хикәяләүче генә түгел, ә бәлки Зөбәйдәнең язмышын үз күңеле аша кичерә торган, актив һәм кызыксынучан шәхес. Поэмадагы ихлас лиризмны әнә шул тудыра да инде. Хикәяләүче-автор әле үз яшьлеге, үз мәхәббәте белән мавыгып китә («Җырланган җыр кебек, яшьлек таңым шаулап үтте... шаулап үтте инде гомергә...»), әле турыдан-туры вакыйгалар агышына катнашып китә: «Зөбәйдә, бар бүген собраниегә...»; «Зөбәйдә, бар бүген театрга...»; «Зөбәйдә, син бармә театрга, йөрмә, бәгърем, аның артыннан...» (Киңәшләрнең капма-каршы характерда

булуында герой күңелендә барган каршылыкларның катлаулы бәрелеше дә чагылыш таба).

Икенче бер очракта автор үз уй-фикерләрен истә калырлык образлар, күпсыйдырышлы формалар ярдәмендә турыдан-туры да белдерә: «Ана — бөек исем, нәрсә җитә ана булуга; хатыннарның бөтен матурлыгы, бөтен күрке ана булуда...»

Сүз җаеннан шул кадәресен дә әйтеп китәргә кирәк, әлеге юллар шагыйрь үзе исән вакытта ук башланып, ул үлгәннән соң да дәвам иткән төрле һөҗүмнәр, тәнкыйть фикерләре өчен нигез булып кала. Хәтта Такташның иҗат мирасына карата хәер-хак кешеләр дә (әйтик, үзенең «Һади Такташ поэзиясе» исемле хезмәтендә Ш. Маннур) шагыйрь совет хатын-кызларының иҗтимагый тормыштагы рольләрен бәяләп җиткерми, Такташ ялгыша дип санадылар. Әмма бу аңлашылмаучылык авторның әлеге сүзләрен контексттан аерып карау нәтиҗәсендә килеп чыга. Ул сүзләр бит «кан эчендә яткан» Зөбәйдәне юату, аның күңелен күтәрү өчен әйтелә. Аның хәлен автор шактый ачык итеп сурәтли: «Нигә авыр болай?.. Күз аллары шундый караңгы»... Ана булу барлык газаплардан, бөтен авырлыклардан өстен булуын исенә төшереп, автор Зөбәйдәне юата, аның авыр хәлен, кайгысын уртаклаша. Ә хатын-кызның иҗтимагый роле хакында исә Такташ публицистик чыгышларында да, күп кенә шигъри әсәрләрендә дә (мәсәлән, «Алсу» поэмасында) бик ачык итеп әйтә.

«Мәхәббәт тәүбәсе»ндәге чигенешләр хакында күп сөйләнгән, күп язылган. Билгеле, Такташның кыю новатор булуы һәркем тарафыннан да җиңел генә кабул ителми. Күпләргә шагыйрь төп максатыннан, төп бурычларыннан читләшә кебек тоела. Поэмадагы ай, җил, хуҗасыз песи балалары турындагы өлешләрне алар шундый читләшү дип аңлата. Хәлбуки, әлеге чигенүләр төп теманы ачарга хезмәт итә — алар әсәрнең драматизмын киметмиләр генә түгел, киресенчә, арттыралар, көчәйтәләр. Әйтик, Зөбәйдәнең алдану күренешеннән соң автор укучы каршына менә мондый чигенү күренеше китереп бастыра:

> Ул төнне ай күктә эш тапмыйча,
> Эче пошып сүгенеп йөргән,
> Ул төнне Әүхәди юлга чыгып,
> Кире кайткан куркып бүредән...
> Шушы төнне Гыймади, эт өрсә дә,
> Тәмле йокысыннан тормаган,
> Шәкүр карак аның abзарыннан
> Күк айгырын кереп урлаган...

Бер уйласаң, поэмада башка бер тапкыр да күренми торган Әүхәди белән Гыймадиның монда ни катнашы бар? Яки күк айгырны урлаган Шәкүр каракның?.. Хикмәт шунда, бу ишарәләр аша шагыйрь әлеге шомлы һәм куркыныч төндә героиня күңелендә купкан хисләр давылын аңлатырга тели. Бу музыкаль чигенеш, хәвефле, шомлы образларның (төн, бураң, тынычсызланып өргән этләр һ. б.) какофониясе аша шагыйрь монда төп нәрсәне — хәвефне, бу төнне эшләгән эшне сиздерергә тели.

Укучы игътибарын тагын бер төгәлсезлеккә юнәлтәсе килә. Алда шагыйрь төне буе җиргә «ап-ак карлар яуганнар» дип, ягъни төн караңгы, күк болытлы булган, дип язган иде. Шунда ук «күктә эш тапмыйча, эче пошып сүгенеп йөргән» ай турында яза. Боларның берсе икенчесен инкарь итә кебек. Әмма поэмада ай коры бер пейзаж детале генә түгел. Ул — ялгызлык символы: Зөбәйдәнең күңелен киләчәктә ялгыз калу кебек куркыныч уйлар телгәли башлау белән, поэмага ялгыз ай образы килеп керә. Дөресрәге, символ гына да түгел, ә үзендә ялгызлыкны гәүдәләндергән, юри кечерәйтелгән, беркадәр дәрәҗәдә комик образ. Аны Такташ шулай ук халыкның образлы фикерләү үзенчәлегенә таянып иҗат итә («Сагынганда айга карыйм, ай да ялгыз минем күк»), тик аны үзгәртә, яңа эчтәлек белән баета. Аның ае — эч пошудан, эшсезлектән һәм ялгызлыктан күктә сүгенеп йөри торган тол ир. Автор үзе кайчандыр хатынсыз ай образы миңа комик фон өчен кирәк, дип язган. Ләкин бу образның роле һич кенә дә фон булу, вакыйганың киеренкелеген йомшартып, укучы хыялына күпмедер ял бирү белән генә чикләнми. Хатынсыз ай башыннан узган газапмихнәтләрне күзәтә торгач, без, ирексездән, Зөбәйдәне көткән шыксыз ялгызлык ту-

рында уйлый башлыйбыз. Шулай итеп, автор безнең хыялга уйланыр «азык» бирә, аны тиешле юнәлешкә кертеп җибәрә.

Поэманың иң ахырында ялгыз ай образы тагын килеп керә, бу юлы инде контрастлык законы буенча килеп керә. Гашыйклар кавышып бәхетле була, ай гына элеккечә үк хәсрәт эчендә ялгызы кала. Мәгълүм булганча, Такташ башта поэмасын алда китерелгән юллар белән тәмамларга уйлаган: язгы табигать гөр килә, геройлар бәхет кочагында йөзә. Күрәсең, андый тәмамланмыш артык төче, сентименталь булып тоелгандыр, һәм поэманы ул шаян тонда бетереп куя. Моның зур гомумиләштерү көченә ия булган үз мәгънәсе бар: Зөбәйдә бәхеткә иреште ирешүен, тик мәхәббәт драмалары һәрчак болай бәхетле тәмамланмый, күкләр гел аяз тормый...

Поэмадагы чигенүләрнең һәркайсы урынлы һәм нигезле генә түгел, ә бәлки сюжет сызыгы һәм төп фикер өчен зарури да. Әйтик, поэмада 30 юл урынны алган ачулы җил образының мәгънәсе нидә? Ул образ әсәргә Мәхмүт хакында сүз барганда, аның эшләрен ничек тә булса аңлатырга ихтыяҗ туганда килеп керә. Үз бәяләрен кочләп такмастан, автор безгә бөтен эш Мәхмүтнең җилбәзәк характерлы кеше булуында дип ишарәли. Мәхмүт купшы сүзләр, матур җөмләләр (яңа тормыш, ирекле сөю һ. б.) артына яшеренеп йөри, асылда ул җилбәзәк характерлы җилкуар бер зат булып чыга. Очраклы бер күренештән этелеп китеп, ачулы җил образы зур гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек бирә. Бу бүлекчәнең ахырында автор сүзне бер дә юкка гына Мәхмүткә күчерми («Кайда син, әй, ата булыр кеше»...), моның белән ул сүзнең баштан ук нәкъ менә аның хакында баруына ишарә ясый.

Хуҗасыз, ташландык песи малае хакындагы чигенүнең мәгънәсе тагын да ачыграк. Бу образ әсәргә Зөбәйдә ятим бала тапкач килеп керә. Бу юлы автор әлеге мәсьәлә турында ачыктан-ачык яза: «Шулай, дустым! Сезнең песи халкы балаларын ташлап китәләр; Песи халкы гына түгел, этләр, аюлар да, кешеләр дә шулай итәләр...»

Чигенүләр поэманың офыкларын киңәйтә, әсәрне фәлсәфи сулыш белән баета, аңа полифоник яңгыраш бирә. Тиз узучан яшьлек, кыска, әмма гүзәл һәм газаплы мәхәббәт, җилбәзәклек, шуның нәтиҗәсе булган ялгызлык һәм ятимлек темалары үзәрә үрелеп килеп, поэманың катлаулы, табигате белән симфоник характерда булган структурасын билгелиләр. Чигенүләр белән генә чикләнмичә, шагыйрь контрапункт алымнарына мөрәҗәгать итә, шул чагында ике капма-каршы, еш кына контраст «мелодияләр» яңгырый башлый: караңгы төн һәм ак кар, Зөбәйдә һәм ай, җил һәм ай һ. б. ш. Мин'емчә, Такташның осталыгы шунда чагыла да.

Шул кадәресен басым ясап әйтергә кирәк, поэмадагы әлеге катлаулы полифонизм тулысы белән төп нәрсәгә — әхлакый идеалны эзләүгә, игелекнең бизмәнен ачыклауга буйсындырылган. Әсәрнең бүгенге укучы өчен булган әһәмияте шуның белән билгеләнә.

Симфонизм принциплары дигәндә, бередә гомуми фикер, бердәм максат нигезендә берләшкән темаларның, мотивларның күп кенә музыкаль әсәрләргә, бигрәк тә симфонияләргә хас булган катлаулы үрелеше күздә тотылды. Әйтергә кирәк, мондый төр композициянең музыка сәнгате тәэсирендә туу һич мәҗбүри түгел. Иҗади бурыч һәм максатларның уртаклыгы шуңа китерә, һәркайсы үз юлы белән үсеп, сәнгатьнең төрле төрләре гомуми нәтиҗәләргә, материалны оештыруның, композиция төзүнең гомуми алымнарына киләләр. Хәер, бу хәл музыкаль гармония алымнарын аңлы рәвештә үзләштерүне дә кире какмый.

Такташның әһәмиятле башка эпик әсәрләренә күз салсак, без аларда кайчак ныклы рефреннар булып яңгыраган, кайчак беленер-беленмәс кенә сизелгән музыкаль темаларның шундый ук байлыгын һәм катлаулы тестә үрелеп баруын күрербез. Әйтик, «Урман кызы» поэмасында ук бөтен әсәр буена сузылып барган берничә тема бар: куе кара урман, чәчәкләр, героиняның тузгыган толымнары белән уйнаучы ирекле җил темалары. Поэмада толымнар темасы һейне Матильдасының таралган чәчләр темасы белән керешеп китә һәм тепсез күзләр темасы белән тулыландырыла. Төрләнә һәм кабатлана барып, ахырда бу тема аерым бүлеккә үк бүленеп чыга («Нига? Нига синең шаян күзләр»...). Асылда, әлеге ике детальдән тыш, Такташ безгә үз героинясы хакында берни дә хәбәр итми. Әмма шул мөһим детальләр Әминәнең тышкы портретын гына тудырып калмый, ирек сөюче хөр табигатьле кызның эчке романтик кыяфәтен дә күз алдына китереп бастыра.

Буйдан-буйга сузылган шундый ук мотивлар Такташның башка әсәрләрендә дә бар. Шагыйрь талантының музыкаль ягы беренче чиратта шуларның оста үрелүендә, бер-берләренә керешүләрендә һәм симфоник яңгырашларында чагыла да.

Музыкаль керешүнең шундый ук принцибын Ә. Фәйзинең «Флейталар» (1934) поэмасында очратырга мөмкин.

Такташтан соң татар поэмасында симфонизм принцибы озак елларга онытылып торды. Поэманың сюжетлы төре алгы планга чыкты (Ш. Маннур, Г. Хуҗиев һ. б. поэмалары). М. Җәлилнең «Хат ташучы» поэмасы күп поэмалар арасында искәрмә булып тора, анда төп сюжет линиясе ачык беленеп торса да, әсәр халык җырлары рухындагы күп төрле чигенүләр белән үрелеп бара. Шул чигенүләрне алып ташлап, сюжет өслегән генә калдырсаң, әсәр берничә мәртәбә кыскарачак. Тик ул чагында, кабатланмас колорит, юморы һәм лиризмы, халыкчанлыгы һәм тормышчанлыгы белән бергә, поэма үзе дә юкка чыгачак.

Соңгы елларда язылган күп кенә поэмаларда симфонизм принцибы үзен тагын сиздерә башлады: мәсәлән, С. Хәкимнең «Дәверләр капкасы», «Васыятьләр», «Кырыгынчы бүлмә» кебек поэмалары, Р. Мингалимов белән И. Юзеевның аерым әсәрләре шундый. Бу һич тә сюжетлы поэма начар, симфонизм принцибына корылганнары гына яшәргә хаклы дигән сүз түгел. Сүз композиция төзүнең, материалны оештыруның бер алымы хакында гына барды.

Галимҗан Гыйльманов

# ВАКЫЙГА ҺӘМ ХИС ГАРМОНИЯСЕН ЭЗЛӘП

Муса Җәлилнең фронттан язган бер хатыннан шундый юлларны укыйбыз: «Минем ике әйбәт балладам бар: «Соңгы патрон турында баллада» һәм «Ике кыз һәм ике ул турында», ләкин әле алар эшләү өстендә». Шагыйрьнең баллада жанрына җитди мөнәсәбәте шушы берничә юлдан да аңлашылып тора. «Әйе,— ди ул соңгы хатларының берсендә,— җанлы кешеләр, җанлы геройлар турында... күп язарга кирәк» [1]. Димәк, шагыйрь совет сугышчысын тышкы характеристика белән түгел, нәкъ менә җанлы итеп, героика да, тирән драматизм да ташып торган вакыйга, көрәш эчендә ача торган балладаның мөмкинлекләрен сизенгән.

М. Җәлил үзенең үлемсез балладаларын фашист тоткынлыгында — «таш капчык»та язды. Батыр егетне коткарып үлгән сандугач («Сандугач һәм чишмә»), ике улын югалтып та, өченче улын, җиңүне көтеп ала белгән ана («Ана бәйрәме»), бар мәхәббәтен, ышанычын, өметен кушып суккан күлмәк белән сөйгәнен терелтә алган сылу («Күлмәк») образларында без сугышның иң хәтәр язмышын татыган шагыйрь характерын, батырлыгын, ныклыгын һәм мәхәббәтен дә таныйбыз.

Сугыш чорында татар совет балладасын яңа үсеш баскычына күтәргән шагыйрьләр арасында Фатих Кәрим иҗаты да махсус игътибарга лаек. Ул гадәттә үзе күргән-кичергән героик вакыйгалар турында баллада теле белән сөйли («Тимер һәм тимерче турында баллада», «Идел егете», «Шомырт куагы», «Диңгез ярында» һ. б.). Ә. Фәйзи, Ә. Исхак, С. Хәким, Ш. Маннур, Ш. Мөдәррис, М. Садриларның шул чорда иҗат иткән балладалары мәгълүм.

[1] Кашшаф Г. Халык шагыйре — халык герое. «Совет әдәбияты», 1954, 1 нче сан, 77 бит.

Утызынчы елларда гына формалашып җиткән баллада жанрының[1] Бөек Ватан сугышы чорында активлашып китүе, нигездә, сугыш чоры үзенчәлеге, әлеге үзенчәлек йогынтысында үзгәргән әдәби эстетик концепцияләр белән бәйле. Икенчедән, нәкъ менә бу жанрның сыйфатлары чор рухын аеруча ышандыргыч, тәэсирле итеп күз алдына китереп бастыра, сугыш турында берьюлы ике планда — хис-кичерешләр ярдәмендә һәм иллюстратив планда сөйли ала иде. Шагыйрь балладада вакыйганы хикәяләп кенә калмый, аңа карата үз сүзен, үз бәясен әйтә, хәтта вакыйгада үзе дә катнашып китә. Бу чорда балладаның активлашуы героик-романтик сюжетларны сурәтләү теләге көчәю белән дә бәйләнгән, ә героика һәм романтика исә Бөек көрәшнең һәр фронтында көн саен, адым саен очрап тора. Аллегорик һәм символик сурәтләүгә, күтәренке пафослы тасвирлауга нигезләнгән поэтика чорның шушы үзенчәлеген гәүдәләндерүдә зарури чарага әверелә.

Сугыш чоры поэзиясен укыганда, татар әдәбият белемендә һаман игътибарсыз калып килә торган баллада жанрының көченә, мөмкинлекләренә ныграк ышана барасың. Һәм бу жанрның сугыштан соңгы язмышы белән кызыксынасың... Ләкин 40 нчы елларны үтеп, 50 нче елларга кергән саен, бу кызыксыну кими башлый. Бу чорда күзгә бәрелеп тормаган ике-өч баллададан артык әсәр очрамый.

Сугыштан соңгы татар әдәбиятында баллада жанры ни өчен пассивлашты соң? Сәбәпне иң беренче чиратта бу чор татар әдәбиятының эстетик концепциясеннән эзләргә кирәктер. «Лирикада кеше җанын бирү урынына без күп очракларда тышкы эффект белән мавыктык, кызны матур дидек,... егетне, әлбәттә, батыр дидек. Нишлисең! Традиция! Геройлардан без бик шәп сөйләтәбез, ләкин аның йөрәге читтә кала. Сүзен ишетәбез — хисен сизмибез», — дип язды сугыштан соңгы чор татар поэзиясе турында Ш. Мөдәррис[2]. Шул рәвешле, балладаны оештырып торучы үзәк — драматик конфликт, психологик һәм әхлакый каршылыкларны сурәтләү кимеде, алар белән бергә баллада да жанр буларак нык пассивлашты.

Татар совет балладасының икенче көч алуы 60 нчы елларга туры килә. 50 нче елларның икенче яртысында бу үсеш өчен бөтен шартлар да барлыкка килгән иде. Нәкъ шушы елларны әдәбиятыбызга Туфан кайтты. Ул 50 нче еллар поэзиясен татар әдәбиятына баллада жанры биргән 30 нчы еллар белән, андагы матур традицияләр, табышлар белән тоташтырды. Шагыйрь үзенең иң матур ачышларын, тәҗрибәләрен саклап алып чыкты, аларны драматизм, сагыш, моң тулы сугыш авазы белән кушып бирде. Шул чак аның беренче балладалары кабат яңаргандай булды. Тимерләр, Хәйбуллалар инде канлы сугыш кичкән батырлар булып күз алдына килеп бастылар.

Туфанның 30 нчы елгы балладаларыннан ук килүче сыйфатлар (көчле романтизм, кискен сюжет, композицион төрлелек, кыю шартлылык, тирән лирик башлангыч), сугышның драматик, героик аһәңенә кушылып, әр-яңа сыйфат тудырдылар. Яңа сыйфат яңа балладаларга нигез булырга тиеш иде.

Исебезгә төшерик: Туфанның беренче лирик балладаларында («Ак каен», «Су астында бер егет бар») төп геройлар күбрәк ярдәмчесез, фаҗига алдында көчсез кешеләр иде. Шагыйрь аларны шуңа күрә фаҗигадан соң гына күрсәтә, ә әсәр исә шушы үлемне табигатьтәге образлар тарафыннан кабат кичерү рәвешендә тәзелә. Герой үзе исә пассив. Аны укучы күбрәк кызгана гына.

1939 елны иҗат ителгән «Тимеркәй турында җырлар» балладасында инде төп герой — заманның иң актив геройларыннан. Ул көчле, кыю, тугры, нык ихтыярлы кеше. Ләкин бу актив герой автор хыялына нәреп шулкадәр активлашып китә, хәтта мавыктыргыч әкият геройларын да хәтерләтеп куя иде. Шагыйрь әле үз геройлары — Тимер, Ләлә кичергән тойгыларны, драмаларны кичеп тетрәнмәгән...

Бу драманы, бу кичерешләрне, бу тетрәнүләрне Туфанга сугыш бирде. Ул тере Тимерләр күрде, үзе үк Ләлә, Тимерләрдән дә кыенрак хәлләрдә калды. Шагыйрь үлемнең, фаҗиганең, батырлыкның нәрсә икәнен күреп, тоеп, яшәп белде. Шул рәвешле, ул тормышны, яшәүне раслауда яңа юллар тапты... Хәтергә аның «Чәчәк сибелә җилдә» әсәре килә.

Кешене үлемгә алып баралар. Ул горур басып, тыныч кына үз үлеменә китеп бара. Менә аның шушы үлем алдындагы, дошманнары алдындагы тынычлыгында — кө-

---

[1] Бу турыда: Галиуллин Т. Яңа үрләр яулаганда. Казан, 1972.
[2] Мөдәррис Ш. Уйлану сәгате. «Совет әдәбияты», 1953, 2 нче сан.

че, каһарманлыгы. Без инде аны, Хәйбулланы яки су астындагы кытай егетен кызганган кебек кызганмыйбыз, без аңа сокланабыз! Без аның белән горурланабыз! Дошманның кулы калтыраган саен, аның батырлыгы, үлемсезлеге дә үсә. Кеше үз үлеме белән башка миллионнарның яшәвен раслый. Аның хәрәкәтләре, үлеме, батырлыгы да табигый, ышандырырлык. Анда инде Тимердәге ясалмалык та, тылсымлы әкият герое сыйфатлары да юк. Ул — Туфанның замандашы, яшьтәше, кирәк икән — каләмдәше (эпиграф итеп М. Җәлил шигыре алынуы — очраклымы?). Шул рәвешле, татар әдәбиятында әр-яңа баллада туды.

60 нчы еллар татар поэзиясе өчен икенче мәктәп — Җәлил мәктәбе. Туфан белән бергә диярлек әдәбиятка Муса Җәлил, аның атаклы «Моабит дәфтәрләре» кайтты. Моабит циклы риторика белән әртелгән, лозунглар белән сөйләүче поэзия телен әрьяңадан үзгәртеп корырга кирәклеген күрсәтте. Геройның батырлыгын сөйләп чыгу гына җитми; аның күңел ныклыгын, бу батырлыкның мотивларын ачу юк икән әле... Дөрес, яңарыш яралгылары сугыштан соң үсеп җиткән риторик поэзиянең үзендә дә бар иде. 50 нче елларда әдәбиятка килеп кергән И. Юзеев, Ш. Галиев, Г. Афзаллар буыны, алар артыннан ук килгән яшь шагыйрьләр яралгы хәлендә генә булган әлеге матур ачышларны тотып алып, яңа сыйфат итеп үстереп җибәрделәр. Бу сыйфатларның күпчелеге (күчле лирик башлангыч, фәлсәфи фикер тирәнлеге, шартлы алымнар, символлар, гомумиләштерүләр белән кыю эш итү h. б.) 60—70 нче еллар татар поэзиясендә баллада жанрының үсүенә алып килде.

Балладаның активлашуына алып килгән тагын бер мөһим момент бар. Ул — фәнни-техник революция (ФТР) һәм баллада жанры мәсьәләсе. Беренче карашка, алар арасында берниндн уртаклык та булырга тиеш түгел. Ләкин күчле үсешкә ирешкән ФТР заманы поэзиясен тикшерену бөтенләй көтелмәгән нәтиҗә бирә: нәкъ шушы чорда бу жанр яңа бер кискенлек, сыйфат алып үсеп китә икән! Әлеге балладик кискенлек ФТР алып килгән машиналар, тизлек чорына реакция буларак алынган, кешелек һәм аерым халык тарихын барлау, бүгенгене тарихи бәяләү, әдәби һәм культура мирасы өчен борчылу мотивлары аркылы ирешелә. И. Юзеевның «Курай һәм егет», «Моң турында баллада» кебек әсәрләре нәкъ шул планда иҗат ителгәннәр дә. Табигать белән кеше арасында ара һаман ераклаша бармыймы? Карурманнар табигыйлеген югалтканда, күңелебездә табигатькә урын һаман тарая түгелме соң?... И. Юзеев балладаларында бу сорау, бу борчылу да бар.

И. Юзеевның балладалары бер-берсенә охшамаганнар, ләкин аларны бер иткән сыйфат та бар. Ул — халыкчанлык. Шагыйрь гасырлар масштабында фикер йөртә, хәзергегә үткән яки киләчәк аша бәя бирә, үткәне һәм киләчәге булган халык улы булып чыгыш ясый.

60 нчы елларда татар совет балладасының яңарышы куелган мәсьәләләрнең әһәмиятендә генә булмыйча, формадагы, композиция төзелешендәге яңалык һәм ачышлар белән дә билгеләнә.

Үзенең композицион байлыгы ягыннан бу елларда Г. Хуҗи әсәрләре аерым урын тота. Арабыздан бик иртә киткән бу талантлы шагыйрь татар һәм рус балладасында моңарчы булган тәҗрибәне үз иҗатында туплап бирә кебек. Шулай да аңа аеруча кадерле бер шагыйрь, бер баллада мәктәбе бар. Ул — Туфан. Г. Хуҗи иҗатында Х. Туфанның 30 нчы елгы балладалары кабат яшәү ала. Шагыйрь Туфан иҗатында очраган рефренның ике вариантын эшли. Беренче очракта рефрен булып килгән өлеш вакыйга үстерелешендә даими кабатланып, үзәк драманы көчәйтүче чара буларак килсә, («Раифа фаҗигасе», «Иман шавы», «Йөрәгемдә ике өлеш» h. б.), икенче очракта, әсәр башында һәм ахырында килеп, аны бөтенәйтү һәм эффектлы тәмамлау өчен хезмәт итә («Сергей Чекмарев белән очрашу», «Ә ул җырлый...» h. б.). Г. Хуҗи шулай ук Х. Туфан татар балладасында беренче тапкыр эшләнгән, «кадрлар принцибын» да кыю куллана («Иман шавы», «Таныш күзләр, таныш карашлар»), үз каләмен амебей композициясендә дә (сорау-җавап) сынап карый («Җыр дөнья гизә», «Йөрәгемдә ике өлеш» h. б.). Г. Хуҗиның күпчелек балладалары үткәндәге данлыклы чорны һәм фаҗигале вакыйгаларны хәзерге заман кешесе булып кабат кичерүгә, уйлауга корылган. Монда да Туфанның беренче лирик балладаларына ох-

шашлык сизелә. Гомумән, хәзерге татар совет балладасының өч композицион тибын аерып күрсәтергә мөмкин. Тарихи вакыйгаларны кабат кичерүгә корылган, шул сәбәпле лирик башлангыч өстенлек алган, Х. Туфан һәм Г. Хуҗи балладаларында эшләнгән композицион форма — шуларның беренчесе.

Икенче очракта үзәк конкрет бер драматик вакыйга сюжеты алына, һәм укучының игътибары әсәрнең башыннан ахырына кадәр шул сюжет үстерелешенә төбәлгән була. Мондый тип балладаларга Х. Туфанның «Тимеркәй турында җырлар», Ә. Фәйзинең «Дала һәм кеше», М. Җәлилнең «Кызыл ромашка», «Сандугач һәм чишмә», Ф. Кәримнең «Тимер һәм тимерче турында баллада», Н. Дәүлинең «Диңгез һәм солдатлар», И. Юзеевның «Курайчы турында баллада», Р. Әхмәтҗановның «Соңгы танк», Г. Хуҗиның «Капитан Русанов» кебек әсәрләре керә.

Ә бер төркем балладалар исә ассоциатив фикерләүгә корыла. Мондый тип әсәрләрдә үзәк конфликт, драма ассоциацияләр рәвешендә кабынып-кабынып, этаплар үтеп килә. Зөлфәтнең «Вәгъдә» балладасында композиция нәкъ шул рәвешле бирелгән.

Баллада өч өлештән тора. Алар күпмедер мөстәкыйльләр дә. Ләкин бу кисәкләрне оештырып, берләштереп торган үзәк, төен дә бар. Ул — ата кешенең һәм аның улларының дошман алдындагы ныклыгы, героик үлеме, ике буынның ил алдында биргән уртак анты, җиңүгә вәгъдәсе. Җитмәсә, әлеге өлешләрне берләштереп торучы төп фактор формаль, поэтик чаралар, башлыча, рефрен ярдәмендә дә ныгытыла.

Ш. Галиевнең балладада үзенә генә хас композицион принцибы бар. Барыннан да элек ул документаль материал нигезендә язарга ярата. Еш кына аның әсәрләрендә эпиграф рәвешендә хәбәрләр, аңлатмалар, багышлаулар бирелә («Ленин сәгате», «Ике дус турында баллада», «Чаң турында баллада», «Кыя һәм кеше»), кайбер балладаларында турыдан-туры тарихи шәхесләр турында сүз бара («Муса елмаюы турында баллада»). Шагыйрь конкрет тарихи фактны баллада жанры таләп иткән көчле гомумиләштерүләр аша үткәреп, аның тарихи-философик мәгънәсен табарга омтыла. Тарихи вакыйгалар безнең замандаш, яңа буын исеменнән бәян ителә. Мондый әсәрдә ике башлангыч бергә яши: берсе — үткән тарихка, икенчесе хәзерге тормышка бәйләнгән. Беренче өлештә баллада нигезендәге вакыйга тулысынча бирелсә, икенче өлештә бу вакыйганың дәвамы, безнең заманга күчеп, яңаруын күрсәткән картина бирелә. «Ике дус турында баллада» әсәре — шундыйлардан.

Күпчелек шагыйрьләр баллада драматик, трагик ситуациягә нигезләнергә, ә геройларның язмышы фаҗига белән бетәргә тиеш дип уйлыйлар. Әлбәттә, бу планда да менә дигән әсәрләр иҗат ителгән. Ш. Галиев исә үз әсәрләрендә драматик конфликтны үзенчәлекле чишеп карый. Ул драматик конфликтны әсәрнең беренче өлешендә үк бирә. Бу алым конфликтның чишелешен эффектлы итә. Мәсәлән, Кыя белән Кеше бәхәсендә, беренче карашка, кешене котылгысыз һәлакәт көтә кебек. Драма иң кискен ноктасына җитә, ләкин чишелеш булмый кала. Һәм алар кабат очраша. Алар арасындагы бәхәсне инде вакыт чишкән. Кемнең кем икәнен вакыт әйтеп бирә: «Кырык давылда айкалган Кеше, кырык батып та, сау калган Кеше... Кыя яртылаш иңгән, ишелгән...» Шул рәвешле, Кешенең драмасы Кыя драмасына күчеп дәвам итә. Кыя үзенең көчсезлеген аңлаган: «Эх, булса миндә Кеше ныклыгы!..» — ди ул. Кешенең ныклыгы — сыналган ныклык. Аның дәлиле — халык. Ә халык ул — үлемсез, мәңгелек. Кешенең: «Кыя-кыя таш, йөрәгем минем халыкка тоташ», — дигән сүзләре кисәктәге Кыя сүзләренә («Тамырым белән тауларга тоташ!») рефрен булып килеп, укучыны үткән бәхәскә кабат алып кайта, үткәндәге драманы яңарта, җиңүнең нинди кискен көрәш нәтиҗәсе булып тууы турында сөйли.

Ә. Фәйзинең «Дала һәм кеше», М. Җәлилнең «Ана бәйрәме», Н. Дәүлинең «Диңгез һәм солдатлар» кебек балладаларында очраган бу матур алым (кискен драматик ситуациядән соң, әсәр үз героеның җиңүе, тантана итүе белән бетә), шул рәвешле, Ш. Галиев балладаларында яңартып эшләнә, алга үстерелә.

Шуны да искәртергә кирәк: әлеге алымны үзмаксатка әйләндергәндә, жанрны оештырып торучы үзәк — драматик момент — риторика эчендә югалып калачак.

70 нче елларга татар совет балладасы бай традицияләр белән килеп керде. Х. Туфан, Ә. Фәйзи, Җәлилләр башлаган эшне Г. Хуҗи, И. Юзеев, Ш. Галиевләр дәвам итте, алар артыннан килгән яңа буын да бу үзенчәлекле поэтик жанрда кызыклы гына әсәрләр бирде. Үзләренең кыю тәҗрибәләре белән алар арасында Роберт Әхмәтҗанов белән Р. Харис аерылып тора иде.

Сугыш чорында чәчәк аткан татар совет балладалары да кабат тугандай булды. Р. Әхмәтҗановның Ф. Кәрим һәм М. Җәлил балладалары рухында язылган «Соңгы танк» исемле балладасы — шуның бер мисалы. Шагыйрьнең әйтергә теләгән фикере — җиңү җиңел генә бирелмәде, ул күп корбаннар бәрабәренә яуланды. Әсәрдәге төп геройның табигатен шушы мотив билгели дә. Ул дошман танкын яндырып, үзе дә һәлак була. Шуңа да карамастан, әсәр оптимистик ноталарда бетә.

**Дымсу юлда танк сүнгән,**
**Гөлләр һаман янып тора.**

Әйтергә кирәк, батыр солдат кабере өстендә гөлләр шытып чыгу мотивы 60—70 нче еллар татар балладасында тиз таралып өлгерде. Р. Әхмәтҗанов үзенең «Ак чәчәкләр» балладасын да шушы сурәткә нигезләнеп иҗат иткән. Ләкин бу әсәрендә шагыйрь «Соңгы танк»ны һич кабатламый, бәлки Ф. Кәрим, М. Җәлил иҗатларыннан ук килүче әлеге сурәтнең яңа композицион вариантын эшли. Ул сөйгәнен өзелеп көтүче кызның кичерешләр дөньясына чумып, әлеге матур сурәтнең төрле төсмерләрен эзли башлый.

Дөрес, бу әсәрне эшләнеп җиткән лирик баллада дип әйтүе кыен әле. Ул бер фикергә, бер төенгә тупланып бетә алмаган. Шул сәбәпле укучы берничә урында драманың җеп очын югалтып ала. Шагыйрь хисләр ташкынына ияреп, жанрның тагын бер хасиятен — эпик башлангычын онытыбрак җибәрә. Ә баллада ярым-йорты булуны яратмый. Анда хис, кичерешләр үсеше вакыйга, драма үсеше белән тәңгәл барырга тиеш...

Р. Харис, билгеле булганча, 60 нчы еллар ахырында берничә шигырь һәм баллададан торган һәм Ф. Кәримгә багышланган яңа цикл иҗат итте. Баллада жанры мөмкинлекләреннән файдаланып, шагыйрь вакыт чикләрен вата, җимерә, тарихны аркылыга-буйга иңли, аннан Ф. Кәрим хакында хатирәләр эзли, бу хатирәләрне безнең көннәргә алып чыга. Заман белән заман, шагыйрь белән шагыйрь очраша...

Р. Харисның «Камыш һәм кувшин» балладасы исә бөтенләй башка интонациядә, башка композицион принципка нигезләнеп язылган. С. Рәмиевнең «Перчатка»сыннан ук килүче баллада мотивын шагыйрь психологик аспектта уңышлы бирә алган. Ф. Кәримгә багышланган циклдагы балладалар хис, фикер кырыслыгы, сурәтләр, образлар тыгызлыгы, антитеза алымына нигезләнгән конфликт белән аерылып торса, яңа балладада исә шагыйрь күбрәк геройларның күңеленә үтеп керергә омтыла. Драма әнә шунда — геройлар күңелендә тәкәббер горурлык белән сөю хисе арасындагы гармония юкка чыккан... Р. Харис бу балладасы белән Ә. Баяновның «Тәңге бәхәс»ендә инде бер күренеп калган психологик балладаны яңартып, үстереп җибәрде.

Күңелдәге бер борчу хакында да әйтми мөмкин түгел. 70 нче еллар ахырында, 80 нче еллар башында беренче җыентыкларын чыгарган яшь шагыйрьләр (З. Мансуров, Б. Сөләйманов, Р. Низамиев, Н. Измайлова һ. б.) баллада җебек кызыклы жанрны читләтеп узганнар. Фикер, деталь белән мавыгу сәбәпле, аларның күп кенә әсәрләрендә балладага хас коллизия, хис, фикер кискенлеге белән вакыйга берлеге җитеп бетми. Шул ук вакытта баллада жанрында шактый уңышлы эшләп килүче шагыйрьләр хакында да әйтергә кирәк. Зөлфәт, М. Әгъләмов, Р. Миңнуллин иҗатларында һәр баллада, чыннан да, зур вакыйга кебек кабул ителә. Укучыларны дулкынландырырлык, уйландырырлык әнә шундый вакыйгалар күбрәк булсын иде.

Рәфыйк Мөхәммәтшин

# ЯҢА ӘДӘБИЯТ БИШЕГЕ ЯНЫНДА

Бөек Октябрь социалистик революциясе яңа мәдәниятнең үсүенә киң юл ачу белән беррәттән, совет әдәбият белеме һәм сәнгать фәне алдына күп кенә принципиаль яңа мәсьәләләрне дә куйды. Марксистик-ленинчыл тәгълиматтан чыгып бу фәннәрнең теоретик һәм тарихи проблемаларын өйрәнүне тагын да тирәнәйтү, аларны яңа позицияләрдән торып күзаллау һәм социалистик революциядән соң туган башка бик күп мәсьәләләрне чишәргә кирәк иде. Иң беренче планда әдәбият белеме һәм сәнгать фәнен социалистик төзелеш белән бәйләүче эчке закончалыкларны билгеләү, социалистик сәнгатькә генә хас үзенчәлекләрне ачыклау кебек проблемалар торды.

Совет властеның беренче елларында иҗат итүче әдәбият галимнәрен, тәнкыйтьчеләрне, философларны, шул исәптән Г. Ибраһимовны да, социалистик революция тудырган бу мәсьәләләрне 20 нче еллар башында ук, тиз арада чишә алмауда гаепләү дөрес булмас иде. Чөнки бу проблемалар зур тарихи әһәмияткә ия булу белән бергә гаять катлаулы да иделәр. Шуңа күрә дә революциядән соңгы беренче елларда фәннең бу өлкәләре формалашу, аякка басу чорын кичерделәр. Галимнәр әдәбият белеме һәм сәнгать фәненең аерым мәсьәләләренә җавап эзләп кенә калмадылар, ә аларның методологик һәм теоретик нигезләрен ачыклауга да зур игътибар бирделәр.

Иң беренче чиратта XIX гасыр ахыры һәм XX йөз башында буржуаз эстетикада хөкем сөргән методологик кризис калдыкларыннан котылырга кирәк иде. Ибраһимовның, башка бик күп совет галимнәре кебек, сәнгатьне һәм иң беренче чиратта әдәбиятны марксистик методология нигезендә социологик принциплар аша тикшерергә омтылуын шуның белән аңлатырга мөмкин. Дөрес, 20 нче елларда киң кулланылган «социологик метод»ның сәнгатькә марксизм нигезләрен нигъту белән бергә, аның үсүенә кайбер тискәре йогынтысы да булмый калмады. Чөнки бу методны теоретик нигез итеп алган галимнәр, сәнгатьнең иҗтимагый ролен ачыклауга зур игътибар биреп, мәсьәләнең икенче ягыннан — сәнгать әсәрләрен конкрет-тарихи анализлаудан — читкәрәк киттеләр, ягъни алар кайчагында сәнгатьнең иҗтимагый аң формасы буларак үзенчәлекләрен игътибарсыз калдырдылар.

Марксистик методологияне дөрес куллану Ибраһимовны 20 нче еллар уртасында яңа социологик нәтиҗәләргә китерде һәм болар, үз чиратында, әдәби иҗат процессының игътисад белән турыдан-туры түгел, ә берничә төрле мөнәсәбәтләр аркылы бәйләнешен ачыкларга, конкретлаштырырга мөмкинлек бирде.

Марксизм-ленинизм классикларының әдәбият һәм сәнгать турындагы хезмәтләренең һәм фикерләренең әһәмияте, беренче чиратта, фәнни эстетиканы һәм әдәбият тарихын, Г. В. Плеханов сүзләре белән әйткәндә, «дөрес метод» белән коралландыруында. Ибраһимов «тикшерүдә төп ысул тарихи материализм»[1] дип язып кына калмады, ә үзе дә һәрвакыт бу методка таянып эш итте. Аның марксистик эстетик карашларын өйрәнгәндә, бу методны аңлау һәм куллануның үзгәрүен күзәтергә мөмкин.

Сәнгатьнең иң мөһим фәлсәфи проблемаларыннан берсе — аның социаль җирлеген ачыклау — эстетика тарихында төрлечә хәл ителгән. Бу мәсьәләнең принципиаль чишелешен К. Маркс һәм Ф. Энгельс хезмәтләрендә табарга мөмкин. Әлеге проблемага Г. В. Плехановның да шактый хезмәтләре багышланган. Әмма 20 нче елларда бу принципларның күбесе артык гадиләштерелде. «Чтобы понять историю

[1] Г. Ибраһимов. Әсәрләр, 5 том. Казан, 1978, 390 бит.

искусства в одной стране, недостаточно знать ее экономию»,— дип кисәткән иде Г. В. Плеханов [1]. Аның бу сүзләре К. Маркс һәм Ф. Энгельсның: җәмгыять тарихында икътисади мөнәсәбәтләр хәлиткеч роль уйныйлар, ләкин бөтен иҗтимагый тормышка механик рәвештә тәэсир итмиләр дигән фикереннән чыгып әйтелгән иде. Г. В. Плеханов иҗтимагый психологиянең сәнгать белән җәмгыятьнең икътисади мөнәсәбәтләрен бәйләүче арадаш буын икәнлеген ассызыклап күрсәтте: «...новое состояние производительных сил ведет за собой новую экономическую структуру, равно как и новую психологию» [2].

20 нче елларда кайбер марксист галимнәр иҗтимагый психологиянең җәмгыять белән сәнгать арасындагы мөнәсәбәтләрне билгеләүдәге ролен инкарь итмәсәләр дә, күп очракта аның урынын дөрес аңлый алмадылар, ә кайберәүләр сәнгатьнең эчтәлеген ачыклаганда бу төшенчәне бөтенләй үк истән чыгардылар.

Бу очракта Г. Ибраһимов та Г. В. Плеханов позициясен бераз гадиләштерүдән котыла алмады. Ул тарихи материализмны бердәнбер дөрес фәнни теория дип югары бәяләсә дә, Плеханов хезмәтләреннән өзекләр китерсә дә, аны күбрәк сәнгатьнең икътисад белән «турыдан-туры» бәйләнеше кызыксындыра: «Марксистлар өчен тарихның бөтен материалы, идеологиянең, әдәбиятның бөтен тармаклары — һәммәсе дә тик үткән тормыштагы техниканың, иҗтимагый-икътисади хәлләрнең өскә чыгарган җимешләре генә» [3].

Ибраһимов сәнгать үсешен җәмгыять үсешенең чагылышы итеп карады. Сәнгать тарихын аның үзеннән генә чыгып аңлатырга мөмкин түгел: «Тикшерүдә төп ысул тарихи материализм, ягъни идеологияне, әдәбиятны матди туфракта үсеп чыккан җимешләр дип карау, әдәбияттагы үзгәрешләрне, хасиятләрне мөндәриҗә, төп фикерләрне аларның шул дәвернең техникасы, икътисади иҗтимагыяте белән ни дәрәҗәдә бәйләнуларын ачып бару ысулы кулланырга тиешле» [4].

Шушы принциптан чыгып, Ибраһимов, иң беренче чиратта, иҗтимагый тормыш үсешенең схемасын төзергә омтылды һәм бары тик шул схемадан гына чыгып сәнгать үсешенең юнәлешен билгеләргә тырышты. Әгәр бу схеманы гыйльми яктан тикшерсәк, анда күп бәхәсле моментлар табарга мөмкин. Ләкин Ибраһимовның марксистик принципны — җәмгыять үсешенең төрле этапларына сәнгать тарихының төрле этаплары туры килү принцибын куллануы аның концепциясенең бик мөһим якларын тагын да ачыклый төшә.

Дөрес, Ибраһимов әдәбият-сәнгать үсү этапларының нигезе итеп аерым иҗтимагый-иктисади формацияләрне алмаган. Аның этаплары я берничә формацияне үз эченә ала, яки бер формация берничә этапка бүленеп карала. Мәсәлән, татар әдәбияты үсешен тикшереп, Ибраһимов аны өч дәвергә бүлә [5].

Г. Ибраһимов бу елларда әле сәнгать үсешенең эчке закончалыкларына кагылган һәм аның үзенчәлекләрен ачыклаучы мәсьәләләргә зур игътибар бирмәде. 20 нче елларда сәнгатьнең социологик проблемаларын өйрәнүчеләр өчен хас күренеш иде бу. Шулай да инде аның хезмәтләрендә әлеге өлкәгә кагылышлы кызыклы күзәтүләр табарга мөмкин. Бу бигрәк тә аның методологик фикерләрдән конкрет мәсьәләләр тикшерүгә күчкән хезмәтләрендә күзгә ташлана. Мәсәлән, Ш. Бабич иҗатына багышланган мәкаләсендә ул үзенең методологик системасы чикләренә сыймаган әдипнең шәхес проблемасына киң туктала, шагыйрьнең әсәрләрен өйрәнеп, иҗатының үзенчәлекле моментларын ачыклый һәм шагыйрь белән җәмгыять арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне күрсәтә. Ш. Бабичның үзенә генә хас иҗади үзенчәлекләрен күрсәтү, шагыйрьнең дөньяга карашындагы кайбер каршылыклы якларны ачыклау, аның иҗатында рациональ һәм эмоциональ яссылыкларның һәрвакытта да кисешмәгәнлекләрен билгеләү Ибраһимовның гомуми концепциясенә хас кайбер каршылыкларның нигезен ачыклады: алар, беренче чиратта, идеология белән сәнгатьне аерып карамау белән бәйләнгәннәр иде.

---

[1] Г. В. Плеханов. Избр. филос. соч., в 5 томах, т. 2. М., 1956, 247 бит.
[2] Шунда ук, т. I, 645 бит.
[3] Г. Ибраһимов. Әсәрләр, 5 т., 383 бит.
[4] Г. Ибраһимов. Шунда ук, 390 бит.
[5] Шунда ук, 288—293 бит.

Сәнгатьнең социологик мәсьәләләрен тикшерү процессында сыйныфчылык проблемасына ачыклык кертү мөһим роль уйный иде. Чөнки бу мәсьәләне хәл итү сәнгать тарихына методологик күзлектән чыгып бәя бирү һәм килачәкнең әдәби мәдәниятен төзү белән бәйләнгән.

Үзенең методологик карашларыннан чыгып, Ибраһимов бу катлаулы мәсьәләне кайбер гадиләштерүләрсез генә чишә алмады. Сәнгатьнең эчтәлеге, мәгънәсе тулысынча икътисади һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрдән генә чыгып аңлатыла икән, анда сыйныфчылык элементы, һичшиксез, урын алырга тиеш: «әдипләр, шагыйрьләр күктә яшәми, талантлар күктән рухланмый — болар мәгълүм дәвернең, мәгълүм иҗтимагый-икътисади зәминнәрнең җимешләре булганга, шуңа карап, аларның безгә ача торган дөньялары, тормышлары, җанлы картиналары төрлечә була. Тормышның үзендәге төрле күренешләр безгә төрле фикер, төрле тәрбия биргән кебек, шагыйрьнең, әдипнең «битараф» җанлы тасвирлары, җанлы күренешләре дә укучының рухында үзенең мәндәриҗәсе, әдәби пәрдә астына яшерелгән мәгънәсе буенча төрле эз калдыра.

Менә шушы ноктадан инде шагыйрьнең, әдипнең кемгә, нинди әмәлгә, кайсы сыйныфка хезмәте мәсьәләсе килеп чыга»[1].

Матур әдәбиятта сыйныфчылык принциплары ничек чагыла соң? Ибраһимов әдип иҗатының социаль характерда булуы турында бик күп яза[2]. Иҗат процессының кайбер гомуми якларын тикшергәндә бу категориядән чыгып эш йөртү дөрес, чөнки ул иҗатның тарихи рамкаларын билгели. Ләкин, икенче яктан, шунда ук икенче адымны атлау кирәклеге килеп баса: сәнгать әсәрләренең шәхси үзенчәлекләрен аңлату һәм аларның башка идеология формалары белән таңгал килмәвен ачыклау. Монда шуны да искәртеп узарга кирәк, Ибраһимов әдәби әсәрләрнең «әдәби кыйммәт», «әдәби дәрәҗә», «әдәбилек», «тел-өслүб» кебек якларын өйрәнергә кирәклеген әйтеп үтә[3]. Ләкин Ибраһимов өчен әдәби әсәрне тикшерүдә төп моментларның турыдан-туры иҗтимагый-икътисади мөнәсәбәтләргә бәйле булуында[4].

1924 елда Ибраһимов «Пролетариат әдәбияты турында» дигән хезмәтен язып тәмамлый. Бу хезмәт зур проблемалар куюы белән генә түгел, ә бәлки методологик хаталардан арыну процессында зур адым буларак та бик әһәмиятле.

Марксизм-ленинизмга нигез салучыларның әсәрләре белән тагын да тирәнрәк танышу, Плеханов, Луначарский, Воровский хезмәтләрен өйрәнү, эстетик проблемаларны өйрәнгәндә марксистик методологиянең тирәнтен мәгънәсен аңлап куллану Ибраһимовны яңа теоретик нәтиҗәләргә китерә. Сәнгать һәм әдәбият үсеше турыдан-туры матди шартлар үзгәрүгә бәйләнгән дигән схема гына аны инде канәгатьләндерми. Ул бу хакта «...болар төп нигезләр генә. Ачык аңлау өчен (әдәбият һәм сәнгать үсешен — М. Р.) бераз нечкәрәк керү кирәк була»,— дип язды[5].

Әдәбият һәм сәнгатькә тирәнрәк үтеп керүгә әдип Плехановның мәшһүр схемасын анализлаудан башлый:

«1 — әйбер эшләп чыгару көчләренең дәрәҗәсе,

2 — шулар аркасында туган икътисади мөнәсәбәтләр,

3 — менә бу икътисади нигезгә үскән сәяси-иҗтимагый төзелеш,

4 — шул җәмгыять кешесенең психикасы (психологиясе),

5 — шул психиканың төрле хасиятләрен үзендә күрсәткән төрле идеологияләр.

Номерлап төзелгән бу формуланы нечкәлек белән өйрәнергә кирәк. Бигрәк тә бөтен җәмгыятьләрнең тарихларында төп факт булган беренче нигездән (әйбер эшләп чыгару көчләренең мәртәбәсеннән) идеологиягә, димәк, әдәбиятларга да ясала торган тәэсирнең нинди баскычлар, нинди трубалар аша-сыннан үткәнлеген аеруча уйларга кирәк»[6].

Бу схеманың төрле буыннарын тикшерү, аларның үзара бәйләнешен ачыклау Ибраһимовка әдәби иҗатның икътисад белән бәйләнешенең берьяклы гына булмавын тирәнрәк аңларга ярдәм итте.

Ибраһимовның җәмгыятьтә социаль психологиянең ролен ачыклауга игътибар

---

[1] Шунда ук, 311—312 бит.
[2] Мәсәлән, «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы».— Шунда ук, 330—338 бит.
[3] Шунда ук, 388 бит.
[4] Шунда ук, 383 бит.
[5] Шунда ук, 428 бит.
[6] Шунда ук, 429—430 бит.

итүенә аерым тукталырга кирәк». «...әдәбият тарихының кайбер баскычларында «талантлар»ның күп чыгулары, күп кыйммәтле нәрсәләр бирүе, кайбер дәверләрдә «илһам» тукталуы кебек хәлләрнең дә шул иҗтимагый-икътисади эшләрнең тудырган психологиясендә күрербез»[1].

Иҗтимагый аңның эчтәлеге иҗтимагый яшәештән чыгып билгеләнә дигән караш нигезендә, Ибраһимов марксистик тәнкыйть һәм эстетиканың мөһим социологик принципларын үзләштерде: «тәнкыйтьне әдәби әсәрнең нигезенә салынган идеясен сәнгать теленнән социология теленә күчерү — тагы башкача әйткәндә, әсәрнең иҗтимагый эквивалентын табып чыгару... тәнкыйтькә төп момент»[2]. Әгәр 20 нче еллар башында Ибраһимов бу принципны бердәнбер дип санап ялгышкан булса, хәзер инде ул икенче адым итеп әдәби әсәрнең эчтәлеген тикшерүне ала: «...әдәби иҗатларда беренче нигез идеология һәм иҗтимагый кыйммәт ягы булса, шуның белән бергә форма, эстетика яклары да диалектик материалист язучыларның карамагыннан читтә калырга тиеш түгел»[3] яки «...идеология ягыннан югары куелышы нигезендә форманың камиллеге табылырга тиешле»[4]. Дөрес, мәсьәләнең бу ягына Ибраһимов әсәрләрендә Плеханов хезмәтләрендәгечә үк киң урын бирелмәгән.

Г. Ибраһимовның марксистик эстетик карашларының формалашуында Плеханов хезмәтләренең роле зур. Ләкин Ибраһимов һәрбер мәсьәләдә тулысынча Плехановның карашын кабул итте дию дөрес булмас иде. Аның «бишбуын», «социологик эквивалент», «сәнгатьне социология күзлегеннән чыгып тикшерү» кебек теоретик билгеләмәләрен кабул итсә дә, Ибраһимов мәсьәләгә болай якын килүнең кайбер җитешмәгән якларын да күрде. Эш аның Плеханов хезмәтләренә субъектив карашында түгел, билгеле. Замана үзе фән һәм галимнәр алдына проблемалар куйды. Әгәр Плеханов субъектив социологлар белән бәхәс вакытында сәнгатьнең гносеологик моментларына басым ясаган булса, Ибраһимов алдына заман икенчерәк таләпләр куйды: аңа сәнгатьнең социалистик җәмгыятьтәге ролен, урынын ачыкларга кирәк иде. Ибраһимов үзенең хезмәтләрендә аеруча игътибар иткән проблемаларның берсе — сәнгатьтә сыйныфчылык мәсьәләсе. Аны хәл итмичә, сәнгатьнең социалистик җәмгыятьтәге урынын һәм функцияләрен билгеләү мөмкин түгел иде. «Тарихи материализм каршында бу мәсьәләнең нигез ташларыннан берсе — идеология тамырлары җәмгыятьтәге төрле психология, сәяси-иҗтимагый төзелеш, икътисади мөнәсәбәтләр аркылы эшләп чыгару көчләренә барып, шуңа тукталуда булса, икенчесе — шул күп катлаулы, күп тармаклы вакыйгалар эченнән сыйныфчылык моментларын билгеләү, шуның тышка чыгу рәвешләрен ачып бирүдер»[5].

Бу мәсьәләгә әдип киң туктала. Иң беренче чиратта ул пролетар әдәбиятының асылын билгеләргә омтыла. Ибраһимов фикеренчә, бу төр сәнгатьнең асылын, сыйнфый нигезен ачыклау идеологик аспектта гына кайтарылса, әсәрнең әдәби эчтәлеге игътибар үзәгеннән төшеп калачак иде.

Шуңа күрә дә ул пролетариат әдәбиятының асылын эчтәлек һәм форма бердәмлегендә эзли. Үзенең бу өлкәдәге фикерләрен йомгаклап, Ибраһимов, «пролетариат әдәбиятында төп нигез булган, аны башка әдәбиятлардан аерган моментларның башлычалары: динамика, көрәш, сыйныфчылык, коллективизм, хезмәт вә интернационализм кебек берничә мәгълүм нәрсәгә кайтып каладыр ки, боларның һичбере әдәбият өчен генә ясалган хасиятләр түгел, бәлки пролетариатның сәясәтендә, хәрәкәтендә, фәлсәфәсендә, бөтен идеологиясендә уртак булган нигез ташларыдыр»[6], дигән нәтиҗә ясый.

Гомумән, Ибраһимов яңа әдәбиятның асылын ачыклауга киң урын биргән. Ә форма мәсьәләсе өстәнрәк кенә яктыртылган. Эш, билгеле, Ибраһимовның «чын пролетариат әдәбиятында форма мәсьәләсе һичбер вакыт иң беренче урынга куелачак түгел. Марксистның күзе фикергә, мөндәриҗәгә төшәчәк... Әдәбиятта гына түгел, тормышның башка якларында да марксизм алдан әзерләнгән формалар бирми»[7],— дип фикер йөртүендә генә дә түгел. Әгәр пролетариат әдәбиятын киң мәгънәдә

[1] Шунда ук. 429 бит.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук.
[4] Шунда ук.
[5] Шунда ук. 436 бит.
[6] Шунда ук. 452 бит.
[7] Шунда ук. 453—454 бит.

алып, аны буржуаз сәнгатьтән аермалы яңа форма сәнгать дип карасак, 20 нче елларда, бу яңа әдәбият формалашып кына килгәндә, ниндидер конкрет формалар билгеләү җирлексез тоелыр иде. Шуңа күрә дә Г. Ибраһимов, заманы өчен иң дөрес юлны сайлап, әдәбиятның төп үсеш юнәлешләренә генә тукталган: «...бу яңа калыпларның тенденциясе иң югарыда төп нигез аермаларны санаганда әйтелгән мәгънәләрне пролетариатка җиңел һәм көчле аңлату ягын эзләүдә, шуны табарга тырышуда булачак. Шулай ук бу калыплар кемнеңдер кабинетында уйлану юлы белән түгел, бәлки революция мәйданнарында, урам митингларында, кызыл казарма эчендәге әдәби түгәрәкләрдә, татар пролетариатының кайнаган урыннарында боларның направлениесе биреләчәк, шуннан кузгалып, профессиональ әдәбиятчылар каләмендә үзенең ахыр матурлыгын табачак. Ягъни: яшь көчләребез форманы китаптан яки үзләренең миләреннән эзләмәсеннәр, буның өчен массаның үзәгендә булсыннар, нинди калыпка салганда яхшы булачагын шунда өйрәнсеннәр!» [1]

Чыннан да, 20 нче елларда социалистик җәмгыять сәнгатенең конструктив формаларын билгеләргә иртәрәк иде әле. Бу елларда иске реакцион традицияләрдән котылу, иҗади мирасның файдалы якларын үзләштерү һәм аны социализм төзү коралына әверелдерү кебек мәсьәләләр мөһимрәк иде. Алда торган шушы проблемалардан чыгып, Г. Ибраһимов үзенең төп позициясен ачыклады: мирастан тулысынча баш тарту түгел, ә барыннан да бигрәк тарихи кыйммәте булган өлешен үзләштерү һәм файдалану дөрес. Яңа әдәбият тууы процессын күрсәтеп ул: «яңа иҗтимагый хәрәкәт яңа сыйныф, яңа идеология, яңа әдәбият тудырды, күктән төшмәде, диалектика буенча, элеккеләрнең эчендә акрынлап эзләнә-эзләнә өлгерде» [2] — диде.

Г. Ибраһимовның бу фикере ул чорда киң таралган һәм иске мирасны бөтенләе белән инкарь итүче нигилистик агымнарга капма-каршы иде. Ибраһимов сәнгать әсәрләренең әдәби кыйммәте турында онытмаска кирәклеген дә ассызыклап күрсәтте.

Йомгаклап, шуны әйтергә мөмкин, Ибраһимов 20—30 елларда бу чор эстетикасы өчен иң актуаль мәсьәләләрне күтәреп кенә калмады, ә бәлки, марксистик методологиягә таянып, аларның теоретик нигезләрен, асылын ачыклауга да зур өлеш кертте.

---

[1] Шунда ук, 456 бит.
[2] Шунда ук, 464 бит.

Әнвәр Шәрипов,
филология фәннәре кандидаты

# ИҖАДИ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ТАМЫРЛАРЫ

Борынгы Болгар дәүләтенең якын һәм ерак күршеләре белән тыгыз экономика, сәүдә мөнәсәбәтләре болгар культурасы һәм әдәбияты белән әлеге халыклар культура-әдәбиятлары арасында турыдан-туры бәйләнышлар урнашуга нигез булган. Гомумән, Идел буендагы төрки халыкларның гарәпләр белән элемтәсе ерак гасырларга барып тоташа. Рәсми рәвештә ислам кабул ителгәнгә кадәр үк инде болгар кешеләрен Гарәбстан белән сәүдә һәм культура мөнәсәбәтләре бәйләгән. Билгеле булганча, 922 елда рәсми төстә ислам дине кабул ителүе, бер яктан, Идел буенда үзәкләшкән Болгар дәүләте төзелүен тизләтсә, икенче яктан, Болгар дәүләте белән Багдад хәлифәлеге арасындагы һәртөрле мөнәсәбәтләрнең нык көчәюенә китерә. Ике дәүләт арасында илчеләр йөри башлый, болгар укымышлыларының Гарәбстанга белем алырга, хаҗ кылырга йөрүләре ешая.

IX—X гасырларда Идел буе төркиләре арасында уйгур, гарәп, еврей һ. б. язудагы әсәрләр таралган була. Тора-бара исә гарәп язуы өстенлек ала һәм башка язуларны бөтенләй кысрыклап чыгара. Болгар мәктәпләрендә гарәп теле укыта башлыйлар. Гарәп әлифбасы мәгърифәтнең үсүенә этәргеч ясый, болгарларны Көнчыгышның дөньякүләм әһәмияткә ия булган фән, культура казанышлары белән таныштыра. Болгарлар арасында, беренче чиратта, әлбәттә, дини әдәбият — коръән, хәдис җыентыклары килеп керә. Әмма шуның белән берләттән бу чорда ук Идел буенда атаклы гарәп шагыйрьләре һәм әдипләренең әсәрләре дә таралгандыр дип уйларга мөмкин.

XI—XIII гасырларда гарәп теле богарлар арасында фән һәм әдәбият теленә әверелә. Идел буена мәшһүр гарәп галим һәм шагыйрьләре әл-Җаһиз (767—878), әл-Мотәнәбби (965 елда вафат), әл-Хәмадани (969—1007), Әбүл Галә әл-Мәгарри (973—1057, әл-Назили (1111 елда вафат була), әл-Харири (1054—1122) һәм башкаларның әсәрләре дә килеп җиткән булырга кирәк. Шушы чорда ук болгарлар арасында гарәп әдәбиятының мәшһүр әсәре — «Мең дә бер кичә» әкиятләре киң таралыш ала.

Ул чорда гарәп культурасы Көнчыгыш илләрендә иң югары үсешкә ирешкән культура булып санала. Болгар дәүләте һәм анда яшәгән төрки халыклар да, әлбәттә, аның йогынтысыннан читтә кала алмаган. Болгар галим-укымышлылары гарәп телен шул дәрәҗәдә өйрәнгән һәм белгәннәр ки, алар бу телдә иркенләп сөйләшү генә түгел, бәлки әдәби һәм фәнни хезмәтләр дә иҗат иткәннәр. Мәсәлән, XIII гасыр башында Гыйрактагы Мосул шәһәрендә Болгардан килгән ике галим — Таҗетдин ибне Юныс әл-Болгари һәм аның энесе Хәсән ибне Юныс әл-Болгари яшәгән. Шулардан Таҗетдин ибне Юныс әл-Болгари гарәп телендә фармакология фәне буенча «Әттирьяк әл-Кәбир» («Агуга каршы дарулар») исемле китапны язган. Ул китапны энесе Хәсән 1220—1221 елда заманның зур врачы Бәдретдин Мәхмүд ибне Госман өчен күчереп биргән[1]. Шушы чорда яшәгән болгар шагыйре Кол Гали үзенең мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасын иҗат иткәндә гарәп әдәби-язма чыганакларыннан да файдаланган[2].

[1] Таһирҗанов Г. Тарихтан — әдәбиятка. Казан, 1979. 38—39 битләр.
[2] Хисамов Н. Ш. Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул али. М., 1979, 32 бит.

Шундый ук тыгыз бәйләнеш Урта Азия халыклары һәм беренче чиратта фарсы әдәбият-культурасы белән дә күзәтелә. Ул чорда, мәсәлән, болгар укымышлыларының Бохара, Сәмарканд, Гәзнә, Нишапур, Балх, Мәрвә кебек шәһәрләргә барып, белем алып кайтулары киң таралган булган. Ә ул укымышлылар белән Идел буена Урта Азия халыкларының язма әсәрләре дә кайткан.

Фарсы әдәбияты X—XV гасырларда, билгеле булганча үзенең классик чорын кичерә. Ул гасырлардагы фарсы филология фәне һәм поэзиясенең торышын соңыннан бөтен дөньяга танылган мәшһүр галим һәм шагыйрьләр билгели. Урта Азия һәм Иран халыклары белән тыгыз экономик-сәүдә мөнәсәбәтләрендә яшәгән болгарлар һәм аларның язма әдәбияты да фарсы әдәбияты йогынтысыннан читтә калмагандыр, күренекле фарсы әдипләренең әсәрләре Болгар иленә дә килеп җиткәндер. Мәсәлән, «Кәлилә вә Димнә» әсәренең инде шул ук чорда Болгар җирендә укылып йөргәнлеге турында мәгълүматлар бар.

XII—XIII гасырларда фарсы поэзиясендә мәшһүр шигъри әсәргә җавап язу күренеше барлыкка килә һәм соңга таба ул билгеле бер традициягә әверелә. Мәсәлән, Низаминың мәшһүр «Хәмсә»се (биш поэмасы) иҗат ителгәннән соң (1173—1203 еллар), аңа җавап итеп, Әмир Хөсрәү Дәһләви исемле икенче бер фарсы шагыйре үз «Хәмсә»сен яза (1299—1302 еллар). һәм менә, соңгырак чорларда булса кирәк, болгар-татар әдәбиятына да шуңа охшаш күренешләр килеп керә.

«XIII—XIV гасырлардагы төрки әдәбиятта,— дип яза А. Краубаева,— үзенең үткәненә карата көчле кызыксыну туу хас. Гали, Котб, С. Сараи кебек әдип һәм шагыйрьләр үзләрен уратып алган чынбарлыктан борынгы әдәби әсәрләрдә сурәтләнгән вакыйга һәм күренешләргә охшаш вакыйгалар табарга тырыштылар. Бу исә аларның үзләренчә «үткәннәренә кире кайтулары» иде. Әлеге әдипләр үзләреннән алда язылган әсәрләрне [1] аңларга һәм үз телләрендә «сөйләтергә», аларны үз телләренә күчерүдә камиллеккә һәм зур осталыкка ирешергә омтылдылар. Үзләренә өлге итеп алар гуманистик фарсы әдәбиятын, барыннан да элек үлемсез Фирдәүси, гуманистик юнәлештәге әдәбиятның иң югары ноктасы булган Низами, поэзиясендә социаль протест идеяләрен чагылдырган Сәгъди һәм башкаларның әсәрләрен алдылар» [2].

Фарсы әдәбиятыннан өлге алып язу XIII—XIV гасырлар болгар-татар әдәбиятында иҗади төстә бара. Бу нәрсәдә, классик фарсы поэзиясендәге кебек үк, сәнгатьчә эшләнгән яңа әсәрләр тудырырга омтылу һәм мәшһүр фарсы шагыйрьләре белән сәнгатьлелектә, осталыкта ярышырга теләү, хәтта аларны уздырырга тырышу, гомумән, төрки теленең бөтен мөмкинлекләреннән тулысынча файдалану моменты да бар.

XIII—XIV гасыр төрки әсәрләренең барысында да диярлек, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ыннан алып С. Сараиның «Гөлестан бит-төрки» әсәренә кадәр, тегә яки бу күләмдә фарсы әдәбиятына нәрү моменты чагыла. Бу әсәрләрдә нәреп язуның төрле формаларын табарга мөмкин.

Иң элек шуңа игътибар итәргә кирәк: Кол Гали үз халкының фольклорына, бай поэтик мирасына нигезләнеп иҗат иткән. Шул ук вакытта әсәрдә башка әдәбиятларның да йогынтысы сизелә. Мәсәлән, Н. Хисамов шагыйрьнең «Кыйссаи Йосыф»ны язганда, Фирдәүси поэмасыннан тыш, Абдулла Әнсариның «Әнис-эл-мөридин» әсәренә һәм фарсыча «Кыйссас-эл-әнбия» китабына да таянып эшләгәнен искәртә [3]. Кол Галинең бу поэманы күпмедер дәрәҗәдә Фирдәүсинең фарсы телендәге «Йосыф вә Зөләйха»сына төркичә җавап рәвешендә язган булуы да мөмкин.

«Кыйссаи Йосыф» әсәре төрки телдәге башка әдәбиятларга зур йогынты ясаган. «Бу поэма Болгар илендә генә түгел, аның тирә-күршесендә дә тиз таралган булса кирәк,— ди Г. Таһирҗанов.— XIII гасырда ук инде Мәхмүд Кырымлы исемле Кырым шагыйре Гали поэмасының кыпчак телендәге вариантын язган. Бу вариант үз чиратында шул ук XIII гасырда төрек шагыйре Хәлил углы Гали тарафыннан анатолий төрекләре теленә тәрҗемә ителгән.

Моннан тыш Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын XIII гасырның икенче яртысында Акшәһәрдә яшәүче шагыйрь Шәйяд Хәмзә анатолий төрекләре теленә тәрҗемә

---

[1] Бирәдә барыннан да элек классик фарсы поэзиясе үрнәкләре күздә тотыла.

[2] Краубаева А. Идейно-художественные особенности «Кыйсас Рабгузи» и «Мухаббат-наме». Автореферат кандидатской диссертации. Алма-Ата, 1974, 5—6 битләр.

[3] Хисамов Н. Ш. Искә алынган хезмәт, 32—35 битләр.

иткән; ә Шәйяд Хәмзәнең «Йосыф вә Зөләйха»сы үз чиратында башка төрек шагыйрьләренә ияреп язар өчен материал булып торган» [1].

«Кыйссаи Йосыф»та булган аерым моментлар, аерым поэтик детальләр XVI—XVIII гасыр татар шагыйрьләре Мөхәммәдьяр, Сәйяди, Г. Утыз Имәни иҗатларында да кабатлана.

Идел буендагы төрки телле әдәбият Алтын Урда чорында да үз күршеләре белән тыгыз элемтәдә тора. Монголлар һөҗүме, мәгълүм булганча, җирле халыкларга зур һәлакәт алып килә. Әмма ул җирле культура, Идел буендагы төрки телле әдәбият үсешен тулысынча туктата алмый. Төрле товар, чимал белән бергә Идел буена гарәп авторларының әсәрләре, фәнни һәм әдәби китаплар да килә. Мәсәлән, Нәҗметдин әз-Заһидиның (1260 елда вафат) «Коният әл-мөния» исемле гарәпчә әсәренең 1319 елда күчерелгән нөсхәсе 1967 елда Рязань өлкәсенең Кадом районында табылды [2]. Мондый мисалларны, әлбәттә, тагын китерергә дә мөмкин булыр иде.

Гарәп теленең мәдрәсәләрдә укытылуы, болгар-татар әдипләренең гарәп һәм фарсы телләрен тирән үзләштерүе нәтиҗәсендә бу чорда гарәп теле дин һәм фән теле, ә фарсы теле — поэзия, нәфислек теле булып саналган. Мәсәлән, 1333 елны Сарай шәһәренә килгән сәяхәтче Ибн Батута башкала укымышлылары җыелган мәҗлесләрдә гарәп, фарсы һәм төрки телләрдәге поэтик әсәрләрдән берәр юл алып шигырь әйтешү, ягъни «мөләммагъ» ярышлары оештырылу турында хәбәр итә [3]. Мөләммагъ ярышларында катнашучы кеше бу телләрне үз ана теле кебек яхшы белгән, чит телләрнең һәм әдәбиятларның төсмер-нечкәлекләренә бик сизгер булган, әлбәттә.

Бу чорда төрле телдә язган авторларның бер үк легенда яки риваятьләр нигезендә мөстәкыйль әсәрләр иҗат итү очраклары мәгълүм. Әлеге күренеш әдәбияттагы «күчмә сюжет» алымына барып тоташа. «Күчмә сюжет» XIII—XIV гасырлардагы болгар-татар әдәбиятында да үзенең чагылышын таба. Шундый әсәрләрдән, мәсәлән, «Кисекбаш китабы» (XIII—XIV) белән Хисам Кятибның «Җөмҗөмә солтан» дастанын (1370) бер үк сюжетны файдаланып, уртак легендага таянып иҗат ителгән әсәрләр дип карарга мөмкин.

«Кисекбаш китабы» турында әдәбият белемендә төрле фикерләр әйтелгән. Мәсәлән, Ш. Мәрҗани аны урта гасырлар болгар-татар әдәбияты ядкаре итеп саный. Бохара һәм Сәмәрканд китапханәләрендәге кульязмаларны өйрәнеп, ул «Кисекбаш китабы»ның болгар-татарлардан тыш башка төрки халыкларда очрамавы, әсәрнең теле болгар-татар каберташ язмалары теленә охшаш булуы турында яза [4]. «Кисекбаш китабы»ның тел үзенчәлекләрен өйрәнгән Я. Әхмәтгалиева әсәрнең 19 кульязмасыннан 17 сенең Казан белән бәйле булуын күрсәтә [5].

Әсәрнең үзе турында да фикерләр төрле. «Кисекбаш турындагы легендаларның бер тармагы көньяктагы госманлы төрекләренең борынгы халык риваятьләрендәге мифологик образларга, икенче тармагы — Казан татарлары фольклорына барып тоташа,— дип яза, мәсәлән, Ш. Абилов.— Әмма шулай булуга да карамастан, безнеңчә, «Кисекбаш китабы» шул үк исемдәге фарсы әсәренең иске татар теленә иҗади тәрҗемәсе булып тора. Бу китапның тәрҗемә булуына үз чиратында әсәр кульязмаларының берсе күрсәтеп тә тора: аңарда фарсы телендәге төп нөсхәнең исеме дә сакланып калган — «Сәр Бурда» — «Киселгән баш» [6].

Я. Әхмәтгалиева исә бу әсәрнең башка чыганаклар белән бәйләнешен күрсәтә: «Кисекбаш китабы» дастанының эчтәлеге белән танышканда аның әлеге популяр сюжетка язылган урта гасырдагы башка әсәрләр (Хисам Кятибның «Җөмҗөмә солтан»ы, Фәридетдин Гаттарның «Җөмҗөмә-намәсе» һ. б.) белән охшаш булуы ачыклана» [7]. Шушындый ук фикерне Г. Таһирҗанов та куәтли. Ул «Кисекбаш китабы»ның Х. Кятиб әсәреннән рухланып иҗат ителүен күрсәтә [8].

---

[1] Таһирҗанов Г. Искә алынган хезмәт, 48—49 битләр.
[2] Госманов М. Тарихтагы тирән эзләрдән. «Казан утлары», 1970, 5 сан, 164 бит.
[3] Таһирҗанов Г. Әдәбият тарихында иҗтимагый-мәдәни мөнәсәбәтләрнең роле. «Казан утлары», 1975, 8 сан, 148 бит.
[4] Бу мәгълүматлар «Габдулла Тукай» җыентыгындагы Ш. Абилов мәкаләсеннән алынды. Казан, 1968, 166 бит.
[5] Ахметгалеева Я. С. Исследование языка памятника тюркоязычной письменности «Кисекбаш китабы». Автореферат кандидатской диссертации. Алма-Ата, 1978, 4 бит.
[6] Абилов Ш. Искә алынган хезмәт, 166 бит.
[7] Ахметгалеева Я. С. Искә алынган хезмәт, 5 бит.
[8] Таһирҗанов Г. Күрсәтелгән хезмәт, 51 бит.

Х. Кятибның «Җөмҗөмә солтан» дастаны исә (1370) күпмедер дәрәҗәдә шушы ук күчмә сюжетка нигезләнеп язылган. Е. Э. Бертельс, мәсәлән, әсәрнең сюжеты борынгы легендадан һәм шуңа нигезләнеп язылган Ф. Гаттарның «Җөмҗөмә-намә»сеннән алынганлыгын күрсәтеп үтә[1].

Дастан нигезенә салынган легенда турында профессор Х. Госман: «Ул бик борынгы еврейлар теләндә йөргән, аннан гарәпләргә кергән, гараплардән Иранга үткән, аннан Хисам Кятиб Идел буена алган һәм мондагы иҗтимагый тормыш материалы белән баетып җибәргән. Әсәрдә шулай ук философик фикер, шигъри идея ягыннан карaганда да, башка халыклардан үзләштерелгән, алардан орлык алып, үстереп җибәрелгән юллар очрамый калмый. Хисам Кятиб, әгәр аны төбендә суфичылык юлындагы шагыйрь дип танысак, хәтта идея позициясе белән бөтенләй бүтән якта торган, материалистик карашка тартымлы шагыйрьләрдән дә үзенә өлеш ала» — дип яза[2].

Әсәрдә Җөмҗөмә үлеп «теге дөньяда» тәмугка эләккәч, анда ниләр күрүен сөйли. Х. Госман, мәсәлән, мондый хикәяләүнең төрле халык әдәбиятларында еш очравын билгеләп үтә: «Борынгы рус әдәбиятында, мәсәлән, «Хождения богородицы по мукам» (XII гасыр) әсәре шундыйлардан...— дип яза ул.— Хисам Кятиб поэмасы Зу «апокриф»ка билгеле дәрәҗәдә охшаш. Бу охшашлык аларга сюжет чыганагы булган борынгы легендаларның уртаклыгыннан килә. Шушы ук сәбәп аркасында ул хәтта Алигъери Дантеның (1265—1321) «Илаһи комедиясе» белән охшаш. Югыйсә, бу әч автор бер-берсенең әсәрләрен укып, бер-берсеннән күчерге алмаганнар. Аларны идея-эстетик яктан да, әлбәттә, бер дәрәҗәгә куеп булмый»[3].

Х. Госман бу әсәрдә ияреп язуның бер төре булган контаминация алымы кулланылуын исбатлый. «Контаминация нинди дә булса шагыйрьнең берәр әсәреннән теге яки бу юлларны, хәтта строфаларны икенче берәүнең үз әсәренә органик үреләреп җибәрүеннән гыйбарәт,— дип искәртә ул.— ...Борынгы Идел буе төрки шагыйрьләрендә контаминация бөек фарсы шагыйрьләреннән үз иҗатларына орлык алу төсендә барган. Хисам Кятибка килгәндә, а[illegible]рда Рудакидән (X гасыр шагыйре) һәм Гомәр Хәйямнан (XI гасыр шагыйре) контаминация юлы белән алынган дип әйтерлек юллар очрый».

«Җөмҗөмә солтан» кулъязмаларының күпчелеге Идел буе татарлары кулында булган[4]. Әсәр 1881 елда Казанда басылып та чыккан. 1977 елда Татарстанның Әгерҗе районында дастанның тагын бер кулъязмасы (бүгенге көндә билгеле булган күчермәләрнең иң борынгысы) табылды. Шуның белән бергә «Җөмҗөмә солтан»ның казакъ һәм кыргызлар арасында сакланган вариантлары булуын да искәртеп китәргә кирәк. (Мәсәлән, XIX гасырда Мәүләкәй Юмачиков «Җөмҗөмә солтан» поэмасын казакъ теленә тәрҗемә иткән. (Кара: Г. Таһирҗанов. Әдәби бәйләнешләр һәм аларның нәтиҗәләре.— «Казан утлары», 1975, 10 сан, 132 бит.)

Шушы ук чорда әдәби әсәрләр тудыру өчен чимал-чыганак ролен халык легендалары гына түгел, ә язма әдәби әсәрләр дә үти башлаган. Шундый күренешнең типик бер үрнәге — Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасы (1342).

Бу поэма — уртак сюжетка нигезләнгән әсәр. Хөсрәү-Ширин сюжетына Котб төрки әдипләрдән беренче булып мөрәҗәгать итә һәм нигез итеп фарсы-әзербайҗан шагыйре Низаминың (1141—1209) «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын (1181) ала. Күп санлы тикшеренүчеләрнең күрсәтүенчә, автор Низами әсәрен иҗади тәрҗемә итү белән генә чикләнмичә, аңа җавап-назирә язган. Х. Миннегулов Низами поэмасы белән Котб әсәрен үзара чагыштырып, мондый нәтиҗә ясый: «Низами поэмасы Котб дәверендәге чор һәм җирлек ихтыяҗларына яраклаштырылган, төрки шагыйренең көчле иҗади эшкәртүенә дучар булган. Нәтиҗәдә, югары художестволы мөстәкыйль яңгырашлы өченчел бер чынбарлык туган. Анда Котбның үз тавышы ишетелә, үз поэтик фикерләве, индивидуаль стиле ярылып ята... Ул тәрҗемә, назыйрә, контаминация, оригиналь һәм башка иҗат принциплары белән тудырылган катлаулы

[1] Бертельс Е. Э. Литература народов Средней Азии от древнейших времен до XV в. н. э.— «Новый мир», 1939, 9 сан, 272 б.

[2] Госман Х. Татар әдәбияты тарихына материаллар. «Җөмҗөмә солтан». Казан, 1970, 25 бит.

[3] Госман Х. Татар әдәбияты тарихына материаллар. «Җөмҗөмә солтан». Казан, 1970, 17—18 битләр.

[4] Үз кулъязмалар Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты архивында (колл. 39, опись 1, с. б. 740), КДУ китапханәсендә (№ 1971 т., № 620 т.), Ленинградның Көнчыгышны өйрәнү институтында (10. 319 с. Т) саклана.

күренеш. Шуңа күрә Котб поэмасын ярымтәрҗемә, ярыморигиналь әсәр дип бәяләү хата булмастыр»[1].

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, кайбер галимнәр күрсәтүенчә, Котб Идел-Урал буйларында яшәп иҗат иткән шагыйрь. Х. Миннегулов, мәсәлән, «...без хаклы рәвештә «Хөсрәү вә Ширин» авторы (биредә сүз Котб турында бара — Ә. Ш.) төрки-татар вәкиле дип әйтә алабыз»,— ди[2].

XIII—XIV гасырларда башка әдәбиятлардан турыдан-туры тәрҗемә итү юлы белән дә әсәрләр язылган. Әлбәттә, алар сүзне-сүзгә тәрҗемә итү алымы белән генә барлыкка килмәгән; төрки авторлар тәрҗемә эшенә иҗади караганнар. XIV гасыр болгар-татар әдәбиятындагы шундый әсәрләрнең берсе — Сәеф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» поэмасы (1391) — шәрыкънең мәшһүр шагыйре Сәгъдинең фарсыча «Гөлестан» әсәренә ияреп язылган.

С. Сараиның бу поэмасы, тәрҗемә әсәре буларак, галимнәр тарафыннан шактый өйрәнелгән. Ф. Көпрүлүзадә, Ә. Нәҗип, Х. Госман, Н. Дәүранов, В. Рахманов, Х. Миннегулов кебек галимнәрнең тикшеренүләрендә күрсәтелгәнчә, «Гөлестан бит-төрки» — Сәгъди «Гөлестан»ының юлдан-юл тәрҗемәсе генә түгел. С. Сараи биредә тәрҗемә итүнең төрле формаларыннан файдаланган.

XIII—XIV гасырларда нәзирә язу практикасы төрки телләрендәге прозага да үтеп керә. Ул әсәрләрнең күбесе гарәп әдәбиятыннан үрнәк алып иҗат ителгәннәр. Алар арасында дини эчтәлектәге кыйсса җыентыклары да (коръән тәфсирләре, дини хикәяләр), дөньяви темага язылган әдәби-дидактик хикәяләрдән төзелгән китаплар да бар. Ә еш кына андый кыйсса җыентыкларында дини һәм дөньяви характердагы парчалар бер-берсе белән үрелеп биреләләр. Шундый китапларның берсе — Рабгузиның «Кыйсса-с-эл-әнбия» (1310) әсәре. Ул гарәп теленнән угыз-кыпчак теленә тәрҗемә ителгән.

Әсәрнең сюжеты борынгыдан ук гарәп-фарсы халыклары арасында сөйләнеп йөргән, ә аннан башка халыкларга да күчкән хикәя һәм легендалардан төзелгән. Аңарда темалары, идеяләре һәм эчтәлекләре төрле-төрле булган 60 ка якын аерым кыйссалар (әсәрнең кульязмасында — 42, басма нөсхәсендә — 64 кыйсса) теркәлгән. Аларны нигездә ике төркемгә бүләргә мөмкин: 1) табигать, аның аерым күренешләре һәм законнары, кешенең барлыкка килүе турындагы фантастик-мифик һәм философик хикәяләр, 2) ельязма характерындагы легенда-хикәяләр, телдән сөйләнеп йөри торган әдәби әсәрләр, шигъри парчалар. Шунысы игътибарга лаек: Рабгузи әсәренең тематикасын, идея эчтәлеген билгеле торган төп иҗат чыганагы булып халыкның телдән сөйләнеп йөртелә торган, тормыш, чынбарлык белән бәйләнгән тарихи һәм реалистик кыйссалары санала. Ә аларның күбесе күчмә сюжетлы кыйссаларның төрки телләрдәге эшкәртмәсе булып тора. Мәсәлән, җыентыктагы Локман ага, Зөлкарнай, Давыт, Сөләйман, Аһил Хәйруан хакындагы, карлыгач, җир һәм утның үзара бәхәсе турындагы хикәяләр күп халыкларда сөйләнеп йөртелә торган кыйссалардан алынганнар. Ә андагы «Йосыф кыйссасы»н исә Рабгузи үзе ук шул чордагы язма чыганакларга, аерым алганда, «Тәфсир» китабына, Әбү Исхак Нишапуриның «Кыйсса-с-эл-әнбия»сенә, Шәех Хөсәен Басарига, Габдулла бине Габбаска һәм башкаларга таянып язганлыгын искәртә[3].

XIV гасыр болгар-татар әдәбиятының икенче бер проза әсәре — Мәхмүд Болгариның «Нәһҗ-эл-фәрадис»ы (1358) ияреп язуның нәзирә алымына гына түгел, бәлки башка төрләренә дә нигезләнеп иҗат ителгән. Шунысы кызыклы, автор үзен бу әсәрдә «мосанниф» (үз башыннан уйлап язучы) дип түгел, ә бәлки «җамигъ кыйлучы» (җыйнаучы, бер урынга туплаучы) дип күрсәтә. Бу үзе генә дә инде «Нәһҗ-эл-фәрадис»тагы күп хикәятләрнең башка авторлардан алынганлыгын аңлатып тора. Ул чыганаклар китапның һәр бүлегендә күрсәтеп барылган, китап ахырында да бирелгән. Аларның күбесе — борынгы Хәрәзм, Таҗикстан, Әзербайҗан һәм башка төбәк авторларының китаплары.

Бу хезмәтләрдән Мәхмүд Болгари төрле формаларда файдаланган. Мәсәлән, Әбү-

---

[1] Миннегулов Х. Ю. Котб иҗаты. Казан, КДУ нәшрияты, 1976, 56—57 битләр.
[2] Шунда ук, 19 бит.
[3] Краубләева А. Күрсәтелгән хезмәт, 13 бит.

Гали әл-Әвашинең «Нисаб әл-әхбар»ыннан, Имам Баһавиның «Мәсабих»ыннан берничә өзекне тәрҗемә итеп алган.

Тәрҗемә алымнары да төрле биреда. Шуларның берсе — хикәяләрне фикер агышыннан тәрҗемә итү. Автор беренче урынга төп фикерне бирүне куя, шуңа күрә аерым очракларда ул үзеннән өстәмә аңлатмалар китерүне дә кирәк саный. Бу яктан аларны ирекле тәрҗемәләр дип тә атарга мөмкин. Тәрҗемә алымнарының тагын берсе — оригиналның аерым урыннарын сайлап тәрҗемә итү. Автор бу очракта кыйссаның төп фикерен ачыклый торган урыннарны гына тәрҗемә итә (мәсәлән, «Тәкәббер патша», «Габид» кыйссалары).

«Нәһҗ-эл-фәрадис»тә шулай ук Шәрыкнең бик борынгы китапларыннан алынган хикәяләр дә бар. Андыйларга, мәсәлән, һарут һәм Марут, Каин һәм Кабил, Сөләйман патшаның оча торган тәхете, үлгән шәһәр һ. б. турындагыларны китерергә мөмкин.

«Мәхмүд Болгари әсәре тулысынча тәрҗемә ителгән текстлардан гына тора дип уйлау дөрес булмас иде,— дип күрсәтә Б. Яфаров.— Анда авторның үз оригиналь әсәрләре дә аз түгел. Тарихи вакыйгалар турында сөйли торган иң алдагы ике бүлекне без авторның оригиналь иҗаты дип исәплибез... Шулай ук башка бүлекләрдәге фасыл башларында, бетем өлешләрендә һәм башка урыннарда авторның үз фикерләүләре аз түгел икәнлеге шик тудырмый»[1].

«Нәһҗ-эл-фәрадис» әсәре, нигездә, Идел буендагы болгар-татар халкы арасында таралган булуы белән дә характерлы. «Бүгенге көндә,— дип күрсәтә Ш. Абилов,— «Нәһҗ-эл-фәрадис»нең татар халкы арасында табылган 8 кульязмасы Советлар Союзында саклана. Аларның барысы да татар хаттатлары тарафыннан күчереп язылган һәм урта гасыр болгар-татар әдәбияты җыентыкларына кертелгән. «Нәһҗ-эл-фәрадис»нең теле, стиле һәм образлар системасы татар әдәбияты традицияләренә якын тора»[2].

Мәгълүм булганча, Идел буе болгар-татар халкы арасында бу чорда башка төбәкләрдә яшәгән төрки авторларның әсәрләре дә киң таралыш алган. Төрек шагыйре Гашыйк-пашаның «Гариб-намә» поэмасы (1329) әнә шундыйлардан санала.

Зур күләмле бу поэма үз чорының күренекле энциклопедик характердагы әсәрләреннән берсе булган. Гашыйк-паша аны Җ. Руминың мәшһүр «Мәснәви»ләренә ияреп язган. Әсәр ун бабка бүленә, һәр бабы ун дастаннан тора; ягъни «Гариб-намә» барлыгы йөз дастанны эченә ала. Һәр дастан аерым бер мәсьәләне яктыртуга багышланган. Мәсәлән, анда философик мәсьәләләр дә (дөньяда һәр нәрсәнең, һәр тереклекнең сәбәпсез барлыкка килә алмавын исбатлавы, тереклектә кояшның, яңгырның, һаваның әһәмияте зурлыгы турындагы фикерләре һ. б.), тормыш-көнкүреш мәсьәләләре дә (кәсепне, һөнәрле булуны алга сөрү, бала тәрбиясе, дөньяны танып-белү турындагы фикерләре), тел, сәнгать мәсьәләләре дә яктыртыла. Бүгенге көнгә «Гариб-намә»нең бөтен дөньяда барлыгы 27 кульязмасы барлыгы билгеле. Шуларның унбише СССР территориясендә саклана. Шушы 15 нөсхәнең 12 сен татар хаттатлары күчергән. Болардан тыш әсәрнең күп нөсхәләре Төркиядә саклануы мәгълүм. Шуңысы игътибарга лаек, поэманың Төркиядә сакланган нөсхәләрендә барлыгы 12 мең шигъри юл икәнлеге әйтелсә, Казанда сакланган ике нөсхәдә исә 16 мең шигъри юл. Әсәрнең бу артык 4 мең юлы болгар-татар әдипләре тарафыннан иҗат ителгәндер, дип уйларга мөмкин. Бу мәсьәлә әле киләчәктә аерым өйрәнүне сорый[3].

Бу чордагы культура бәйләнешләренең ни дәрәҗәдә тыгыз булуын шул елларда төзелгән сүзлекләрдә дә күрергә мөмкин, чөнки сүзлекләр төрле халыкларның берберсе белән аралашуга, бер-берсенең телләрен, культурасын өйрәнүгә булган омтылышларына нигезләнеп эшләнгәннәр. Мәсәлән, шундыйлардан 1245 елда Мисырда төзелгән «Төркичә-гарәпчә сүзлек» игътибарга лаек. Ул Мисырда мәмлүкләр идарәсе башланыр алдыннан төзелгән.

1303 елда «Кодекус куманикус» («Коман мәҗмугасы») исемле сүзлек язылган. Күп тикшеренүчеләрнең күрсәтүенчә, ул — Венеция купецларының кыпчаклар белән сәүдә мөнәсәбәтләренә керергә омтылышының бер чагылышы. Ул ике дәфтәрдән

[1] Яфаров Б. А. Литература Камско-Волжских булгар X—XIV вв. и рукопись «Нахдж-эль фарадис». Автореферат кандидатской диссертации. Казань, 1950, 10 бит.

[2] Абилов Ш. Ш. О новонайденных списках памятника XIV века «Нахдж-эль-фарадис».— «Советская тюркология», 1977, № 2, 73 бит.

[3] «Гариб-намә» әсәре турындагы мәгълүматлар борынгы татар теле һәм әдәбияты белгече Э. Б. Булатовның шәхси архивыннан алынды.

тора: беренче дәфтәр латинча-фарсыча-команча сүзлек (барлыгы 1600 чамасы сүз), ә икенче дәфтәрдә кыпчакча-немецча сүзлек урнаштырылган.

XIII йөз ахырында яки XIV йөз башларында Ибне Мөһанна гарәп телендә «Китабе тәрҗемәне фарси вә төрки вә магулый» исемле сүзлек төзегән. Анда бу телләрнең грамматикасы да бирелә. Сүзлекең кереш өлешендә Ибне Мөһанна төрки тел грамматикасына шактый киң тукталa, аның фонетикасы һәм морфологиясе турында әһәмиятле белешмәләр бирә.

1313 елда Әбүхәйян Гарнати Каһирә шәһәрендә «Китаб-эл-идраке ли-лисан-эл-этрак» («Төрки телләргә аңлатмалар бирү китабы») исемле хезмәтен язган. Галимнәр күрсәтүенчә, бу сүзлектәге сүз хәзинәсе кыпчак, төрекмән телләренә якын тора. Моннан тыш тагын шушы чорларда билгесез авторларның «Булгату-л-моштак фи-лөгати-т-төрек вә-л-кыпчак» һәм Әттөхфәтү-з-зәкия фи-л-лөгати-т-төркия» исемле сүзлекләре дә төзелгән булган. Мондый сүзлекләр Идел буена да килеп җиткәннәр һәм Идел буе төрки халкының белемен арттыруда, аларны гарәп-фарсы культурасы һәм әдәбияты белән таныштыруда зур роль уйнаганнар.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: XIII—XIV гасырлар болгар-татар әдәбияты һәрдаим башка халык әдәбиятлары белән тыгыз бәйләнештә булып, башка әдәбиятлар белән үзара фикер-хис, сюжет, сәнгать чаралары алмашып яшәгән. Бу бәйләныш болгар-татар әдәбиятының иң борынгы чорында ук башлана һәм соңыннан, һәр чорның үзенчәлекләренә бәйле рәвештә, төрле юнәлештә, төрле дәрәҗәдә яшәп килә. Бу бәйләнеш барыннан да элек болгар-татар әдәбияты белән башка халыкларның үзара оригиналь әсәрләр алмашуларында һәм бер-берсеннән тәрҗемә итешүләрендә чагылыш таба. Шушы юл белән әлеге халыклар бер-берләренең әдәбиятларын үзара баетышалар, үстерешәләр.

Болгар-татар әдәбиятының башка әдәбиятлар белән бәйләнеше аның халыкара әһәмиятен, фәнни-методологик дәрәҗәсен күтәрүгә хезмәт итә, дөньякүләм әһәмиятле, күренекле әсәрләр белән таныштыра. Шуның белән беррәттән болгар-татар әдәбияты үз чиратында бөтен дөнья әдәби процессына үз өлешен кертә. Әдәбиятлар арасындагы мондый бәйләнешләр — халыкларның үзара дус-туган булып яшәргә омтылышларының да бер чагылышы.

# МӘРҖАНИ ТУРЫНДА ЯҢА СҮЗ

Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләренең фән, мәгариф, иҗтимагый фикер тарихыбыздагы урынына вакытында бик ачык бәя бирелгән. Габдулла Тукай: «Мәгарифтә әүвәл башлап адым салган, милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт»,— дип язып калдырган. Р. Фәхретдин, татарларда тарих фәне, Ш. Мәрҗани хезмәтләре нәтиҗәсендә әкият-риваятьләр дәрәҗәсеннән үсеп, фәнгә әйләнде, дигән. Җ. Вәлиди аны татар Геродоты — тарих фәненә нигез салучы дип атаган. Аның хезмәтләренә югары бәя бирүчеләр арасында без Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Сәгъди, Г. Газиз, Г. Чокрый, М. Гали, М. Акмуллаларны күрәбез. Соңгысы Ш. Мәрҗанинең замандашы булган, шул чорда аңа тиң галимнәр бөтен шәрык дөньясында юк дип санаган. Ш. Мәрҗани исеме, аерым хезмәтләре революциягә хәтле үк Һиндстан, Төркия, гарәп илләрендә билгеле булган, Европа ориенталистларына барып җиткән.

Зур галим, халкыбызның бөек улы турында без нәрсә беләбез дип сорау куелса, моңа җавап бик үк куандырырлык булмаячак. 16 томнан торган «Краткая историческая энциклопедия» дигән, урта кул тарихчылар турында да мәкаләләр урнаштырылган зур белешмәдә Ш. Мәрҗани турында ләм-мим сүз әйтелмәгән. Сәбәбе билгеле: Шиһап Мәрҗани иҗатының онытылып, тиешенчә өйрәнелми торуы. Югарыда исемнәре күрсәтелгән әдип, галимнәрнең Ш. Мәрҗани турында фикерләрен эченә алган, 1968 елда Х. Хисмәтуллин төзегән кечкенә генә җыентыкны искә алмаганда, соңгы елларда басылган аерым мәкаләләрне кертеп исәпләсәң дә, Мәрҗани турында бездә кулга тотып сөйләрлек хезмәтләр булмады. Дөрес, М. Госманов мәкаләләрендә, Я. Абдуллинның татар мәгърифәтчелеге турындагы хезмәтләрендә Ш. Мәрҗани иҗатын тирәнтен аңлап, аңа яңача килеп бәя бирү алга чыга башлады.

Мөнир Юсуповның әле генә Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән монографиясе[1] Ш. Мәрҗани иҗатын өйрәнүдә яңа этапның башлангычы булып тора.

Шәрык халыклары тарихында ориенталистикада ибн Халдун, әл-Бируни, ибн Рөшд кебек гигантлар белән беррәттән торырлык Ш. Мәрҗанинең иҗаты өйрәнелүдән читтә калып килүнең төрле сәбәпләре бар. Аларның кайберләре М. Юсупов монографиясендә дә күрсәтелә. Арада автор әйтеп бетермәгән сәбәпләр дә бар. Шуларның берсе — борынгы чыганакларның гарәп, фарсы телләрендә борынгы төркичә язылуы, бу язмаларның тарихчылар өчен кайвакыт үтә алмаслык киртә булуы. Сүз уңаеннан әйтеп үтү кирәк, шушы сәбәпләр аркасында без әдәбиятыбызның күп кенә истәлекләренә үтеп керә алмыйбыз.

Болар өстенә Ш. Мәрҗани мирасына тешләре үтә алмаган кайбер авторлар аның чалмасы белән генә көрәшүне уңай тапканнар, әнә шундый нигездән чыгып аны Каюм Насыйрига каршы куюга барып җиткәннәр. Бу төр «хезмәтләр» Ш. Мәрҗани иҗатын объектив бәяләүне тоткарлап килгәннәр, шул уңайдан аның исемен, иҗатын атлап үтүгә китергәннәр.

Ш. Мәрҗани мирасына үтеп керү өчен, гарәп телен белү өстенә, көнчыгыш халыклары тарихын, ислам культурасын, рус, Европа ориенталистикасы казанышларын үзләштергән галим булу сорала. М. Юсуповның әнә шундый галим икәнлеген монография ачык күрсәтә.

Ш. Мәрҗани — төрле өлкәләрдә тирән эз калдырган галим, шул ук вакытта ул педагог һәм философ та. Монографиядә аның күпкырлы эшчәнлегенең бер ягы, тарихчы буларак башкарган хезмәтләре генә тикшерелә. Ләкин, Ш. Мәрҗани турында беренче монография буларак, аның эчтәлеге исеменнән шактый киң булып чыккан.

Ш. Мәрҗани турында басылып чыккан әдәбиятка анализ ясау белән бергә М. Юсупов галимнең төрле өлкәләрдәге эшчәнлегенә дә экскурслар ясап үтә. Бу

[1] Юсупов М. Шигабутдин Марджани как историк. Казань, 1981.

үз чиратында галимнең иҗат портретын киңрәк ачуга китерә.

Монографиядә Ш. Мәрҗанинең нәсел-нәсебе, Бохара, Сәмәркандта уку еллары, Казан чорындагы эшчәнлеге шактый тулы ачыла, иҗат лабораториясе киң планда тасвирлана. Галимнең иҗаты шул заман җирлегендә, үз чоры шартлары күзгесендә анализлана. Мәрҗани турында элек дөнья күргән кайбер хезмәтләргә менә шул җитми иде. Ш. Мәрҗани мирасын анализлаганда М. Юсупов марксистик-ленинчыл методологиягә таяна, ә бу үз чиратында галимнең уңышларын, тарихта, фәндә тоткан ролен дөрес бәяләргә, шул ук вакытта аның тарихи чикләнгәнлеген, йомшак якларын, каршылыкларын дөрес бәяләргә юл ачкан.

Ш. Мәрҗани — энциклопедист галим. Ул гади тарихчы гына түгел, археолог һәм археограф та, нумизматист һәм палеограф та, этнограф һәм историограф та. Монографиядә Ш. Мәрҗанинең менә шул күпкырлы эшчәнлеге шактый киң күрсәтелә. Тарихчы буларак галимне болгар-татар Идел буе, Урта Азия халыкларының килеп чыгышы, тарихи үсеш юлы да, ислам культурасы, Шәрык дөньясы да кызыксындырган, әнә шул өлкәләрне өйрәнүдә ул шактый зур эш башкарган, яңа сүз әйткән. Аның гыйльми колачы бик зур дәверне — VII гасырдан алып XIX гасыр ахырына хәтле чорны иңли.

Ш. Мәрҗани хезмәтләре фәннилеге һәм куйган проблемаларының актуальлеге белән бүгенге көн өчен дә әһәмиятле. Мәсәлән, татар халкының килеп чыгышы проблемасын беренче мәртәбә Ш. Мәрҗани куйган, аны чишү өчен ул беренче зур адымнар ясаган. Халкыбыз этногенезын тикшергәндә, билгеләгәндә без аның хезмәтләренә таянмыйча гына әлеге мәсьәләгә ачыклык кертә алмаячакбыз.

Ш. Мәрҗани ориенталистикада нәрсә ул «гарәп культурасы» дигән мәсьәләне күтәреп чыккан, шуны нигездә дөрес хәл иткән галим дә. Ул, беренчеләрдән буларак, гарәп культурасы дигән нәрсәнең ислам динен кабул иткән халыклар тудырган культура булуын, ислам культурасы белән гарәп халыклары культурасының бер үк булмавын күрсәтә. Фәндә шушы көнгәчә гарәп телендә язылган барлык мирасны гарәп культура мирасы дип карау яшәгәнлеген искә алсак, Мәрҗанинең бу мәсьәләне беренче күтәреп чыгуы, аңа фәнни дөрес бәя бирүе үзе гаять әһәмиятле ачыш булып тора.

Ш. Мәрҗани — «Шәрык белән Гарәп» мәсьәләсен беренчеләрдән буларак дөрес хәл иткән галим. Ул бөтен дөнья культурасын Европа халыклары тудырган, Шәрык халыклары гомер-бакый артта калган дип алга сөрелгән теорияләрнең реакцион нигезен күрә алган. Моның нигезендә Ш. Мәрҗанинең шәрык культурасын тирән белүе, шул ук вакытта Европа культурасыннан яхшы хәбәрдар булуы ята. Бу яктан ул Европа ориенталистларыннан да, шәрык зыялыларыннан да өстенрәк, объективрак булган.

Автор күрсәтеп үткәнчә, кешелек җәмгыятенең үсешенә карашы буенча Ш. Мәрҗани тарихи материализмнан ерак торган. Азатлык, бәхет өчен көрәшнең нигезендә сыйныфлар көрәше ятуын күрә алмаган. Ул халыкны фән казанышлары белән таныштырып, мәгърифәт юлы белән генә азатлыкка, бәхеткә чыгуны алга куйган. Тарихны аңлауда идеалистик позицияләрдә торуга карамастан, халыкны аң-белемгә өндәве, һәрнәрсә алла кулында, язмыштан узмыш юк дигән өметсезлек теорияләренә каршы чыгуы белән, Ш. Мәрҗани карашы, һичшиксез, заманы өчен прогрессив булган.

Монографиядә Ш. Мәрҗанинең заманы, Урта Азиядәге рухи тормыш, галим яшәгән чорның инфраструктурасы киң тасвирлана. Бу хәл галимнең эшчәнлеген һәм көрәшен калкурак, тулырак тасвирлауга ярдәм иткән.

Бу хезмәт совет ориенталистикасында яңа сүз диеп бәяләнүгә лаек. Дөрес, анда Ш. Мәрҗанинең күп кырлы эшчәнлегенең бер ягы гына тикшерелә. Киләчәктә Ш. Мәрҗанинең фәлсәфи карашларын, тел, әдәбият, сәнгать турында фикерләрен, педагогик эшчәнлеген өйрәнү буенча да хезмәтләр язылыр дип өметләнергә кирәк.

М. Юсупов монографиясеннән соң бу өлкәдә эшләячәк тикшеренүчеләргә җиңелрәк булган. Беренчедән, бу монографиядә Ш. Мәрҗани иҗатына һәм мирасына бәя бирү — үзе зур күрсәткеч. Шуның өстенә, М. Юсупов галимнең бөтен мирасын диярлек чагылдырган: аерым китап булып басылган, шулай ук кулъязма хәлендә сакланган, яисә безнең көннәргә хәтле сакланмаган дип санала торган барлык хезмәтләрен барлап чыккан, аларга анализ биргән, ниһаять, Ш. Мәрҗани турындагы әсәрләрнең бай библиографиясен төзегән.

Монографиянең, һичшиксез, югары бәя-

ләнергә тиешлеге — әле анда аерым төгәлсезлекләр юк дигән сүз түгел. Мәсәлән, автор Ш. Мәрҗани Казан, Петербург ориенталистлары һәм тарихчылары мәктәбендә үскән галим дип чыга (60 нчы бит). Монографиянең үзеннән күренгәнчә, Ш. Мәрҗани — көнчыгыш культурасы традицияләрендә, Көнчыгыш дөньясында тәрбияләнгән галим. Ул Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләрендә укыган, Урта Азиядәге бай китапханәләрдә белемен камилләштергән, әл-Фараби, ибн-Сина, әл-Бируни, әл-Гарнати, А. Нәвои, Г. Сәгъди, Г. Хәйям кебек шәрык культурасы гигантлары мирасын үзләштергән. Соңыннан шәрык культурасының икенче үзәкләре булган Каһирә, Искәндәрия, Дамаск, Истамбул китапханәләрендә булган, бу шәһәрнең галимнәре белән аралашкан... Инде аның тарих буенча хезмәтләренең ибн-Халдунның «Мөкаддимә»сенә ияреп язылуын да искә алыйк... Болар барысы да Ш. Мәрҗанинең шәрык мәктәбендә, аның традицияләрендә җитешкән галим булуын сөйлиләр.

Шул ук вакытта, Казанга кайткач, Ш. Мәрҗани бирелдә эшләүче рус ориенталистлары һәм тарихчылары белән нык аралаша. Университет каршындагы археология, этнография һәм тарих фәнни җәмгыяте әгъзасы була, Бөтен Россия күләмендәге археографик съездга катнаша. Үзенең шәкерте Х. Фәезханов аркылы башкаладагы рус ориенталистлары хезмәтләрен яхшы белә. Икенче төрле әйткәндә, Ш. Мәрҗани шәрык традицияләрендә формалашкан, шул ук вакытта рус ориенталистикасы казанышларын үзләштергән, ике башлангычны бергә синтезлап иҗат иткән галим буларак билгеле.

Монографиядә М. Юсупов Ш. Мәрҗанинең «татар» этнонимын кабул итмәвен билгеләп, «болгар» этнонимы турындагы фикерләренә дә туктала, ләкин бу мәсьәләләрдә Ш. Мәрҗани тоткан юлга үзенең мөнәсәбәтен белдерми генә үтә. Монографиядә кайбер рус тарихчыларының Казан ханлыгын оештыручы Алтын Урдадан килгән Олы Мөхәммәд булган дигән фикере китерелә. Бу гаять бәхәсле карашка да М. Юсупов үзенең фикерен әйтми генә уза. Тарихчы буларак, автор бу актуаль, бәхәсле мәсьәләләрне атлап кына үтмәскә тиеш иде. Революциягә хәтле Ш. Мәрҗани турында чыккан җыентыкка таянып, М. Юсупов аның иҗаты белән Англиядә кызыксынганнар, «Зур Британия энциклопедиясе»ндә белешмә бирү өчен аның рәсемен соратып алганнар, аның аерым әсәрләре шәрык илләрендә басылып чыккан дип искә ала. Ш. Мәрҗани турында һәр мәкаләдә диярлек кабатланып килә торган бу сүзләр, раслаулар никадәр дөреслеккә туры килә: Британия энциклопедиясендә Мәрҗанига урын бирелгәнме, кайчан, кайсы илдә Ш. Мәрҗанинең кайсы әсәрләре басылган — бу мәсьәләләр бирелдә дә гипотезадан уза алмаган, дәлилләнмәгән.

С. Вахидиның (монографиядә «С. Валиди» диелгән) «Мәрҗани китапханәсе һәм аның соңгы язмышы» дигән мәкаләсенә таянып, М. Юсупов Ш. Мәрҗани китапханәсенең һәм кульязмаларының янгында юкка чыгуын яза. Хәзерге көндә Ш. Мәрҗанинең 6 томлык «Вафият-әл-әслаф», 3 томлык «Мөстәфад-әл-әхбар» һәм башка (барлыгы 30 томнан артык) кульязмалары Казан дәүләт университеты китапханәсендә саклана. Шунда ук Ш. Мәрҗани китапханәсе аркылы кергән «Нәһҗ-әл-фәрадис» һ. б. кульязмалар саклана. Димәк, Ш. Мәрҗани кульязмалары янып юкка чыккан дигән фикернең дөреслеге шик астына алына. Бу — Ш. Мәрҗани турындагы әдәбиятка тәнкыйть күзлегеннән чыгып карау кирәклеген күрсәтә.

Ш. Мәрҗанинең тормышын, иҗади мирасын өйрәнү, бәяләүдә әле ак таплар җитәрлек, аларны бер монографиядә тулысынча ачып, хәл итеп бетерү мөмкин түгел. Бу — табигый күренеш. Күрсәтелеп үтелгән һәм бирелдә искә алынмаган аерым төгәлсезлекләр монографиянең югары фәнни дәрәҗәсен, аның Мәрҗани турында яңа сүз, олы сүз, зур сүз буларак бәһасен киметә алмыйлар.

Әлеге монографиянең дөнья күрүе инде Ш. Мәрҗани хезмәтләренең үзләрен басып чыгару ихтыяҗының никадәр зур булуын күрсәтә. Бу аның кульязма һәм китап булып чыккан әсәрләренең укучылар гына түгел, тикшеренүче галимнәр өчен дә кул җитмәслек сирәк булуы белән дә, шулай ук ул әсәрләрнең актуальлеге белән дә бәйләнгән. Икенче, өченче кул комментарийлар аша гына үткәндә иҗат иткән әдип, галимнәрнең тулы колоритын, рух нечкәлекләрен тулы ачып булмый. Менә шуңа күрә рус тарихчылары Соловьев, Карамзин, Ключевскийларның күп томлы әсәрләре яңадан басылып чыгуы зур әһәмияткә ия. Шул ук эшнең Ш. Мәрҗани хезмәтләренә карата да актуаль булуын әйтергә кирәк.

**Әбрар КӘРИМУЛЛИН,**
филология фәннәре докторы.

Фуад Вәлиев

# ТАТАРЛАРДА КЕРАМИКА СӘНГАТЕ

«Сезнең халык сәнгатенең төп үзенчәлеге нидән гыйбарәт?» — дип сорау-чылар булса, мин еш кына даны еракларга таралган нәкышле чүәклар һәм уникаль бизәкле ювелир әйберләре турында, борынгы архитектура формаларын оста кулланып салынган матур-матур йортлар һәм укалап чигелгән нәфис сөлгеләр турында тәфсилләп сөйлим.

Исемнәре билгесез йөзләрчә осталарның бик күп санлы әсәрләре элек-тән үк халыкның материаль культурасы, көндәлек тормышы белән аерылгысыз бәйләнгән булган. Алар бүгенге көндә дә халык тормышының этник, эстетик үзенчәлекләрен гәүдәләндерүен дәвам итә. Әмма хәзер инде бу әсәрләр материаль культура сферасыннан рухи сферага күчә баралар. Сәнгать әсәренең утилитар функцияләре сакланып калган хәлдә исә аларның художество сыйфатлары аерым бер кыйммәткә һәм социаль-идеологик әһәмияткә ия.

Безнең ерак бабаларыбызның үзенчәлекле тарихи тормышы борынгы чорда авылларда һәм шәһәрләрдә үзенә бер „төр һөнәрләрнең һәм декоратив сәнгатьнең үсешенә сәбәп булган. Ләкин ул сәнгатьнең барлык төрләре дә безнең көнгә хәтле килеп җитмәгән. Монументаль архитектура юкка чыгу белән, уналтынчы йөзнең икенче яртысыннан башлап (кабер өстенә куела торган ташларны искә алмаганда) ташка уеп рәсем ясау сәнгате дә, бизәкләп төрле савыт-сабалар, кораллар, көнкүреш әйберләре ясауга нигезләнгән сәнгать тә үзләренең көчләрен югалталар. Унтугызынчы йөзнең беренче яртысында хатын-кыз осталарның иҗатында тукымага төрле төстәге кәгазь, күн, материя кисәкләре ябыштыру яки тегеп кую юлы белән ясалган сурәтле, рәсемле, орнаментлы әйберләр күренми башлый. Шул ук гасырның икенче яртысында йон келәмнәр туку, ә аннан да алданрак киез басу производствосы туктый. Унтугызынчы гасыр азакларында — егерменче гасыр башларында халык сәнгатенең яңа туып килгән эстетик ихтыяҗларны канәгатьләндерә алмаган башка төрләре дә юкка чыга. Шуның белән бергә халык сәнгатенең яңа төрләре барлыкка килә. Аның сакланып калган үрнәкләре исә совет чынбарлыгы шартларында йорт һөнәрләре формасында тагын да зуррак үсеш ала.

Бүгенге көндә халык сәнгате социалистик чорның эчтәлеген чагылдыра торган өр-яңа күренешкә әверелде. Ул яңа эчтәлек белән генә түгел, сәнгатьнең яңа формалары һәм чаралары белән дә баеды. Совет чынбарлыгының төп үзенчәлеген, иң характерлы ягын саклап калган хәлдә, татар халкы үзенең сәнгать эшчәнлегендә яңадан-яңа формалар да таба. Аерым алганда, үзешчән рәссамнар, кул эше осталары елдан-ел арта бара. Аларның барысының да диярлек иҗатлары халык сәнгатенә таяна. Профессиональ рәссамнарыбызның иҗатлары да халык сәнгатенең бетмәс-төкәнмәс хәзинәсе исәбенә байый.

Болгар заманнарыннан ук килә торган сәнгать әсәрләрен комплекслы өйрәнү һәм тирәнтен белү генә халыкның этнографик һәм эстетик үзенчәлекләрен тулырак ачарга, аның иҗатының милли йөзен ачыграк билгеләргә мөмкинлек бирә. Кызганычка каршы, безнең халкыбыз иҗатының ифрат кызыклы һәм тирән үзенчәлекле бер төре — керамика сәнгате — халкыбыз культурасын, сәнгатен өйрәнүче галимнәребезнең игъ-

тибар үзәгеннән шушы көнгә кадәр читтә кала килә. Дөрес, берникадәр археологик материал тупланган. Ләкин аларның да күбесе фрагментлар хәлендә генә. Шуның өстенә ул материаллар турындагы мәгълүматлар да гомуми сүзләрдән торган берничә җөмләдән артмый. Ә шулай да, төп билгеләренә һәм төзелешләренә карап, бу материалларның сәнгатьчә эшләнгәнлекләрен абайларга мөмкин.

Болгар-татар керамика сәнгатенең әһәмияте — аның камиллегендә һәм оригиналь булуында, декоративлыгында, осталарның җиңел пластиканы табигать образларын чагылдырган сурәтләр рәвешендә файдалана алуларында. Узган чорларда яшәгән керамистларның сәнгать телен, аның эмоциональлеген озак вакытлар буена нәкъ менә шушы чаралар билгеләгән дияргә нигез бар. Ул алымнар бүгенге профессиональ һәм үзешчән рәссамнарыбызның практикасын баета алачак һәм баетырга тиеш тә. Керамик савытларның камил үрнәкләре халык сәнгатен яратучыларга, һичшиксез, зур шатлык китерәчәк, хәзерге заман интерьерына оригинальлек, матурлык, кабатланмаучанлык кебек сыйфатлар өстәячәк.

Казан татарларының керамика сәнгате чыганаклары Идел буе болгарлары культурасына барып тоташа. Аларда исә художестволы иҗатның бу төре бик нык үскән була. Моны бигрәк тә унынчы-унөченче гасырларга, ягъни чүлмәк ясау эшләре чәчәк аткан чорга карата әйтергә кирәк. Болгар осталары искиткеч күп төрле савытлар, шул җөмләдән бик нәфис итеп эшләнгән савытлар — төрле зурлыктагы кувшиннар, хумнар, зур чүлмәкләр, комганнар, кружкалар, мискиләр, тәлинкәләр, кара савытлары, сфероконуслар, лампадалар ясыйлар. Моннан тыш алар балалар уенчыклары — шалтыравыклар, ат, эт һәм башка хайваннарның фигураларын, әтәчләр, кошлар ясау белән дә шөгыльләнәләр. Сүс һәм йон эрләү өчен керамик кабалар, балык ятьмәләре өчен батыргычлар җитештерәләр һәм аларны еш кына чокып эшләнгән матур-матур орнаментлар белән бизиләр. Болгар чүлмәкчеләренең остаханәләреннән шулай ук төзелеш өчен зәңгәр һәм яшел төстәге архитектура керамикасы, су торбалары һәм декоратив элемент булып хезмәт иткән зәңгәрсу төстәге кирпечләр алып китә торган булганнар. Боларның барысы да болгарларда хуҗалык итү культурасының югары булуы турында сөйли.

Балчыктан эшләнгән бу әйберләрнең барысы да төрле тарихи чорларда һәм төрле ысуллар белән җитештерелгән, алар ярдәмендә бизәү эшләре төрле алымнар ярдәмендә башкарылган. Бик борынгы савытлар кул белән әвәләп, соңгыраклары — кул һәм аяк белән әйләндерешле махсус җайланмаларда ясалган. Мәгәр соңыннан да әйбергә оттиск төшерү, штамплау яки кою юлы белән орнамент куеп, элеккечә әвәләп ясау ысулы да бөтенләй үк юкка чыкмаган. Савытларның тышларында булсын, вак пластик фигураларда булсын, геометрик орнаментларны киң куллану болгар чүлмәкчеләре иҗатының югары баскычта торганлыгын ачык раслый.

Болгарлар һәм Казан татарлары тормышында художестволы керамика көндәлек тормыш максатлары өчен генә хезмәт итми. Өй җиһазлары һәм бизәкле савыт-сабалар аз булган көнчыгыш илләрендәге шикелле, биредә дә матур нәкышлы тукымалардан тегелгән кием-салым һәм художество керамика торак йортларның интерьерлары өчен мөһим роль уйный.

Бу мәкаләдә җиденче йөз ахыры — сигезенче йөз башыннан алып Идел болгарларының тарихи тормышындагы һәр чорга аерым тукталырга һәм ул чорлардагы керамиканың барлык төрләре һәм үзенчәлекләре турында озаклап сөйләргә мөмкинлек юк. Шунлыктан без биредә художество-декоратив әһәмияте ягыннан аеруча игътибарга лаек булган кувшиннарга, аларның да кайбер төрләренә генә тукталып үтү белән чикләнәбез.

Зурлыкларында, формаларында, тоткаларында, орнаментларында, төсләрендә, нәмә составларында аерымлыклар булса да, балчык кувшиннар, нигездә, бер-берләренә охшаш. Шул ук вакытта алар бер-берләреннән өслекләренең художестволы эшләнешләренә карап та аерылалар. Бер очракта осталар кувшиннарны ялтырату белән чикләнсәләр, икенче очракта аларны ангоб дип аталган юка гына тышча (ак, кызыл, соры төстәге кызыл балчыктан ясалган сыекча) белән каплыйлар. Өченчеләре исә, ангоб кипкәч, савытның тышы җем-җем килеп торырлык итеп ялтыратканчы шомарталар. Шомартып ялтырату болгар савытларын орнаментлауда төп чараларның берсе булып саналган. Ялтыратылган өслектә барлыкка килгән бизәкләр төрле-төрле

комбинацияләргә кертеп үзгәртелгән. Савыт өстендәге ялтыравыклы штрихлар хасил иткән челтәрсыман ромбик бизәкләр аеруча киң кулланыш тапкан. Кувшин тышчасында ялтыратылмыйча калган урыннардагы тар гына буй-буй сызыклар белән ритмик аралашып килгән вертикаль сызыклар ярдәмендә ясалган бизәкләр дә начардан саналмаган. Ә инде шомартылган һәм киң вертикаль буй-буй эзләр белән шомартылмаган җирләрдәге шундый ук киң буй-буй эзләрнең үзара чиратлашуыннан барлыкка килгән бизәкнең абруе түбәнрәк булган һәм аннан азрак файдаланганнар.

Төрле үзенчәлектәге шушы бизәкләр кувшиннарның билен буып алган калын каймага төрле нисбәттә урнаштырылганнар. Каймалар, гадәттә, ике-өч сызыктан артмаган һәм алар бер-берләреннән нечкә генә шома сызыкчалар белән аерылганнар.

Ялтыравыклы нәкышлардан тыш кувшиннар горизонталь юнәлештәге параллель линияләр яки савытның өске, урта һәм сирәк кенә очракларда аскы өлешен әйләндереп алган берничә текә һәм сөзәк дулкыннар белән бизәлгәннәр. Линияләр кайчагында «авыш» дулкыннардан, интеграль спиральләрдән, каймалардан торган. Кувшиннарның өске өлеше еш кына яфраклар һәм үрентеләр рәвешендә ясалган орнамент белән дә бизәлгән.

Болгар чүлмәкчеләре шулай ук кара һәм кызгылт көрән төстәге геометрик бизәкләр төшерелгән кувшиннар ясый торган булганнар. Бу очракларда савытларның тышы үтә күренмәле, яшел һәм, сирәк кенә булса да, зәңгәр ялтыравык белән капланган. Шул ук вакытта бизәкләре әзер өлге буенча төшерелгән кувшиннар да эшләнгән.


Болгар кувшиннары арасында тәбәнәк һәм артык зур булмаган, ялтыравык бизәкле, тоткаларына хайван, җәнлек, кош сурәтләре төшерелгән кувшиннар аерылып тора. Кайбер кувшиннарның тоткаларында, мәсәлән, реалистик рухта эшләнгән тәкә, аю һәм ат сурәтләрен дә күрәбез. Күп кенә кувшиннарның борыннары җәнлекләр һәм кошлар формасында ясалган. Кайбер очракларда осталар теге яки бу җәнлекне, кошны шартлы аңлату белән чикләнәләр. Әйтик, ул җәнлек-кошларның башлары еш кына символик мәгънәдә аңлатыла, һәм чүлмәк ясаучы савыт тоткасына ярымшар формасындагы чыгынты әвәләп кую белән чикләнә. Хайваннар һәм кошлар формасындагы тоткаларны нинди дә булса бер фикергә китереп бәйләү болгар чүлмәкчеләре сәнгатендә, гомумән, традициягә кергән. Ләкин мондый савытлар безнең эрага кадәр икенче гасырда ук инде Төньяк Кавказда яшәгән сармат-алан, ә аларга чаклы Фирганә һәм Чача (Ташкент) халыкларында да киң таралган булган. Бу система борынгы кытайлар (безнең эрага кадәр уникенче-унөченче гасырларда) сәнгатендә дә кулланылган.


Кувшиннарны декоратив яктан хәл итүдә сәнгать теленең байлыгы, болгар керамистларының техник осталыктагы камиллекләре, халыкның рухи тормышындагы, культурасындагы үзенчәлекләр ачык чагыла. Дөрес, болгар осталарының барлык савытлары да орнамент белән бизәлмәгән. Ләкин шулай булмаган очракларда да савытлар эстетик зәвык белән ясалганнар. Моңа исә гадилек һәм формаларының аңлаешлылыгы, аерым кисәкләренең бер-берләренә үзара тыгыз бәйләнгән булулары аркасында ирешелгән.

Кувшиннарда, бигрәк тә бик борынгы болгарларның кувшиннарында, клеймәләрнең рельефлы рәсемнәре сокландыра. Аларның күбесе ыруг тамгаларыннан үзгәртелгән булса кирәк. Клеймәләр гадәттә савытларның төпләренә урнаштырылганнар. Арада «Н» хәрефе рәвешендәге клеймә аеруча кызыклы. Ул ике атның алгы саннары бергә кушылудан гыйбарәт. Мондый композицияләр («ике башлы ат»), гомумән, болгар сәнгате өчен характерлы. Мәгәр аның килеп чыгуы Идел буе болгарлары сәнгатенә шактый йогынты ясаган сармат-алан сәнгате белән бәйләп аңлатыла. Икенче бер савытның төбендә исә биленә зур кәрзин асылган ат һәм аның янында ятучы эт рәсемен дә күрергә мөмкин.

Саналып узылган сынлы сәнгать тамгалары — символлар башка савытларда да, аерым алганда, төрле сыеклыклар саклау өчен хезмәт итә торган сфероконусларда да очрый. Аларның күбесендә орнаменталь бизәкләр, мәсәлән, болан, ана поши белән ата поши, атка атланган кеше, ай яктысында очып баручы кош рәсемнәре белән аралашып килә.

Керамика сәнгатенең үсеш процессында болгарлар үзләренең традицияләренә — бик борынгы заманнарда Көнчыгыш Казагыстан һәм Көнбатыш Себер җирләрендә




күчмә тормыш белән яшәгән бабаларыннан калган традицияләргә — таянганнар. Дүртенче гасыр ахырыннан алып сигезенче гасыр башларына кадәр алар Азов һәм Дон буйларында, Төньяк Кавказда яшәгәндә ул традицияләр тагын да байый төшә. Сармат-алан кабиләләре, Азов һәм Кара диңгез буендагы шәһәрләр халкы белән тыгыз элемтәдә булу, алар белән берга-бергә тереклек итү, Иран, Византия сәнгатенә якын тору нәтиҗәсендә болгарлар культурасы шактый гына үзгәрешләр кичерә. Бу чор — игенчелекнең зур тизлек белән үсү, болгарларның утрак тормышка күчү чоры. Яңа социаль-экономик шартлар болгарлар яшәгән урыннарда аларның феодалларының кирпечтән һәм ак таштан салынган күп санлы замоклары барлыкка килүгә сәбәпче була. Сигезенче гасырда Урта Иделдә болгарларның төзелеш өлкәсендәге эшчәнлегенә Алабуга шәһәре янындагы «Шайтан шәһәрчеге»н һәм тагын кирпечтән, саманнан, штукатурланган камыштан җиткерелгән торак йортларны мисал итеп китерергә мөмкин булыр иде.

Шулай итеп, бу якларга болгарлар игенчелек культурасын, төзелеш эшләрен инде шактый үзләштереп, үз архитектураларына, төрле һөнәрләргә, шул нисбәттән, сәнгать һөнәрләренә ия булган хәлдә килеп утыралар.


Дөрес, аларның архитектурасындагы, төзелеш эшләрендәге һәм сәнгатендәге күп кенә күренешләрдә Кавказ, Иран, Византия халыклары ирешкән казанышларның йогынтысы үзен ярыйсы ук сиздерә. Ләкин ул казанышлар кул астындагы материалдан, җирле шартлардан чыгып, алар тарафыннан иҗади кабул ителгән, эшкәртелгән, соңыннан Салтов[1] культурасы дип аталган үзенчәлекле бербөтен культурага әверелгән. Нәкъ менә шушы культураның нигезе Идел буендагы Болгар иленең культурасы, сәнгате һәм архитектурасы тизлек белән үсүгә, алай гына да түгел, фин-угор төркеменнән булган халыкларга шифалы йогынты ясауга ярдәм иткән дә инде.

Болгарларның керамика сәнгате унынчы гасырда — уникенче гасыр башында чәчәк атуының иң югары ноктасына ирешә. Унынчы гасырда ислам дине кабул ителгән булуга карамастан, бу чорда болгарларның барлык төр художество һөнәрләрендә тормыш белән тирәнтен бәйләнгән мотивлар, форма һәм сюжетлар сәнгатьчә киң чагылыш таба. Шул ук вакытта боларның һәркайсы үзенең элеккеге семантикасын, символикасын һәм халыкның борынгы гореф-гадәтләре, авыз иҗаты, эпосы белән турыдан-туры бәйланышын саклап кала. Художестволы һөнәрләрнең, шул җәһәттән керамиканың бик күп күренешләрендә Салтов культурасы традицияләре дәвам итә.

Аннан соңгы чорда, ягъни Алтын Урда чорында (унөченче гасырның икенче яртысы — унбишенче гасыр башлары) болгар осталарының, аерым алганда керамистларның, художество теләндә байтак кына үзгәрешләр барлыкка килә. Моңа кадәр яшәп килгән тематика, үз урынын орнамент һәм эпиграфикага бирә барып, акрынлап үзенең мәгънәви һәм художество әһәмиятен югалта. Моның сәбәбен, безнеңчә, ислам дине кабул ителү белән генә түгел, ә бәлки бәеганнан-байый барган болгар сәнгате үсешенең эчке һәм тышкы процесслары белән аңлатырга кирәктер. Мондый процесс бер болгар сәнгате өчен генә түгел, башка бик күп көнчыгыш илләре халыклары сәнгате өчен дә хас күренеш. Ул үзенең якты чагылышын, аеруча, декоратив сәнгатьтә, шул җөмләдән соңыннан Казан татарлары дип аталып йөртелә башлаган яңа болгарларның керамика сәнгатендә дә таба.

[1] Бу — Төньяк Донец елгасы (Харьков өлкәсе) буендагы югары Салтов каберлеге исеме белән бәйләнгән археологик культура.

Кызганычка каршы, археологик табылдыклар аз булганлыктан, Казан ханлыгы чорындагы керамика сәнгате турында безнең мәгълүматларыбыз шактый ярлы. Татар чүлмәкчеләре бу чорда да кызыл һәм кызгылт көрән төстәге кирпечтән төрле формадагы һәм орнаменттагы савытлар ясаганнар. Савытлардагы клэймәләр чүлмәк ясау эшләрен башкару өчен җирле остаханәләр булганлыгын исбатлыйлар.



Татар осталары да зур чүлмәкләр, кувшиннар, су савытлары, комганнар, гади чүлмәкләр, чынаяклар, тәлинкәләр, кара савытлары һәм башка шуның ише әйберләр ясау белән шөгыльләнгәннәр. Ул әйберләрнең күбесе тасма-каймалар, бербersенә параллель булган горизонталь сызыклар, зигзаглар, меандрлар, түгәрәк уемнар белән орнаментланган.

Саналып узылган савытлар арасында игътибарны бигрәк тә җәлеп иткәне — егерме сантиметрдан алып утыз сантиметрга чаклы биеклектәге комганнар. Килеп чыгышы буенча Көнчыгыш илләр савыты булган комган татар чүлмәкчеләре иҗатында Көнчыгыш үрнәкләреннән үзгәрәк чишелеш таба. Күп кенә комганнарның игътибарга лаеклы үзенчәлеге шунда: аларның борыннары ат, тәкә, әтәч сыннары формасында эшләнгән. Идел буе болгарларында гына түгел, ә бәлки Иран һәм славяннар сәнгатендә дә киң таралган әтәч башының сыны һәркемдә зур кызыксыну уята. Археолог Н. Ф. Калинин билгеләп үткәнчә, савыт борыннарын бизәүче әтәч башы — борынгы форма, һәм ул, нигездә, Казан формасы. Татарлар арасында бу форма унбишенче-уналтынчы гасырларда ук очрый.

Ялтыравыклы керамиканың табылдык кисәкчекләре татар чүлмәкчеләренең, болгарлар шикелле үк, ялтыратылган савыт-сабалар һәм төсле рәсемнәр ясалган савытлар җитештергәнлекләрен дәлилли. Болгар чорындагы шикелле үк, биредә дә савытларны бизәгәндә аларны орнаментлауга һәм шомартуга, аерым кисәкләренең төзеклегенә һәм гармониялелегенә, матур савытлар ясауга зур игътибар бирелгән.

Татар керамистларының кызыл балчыктан ясалган савытларын бигрәк тә җәнлек һәм кош сурәте формасындагы комганнарны күршедәш халыклар, шул җөмләдән руслар да бик теләп ала торган булганнар. Казылма материаллардан күренгәнчә, уналты-унҗиденче гасырларда рус чүлмәкчеләре татарлар үрнәгендә үзләре дә шундый ук комганнар ясаганнар. Җәнлек һәм кош сурәтләре формасындагы борынгы комган фрагментлары берничә тапкыр Мәскәүдә дә табылган. Археолог Н. Ф. Калинин сүзләре белән әйткәндә, «Казан татарлары чүлмәкчеләренең русларга культура йогынтысы ясавы бик табигый».

Бу төбәкнең Россиягә кушылуы белән Казан татарларының тарихи тормышында чүлмәк ясау эше белән шөгыльләнү кузгә күренеп кими. Моның сәбәбе — нигездә аларны — чүлмәкчеләрне — савытлар ясау өчен яраклы булган сутлы балчык алына торган карьерлар урнашкан җирләрдән күчерү белән аңлатыла. Андый карьерларның хәзерге Питрәч авылы һәм Алабуга районы территорияләрендә урнашкан булулары билгеле. Кукмара районы тирәләрендә дә балчык савытлар ясау эшләре алып барылганлыгы турында кайбер мәгълүматлар бар. Чүлмәк ясауның кимүенә акчалата оброк түләү системасы кертелү аркасында бу төбәктә товар-акча мөнәсәбәтләренең тизлек белән үсеше дә, һичшиксез, сәбәпче була. Татарлар күрше халыкларның савытларын сатып алырга һәм үзләре ясаган агач савытлардан файдаланырга мәҗбүр булалар. Бүгенге көндә татар халкының керамика сәнгате аерым рәссамнарның иҗатында үзенең чагылышын таба.

Казан татарлары керамика сәнгатенең кыскача тарихы әнә шуннан гыйбарәт. Культурабызның бу өлкәсе алда әле үзенең яңа тикшерүчеләрен көтә.

*Совет язучылары гомер-гомердән чит ил темасына бик күп әсәрләр иҗат итә. Аларның төп максаты экзотика һәм төрле мажараларны мәкиббән китеп сөйләүдән тормыйча, бүгенгенең һәм киләчәкнең кыйбласын күзәлларга булышудан, дөнья буенда барган идеологик көрәш асылын аңлатудан, изүче сыйныфның ялган битлеген ачып, азатлык һәм тынычлык дошманнарын фаш итүдән, хезмәт ияләренә туганнарча теләктәшлек һәм ярату хисләрен белдерүдән гыйбарәт. Илебез язучыларының чит илләр турында язмалары гуманизм рухы белән сугарылган. Алар халыклар арасында туганлык урнашуга, үзара аңлашу-аралашуга, ышаныч булдыруга хезмәт итә. Язучыларыбызның чит ил тормышын социаль яктан дөрес бәяләве шиксез. Элек һәм бүген язганнарының чагыштырмасы — моңа ачык дәлил. Әйтик, В. Маяковскийның Америка империализмына моннан ярты гасыр әүвәл биргән тасвирламасы хәзер дә шиксез актуаль яңгырый, бу илнең бүгенге хәленә тулысынча туры килә.*

*Редакция укучыларыбызны чит ил темасына берничә әсәр белән таныштырырга булды. Шул җөмләдән татар язучылары иҗатына да мөрәҗәгать итәргә уйлыйбыз.*

*Бу санда исә, үрнәк рәвешендә, бөек пролетар язучы Максим Горькийның Америка миллионерын фаш итү гротескысы, ачы көлү белән тулы бер памфлетын тәкъдим итәбез.*

Максим Горький

# РЕСПУБЛИКА КОРОЛЬЛӘРЕНЕҢ БЕРСЕ

Кушма Штатларның корыч, керосин һәм башка корольләре минем хыялымны һәрвакыт тынгысызлап киләләр иде. Акчалары шулкадәр күп булган кешеләрне мин гадәти кешеләр итеп күз алдыма китерә алмый идем.

Миңа аларның иң кимендә өч ашказаны һәм авызларында йөз иллеләп теше бар кебек тоела. Миллионерның һәр көнне иртәнге сәгать алтыдан төнге уникегә тикле туктаусыз, ялсыз-нисез ашап торуына минем иманым камил иде. Ул иң кыйммәтле ризык: каз, күркә, чучка балалары, каймаклы редис, пудинг, кэк һәм бүтән нәрсәләрне юкка чыгарып бара. Кичкә аның теш казналары эшләүдән арый да ул ризыкны негрларга чәйнәргә куша, ә үзе шуны йотып кына тора башлый. Шулай итеп, ул соңгы мыскал көчен тотып бетерә һәм, шабыр тиргә батып, инде тыгыла дигәндә, негрлар аны йокларга чыгарып сала. Ә иртәнге сәгать алтыдан ул яңадан үзенең газаплы гомерен чигәргә керешә.

Әмма шулай бүртенгәнче көчәнсә дә, ул үз капиталының ярты процентын да ашап бетерә алмый.

Аңлашылганча, болай тормыш кичерүе авыр. Ләкин нишләмәк кирәк? Гадәти кешедән арттырып ашый алмагач, миллионер булудан ни мәгънә?

Миңа ул парчадан тегелгән эчке кием киеп йөрергә тиеш, итегенең үкчәләренә алтын кадаклар кадакланган, ә башында эшләпә урынына зәбәрҗәтле берәр нәрсә торырдыр кебек тоела иде. Сюртугы иң затлы бархеттән тегелгән, буе җиде сажиннан да ким түгел һәм өч йөз данә алтын төймә белән бизәлгән. Бәйрәм көннәрендә ул берьюлы сигез сюртук белән алты пар чалбар кия. Билгеле, бу җайсыз да, кысан да... Әмма шундый бай була торып, бүтәннәр шикелле киенеп булмый лабаса...

Миллионерның кесәсен мин иркенләп чиркәү, сенат бинасы һәм ни кирәксә шул сыярдай чокыр рәвешендә дип аңлый торган идем. Шул ук вакытта, мондый джентельменның эче сыешлыгын яхшы бер диңгез пароходы трюмы сурәтендә күзаллаган хәлдә, мин ул җан иясенең аягы белән чалбары озынлыгын тасвирлый алмамындыр. Әмма ул ябынып яткан юрганны бер квадрат чакрымнан да ким булмастыр дип уйлыйм. Инде чәйнәгән тәмәкесенә килсәк, ул, әлбәттә, иң әйбәтеннән һәм берьюлы ике кадак тартыр. Әгәр инде исни торганы икән, бер алымга бер кадактан да ким түгел. Акча үзен тарaтканны таләп итә...

Аның кул бармаклары гаҗәеп тоемга һәм теләгәнчә озынаю тылсымына ия: Нью-Йоркта утырган килеш кайдадыр Себердә доллар үсеп чыкканын сизеп алса, ул, урыныннан кубып тормастан, Беринг бугазы аша кулын суза да яраткан үсемлеген әзеп ала.

Сәер: шушыларга карамастан, мин ул әзмәвернең башы ниндилеген күз алдыма китерә алмадым. Ул гына түгел, бар нәрсәдән алтын сыгып чыгару шөгыле җәһәтлек иңдергән ул мускул һәм сөяк тавына, миңа калса, баш бөтенләй кирәк түгел. Минем миллионерны күзаллавым, гомумән, төгәл сурәтле түгел иде әле. Кыска гына итеп әйткәндә, ул иң әүвәл сыгылмалы озын куллардан гыйбарәт иде. Ул бөтен җир шарын урап алган да зур, караңгы танавына якынайткан, һәм ул танау, пешкән кайнар бәрәңгене төкерек сылап ашагандагы шикелле, безнең планетабызны имә, кимерә һәм чәйни...

Миллионерны очратып, аның гап-гади бер кеше икәнен күргәч гаҗәпләнүемне күз алдыгызга китерә аласыздыр.

Минем каршымдагы тирән кәнәфидә, гадәти зурлыктагы корсагына гадәти кешеләрнеке зурлыгындагы көрән тиресе бөрешеп торган кулын салып, озын буйлы, ябык бер карт утыра иде. Битенең бөрешкән тиресе шома итеп кырылган, хәлсез салынып төшкән түбәнге ирене астыннан нык утырган теш казналары күренеп тора, аларга алтын тешләр тезеп чыгылган. Кырылган, каны качкан һәм юка өске ирене аның чәйнәвеченә ябышып каткан, карт сөйләшкәндә бөтенләй диярлек хәрәкәтсез. Төссез күзенең кашы юк, тонык ак башы чәчсез. Бу йөзгә әзрәк тире җитми калган шикелле, һәм ул бөтенләе белән кызгылт, хәрәкәтсез һәм шома булганга күрә яңа туган бала йөзен хәтерләтеп тора иде. Бу җан иясе яши генә башлагангамы, әллә инде гомеренең чигенә килеп терәлгәнме икәнлеген чамалау кыен иде. Киенгәне дә үләргә туган һәркемнеке шикелле. Балдак, сәгать һәм тешләре—аның бар алтыны шуннан гыйбарәт. Ихтимал, җәмгысе ярты кадактан артык тартмастыр. Гомумән, бу кеше Европадагы аристократ өйләрендәге бер карт хезмәтчене хәтерләтә иде...

Ул мине кабул иткән бүлмә бизәлеше зиннәтлеге белән ис китерердәй, матурлыгы белән сокландырырдай түгел. Мебеленә карата «саллы» дигәннән гайре ни дә әйтеп булмый.

«Бу өйгә кайвакытны филләр кереп чыккалый, ахрысы...» — мебель шушындыйрак фикергә китерерлек иде.

— Сезме инде ул... миллионер? — дип сорадым мин, үз күземә ышанмыйча.

— О, әлбәттә! — дип җавап бирде ул, үз-үзенә бик ышанган төстә башын кагып.

Мин ана ышанган булып кыландым да, аның ялганын фаш итәргә теләп:

— Иртән сез күпме ит ашый аласыз? — дип сорадым.

— Мин ит ашамыйм! — дип белдерде ул.— Апельсин кисәге, кечкенә бер чынаяк чәй — бар ризыгым менә шул...

Аның имчәк баласыныкы шикелле гөнаһсыз күзе минем алдымда, болганчык ике зур су тамчысы кебек, тонык кына ялтырап алды, һәм мин анда бер генә ялган чаткысы да күрмәдем.

— Яхшы! — дидем, төшенеп җитмәстән.— Әмма ихластан, ачыктаначык әйтегез әле — көнгә ничә тапкыр ашыйсыз соң сез?

— Ике! — диде ул тыныч кына.— Иртәнге аш белән төшке аш минә бит җиткән. Төшкегә бер тәлинкә шулпа, майсыз ит һәм берәр баллы нәрсә кабам. Җиләк-җимеш. Бер чынаяк кофе. Сигара...

Минем гаҗәпсенүем кабак шикелле зурая башлады. Ул миңа изгеләр карашы белән карап тора иде. Мин тын алып куйдым да:

— Әгәр бу хак икән, сез акчагызны нишләтәсез соң? — дип сорадым.

Ул иңбашын чак кына кагып куйды да, күз алмасын әйләндергәләп:

— Аннан мин тагын акча эшлим,— дип җавап бирде.

— Нигә?

— Тагын акча эшләр өчен.

— Нигә? — дип кабатладым мин.

Терсәкләре белән кәнәфи култыксасына таянып, ул миңа табан иелде дә беркадәр кызыксыну төсмере белән:

— Сез шашканмы әллә? — дип сорады.

— Ә сез? — дип сорау белән җавап бирдем мин.

Карт башын кыңгыр салды да алтын тешләре аша:

— Әкәмәт кеше... Минем мондый кешене беренче күрүемдер әле,— дип сузды.

Шуннан соң ул башын күтәрде дә, авызын колагына кадәр ерып, сүзсез генә мине күзләп торды. Йөзенең тынычлыгына карап хөкем йөрткәндә, ул үзен гадәти бер кеше дип саный иде булса кирәк. Мин аның галстугында бәләкәй генә зөбәрҗәтле каптырма күреп алдым. Ул затлы таш олтан хәтле булса, мин берәр нәрсә аңлар идем әле.

— Сез нишлисез соң? — дип сорадым мин.

— Акча эшлим! — диде ул кистереп кенә һәм иңбашын сикертеп куйды.

— Ялган акчамы? — дип кычкырып куйдым мин шатланып: ничектер аның серен ачуга якынаям кебек булып китте. Ләкин шулчакны ул йөтлыга башлады. Аның бөтен тәне калтырана, әйтерсең лә күзгә күренмәс бер кул аның култык астын кытыклап тора. Күзе ачылып-йомылгаларга тотынды.

— Кызык бу! — диде ул тынычланып һәм минем йөземне канәгать карашы белән капшап.— Тагын берәр нәрсә сорагыз әле! — дип тәкъдим итте ул һәм нигәдер яңакларын күпертеп җибәрде.

Мин уйлап тордым да каты итеп:

— Сез акчаны ничек эшлисез? — дип сорадым.

— Ә! Төшендем! — диде ул, башын кагып.— Бернәрсәсе юк аның. Минем тимер юлларым бар. Фермерлар товар җитештерә. Мин шуны базарга ташыйм. Фермерлар ачка үлмәс өчен һәм эшен дәвам иттерер өчен күпме калдырырга икәнен хисаплыйсың да шуннан калган хәтлесен ташыган өчен тариф рәвешендә үзеңә аласың. Берние юк.

— Фермерлар моңа канәгатьме соң?

— Барысы да түгел дип уйлыйм,— диде ул балаларча беркатлы төстә.— Ләкин бар кеше дә һәммәсенә дә канәгать булып бетми диләр. Мыгырдана торган сәер кешеләр һәрвакыт бар...

— Сезгә хөкүмәт комачауламыймы? — дип тыйнак кына сорап куйдым мин.

— Хөкүмәт? — дип кабатлады ул һәм бармаклары белән маңгаен кашып уйга калды. Аннары, кинәт нидер исенә төшкәндәй, башын кашып алды.— Әһә... Теге... Вашингтондагылармы? Юк, комачауламыйлар. Яхшы егетләр алар... Араларында минем клубыма йөри торганнары да бар. Тик алар сирәк күренә. Шуңа күрә кайвакытны аларны онытып җибәргәлисең. Юк, алар комачауламыйлар,— дип кабатлады ул

һәм шундук кызыксынып: — Кешеләргә акча эшләргә комачаулый торган хөкүмәтләр дә бармыни? — дип сорады.
Мин үземнең беркатлылыгымнан һәм аның акыллылыгыннан оялганымны сизеп алдым.
— Юк,— дидем мин тын гына,— аны әйтмим... Мин, беләсегез килсә, хөкүмәт кайчакны күрәләтә талаучыларны тыярга тиеш дип уйлый идем...
— Юк ла! — дип каршы төште ул.— Идеализм бу. Бездә тәртип башкача. Хөкүмәтнең шәхси эшкә катнашырга хакы юк...
Бу тыныч бала-чага беркатлылыгы минем тыйнаклыгымны арттыра төште.
Мин ягымлы гына итеп:
— Бер кешенең күпләрне бөлдерүе хосусан эшмени? — дип сораштым.
— Бөлдерү? — дип кабатлады ул күзен зур ачып.— Эш көче кыйммәтләнә — менә ни бөлдерә ул. Стачка да. Ләкин бездә эмигрантлар бар. Алар эшчеләргә түләүне киметергә мөмкинлек бирәләр һәм эш ташлаганнарны бик рәхәтләнеп алыштыралар да. Алар илдә арзан хакка эшләрлек һәм күп нәрсә сатып алырлык дәрәҗәдә җыелгач, һәммәсе җайланыр.
Ул беркадәр тернәкләнеп китте һәм картлач белән имчәк баласына буталып охшавы кими төште. Аның нечкә, кара тут бармаклары кузгалышып куйдылар, коры тавышы колакларымда ешрак чыңлады.
— Хөкүмәтме? Бу кызыклы сорау, ахрысы, әйе. Яхшы хөкүмәт — кирәк нәрсә. Ул мондыйрак бурычларны хәл итә: илдә халык саны мин сатарга теләгән бар нәрсәне сатып алыр өчен миңа кирәк кадәр булырга тиеш. Эшчеләр мин аларга мохтаҗлык кичермәслек санда булсын. Ләкин һичберсе артык түгел! Шулай булганда социалистларга урын калмас. Эш ташлаулар бетәр. Хөкүмәт зур налоглар түләтергә тиеш түгел. Халык бирергә мөмкин булган һәрнәрсәне мин үзем алам. Яхшы хөкүмәт дип мин менә шундыйны атыйм.
«Ул ахмакка тартым — бу һичшиксез үз бөеклегең белән масаюдан килә,— дип уйладым мин.— Ул чыннан да король, ахрысы»...
— Миңа илдә тәртип булуы кирәк,— дип дәвам итте ул ышанычлы һәм нык төстә. Хөкүмәт зур булмаган бәягә һәр якшәмбедә сигез сәгать буена халыкны законнар хөрмәт итәргә өйрәтсен өчен төрле философлар яллый. Әгәр моңа философлар гына җитмәсә, солдатларны эшкә кушыгыз. Монда ысуллар түгел, ә бары тик нәтиҗәләр генә мөһим. Ашаучы белән эшче законнарны хөрмәт итәргә тиеш. Менә шул!— дип тәмамлады ул, бармакларын уйнаткалап.
«Юк, ул ахмак түгел, шуңа күрә король булалмый»,— дип уйладым мин һәм:
— Сез хәзерге хөкүмәттән канәгатьме? — дип сорадым.
Ул җавап бирми шактый торды.
— Ул булдыра алганнан әзрәк эшли. Мин эмигрантларны әлегә илгә кертергә кирәк дип саныйм. Әмма бездә алар файдалана торган политик ирек бар — моңа акча түләтергә кирәк. Аларның һәркайсы биш йөз доллар гына булса да акча алып килсен. Биш йөз доллары булган кеше илле долларлыга караганда ун мәртәбә яхшырак... Дәрвиш, хәерче, авыру һәм ялкау эше начар кешеләрнең бернигә кирәге юк...
— Тик бу эмигрантлар керүне әзәйтер ләбаса,— дидем мин.
Картлач килешүен белдереп баш какты.
— Вакыты килеп җиткәч, мин алар өчен илгә керү ишекләрен бөтенләй ябарга тәкъдим итәрмен. Ә хәзергә һәркайсы әзрәк алтын алып керсен. Аннары гражданлык хокукы алу вакытын озайту кирәк. Торабара ул бөтенләе белән бетерелер. Американнар өчен хезмәт итәргә теләгәннәр эшли бирсен, әмма аларга Америка гражданнары хокукы

бирмәскә кирәк. Американнар җитәрлек инде. Ил халкы артсын өчен аларның һәрберсе үзе кайгырта ала. Боларның һәммәсе — хөкүмәт эше. Моны бүтәнчә кую сорала. Хөкүмәт членнарының барысы да промышленность предприятиеләрендә акционерлар булып торырга тиеш — ул чагында алар ил хасиятен җиңелрәк анларлар. Әлегә миңа... төрле вак-төяк ихтыяҗлар өчен сенаторларны үземә сатып алырга туры килә.

Ул тын алып куйды да аягын селкетеп:

— Тормыш алтын тавы югарылыгыннан гына дөрес күренә,— дип өстәде.

Хәзер инде аның политик карашлары җитәрлек ачыклангач, мин:

— Ә сез дин турында ни уйлыйсыз? — дип сорадым.

— О! — дип кычкырып куйды ул, тезенә кул сугып һәм кашын җәһәт сикертеп.— Бик яхшы уйлыйм! Дин халыкка бик кирәк. Мин моңа ихластан ышанам. Якшәмбе көннәрендә хәтта үзем дә чиркәүдә нотык сөйлим әле... әйе, шулай итми ни!

— Ә сез ни сөйлисез?— дип сорадым мин.

— Чын христианин чиркәүдә ни әйтә алса, шуның барысын да! — диде ул чын күңеленнән.— Мин, әлбәттә, ярлылар мәхәлләсендә нотык тотам — ярлылар һәрчак яхшы сүзгә һәм аталарча кайгыртуга мохтаҗ... Мин аларга болай сөйлим...

Аның йөзе бер генә мәлгә нәни бала төсмеренә керде, ләкин шуннан соң ук ул иреннәрен нык итеп кысып куйды да түшәмдәге оялчан мәхәббәт аллалары йоркшир дуңгызының алсу тиресе белән юан бер хатынның шәрә тәнен каплап торган сурәткә күтәрелеп карады. Аның төссез күзе тирәнлегендә түшәмнең чуар буяулары чагылып, төрле төстәге очкыннар уйнаклап алды.

— Христоска табынган агай-энеләр һәм апа-сеңелләр! Көнләшү дигән хәйләкәр Иблис коткысына бирелмәгез, фани дөнья кайгысын читкә куыгыз. Җирдәге тормыш кыска: кеше бары тик кырык яшькә чаклы гына яхшы эшче булып санала, кырыктан соң аны фабрикаларга алмыйлар. Тормыш ышанычлы түгел. Эшләп ятканда кулыгыз саксыз бер хәрәкәт ясадымы,— машина сезнең кулыгызны чәрдәкләп ата, кояш суктымы — бетте! Сезне һәркайда авырулар сагалап тора, һәркайда бәхетсезлек. Ярлы кеше биек йорт түбәсенә менгән сукыр ише ул — кая гына бармасын, апостол Иуданың туганы апостол Иаков әйтмешли, ул егылып чәлпәрәмә киләчәк. Туганнар! Сез фани дөньяның кадерен белергә тиеш түгелсез, аны җан кыючы Дьявол яраткан. Христосның сөекемле балалары, сезнең тереклек кылу урыныгыз, Атакаегызныкы шикелле үк, фани дөньяда түгел, ә күктә. Һәм сез үзегезнең җирдәге көннәрегезне түземлек белән, шикаять белдермичә яшәп китсәгез, ул сезне оҗмах бакчасына кабул кылып, җирдә күрсәткән хезмәтләрегез өчен мәңгелек рәхәтлек белән бүләкләр. Бу тормыш сезнең җаннарыгызның гөнаһларын юар өчен генә, һәм монда никадәр газап чиксәгез, тегендә сезне шулкадәр рәхәтлек көтәр,— Иуда апостол үзе шулай дигән.

Ул бармагы белән түшәмгә төртеп уйланып торды да салкын һәм катгый төстә дәвам итте:

— Шулай, кадерле агай-энеләр һәм апа-сеңелләр! Ошбу тормыш, әгәр без аны кем булуына карамастан якыннарыбызны ярлыкау хакына корбан итмәсәк, буш һәм чүп нәрсә. Иорәкләрегезне көнләшү шайтаны коткысына салмагыз! Сезгә нидән көнләшеп торырга соң? Җирдәге рәхәтлек дигән нәрсә ерак һәм Дьявол вәсвәсәсе ул. Бае белән ярлысы, патшасы һәм күмер чыгаручысы, банкиры белән урам себерүчесе — без һәммәбез дә үләселәр. Бәлки җәннәтнең салкынча бакчаларында күмер чабучылар патша булыр, ә патшалар, себерке тотып, ул бакча сукмакларыннан коелган яфракларны һәм сез көн саен ашаячак конфет кәгазьләрен себереп йөрерләр. Туганнар! Ошбу җирдә кеше җаны

яшь бала шикелле адашып йөри торган ошбу караңгы гөнаһ урманында берәр нәрсә теләрлекме соң? Оҗмахка ярлыкау һәм буйсыну юлы белән барыгыз, өлешегезгә тигән һәр нәрсәгә дәшми-тынмый гына түзеп торыгыз. Барчасын һәм хәтта сезне кимсетүчеләрне дә ярлыкагыз...

Ул яңадан күзен йомды да кәнәфиендә чайкала-чайкала дәвам итте:

— Бераүләрнең ярлылыгы белән икенчеләрнең байлылыгын күрсәтеп, йөрәгегездә көнләшү дигән гөнаһлы хисләр уятучы кешеләрне тыңламагыз. Ул кешеләр — Дьявол илчеләре, ходай тәгалә үз якыныннан көнләшүне тыя. Байлар да ярлы — аларның үз якыннарын яратуы ярлы. Алланың туганы, храмның беренче рухание Иуда: «Байны яратыгыз, чөнки аны хода сайлаган!» — дип өндәгән. Дьяволның тигезлек дигән коткысына һәм башка уйдырмаларына иярмәгез! Мондагы — җирдәге тигезлек нәрсә соң ул? Бер-берегезгә җаннарыгызның Аллагыз каршындагы чисталыгы белән генә тигезләнергә омтылыгыз. Иңегездәге тәре авырлыгын түземлек белән йөртегез, ә буйсыну сезнең ул йөгегезне җиңеләйтер. Сезнең, балакайларым, Аллагыз бар, һәм сезгә башка берни кирәкмәс!

Картлач тынып калды, авызын ерып җибәрде дә, алтын тешләрен җемелдәтеп, тантаналы төстә миңа карап калды.

— Сез динне бик яхшы файдаланасыз,— дидем мин.

— Ә, әлбәттә! Мин аның бәясен беләм,— диде ул.— Кабатлап әйтәм,— дин ярлыларга кирәк. Миңа ул ошый. Ул җирдәге бар нәрсә шайтан дип өйрәтә. Әгәр жаныңны коткарасың килсә, монда — җирдә бер ни дә теләмә һәм бернәрсәгә дә үрелмә, кеше! Яшәү тәмен үлгәннән соң татырсың — күктәге һәммә нәрсә синеке! Кешеләр шушыңа ышанганда, алар арасында эш йөртүе җиңел. Әйе. Дин — май ул. Аны тормыш машинасына никадәр мулрак сыласаң, частьләрнең ышкылуы шулкадәр кимеп, машина йөртүченең бурычы шулкадәр җиңеләер...

«Әйе, ул король» — дигән карарга килеп, мин күптән түгел дуңгыз көтүчеләр нәселеннән булган бу кешедән:

— Ә сез үзегезне христианин дип саныйсызмы? — дип сорадым.

— О, әйе, әлбәттә! — дип кычкырып җибәрде ул тулы ышаныч белән. Кулын югары күтәрде дә саллы төстә: — Ләкин шул ук вакытта мин американ, шулай булгач, кырыс моральче дә,— диде.

Аның йөзе фаҗигале бер рәвешкә керде: иреннәре бүлтәеп чыкты, колаклары борынына таба авышты.

— Ни әйтергә телисез?..— дип белештем мин тавышымны баса төшеп.

— Икебез арасында калса гына! — дип кисәтте ул.— Американның Христосны тануы мөмкин түгел!

— Мөмкин түгел?— дип пышылдап сорадым мин тынлыктан соң.

— Әлбәттә мөмкин түгел! — дип тәкрарлады ул да пышылдап.

— Ә нигә? — дип сорадым мин дәшми торгач.

— Ул уйнаштан туган! — Картлач миңа күз кысып куйды да якягына каранып алды. — Аңлыйсызмы? Америкада уйнаштан туганнарның алла гына түгел, хәтта чиновник булырга да хакы юк. Хәлле кешеләр аны үз араларына бер кайда да кертми. Аңа бер кыз да кияүгә чыкмый. О, без гаять кырыслар! Әгәр дә без Христоска табынсак, безгә уйнаштан туганнарның барчасын яхшы кешеләр дип танырга туры киләчәк... хәтта алар негр белән ак тәнле хатын балалары булсалар да. Моның коточкыч икәнен аңлыйсызмы?! Ә?

Бу хәл чыннан да куркыныч булса кирәк — картның күзе яшелләнеп һәм ябалакныкы шикелле акаеп калды. Ул түбәнге иренен көч-хәл белән өскә тартып меңгерде дә тешләренә ныгытып ябыштырып куйды. Мөгаен, ул мондый кыяфәт аның йөзен саллы һәм кырыс итә дип уйлагандыр.

Демократик илнең әхлагына кәефем кырылып, мин:

— Ә негрны сез һичничек кеше дип танымыйсызмыни?— дип сорадым.

Ул үкенеч белән:

— Нинди беркатлы нәрсә! — дип кычкырып әйтте.— Алар кара тәнле ләбаса! Алардан начар ис тә аңкып тора. Ак тәнле хатын белән яшәгәнен белсәк, без негрны җәзага тартабыз. Шундук муенына бау салабыз да — дарга... тартып-сузып тормастан! Әхлак дигәндә без бик кырыс...

Хәзер ул миндә үзенә карата мәеткә ирексездән күрсәтә торган хөрмәт уятты. Әгәр эшкә керешкәнмен икән инде, аны ахырынача җиткерергә тиешмен. Мин, хакыйкатьне, иректне, акылны һәм үзем ышана торган бар яктылыкны аяк астына салып таптау барышын тизләтергә теләп, сораулар бирүемне дәвам иттердем.

— Сезнең социалистларга мөнәсәбәтегез нинди?

— Шайтан хезмәтчеләре нәкъ шулар инде! — дип җавап кайтарды ул, учы белән тез башына сугып алып.— Социалистлар тормыш машинасына эләккән ком алар, һәр җиргә үтеп кереп, механизмның дөрес эшләвен боза торган ком. Яхшы дәүләттә социалистлар булырга тиеш түгел. Димәк, Вашингтондагы кешеләр үз бурычларын ачык аңлап җиткермиләр. Алар социалистларны гражданлык хокукларыннан мәхрүм итәргә тиешләр. Шул да җитә калыр иде. Минемчә, хөкүмәт тормышка якынрак торырга бурычлы. Моның өчен аның бөтен членнары миллионерлар арасыннан тупланырга тиеш. Шулай менә!

— Сез бик максатчан кеше! — дидем мин.

— О, әйе! — дип килеште ул башын уңай чайкап. Инде аның йөзендәге барлык балалык галәмәтләре юкка чыкты һәм яңакларында тирән җыерчыклар хасыйл булды.

Минем аннан сәнгать хакында сорыйсым килде.

— Сезнең мөнәсәбәтегез... — дип башлавыма, ул бармагын күтәрде дә үзе сөйләргә кереште:

— Социалистның башында — атеизм, эчендә — анархизм. Аның җаны шайтан куйган акылсызлык һәм ачу канатлары белән җилкенә... Социалист белән көрәшер өчен зуррак дин һәм күбрәк солдат булу шарт. Дин — атеизмга каршы, солдатлар — анархиягә каршы. Алдан социалистның башына чиркәү нотыклары кургашыны коярга кирәк. Моның шифасы тимәсә, солдатлар ул кургашынны аның эченә тутырсын!..

Ул ышаныч белән башын чайкады да нык итеп:

— Шайтанның көче зур! — диде.

Мин рәхәтләнеп:

— О, шулай! — дип килештем.

Мин Алтын дигән Сары шайтанның шундый калку рәвештәге тәэсирен беренче кат күзәтә идем. Картлачның коры, сөяк чире һәм ревматизм эштән чыгарып бетергән сөякләренә, аның тузган капчык сыман салынып төшкән хәлсез, ябык тәненә, бу зур булмаган кылка ит күченә ялган һәм рухи бозыклыкның салкын, шәфкатьсез ихтыяры җан өртелгән иде. Картның күзе ике яңа тимер акча шикелле ялтырап тора. Һәм аның бар төше ныгып китте, катып калды. Аның хезмәтчегә охшашлыгы тагын да арта төште, әмма мин аның әфәндесе кем икәнлеген белә идем инде.

— Сәнгать турында сез ни уйлыйсыз?— дип сорадым мин.

Ул миңа карады, кулын йөзендә тиз-тиз йөртеп, әйтерсең, аннан каты ачу төсмерен сөртеп ташлады. Ул йөздә тагын балалык галәмәте пәйда булды.

— Ничек дидегез?

— Сәнгать турында сез ни уйлыйсыз?

— О! — дип тыныч кына аваз салды ул.— Мин аның турында уйламыйм, мин аны сатып кына алам...

— Миңа бу билгеле. Ләкин сезнең, бәлки, аңа карата үз карашларыгыз яисә таләпләрегез бардыр?

— Ә! Минем таләпләрем, әлбәттә, бар... Ул сәнгать дигәннәре кызык булырга тиеш — мин менә ни таләп итәм. Миңа көләрлек булсын. Минем шөгылемнең көлкеле ягы әз. Кайвакытны мине нииндидер тынычландыргыч, ә кайвакытны тәнне дәртләндерә торган нәрсәгә коендырып алырга кирәк. Сәнгатьне түшәмгә яисә стенага ясаганда, ул аппетит уятсын... Рекламаларны иң яхшы, җете буяулар белән ясарга кирәк. Реклама сезнең борынгызны ерактан, үзенә җитәргә бер чакрым кала ук эләктереп алсын да үзе чакырган төшкә тартып китерсен. Шул чагында ул үзенә тотылган акчаны аклый. Статуя яки ваза икән,— аның мәрмәр яисә фарфорга караганда бронзасы яхшырак. Хезмәтчеләр бронзаны фарфор кебек үк еш ватмый. Әтәчләр сугышы белән күсеәр талашы бик шәп! Үлемгә килеп терәлмәсә, бокс та бик күркәм... Музыка патриотик булсын. Марш — һәрчак яхшы, тик иң яхшы марш — американнарныкы. Америка — дөньядагы иң камил ил, шуңа күрә америка музыкасы җирдә иң камиле. Әйбәт музыка әйбәт кешеләр янында гына. Американнар — җирдәге иң күркәм кешеләр. Иң күп акча аларда. Бездәге хәтле акча беркемдә юк. Шуңа күрә безгә тиздән бөтен дөнья күчеп бетәчәк...

Мин бу сырхау сабыйның үз-үзеннән канәгать төстә лыгырдавын күреп, тыңлап тордым да рәхмәт хисе белән Тасмания кыргыйларын уйлап алдым. Аларны да кеше ашаучылар диләр, тик аларның эстетик хисләре бар.

— Сез театрда буласызмы?— дип сорадым мин Сары Дьяволның карт колыннан. Үзенең дөньяда яшәве белән хурлаган илне мактавыннан туктатасым килде.

— Театрдамы? О, әйе! Ул да сәнгать, мин беләм! — диде ышаныч белән.

— Ә сезгә театрда нәрсә ошый?

— Декольтелы яшь ханымнар күп булып, алардан югарырак утыруы хуп! — диде ул бераз уйлап торгач.

— Театрда, барыннан да бигрәк, сез нәрсә яратасыз?— дип сорадым мин аяныч белән.

Ул авызын бөтен бите киңлегенә җәеп алды да:

— О!— дип кычкырып куйды.— Һәммә кеше кебек, әлбәттә артисткаларны... Матур һәм яшь булсалар, артисткалар һәрчак әйбәт. Тик чыннан да кайсысы яшь икәнлеген шундук чамалавы гына авыр. Аларның барчасы шундый шәп кылана... Мин аңлыйм, бу аларның һөнәрләре. Ләкин кайвакытны: «Әһә, менә монысы кыз инде!» дип уйлыйсың. Аннары соң аңа илле яшь икәнлеге һәм моңарчы иң кимендә ике йөз сөяркәсе булганлыгы ачыклана. Бу инде яхшы түгел... Цирктагы артисткалар театрдагыларыннан күркәмрәк. Алар һәрвакыт яшьрәк һәм зифарак...

Ул бу өлкәнең яхшы белгече, ахрысы. Хәтта мин — бөтен гомеремне кимчелекләргә күмеп бетергән азгын гөнаһлы бер кеше дә — күп нәрсәләрне беренче кат аннан ишеттем.

— Ә сезгә шигырьләр ошыймы?— дип сорадым аннары.

— Шигырьләр? — дип кайтарып сорады ул, күзен итек очына төбәп һәм маңгаен җыерып. Уйлап торды да, башын күтәреп бар тешләре күренгәнче авызын ерып:— Шигырьлар миңа бик ошый. Рекламаларны шигырь белән баса башласалар, тормыш бик күңелле булыр иде.

Мин бүтән сорау бирергә ашыктым:

— Сезнең яраткан шагыйрегез кем?

Карт миңа карады да аңламыйча һәм әкрен генә:

— Ни дидегез?— дип сорады.
Мин соравымны кабатлап бирдем.
— Һм... сез бик күңелле егет! — диде ул башын икеләнү белән кагып.— Шагыйрьне нигә дип яратыйм икән соң мин? Аннары аны ярату нигә хаҗәт?
— Гафу итегез! — дидем мин, маңгаемдагы тирне сөртеп.— Мин сездән яраткан китабыгызны сорамакчы идем. Чек кенәгәсен түгел, әлбәттә...
— Ә! Бусы бүтән нәрсә! — дип килеште ул.— Минем яраткан китабым икәү — Библия белән Төп бухгалтерия китаплары. Алар зиһенне икесе дә бердәй дулкынландыра. Кулга алуга, аларның сиңа кирәк нәрсәне бирә торган көчен сизәсең.
«Ул мине мыскыл итә!» — дип уйладым мин һәм игътибар белән аның йөзенә карадым. Юк. Аның күзе бу сабыйның самимилегенә шикләнүгә урын калдырмый. Ул, кабыгында ятучы кипкән чикләвек төше шикелле булып, үзенең кәнәфиенә чумып утырган, аның үз сүзләренең ихласлыгына ышануы әллә каян күренеп тора.
— Әйе! — диде ул, тырнакларын караштыргалап.— Алар житәрлек дәрәҗәдә яхшы китаплар! Берсен пәйгамбәрләр язган, икенчесен мин дөньяга үзем яраттым. Минем китабымның сүзләре аз. Анда — саннар. Алар намус белән һәм тырышып эшләргә теләгән кешенең нигә һәвәслеге турында сөйлиләр. Мин үлгәч хөкүмәт минем китабымны бастырып чыгарырга тиештер. Кешеләр бу биеклеккә ничек ирешергә мөмкин икәнен белсеннәр.
Җиңүчеләрчә тантаналы ишарә белән ул үз тирә-юнен камап алды.
Мин әңгәмәне тәмамларга вакыт житкәнен сизеп алдым. Башыннан йөргәнгә һәркем битараф кала алмый.
— Бәлки сез фән хакында берәр нәрсә әйтерсездер? — дип сорадым мин әкрен генә.
— Фән? — диде ул, бармагын һәм күз карашын түшәмгә чөеп. Аннары сәгатен чыгарды да вакытны карап алды, капкачын япкач, чылбырын бармагына урап, шул сәгатьне болгап торды. Шуннан соң гына тирән итеп сулап куйды да сүзгә керешге.
— Фән... әйе, мин беләм! Фән — китаплар ул. Алар Америка турында әйбәт сөйләсәләр,— файдалы. Әмма китапларда дөреслекне сирәк язалар. Ул китап яза торган... шагыйрьләргә, уйлавымча, аз түли торганнардыр. Һәркем эш белән мәшгуль булган илдә китап укырга кеше калмый... Әйе, шагыйрьләр үзләренең китаплары сатылмаганга күрә ачулы. Хөкүмәт китап язучыларга яхшы түләргә тиеш. Тук кеше һәрвакыт яхшы күңелле һәм шат була. Америка хакындагы китаплар гомумән хаҗәт икән, яхшы шагыйрьләр ялларга кирәк, ул чагында Америка мохтаҗ булган бөтен китаплар эшләнер... Менә шул.
— Сез фәнне таррак күзаллыйсыз! — дидем мин.
Ул күз кабагын төшереп уйга калды. Аннары күзен ачып, ышанычлы төстә дәвам итте:
— Соң... укытучылар, философлар... алары да фән. Профессорлар, акушеркалар, теш врачлары, беләм, беләм. Адвокатлар, докторлар, инженерлар. Бу кирәк нәрсә. Яхшы фәннәр... начарлыкка өйрәтергә тиеш түгелләр... Әмма миңа бервакыт кызымның укытучысы социаль фәннәр бар дип әйтте... Монысын инде мин аңламыйм. Зарарлы дип уйлыйм. Яхшы фәннең социалист тарафыннан эшләнүе мөмкин түгел. Социалистлар фән белән гомумән шөгыльләнергә тиеш түгел. Файдалы яки кызыклы фәнне Эдисон ясый, әйе. Фонограф дисеңме, синематограф дисеңме — алары файдалы. Ә фәнгә караган китапларның күп булуы артык. Кешеләргә анда... төрле икеләнүләр кузгата торган китаплар уку хаҗәт түгел. Җирдә һәр нәрсә тиешенчә ага... китапларны эш белән бутарга бөтенләй кирәкми.

Мин торып бастым.
— О! Сез китәсезмени?— дип сорады ул.
— Әйе!— дидем мин.— Бәлки хәзер, инде минә чыгып китәм дигәндә, сез миңа миллионер булуның мәгънәсен аңлатып бирерсездер?
Җавап урынына аны очкылык тота башлады, аягы таргышып куйды. Ә бәлки аның шулай көләргә күнеккән булуы ихтимал.
— Гадәт ул! — дип кычкырып әйтте ул, хәл алып.
— Гадәт?— дип сорадым мин.
— Миллионер булу... гадәт ул.
Мин уйлап тордым да аңа соңгы соравымны бирдем:
— Сез сукбайлар, опиум тартучылар һәм миллионерлар бер үк нәрсәләр дип уйлыйсызмыни?
Бу аны үпкәләтте, ахрысы. Ул күзен акайтып, аны яшел үт төсле итте дә коры гына:
— Мин сезне начар тәрбия алгансыздыр дип уйлыйм,— диде.
— Сау булыгыз!— дидем мин.
Ул мине кунакчыл төстә болдырга кадәр озата чыкты да, итек башларын бик зур игътибар белән карый-карый баскычның югары басмасында басып калды. Аның йорты алдында тигез итеп кыркылган куе үлән үсеп утыра. Мин шул үләннән атлый-атлый бу кешене инде бүтән күрмәячәгем турында ләззәтләнеп уйлый идем.
Мин артымнан:
— Һалло!— дигәнне ишетеп алдым.
Әйләнеп карадым. Ул болдырга баскан килеш һаман миңа карап тора иде.
— Ә нәрсә, сезнең Европагызда артык корольләр бармы әллә?— дип сорады ул тын гына.
— Миңа дисә, аларның барысы да артык!— дип җавап бирдем мин.
Ул уң якка төкерде дә:
— Мин үземә бер пар шәп король ялларга уйлап торам әле,— диде.
— Нәрсәгә алар сезгә?
— Кәмит өчен. Мин аларга менә шушында бер-берсен боксларга кушар идем...
Ул өе каршындагы мәйданга төртеп күрсәтте һәм сорау төсмере белән:
— Һәр көнне сәгать бердән икенче яртыга хәтле, ә?— дип өстәде.— Төшке аштан соң ярты сәгатеңне сәнгатькә багышлау... начар булмас иде.
Ул җитди сөйли һәм аның үз хыялын тормышка ашырыр өчен бөтен көчен куячагы күренеп тора иде.
— Бу максатыгыз өчен сезгә корольләр нигә кирәк булды соң? — дип белешмәк булдым мин.
— Монда беркемнең дә андый корольләре юк! — дип аңлатты ул, кыска гына итеп.
Мин:
— Тик корольләр бүтән кеше куллары белән генә сугыша лабаса!— дидем дә китеп бардым.
— Һалло!— дип эндәште ул икенче кат.
Мин яңадан туктап калдым. Кулын кесәсенә тыгып, ул һаман әүвәлге урында басып тора әле. Аның йөзендә ниндидер хыял сыман нәрсә төсмерләнә иде.
— Сез нәрсә?— дип сорадым мин.
Ул иреннәрен чәйнәп торды да әкрен генә:
— Ә сез ничек уйлыйсыз: бокска өч ай буена, һәр көнне яртышар сәгатьтән ике король — күпме торыр икән бу, ә?— диде.

**Әхәт ГАФФАР тәрҗемәсе.**

## Таш та сөйләшә икән

1966 елның октябре иде. Уфа-Ташкент поездында барам. Купедә бер үзем. Күңелсез. Минә Оренбургта минем янга бер кеше килеп керде. Ул бик телдәр булып чыкты. Уфа хәлләрен сорашты. Минем язучы икәнне белгәч, М. Фәйзи хакында тезеп алып китте. Менә нәрсә сөйләде ул:

«Мин Мирхәйдәр Фәйзуллинны күреп беләм. Без бәләкәй чакларда ул безнең авылга җәй көннәрендә кардәшләренә кайта иде. Мин үзем Юнай авылыннан. Безнең авыл Орскидан егерме биш чакрым гына.

Авылыбыз янында «Биек тау» бар. Мирхәйдәр абый шул тауның кашлагына чыгып язып утыра иде. Без, балалар, читтән-читтән, ташларга ышыкланып, шаккатып күзәтәбез.

Уңда калкып чыгып торган ике таш бар. «Мирхәйдәр тауда «тыятыр» яза. Анау ике ташны ике кеше итә. Берсен — кыз, берсен егет итеп, сөйләштерә икән», — дип сөйли иде халык. Шуңа бер көнне, ташлар сөйләшкәнне ишетер өчен, без качып-посып, Мирхәйдәр утырган җиргә якын ук бардык. Әмма таш тавышын ишетмәдек. Мәгәр Мирхәйдәрнең сөйли-сөйли язганын ишеттек.

Соңыннан, Мирхәйдәр үлгәч тә, хатын-кыз сөйләнә иде әле:

«Галиябану белән Хәлил булып сөйләшәләр икән анау ташлар!»

«Юк, фәлән кеше ишеткән: берсе—Галиябану, тегесе—Исмәгыйль, ди аларның...»

«Бәр көн соңлатыбрак тау буеннан кайтып килә икән фәлән карчык, әй өздереп җырлый ди инде «Галиябану»! Туктап тыңлап тордым, ди... Өздерә генә ди, таш, бичара. Елап кайтып киттем ди».

Миң авырый идем. Ишеткәч тә язып куя алмадым. Бер-ике көннән соң гына яздым бу истәлекне.

Бу юлдашның исем-фамилиясен дә оныттым. Ә М. Фәйзи хакындагы легенда миңа бик ошады. Барып тыңларга иде. Бәлки, ул ташлар һаман сөйләшәләрдер: телне бит аларга Мирхәйдәр агаң биргән.

**Йосыф ГӘРӘЙ,**
башкорт язучысы.

## Яшьлекне сагыну моңнары

М. Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» повестен укыганда, утызынчы, кырыгынчы һәм илленче елларны татар авылында яшәгән буынның күз алдына балалык һәм яшьлек хатирәләре килеп баса. Без повесть укуны онытып, үзебезнең балалык һәм яшьлек чорына әйләнеп кайтабыз.

...Менә без җәйге кичтә урамда бүрәнә өстенә тезелеп утырып, әкият тыңлыйбыз, бәетләр әйтешәбез, табышмаклар чишәбез:

— Татлыдан татлы ни татлы?

— Сабый баланың йокысы татлы.

— Ачыдан ачы ни ачы?

— Ананың баласын сагынып елаган күз яше ачы.

...Менә кар көртләренә күмелеп утырган авыл өе. Син, авыл малае, тышта утын ярып, абзарны чистартып, бәрәңге бакчасына бәләкәй чана белән тирес чыгарып, малларга печән салып өйгә керәсең. Киемеңне салып эләргә өлгермисең — әниең өстәлгә мичтән яңа гына чыккан, майда чыжлап утырган тары һәм кабак бәлеше китереп куя. Җанга рәхәт булып чишмә суы салган самовар кайнап утыра. Анаң, зәңгәр чәйнектә такта чәй ясап, бер ун минут чиккән тастымал белән ябып тота. Бәлеш ашап, үз умарталарыңнан алган кәрәзле бал белән чәй эчеп җибәрәсең — һәм дөньяда синнән дә бәхетле кеше юк! Битләрең Ык буе әрәмәсендәге гөлҗимеш чәчәге кебек яна, анаң сиңа карап елмая, сөенә, эченнән генә «таянычым минем, куанычым, бәхетең мул булсын», дип теләп куя. Бераз китап укып, ял иткәч, кичен тальян гармуныңны алып клубка «бичыр уйнарга» чыгып китәсең...

Безнең яраткан язучыларыбыз Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев кебек Мөхәммәт Мәһдиев тә — авылга гашыйк кеше, асылда авыл җырчысы. «Торналар төшкән җирдә» повестеның һәр бүлеге — үзе бер җыр, анда шигъри көч бар, үз моңы, үз аһәңе бар. «Лирик документаль повесть» жанры бу әсәргә бик урынлы бирелгән, чөнки повестьтагы һәр персонаж — тормышта реаль яшәгән яисә әле дә исән кеше.

Мәһдиев өлкән буын турында дулкынланмыйча яза алмый, ул заман кешеләренең олуг җанлылыгын, чиста күңеллелеген, эш сөючәнлеген, кунакчыллыгын шундый җанлы итеп тасвирлый, — син аларны үз авылдашларың һәм яхшы танышларың итеп сизә башлыйсың. Алар — матур җанлы, инсафлы, тырыш, намуслы кешеләр. Мәһдиев яшь буынга бу повесте белән үзенең күптән әйтәсе килгән сүзен әйтә кебек: менә сезнең ата-бабаларыгыз нинди иделәр!.. Аларга сезнең замандагы кебек җиңел тормыш, мул яшәү тимәде. Алар тормышның бар авырлыгын үз җилкәләрендә күтәреп чыктылар, азга риза булдылар, ләкин зарланмадылар, рухи яктан бай яшәделәр, җыр-такмак белән, уен-көлке белән, бер-берсенең күңелен күтәреп, күңелле яшәделәр. Алар — табигать балалары иде, шуңа күрә гади, самими һәм юмарт булдылар. Онытмагыз аларны, онытмагыз алар яшәгән заманаларны! Ата-бабаларын оныткан кеше — рухи ярлы, мескен, кызганыч була...

Мәһдиевнең персонажлары кечкенә генә хатирә кебек бүлектә аз гына сурәтләнеп китсә дә, хәтердә бик яхшы кала, чөнки алар бик тә «тере» кешеләр, үзенчәлекле шәхси сыйфатлары белән кабатланмаслык кешеләр. Кибетче вак акча кайтарып биргәндә, «миңа ыздача нәрсәгә», — дип вак акчаны кибетче аяк астына терсәге белән сыпырып төшерә торган Бәдри, «Йосыф-Зөләйха» кыйссасын яратучы хатын Гыйльмениса, бик вәкарь белән генә яши торган, Тукай белән Габдулла Кариевне күреп белгән «ак тегүче» Гатият абзый, авыл эрудиты Насибулла карт, тирән фаҗигалы язмышлы Әсма карчык, «әя агач, яшең күпме, түгелгән яфрагың күпме», дип җырлаучы 80 яшьлек Хәдичәтти — тагын һәм онытылмаслык итеп бирелгән персонажлар.

Ләкин ул кешеләр — изге, әүлия түгел, фәрештә кебек канатлары үсә башлаган бәндәләр түгел. Алар — җир кешеләре. Алар я Зәкәрҗан кебек шаулап-дөрләп, тузан туздырып, кешеләрне шаккатырып яши, я Зөлфия кебек авыл үсмерләренә дөньяның иң серле, иң куркыныч, иң шомлы почмакларын ача, ә бүре Әскый төсле артык дөнья кумыйча, ашыкмый-кабаланмыйча яши, күп балалар үстерә, алар өчен матча астында даимән берничә тал чыбыгы да тота, шулай да ул балалар эшчән, намуслы, аталары кебек намуслы булып үсәләр. Тик — гомер бит — картаялар, гүргә керәләр... «Җир шары шулай тагын бер юньле кешене үзенә алды», — ди Мәһдиев, һәм бу сүзләрдә үткән гомергә, олы буынга карата тирән сагыш сизәсең.

Язучыларга, бигрәк тә шагыйрьләргә күпчелек азыкны һаман да авыл тормышы, авыл кешеләре бирүен дәвам итә. Нинди генә милли әдәбиятны алма, — шагыйрьләрнең туксан проценты авылдан чыккан кешеләр. Моның сәбәбе нидән? Кешеләр анда үз кул көче белән эшләп, саф һава сулап, яңа сауган сөт эчеп, урман шаулавын, сандугач сайравын тыңлап үскәнгәме? Җир һәм табигать белән бәйләнештә яшәгәнгәме? Авырлык күреп үскәнгәме? Авыл халкының үзара мөнәсәбәтләре самими, табигый, үзара элемтәләре нык булгангамы? Әгәр дә киләчәктә авыллар бетеп, алар урынына агрошәһәр генә калса, поэзиянең һәм лирик прозаның чишмәләре корый башламасмы? «Соңгы елларда, тамак туйгач, без авылны шәһәрләштерү турында мавыгып сөй-

ләштек... Авыл тормышы үзенең поэтикасын югалту куркынычы алдына килеп басты». Мәһдиевнең бу сүзләрендә шул проблема турында борчылу сизелә. Бу инде безнең туган якларга гына түгел, ә бөтен илгә (һәм «бөтен кешелеккә» дисәк тә хата булмас) хас булган иҗтимагый, экономик һәм мораль проблема, һәм аның безнең әдәбиятта чагылуы очраклы хәл түгел.

Тамырларны онытмау, тамырларны эзләү...

Авыл клубларында хәзер зур һәм кыйммәтле магнитофоннар уйный, Мәскәүдә һәм Европада соңгы модада булган бию музыкалары яңгырый. Ә шундый үзенчәлекле, кабатланмаслык «түгәрәк уеннарын» һәм уннарча башка төрле матур халык уеннарын һәм биюләрен еш күреп буламы анда? «Юк» дип әйтсәк, гөнаһлы булмабыз. Җәйге кичләрдә авыл өстеннән тальян моңнары яңгырыймы? Соңгы елларда туган якларга кайткач, берничә авылда кичләрен тальян тавышын ишетергә зарыгып йөрдем мин, ләкин ишетә алмадым. Илдар Юзеев, бер шигырендә гармунсыз авылны «сандугачсыз урман шикелле» дип яза — бик төгәл чагыштыру бу.

М. Мәһдиевнең бу повестен укыгач, безнең балалык һәм яшьлек авыр булды, ләкин рухи яктан ямьле һәм бай булды, дип сөенәсең, үзеңнең тамырларыңны онытмаска, оныткannарын эзләргә дәрт туа. Минемчә, әдәби әсәрнең кыйммәте — әнә шундый дәрт кузгатуда.

Тамырларны онытмау, тамырларны эзләү... Соңгы елларда асылда шул проблеманың теге яки бу ягын чагылдырган әсәрләр чыгуы очраклы хәл түгел, әлбәттә (Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев, мөхтәрәм олы буын язучыларыбыздан Гомәр ага Бәширов, Әмирхан Еники һ. б.). Әйдәгез, бер утырып уйлап карыйк әле: хәзер сирәк очрый торган хайваннарны һәм үсемлекләрне «кызыл кенәгә»гә кертәләр, аларны саклап калдыру өчен заповедниклар һәм заказниклар ачалар. Ә соң безнең халыкта гасырлар буена яшәп килгән кайбер гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр, уеннар, җыр-бәетләрне шундый «кызыл кенәгә»гә кертер вакыт җитмәдеме? Яңа уеннар, традицияләр бик хуп нәрсә ул, ләкин алар тиз генә кереп «оялый» алмыйлар, аннан соң уйламыйча башка милли культурадан күчереп алынганнарының кайберсе ничектер ятышып та бетми. Соңгы елларда мин берничә татар туенда булдым. Анда татарча «Ачы! Ачы! Ачы!» дип кычкыруларыннан миңа ниндидер ачылы-төчеле булып китте...

Мин үзем уникe ел чит илләрдә эшләдем, 18 илнең халкын һәм аларның тормышын күрергә туры килде. Туган җирдән бик ерак һәм туган илгә бөтенләй охшамаган хәйран җирләрдә яшәгәндә туган якларны сагыну хисенең көчен һәм тирәнлеген яхшы беләм мин. Синең өстәлеңдә банан, ананас, манго һәм башка әллә нинди җимешләр тулып утыра, ә син әрәмәдән яңа гына җыеп алып кайткан кара карлыган, кара бөрлегән яисә җир җиләген сагынасың. Таиланд патшасының әкияттәгедәй бакчасында үткәрелгән банкетында кырык-илле төрле эчемлекләр, аннан да артык киек җәнлек, кош ите, балык һәм башка тагамнәр тәкъдим итәләр, ә син шуннан кайтканда әнкәң пешергән бәрәңге бәлешен һәм балан суын искә төшерәсең...

Балалык һәм яшьлекне сагыну, туган җирне сагыну көче — илаһи көч ул, һәм менә шул көч М. Мәһдиевнең повестенда бик зур тирәнлек һәм экспрессия белән күрсәтелгән. Мәһдиев — туган җиренә гашыйк язучы, аның һәр җөмләсендә туган җирләргә, андагы халыкка карата сагышлы моң белән сугарылган ярату хисе сизелә.

Мәһдиев иҗатының уңышына һичшиксез аның үткен һәм камил булган теле булышлык итә. Автор җөмләләрен катлауландырып, «бизәкләп» тормый, гади итеп яза, шуңа күрәдер, аның әсәрләрен укыганда үзеңне кышкы кичләрдә авыл өендә хикәят тыңлаучы кебек сизәсең.

Автор, «әйтимме икән, әйтмим микән, әйтсәм, гаепләмәсләр микән», дип тормый, белгәнен, күргәнен, ишеткәнен, хәтердәгеен «шалт итеп» өздереп әйтә дә бирә. Гомумән, Мәһдиев әйтәсе килгән сүзен әйтмичә, куркып-өркеп торучылардан түгел, шуңа күрә аның әсәрләре дә табигый һәм «тозы-борычы» нәкъ төгәл булып чыга.

Аннан килеп, шуны да әйтеп китәсе килә: М. Мәһдиевнең повестен күптән онытылып бетә язган, ләкин көчле экспрессиягә ия булган идиомалар да бизәкли («хач маңалар», «сәзнең белән авыз чайкап ятарга», «төлке уйный торган орлар» һ. б.). Ата-бабаларыбызның телләрендә булган, хәзер сирәк очрый торган әйтем формалары да

бик урынлы кулланылган («ямьсез сүз әйткән авызлары белән ничек ризык кабар икән ул», «илләргә иминлек бирсен», «акрын искел, сәба җиле...»).

«Торналар төшкән җирдә» — лирик-документаль повесть, истәлекләр түгел, чөнки Мәһдиев — «типсә тимер өзәрлек» илле яшьтәге ир, аңа мемуарлар язарга әле бик иртә. Әле алда зур планнар, башланмаган әсәрләр, эшләнмәгән эшләр бик күп. Мәһдиевнең хәзер иҗатының җитлеккән чагы, күзләре үткен, каләме очлы, зиһене саф, сүзләре төгәл, теле бай — аңа киләсе иҗат юллары озын, уңышлары мул булуын теләп каласы килә.

**Вахит ЮНЫСОВ,**
Мәскәү.

## Горурлык хисе

Туган җире, туган авылы шагыйрь Сибгат Хәкимне һәр кайтуында кочагын иркен ачып каршылый. Кайту белән шагыйрь табигать кочагына ашыга: башакларның башларыннан сыйпап акрын гына атлый ул; игътибар белән тирә-юньне күзәтә, кошлар сайравын тыңлый, үләннәрнең җилдә лепердәгән тавышын ишетә, карт өянкеләр белән серләшә. «Шагыйрь кайткан» дигән хәбәрне ишетү белән олысы-кечесе аның янына ашыга. Киңәш сорап та, ярдәм көтеп тә, шатлыгын уртаклашыр өчен дә киләләр аңа. Ә шагыйрь һәркемгә җылы сүз таба. Авыл кешеләре белән һәр очрашудан соң күңелендә горурлык хисе туа, кешеләрне яратуы тагы да арта. Күңел ярларына тулып күтәрелгән шигърият чишмәсе тагы да сафлана.

1921 нче ел. Ачлык ел. Шагыйрьнең әтисе, эш эзләп, Украина далаларына чыгып киткәнче, авыл тегермәнендә улының укытучысы белән очраша. Укытучыны күргәч, болай ди:

— Синең өеңә дә керермен дигән идем, монда очравың бик әйбәт булды әле. Мин иртәгә олы улым Рәхимҗан белән сәфәр чыгарга уйлап торам. Минем Сибгатуллам синең сыйныфта укый икән. Усал малайларга кыерсыттырма. Улым усал да, юаш та түгел, балаларым арасында аерылып тора. Аны мөгаллим булганчы укытасым килә.

Укытучы кечкенә Сибгатне авылның усал малае Гатаулла белән утырта. Берничә көннән Гатаулла:

— Мин Сибгат белән утырмыйм, ул миңа селкенмичә укып кына утырырга куша, — дип зарлана.

Ачлык көчәйгәннән-көчәя. Мәктәпкә укучыларның килүе сирәгәя. Ләкин илебез балаларның тормышын саклап калу өчен барысын да эшли. Мәктәптә кайнар аш бүлдырыла, дежур укучыларга аш бераз артыграк бирелә. Менә Сибгатнең дә дежур тору көне җитә. Аш пешкәч, ул: «Апа, мин өйгә кайтып килим», — ди дә күздән югала. Күп тә үтми ул энисе белән килеп җитә. Ашны өйгә алып кайтып, барысы да бергә ашыйлар.

Күргәнебезчә, шагыйрь бик кечкенәдән нечкә хисле, тыйнак, сабыр бала булып үсә. Класстагы Рәхимә апа Каюмова шагыйрьнең шигырьләрне пышылдап кына укып йөрүен сөйли.

**Көтүчеләр тапкан чишмә кебек,**
**Җырым минем, син дә улаксыз.**
**Шул чишмә күк син дә тыныч актың,**
**Шул чишмә күк син дә гөнаһсыз.**

Шагыйрь туган җиргә һәм ватанга булган иксез-чиксез саф мәхәббәтен сабыр гына, салмак кына, күңелләргә сеңдереп әйтеп бирә.

С. Хәким шигырьләренең һәр юлы халык фикере, хисе, моңы, тормышы белән сугарылган, ул үз халкының культура мирасын, өмет-хыялларын бик яхшы белә. Шуңа да аны үз шагыйребез, халык шагыйре дибез.

Кешенең катлаулы хисләре, кичерешләре дусларга мәхәббәттән, туган-үскән җирләрне яратудан башлана. Бу исә — син алар турында кайгыртып яшәргә, һәр адымда

шулар өчен җаваплы булырга, һәркайда үзеңне шулардан аерылгысыз итеп санарга тиешсең диган сүз. Шагыйрьнең туган авылы турында язылган шигырьләре сине үзләре артыннан ияртәләр, ихтыярсыздан, нәкъ Тукайның «Туган тел»ен кабатлаган шикелле кабатлыйсың:

— Миңа гына шулай тоела микән
Бөтен рәхәтләре соң аның!
Башка берни дә кирәкми,
Үзем тапкан чишмәләриең
Ятып эчсәм суларын.

Безнең арабызда яшәгән намуслы, гадел, алтын куллы авылдашларыбызның образлары шагыйрь иҗаты аркылы әдәбиятка иңде. Авылның алдынгы бозау караучысы Рәшидә Вәлиева, көтүче Фоат Әхмәтшин, элемтә эшчесе Касыймхан Мортазин, сугыш һәм хезмәт ветераннары — Гыйльметдин, Гыйният, Лотфулла, Сәләхи абыйлар...

«Җир үзенең олы рухлы кешеләренә бай. Менә Нурфия. Агроном. Шушында үскән. Кайвакыт минем агрономнан — шагыйрьне, шагыйрьдән агрономны аерасым килми. Шулай да ул әйбәтрәк булә, туфрак фәнен, җир фәнен. Нурфиянең язмышын шушы кырлардан башка күз алдына китерү мөмкин түгел», — ди шагыйрь.

С. Хәким авылның хөрмәтле укытучылары Габдулла Сабиров, Сибгат Хәмитовларны сагына. «Әдәбиятны яратканнары өчен, үзенә өмет белән караганнары өчен, карап үстергәннәре» өчен сагына. Моң-сагышын әнкеләр белән уртаклаша.

Сезгә эндәшми, мин кемгә
Эндәшим, әнкеләр!
Җитте минем дә сезнең күк
Картайдым дияр көннәр.

Болай яшәп картайсаң да ярый. Мондый картлык — бәхетле картлык ул!

«Әнкеләр» диган шигырьне иҗат итәр өчен, халкың белән бергә, чордашларың белән бергә күпне кичергән булу кирәк, чөнки тормыштагы бик күп кайгы-шатлыклар халык күңелендә моң булып тупланган.

Сибгат Хәким — тәэсирләр, хисләр кешесе. Ул, саф сулы чишмә кебек, кешеләргә күңел җылысын биреп яши. Мондый чишмә бер дә саекмас, чөнки кешеләр эчкән саен сафлана гына бара ул.

— Илһамым минем — яшьлектә,
Мәңгелек Фазылларда,

— ди шагыйрь.

Күлле Киме урта мәктәбе һәр елны йөзгә якын намуслы, эшчән яшь Фазылларны зур тормыш юлына озата. Алар илебезнең төрле почмакларына таралган. Илнең иминлеген саклаучы Фазыллар турында рәхмәт хатлары күп килә.

Ә авылыбыз кырларында корыч айгырларны үкертеп эшләтүче Фазыллар белән горурланмаска мөмкин түгел.

Кыскасы, С. Хәкимнең иҗат җимешләре укучыларда кешелеклелек сыйфатлары тәрбияли. Тоя да, кичерә дә, яна да белгән яшьләр арткан саен, эшләве дә, яшәве дә күңелле.

Авылдашларының олы мәхәббәте шагыйребезнең гомере буена җылытып торсын.

Луиза СӘМИГУЛЛИНА,
Арча районы, Күлле Киме урта мәктәбенең әдәбият укытучысы.

## Хатлардан юллар

Менә 15 ел рәттән «Казан утлары»н алдырып укыйм. Яңа романнар, повестьлар, хикәялардән мин үземә рухи көч алам. Ә бик күп шигъри әсәрләрдән ямь тапмыйм. Ә менә Илдар Юзеевның «Очты доньядан читлегеннән» исемле шигъри трагедиясендә

бер генә буш сүз дә юк. Тукай образын яктыртуы белән ул үзенең чын шагыйрь, оста язучы икәнен раслаган.

Мин гомерем буе тезелештә эшләгән кешемен. Төзелештә дә яхшы белән яманны күз ачып йомганчы танып алалар. Күрәсең, әдәбиятта да шулай. Кыскасы, Илдар Юзеевка зур рәхмәтемне ирештерегез.

Х. МӨХӘММӘДИЕВА,
Кыргызстан ССР, Кара-Күл шәһәре.

*
* *

Хөрмәтле редакция! Соңгы елларда, ни сәбәпледер, кыска хикәяләр күренми башлады. Аларны сагынып, көтеп алабыз. Юмористик хикәяләрне бигрәк тә. Бәлки кыска хикәяләргә конкурс игълан итәргә кирәктер. Шулай булса, әр-яңа кыска хикәяләр тууына шик юк. Укучыларны шатландырырлык әсәрләр, яңа авторлар белән очрашыр идек.

Г. САТТАРОВ,
Кукмара районы, Мәмәшир авылы.

*
* *

Миркасыйм Госмановның «Заветная мечта Хусаина Фаизханова» исемле китабын зур кызыксыну белән укыдым. Минем фикеремчә, бу китап данлыклы Фәезханов турында гына язылмаган. Үзе исән вакытта ук халкыбыз горурлыгы булган Шиһап Мәрҗани тормышы сәхифәләре дә, халкыбыз тарихы да, аның шигърият өчен көрәше дә тирән чагыла бу китапта. Шундый китаплар күбрәк язылсын иде. Кызганычка каршы, мондый китаплар Татарстаннан читтә яшәүчеләргә бик авырлык белән килеп җитә, аларны табып алып уку өчен зур мәшәкатьләр кичерергә туры килә.

Я. БАЙГИЛДИН,
Кыргызстан ССР, Фрунзе шәһәре.

*
* *

Газиз Кашаповның яңа әсәрен мин бик дулкынланып укыдым. Анда сурәтләнгән армия тормышы да, авылдагы колхоз эшләре дә минем игътибарны бердәй җәлеп итте.

Язучы бүгенге солдат тормышын карт солдатлар, хәрби кешеләр ышанырлык итеп сурәтли. «Илебезнең һава чикләре сагына басарга атлыгучы егетләр»... турында йөрәк җылысын кушып яза, чөнки ул үзе дә алар арасында яшәгән кеше.

Әсәрнең буеннан-буена сугыш утын кабызмау өчен көрәш сизелә. Һәр хәрби кеше өчен мизгел дигән төшенчә, шомлы да, шатлыклы да була ала. Солдатларның һәм офицерларның маңгай тирләрен чыгарган ракета җибәрү мизгелендә «отбой» командасы бирелүе моның ачык дәлиле.

Газиз Кашапов — безнең авылда туып үскән егет.

Авылдагы, колхоздагы вакыйгалар, андагы кешеләр безгә бар да таныш. Язучы бу вакыйгаларны, кешеләрдәге характерларны оста сурәтләгән. Үземнең шул кешеләр арасында 25 ел яшәп тә, аларны Газиз белгән кадәр белмәгәнгә исем китә. Ул, берике җөмлә белән кешенең игелеклелеген, ярдәмчеллеген, сизгерлеген, матурлыгын, сафлыгын, камиллеген ача белә.

Әсәрдә сурәтләнгән авылдашларыбыздан механик Нәбиулла (авылыбызның иң

хөрматкә лаек кешесе), тракторист Гәрәйсәет (авылыбызның беренче трактористы), Бүкәй абзый, Габделҗан (чын исеме Галимҗан иде). Сәгадәтбанулар гүзәл кешеләр иде. Алар туган җиргә, аның тылсымлы табигатенә гашыйк иделәр. Алар вафат булдылар. Аларның һәрберсе турында аерым-аерым китап язарлык.

Фактик материалларга таянып конкрет кешеләр тормышы, эше, хезмәте турында язылган бу әсәрдә гомумиләштерелгән образлар, вакыйгалар бар. Алар тискәре типлар. Ләкин без аларны да таныйбыз. Кешеләр Фәндәрия (кызын үз юлына этәрергә теләп бәхетсез итүче), Мәннәф (кеше коткысы белән җинаять юлына басучы), Чапак Насыйх (ике айлык баласын калдыртып Сәгадәтбануны урман кисәргә җибәрүче) кебекләрне таныйлар.

Әсәрдә ул чорның гүзәл бер ягы чагыла. Кешеләр эшне күңел биреп, ихлас күңелдән эшлиләр. Галим ун көнгә отпускага кайтып та трактор ремонтларга алына. Бу дәрестән дә шулай иде.

Р. МӘХМҮТОВ,
Аксубай районы, Яңа-Үзи авылы.

*
* *

Газиз Кашаповның «Солдат иртә ир була» дигән әсәрен укыгач, аннан алган тәэсирләрем белән уртаклашмыйча булдыра алмыйм. Ялгышмасам, бу иптәш — яшь язучы һәм бу аның «Казан утлары»нда дөнья күргән күләмле икенче әсәре. Һәрхәлдә бу язучыны өлкән яшьтәге кеше булмаска тиеш дип уйлыйм. Мине, укучы буларак, шатландырганы шул — Г. Кашаповның тормышны тирәннән белүе. Сер түгел, яшь язучы тормышны яхшы белсә дә, юк-юк та әсәрен укыганда без — укучылар төрле төгәлсезлекләрне бик тиз сизәбез. (Аның бит әле укучысы да хәзер нинди!)

Мин әдип тә, әдәбиятка азмы-күпме бәйле кеше дә түгел, шуңа да әлеге әсәрнең башка якларына кагылмыйм. Әмма үзем дә авылда туып үскән, шулай ук хәрби хезмәт тә узган кеше буларак, тик бер генә нәрсә әйтә алам: мин тормышта күрдем язучы иптәшнең бу геройларын, бар алар!

Г. УСМАНОВ,
кранчы.
Нурлат шәһәре.



## Харрас Әюпов


Харрас Әюпов шигырьләрен 1966 елдан бирле укып барам. Нәфис, җыйнак теле, гади, әмма җылы җирдән, тормыштан килә торган сурәтләре белән хәтердә калды ул. Минем карашка, алар Зөлфәт белән бик аваздаш кебек иде (бер төбәктән — Мөслим ягыннан бит): шул ук тел садәлеге, матурлыгы, образларның күңелне яктыртып җибәрә, уйландыра торган яңалыгы, сафлыгы...

«Беренче карлыгачлар» сериясендә күптән басылса да, яшь шагыйрь мөстәкыйль китабын бастырырга ашыкмады, эзләнде, үсте, газета-журналларда күренә килде. Ниһаять, 1980 елда аның «Ышаныч» исемле беренче китабы дөнья күрде.

Минем карашка, бу китап белән ул үзен әдәби җәмәгатьчелеккә кызыклы шагыйрь итеп танытты. Аның әйтер сүзе, үзе язганча, халыктан алган моңы, көче бар һәм бу көч аның үз шигъри дөньясын, сурәтләрен табарга ярдәм итә. Һәм бу моңышаныч шагыйрьнең бүгенге чор, кешеләр, туган җир һәм халык белән тирән бәйләнешен раслый — шигырьләрендә шагыйрь шактый матур гомумиләштерүләргә ирешә.

Шагыйрьгә шуны телисе кала: бу юлда ул абстрактлыктан качарга, җирлеге булмаган фәлсәфә белән мавыкмаска, конкрет образларны кыю рәвештә эзләргә, табарга тиеш. Моның өчен аның бөтен мөмкинлекләре бар дип уйлыйм.

**Рәдиф ГАТАУЛЛИН.**



## Рашат Низамиев

Ил-көнне кайгырткан, шул җаваплылыкны иңенә алган шигырьләрдән генә башлана шагыйрь. Бу сыйфатларны мин Рашат Низамиевның «Йолдыз яңгыры» исемле китабында күрдем. Миңа аның тормышка гражданин күзләре белән карап, заманча күрүе-сурәтләве, сулышының киңлеге ошый: «Җилгә каршы баскан карурмандай, шаулый җанда Вакыт тойгысы». Рашатның шигырьләре конкрет җирлектә туа — аларда безгә кадерле замандашлар язмышы, нык рухлы, иманы камил илдәшләр. Сурәтләү чара-

ларының да, традицион нигезгә таянып, бүгенге көн билгеләре белән яңарып баруы табигый, алар күптән таныш күренешләрне тансык итеп, яңача күрергә булышалар.

Яшь шагыйрьнең әйтер сүзе ул үзе яралган, рухи ныгыган тормыш белән раслаunion тора; читтән күзәтеп таныган тормыш түгел бу, халык күңелендә өлгергән сүзнең шигырьдә тууы. Шуңа күрә мин аның киләчәктә җырланасы җырларын ышанып көтә алам.

Рашат Низамиев бүгенге көндә «Ялкын» журналында җаваплы секретарь булып эшли. Әйе, шагыйрь — халык күңеленең җаваплы секретаре. Рашат Низамиев кебек егетләрнең әдәби хәрәкәтебездә үз-үзенә ышанып, җаваплылык тоеп эшләр чагы. Бүген һәм киләчәктә аңа шул таләпләргә хас эшләр дә йөкләтелә торыр, дип уйлыйм. Мин аның киң колач белән, каләм «сызганып» эшләвен телим.

**Шәүкәт ГАЛИЕВ.**



## Нәбирә Гыйматдинова

Нәбирә Гыйматдинованың беренче хикәяләрен мин «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре булып эшләгәндә укыган идем.

Яшьләргә хас дуамаллык һәм яшьләрчә ихлас күңел белән язылган «Су хикәяте» игътибарны аеруча җәлеп иткән иде.

Бу хикәянең героинясы — катлаулы язмышка дучар булган яшь тәзүче — нинди генә очракларда да кешелек дәрәҗәсен төшерми. Нәкъ менә шул дәрәҗәне саклау өчен көрәше дә аның язмышын катлауландыра, кызыклы итә.

Нәбирә әсәрләрендә вакыйга сөйләми, шул вакыйгалар аша замандашы образын тудырырга, яшь кешенең җанын ачарга омтыла.

Менә бер-ике ел инде мин аның язганнарын күзәтеп барам һәм яшь авторның әсәрдән-әсәргә үскәнен күреп шатланам. Ул кечкенә күләмле повестьларында яшь укытучыларны, сәнгать белән мавыгучы студентларны сурәтләгәндә, «Су хикәяте»ннән үзгә буларак, сабыр-салмак стильгә күчә, татарга гына хас булган моң белән сөйләп бара. Аның геройлары сөйкемлеләр, ялгышлары белән дә ачы нәфрәт уятмыйлар, аларны кызганасың, ярдәм итәргә телисең. Бу — авторның гуманлык сыйфатларыннан киләдер, мөгаен.

Шулар белән бергә, һәр яшь каләм иясенә хас булганча, Нәбирәдә дә урыны-урыны белән ясалмалылыкка бирелү, вакыйгаларны тормыштагыча нигезләү җитеп бетми кебек. Әсәрләрнең теленә дә күбрәк игътибар итсен иде дип әйтәсе килә. Болар, әлбәттә, үсеп килүче яшь организмда була торган чирләр. Вакыт үткәч бетәрләр, тик автор алардан тизрәк котылу чараларына керешсен иде.

**Ләбибә ИХСАНОВА.**

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Чираттагы ачык партия җыелышы КПСС Үзәк Комитетының «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади элемтәләре турында»гы карары яктылыгында язучылар коллективы алдында торган бурычларны тикшерүгә багышланды. Көн тәртибендә торган мәсьәлә буенча доклад белән партия оешмасы секретаре Ринат Мөхәммәдиев чыкты.

Җыелышта катнашучылар КПСС Үзәк Комитеты карарын тормышка ашыру юнәлешендә КПССның Татарстан өлкә комитеты кабул иткән карарны зур игътибар һәм рухлану белән тыңладылар.

Карарларда билгеләнгән мөһим бурычларны тормышка ашыру турында фикер алышуларда язучылар Мөхәммәт Садри, Гомәр Бәширов, Гариз Иделле, союз идарәсе председателе Гариф Ахунов, «Казан утлары» журналының баш редакторы Зәки Нури, проза бүлеге редакторы Марсель Галиев, «Азат хатын» журналының баш редакторы Венера Ихсанова иптәшләр катнашты.

Җыелышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты һәм чыгыш ясады.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» — ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЛАРЫНДА

Журнал редакциясе, әдәбият-сәнгать әһелләре белән хезмәт коллективлары арасындагы бәйләнешләрне ныгыту, алдынгы замандашларыбызның эшләрен һәм уйларын чагылдырган әсәрләр иҗат итүгә авторларның киңрәк даирәсен тарту максатын күздә тотып, күренекле революционер Мулланур Вахитов исемен йөрткән хезмәт коллективларында үзенең әдәби постларын булдырган иде. Питрәч районының М. Вахитов исемендәге колхозы һәм М. Вахитов исемендәге Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Казан химия комбинаты белән журнал арасындагы дуслыкка 1980 елда ук нигез салынды. КПСС Үзәк Комитетының «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади элемтәләре турында» карары игълан ителгән көннәрдә әлеге бәйләнешләр аеруча эшлекле төс алды.

Журналның баш редакторы Зәки Нури, бүлек редакторлары Рәшит Әхмәтҗанов һәм Фәннур Сафин, шагыйрь Мөхәммәт Садри, һәр ике әдәби постта булып, эшчеләр һәм колхозчылар белән очраштылар, аларның хезмәттәге уңышлары белән таныштылар, «Казан утлары» редакциясенең иҗади планнары турында сөйләделәр. Колхоз һәм предприятие китапханәләренә, хезмәт алдынгыларына советча яшәү үрнәген, интернационализм идеяләрен раслаучы, ватандашларыбызның матур эшләре һәм бай рухи дөньясы турында сөйләүче китаплар бүләк ителде. Бу дуслык элемтәләре журнал сәхифәләрендә дә чагылыш табачак.

## ДӘРТКӘ ДӘРМАН ӨСТӘП

Киеренке кыр эшләре чорында авыл хезмәтчәннәренә культура хезмәте күрсәтү буенча аеруча актив төс алды. Республикабыз басуларында 1982 ел икмәге өчен көрәш барган көннәрдә язучылардан һәм сәнгать осталарыннан оештырылган махсус бригадалар кыр станнарында, җәйге терлекчелек лагерьларында чыгышлар ясадылар, авыл уңганнарына дәрт һәм дәрман өстәделәр.

Язучы Мәхмүт Хәсәнов, шагыйрьләр Роберт Әхмәтҗанов, Рәшит Әхмәтҗанов һәм яшь шагыйрь Хәйдәр Гайнетдинов составындагы бер бригада, мәсәлән, Апас районының «Свердлов» совхозында, Горбунов, Вахитов, Крупская исемендәге, «Байрак» һәм «Ярыш» колхозларында, район Август киңәшмәсенә килгән татар теле һәм әдәбияты укытучылары, район үзәк китапханәсе укучылары алдында чыгышлар ясады. Бу очрашуларда шулай ук район Культура йорты каршындагы «Замандаш» агитбригадасы (җитәкчесе К. Насыйбуллин) катнашты.

* * *

Актаныш районы хезмәтчәннәре «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре шагыйрь Роберт Миңнуллин белән иҗади очрашулардан, Арча һәм Саба уңганнары шагыйрьләр Хәкимҗан Халиков һәм Шамил Маннапов чыгышларыннан, Алабуга районы игенчеләре һәм терлекчеләре Чаллы тәбәгендә яшәүче һәм иҗат итүче язучылар Кадыйр Сибгатуллин, Нәҗип Мадьяров, Газиз Кашапов һәм башкалар катнашында үткәрелгән әдәби чаралардан бик канәгать булып калганнар.

* * *

Язучылар И. Юзеев, Р. Мингалимов, Р. Хәмид һәм Н. Гыйматдинова Саба районында иҗади очрашуларда булып кайттылар. Алар районның «Ирек» колхозы

механизаторлары һәм терлекчеләре, Саба Урман хуҗалыгы эшчеләре һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты хезмәткәрләре белән «Казан утлары» журналында 1983 елда басылачак әсәрләр турында сөйләштеләр, үзләренең яңа әсәрләре белән таныштырдылар.

* * *

Язучылар Габдулла Шәрәфи, Самат Шакир һәм Флера Гыйззәтуллина Чирмешән районының алты колхозында булып, әдәби очрашулар үткәрделәр. Балык Бистәсе районындагы шундый чыгышларда шагыйрь Әхмәт Рәшитов катнашты.

## ИҖАДИ ДУСЛЫК ДӘВАМ ИТӘ

Язучылар союзыбызның Чаллыдагы коллективы белән «Камгэсэнергострой» производство идарәсенең йортлар төзү комбинаты эшчеләре арасында нык дуслык элемтәләре урнашкан. Язучыларны төзелеш мәйданнарында, тулай торак һәм кызыл почмакларда көтеп алалар. Шундый очрашуларның берсе 61 нче төзү-монтаж идарәсендә булды. Язучы Эдуард Касыймов, яшь шагыйрьләр Мансур Сафин һәм Николай Алешков идарәнең төзүчеләре һәм инженер-техник хезмәткәрләре алдында чыгыш ясап, яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар, сорауларга җавап бирделәр.

## СӘНГАТЬ ОСТАЛАРЫ — АВЫЛ ХЕЗМӘТЧӘННӘРЕНӘ

Урып-җыю эшләре кызу темп алган көннәрдә Кама Тамагы районы авылларында РСФСР һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор Фасил Әхмәтов җитәкчелегендәге музыкаль бригада чыгышлары булды. Колхоз Культура йортларында, кыр станнарында, терлекчелек лагерьларында композиторның халыкка танылган әсәрләре яңгырады. Аларны М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисткасы К. Хәйретдинова, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе җырчысы И. Биктаһиров, ТАССРның атказанган артисты Г. Сәйфуллин башкарды.

Композиторларның авыл хезмәтчәннәре белән иҗади дуслыгы турында сөйләүче башка мисаллар да күп. Мәсәлән, Сара Садыйкова — Актаныш, Бату Мулюков — Әгерҗе районнарында, Мирсәет Яруллин үз якташлары — Мамадыш районы эшчәннәре белән иҗади очрашулар үткәрделәр.

* * *

Җәйге кыр эшләре чорында авыл халкына культура хезмәте күрсәтүдә республикабызның профессиональ театр коллективлары да актив катнашты. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары, дүрт бригадага бүленеп, республиканың утыздан артык авыл районында 120 спектакль күрсәтте. Аларны 12 меңнән артык кеше карады. Әлмәт татар дәүләт драма театры коллективы Татарстанның төрле төбәкләрендә Т. Миңнуллинның «Бәйләнчек» сатирик комедиясен, А. Гыйләҗевның «Өткәй җырлый да, җылый да», Р. Хәмидиен «Каен җиле» драмаларын күрсәтте. Бу коллектив авыл эшчәннәренә культура хезмәте күрсәтүдә ирешкән уңышлары өчен РСФСР Культура министрлыгының Почет китабына кертелде.

Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Минзәлә дәүләт драма театры, Татар дәүләт курчак театры һәм Татар дәүләт филармониясе артистлары да бу җаваплы чорда авыл хезмәтчәннәренә актив культура хезмәте күрсәттеләр, КПСС Үзәк Комитетының май (1982 ел) Пленумы карарларын тормышка ашыруда үз өлешләрен керттеләр.

## СССР ТӨЗЕЛҮНЕҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

М. Горький исемендәге авыл хуҗалыгы институтының уку шәһәрчегендә СССРның 60 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Шагыйрьләр Рәшит Әхмәтҗанов, Ф. Сафин, прозаик Р. Кәрами, артист М. Галиев, Татар дәүләт филармониясенең яшь җырчысы З. Шәрифуллина һәм баянчы Ә. Кәримов студентлар һәм укытучылар алдында чыгыш ясадылар.

* * *

Мәскәү эстрада театрында һәм Казан Спорт сараенда Татарстан сәнгать осталарының СССР төзелүнең 60 еллыгына багышланган концертлары булды. Ватанга, партиягә, халыклар дуслыгына дан җырлаган бербөтен композициядән гыйбарәт зур концерт программасында Илһам Шакиров, Эмиль Җәлалетдинов, Әлфия Афзалова, Ренат Ибраһимов кебек танылган җырчылар, «Юность» халык хореография ансамбле һ. б. лар катнашты.

## ПАТРИОТ-ШАГЫЙРЬ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Билгеле булганча, 1944 елның 25 августы — Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелгән көн. Каһарманнарның үлемсез батырлыгы онытылмый, яңа буыннарның күңеленә көч-куәт бирә... 

25 август көнне Казанның 1 Май мәйданында җәлилчеләрне искә алу булды. ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов, М. Җәлилнең тормыш иптәше Әминә Җәлилова, кызы Чулпан, язучылар Сибгат Хәким, Рафаэль Мостафин һ. б. лар Җәлил һәйкәленә чәчәкләр куйдылар.

* * *

Язучы һәм тәнкыйтьче Р. Мостафин Казан вертолет производство берләшмәсе эшчеләренә патриот-шагыйрь М. Җәлил-

нең иҗаты, тормыш юлы һәм соңгы вакытта табылган шигырьләре хакында сөйләде.

* * *

Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүче Ташкент галиме — филология фәннәре кандидаты, Үзбәкстан Журналистлар Союзы премиясе лауреаты Исхак Зәбиров Башкортстанның Илеш, Дүртөйле, Чакмагыш һәм Кушнаренко районнары хезмәт ияләре белән очрашты. Республика «Белем» җәмгыяте чакыруы буенча оештырылган бу очрашуларда ул үзенең тикшеренү-иҗат эшчәнлеге, җәлилчеләргә кагылышлы яңа материаллар турында сөйләде, соңгы вакытта табылган кызыклы документлар белән таныштырды, күпсанлы сорауларга җавап бирде. Исхак Зәбиров чыгышларын колхоз һәм совхозларда, предприятие һәм учреждениеләрдә, кыр станнарында барлыгы дүрт меңнән артык кеше тыңлады.

## МӘСКӘҮ НӘШРИЯТЫНДА БАСЫЛДЫ

Язучы Габдулла Шәрәфинең укучылар яратып кабул иткән «Сусыз дәрья» исемле повестенда совет солдатларының 1945 елда япон милитаристларына каршы сугышта күрсәткән чыдамлыгы һәм батырлыгы, рухи пыклыгы гәүдәләндерелә. Мәгълүм булганча, әсәр документаль нигездә язылган иде. Язучының быел Мәскәүдәге «Советская Россия» нәшриятында басылып чыккан «Зур Хинган аша» дигән китабына әлеге повесть белән бергә кайбер хикәяләре дә кергән.

## ЯШЬЛӘР ТУРЫНДА КАЙГЫРТЫП

Чаллы Язучылар оешмасының бер утырышы Түбән Камада яшәүче яшь шагыйрь Мөхәммәт Шәйхинең «Көн үзәге» дип исемләнгән беренче шигырьләр җыентыгын тикшерүгә багышланды. Әсәрләр турында фикер алышуда катнашкан Рөстәм Мингалимов, Разил Вәлиев, Нәҗип Мадьяров, Равил Вәлиев, Ямаш Игәнәй, Фаяз Дунай, Газиз Кашапов һ. б. лар җыентыкның уңай якларын билгеләп үттеләр, авторга киңәшләр бирделәр. Утырыш М. Шәйхинең шигъри җыентыгын матбугатка тәкъдим итәргә дип карар чыгарды.


## РӘССАМНАР ОТЧЕТ БИРӘ

ТАССР Художниклар союзының Күргәзмәләр залында берьюлы диярлек ике яңа экспозиция ачылды. Бирегә килүчеләр рәссамнар Илдар Әхмәдиев һәм Усман Абдулловның үзенчәлекле иҗаты белән таныштылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Ирек Баһмановка, Татарстан АССР Верховный Советы Указы белән, «Татарстан АССР-ның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

# ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН



Шушы елның 7 октябрендә 43 яшендә танылган язучы Фаил Шәфигуллин кинәт вафат булды.

Фаил Хафиз улы Шәфигуллин 1939 елның 18 маенда Татарстан АССРның Зеленодольск районы, Карашәм авылында туа. Бик яшьли, җиденче классны тәмамлаганнан соң, хезмәт юлын башлап җибәрә: колхозда эшли, чирәм җирләрдә тракторчы була, Коми АССРда урман кисә, Ерак Көнчыгыш төзелешләрендә төзүче, балык судноларында матрос, заводта эшче була.

Заводта эшләгән чагында Зеленодольск шәһәр Советына депутат итеп сайлана. Производстводан аерылмыйча урта мәктәпне, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан Дәүләт университетын тәмамлый. Ул «Казан утлары» журналында поэзия бүлеге, «Чаян» журналында әдәбият һәм тәрҗемә бүлеге мөдире булып эшләде.

Ф. Шәфигуллинның беренче шигырьләре матбугатта 1958 елда күренә башлый. Чирек гасырлык иҗат чорында ул поэзия, проза, публицистика жанрларында эшләде, әмма аның язучылык таланты аеруча балалар әдәбияты һәм юмор өлкәсендә ачылды.

Коммунист Ф. Шәфигуллин актив иҗат тормышы белән яшәде, күптөрле җәмәгать эшләре алып барды. Ул «Казан утлары» һәм «Чаян» журналларының, «Яшь ленинчы» газетасының редколлегия члены булды, «Идел» альманахын редакцияләде.

Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте язучының хезмәтенә лаеклы бәя бирделәр. Ул «Хезмәттәге батырлык өчен» медале, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

Танылган язучы, җәмәгать эшлеклесе, коммунист каләмдәшебез Фаил Шәфигуллинның якты истәлеге безнең күңелдә мәңге сакланыр.

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ,**
**«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ.**

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210

## КИЛӘСЕ САНДА:

*СССРның 60 еллыгына*

С. Г. Батыев. **Бердәм, тату гаиләдә.**

*Проза*

Ә. Еники. **Соңгы китап.** Истәлекләр.

Г. Галиев. **Истә, һаман да истә...** Хикәя

*Поэзия*

Р. Гатауллин, Р. Закиров, Э. Мостафин шигырьләре

*Очерк һәм публицистика*

К. Фасеев. **Киләчәге тагын да матуррак.**

М. Мәһдиев. **Авыл белем сорый.**

М. Хәбибуллин. **Җирнең хуҗасы турында тирән кайгыртып...**

**КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)** ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал, орган Союза писателей Татарии